ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

11.2001





Габдрахман Әпсәләмов
1911—1979

# Казан утлары
# Qazan utları

2001

**10**

(948)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***


*БАШ МӨХӘРРИРЕ*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Фоат Галимуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Аяз Гыйләҗев**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Салих Маннапов**
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Альбина Әхмәтова, Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова, Асия Рәхимова** (баш бухгалтер).


420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎: Баш мөхәррир — 92-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 92-36-49.
Җаваплы сәркатип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 92-38-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 92-39-63,
гамәли хезмәткәрләр — 92-39-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## *Бу санда*

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Шәүкәт ГАЛИЕВ. Яңа шигырьләр ........ 5
Нәбирә ГЫЙМАТДИНОВА. Аргы очта, бирге очта... *Повесть* ........ 9
Фәйрүзә МӨСЛИМОВА. Мәңгелек өн. *Шигырьләр* ........ 36
Рәшит ШИҺАП. Утлы уем йөри каударланып ........ 40
Марат ЗАКИР. Шарт. *Хикәяләр (М. Хуҗин кереш сүзе белән)* ........ 43
Фәнәвис ДӘҮЛӘТБАЕВ. Кыска шигырьләр ........ 62
Фәрит ЯХИН. Ат уены. *Хикәя* ........ 65
Илфак ШИҺАПОВ. Аклы-каралы гыйшык. *Сатирик кыйсса* ........ 91
Әдхәт СИНУГЫЛ. Фәрдләр ........ 161

**ДӨНЬЯ ӘДӘБИЯТЫ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ**

Лена ШАГЫЙРЬҖАН. Байрон һәм аның «Төш»е ........ 86

**ДИН ҺӘМ ТОРМЫШ**

Госман ИСХАКЫЙ. Тугры юлга чыкканда ........ 105

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Дания ЗАҺИДУЛЛИНА. «Албастылар» яки татар прозасында яңа сыйфатлар... 111

**ХӘТЕР**

Халисә МӨДӘРРИСОВА. Кем уйлаган? ........ 120

**ТАРИХ**

Альта МӘХМҮТОВА. Иж-Бубый мәдрәсәсенә 220 ел ........ 126

**СӘНГАТЬ**

Әлфия МИҢНУЛЛИНА. Щепкинчылар... ........ 138

**ЮБИЛЕЙЛАР**

Камил КӘРИМОВ. Икенче юл *(Язучы һәм галим Альберт Яхинга 70 яшь)* ........ 147

КОРЪӘН ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ........ 150

**ҮТКӘН МӘСЬӘЛӘ**

Флүс ЛАТЫЙФИ. Мәсләгебезгә тугрыбыз ........ 156

**ӘДӘБИЯТЫБЫЗ ТАРИХЫНА**

Zəfər RƏMİEV. Altaylı tatar şagıre ........ 159
Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ. «Мин синнән ераклармын, ераклармын...» ........ 166
Мансур ВӘЛИ-БАРҖЫЛЫ. Бергәлек бәхете *(Юныс Әминовның тууына 90 ел)*.. 172
Гөлзадә БӘЙРӘМОВА. Китаплы гомер *(Ш. Максудовага 75 яшь)* ........ 176

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ........ 191

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: повесть Н. ГИМАТДИНОВОЙ «За околицей», рассказы Ф. ЯХИНА, М. ЗАКИРА, сатирическая быль И. ШИГАПОВА «Черно-белая любовь», стихи Ш. ГАЛИЕВА, Ф. ДАВЛЕТБАЕВА, А. СИНУГУЛ, Ф. МУСЛИМОВОЙ.
«Из сокровищницы мировой литературы»: стихи БАЙРОНА в переводе Л. Шагирзян.
«Жизнь и религия»: статья муфтия Татарстана Г. ИСХАКИ «На пути справедливости».
«Литературная критика»: рецензия Д. ЗАГИДУЛЛИНОЙ на повесть Г. Гильманова «Лесные забавы».
«Память»: статья Х. МУДАРРИСОВОЙ «Кто бы подумал?»
«История»: А. МАХМУТОВА. «К 220 летию медресы Иж-Буби».
«Актуальная проблема»: Ф. ЛАТЫЙФИ. «Переход на латиницу—требование времени».
«История литературы»: З. РАМИЕВ. «Татарский поэт из Алтая».
«Искусство»: статья А. МИННУЛЛИНОЙ «Щепкинцы».
Коран на татарском языке.
В номере отмечаются юбилии А. Яхина, Ш. Максудовой.
«Новые имена»: рассказы А. МИНГАЛИМОВОЙ.
«Юмор и сатира»: Т. НАЗМИЕВ. Забавные истории.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: фотоэтюд «Зимний пейзаж»; поэтесса Флера Гиззатуллина.

## IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Prose and Poetry": N. GIMATDINOVA'S narrative, stories of F. YAKHIN, M. ZAKIR, R. SHIGAPOV'S satirical story «Black and white love»; the verses of SH. GALIEV, F. DAVLETBAEV, A. SINIGUL, F. MUSLIMOVA.
"From the treasury of wold literatura": BAIRON'S verses in L. Shakirzanova's translation.
"Life and religion": the article Tatarstan's muftiy G. ISKHAKY «On the fair way».
"Literary criticism": D. ZAGIDULLINA'S review of G. Gilmanov's narrative «The forest amusements».
"Memory": H. MUDARRISOVA'S article.
"History": A. MAKHMUTOVA «220th Anniversary of Ige-Bubi».
"Actual problem": F. LATIFI «Latin alphabet is demend of the time».
"History of literature": Z. RAMIEV «Tatar poet from Altai».
"Art": A. MINNULINA'S article «Shipkici»
"Life and religion": Koran in Tartar language.
"Our jubeleears": A. Yakhin, Sh. Maksudova.
Our calendar.
"New names": A. MINGALIMOVA'S stories.
The diary of social and cultural life.
In our covers: photoetude "Winter landscape"; poet Flera Gizzatullina.

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 49-34-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Журнал редакциянен компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 25.10.2001 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108¹/₁₆.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 8219 Заказ А-450
Журнал Татарстан Республикасынын Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2001 ел.



# Шәүкәт Галиев

## ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

Сибелә чәчем, сибелә кылганнар,
Сер пышылдый сыман курганнар.
Җил-җайдаклар моннан узганнар,
Кылыч айкап язмыш урганнар.

Бу ни хикмәт икән, далалар да
Ерак барган саен мәгънәле—
Сүзсез генә җаны-тәне тойган
Бер өлеше микән әллә мин?

### Кеше озак яшәмәкче

Бик озак яшәмәкче дә,
Үзе... яшәүдән кача,
Тырышканы—гомерләрне
Гел кыскарту лабаса!

Ярый, йоклап төш күрсен ди,
Ә бит кояшны күрми:
Туйдым ла дөньясыннан дип,
Ниләр эчеп бетерми!

Адәм озак яшәмәкче
Берсен-берсе үтереп,

---

Шәүкәт ГАЛИЕВ *(1928)—Татарстанның халык шагыйре, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе, Г. Х. Андерсен исемендәге Халыкара Почетлы диплом иясе. Күпсанлы китаплар авторы. Казанда яши.*

Үткәненә, бүгенеә,
Киләчәккә төкереп.

Ачтан үлмәс өчен ясый
Үтерү коралларьт,
Җирдә инде бомба куяр
Урыны да калмады.

Кеше озак яшәмәкче,
Кайсы дөньяда микән—
Көтү ягыннан борылган,
Бетү ягына киткән.

Бетерүгә көйләгән дә
Бар осталык, бар көчен,
Кеше озак яшәмәкче...
Гомер кыскартыр өчен!

## Базар тәгәрмәче

Әйләнә дә Тиен әйләнә,
Тиен бик тиз Сумга әйләнә.
Сумнарына сумнар бәйләнә,
Безнең башлар шунда әйләнә.

Кеше тиен куа дип,
Куасы да килә бит.
Нинди хикмәт бу тагы,
Базар тәмам бутады;

Алабыз да сатабыз,
Кайда безнең атабыз?
Сатабыз да алабыз,
Кайсы безнең анабыз?

Бөтенесе мал даулый,
Әйлән-бәйлән алдаулы.
Кеше хакы, Алла хакыны,
Уйламый аның хакында.
Оят күзгеләре ватылган,
Гөнаһ үзе (күптән) сатылган.

Аптыраумы, бу зармы,
Нишләтергә базарны.
Һаман шулай азармы,
Җан-әхлакны бозармы?
Әйләнә дә Тиен сөйләнә,
Тиген кыйбатлыга әйләнә.
Ике мең дә беренче СУМ быел—
Дөнья базарчага көйләнә!

## Үпкә

Чагыштыру бик урынлы,
Урман—Җирнең үпкәсе.
Кискән саен арта бара
Балталыга үпкәсе.

Каенсарда каен беткән,
Усаклыда усак юк.
Имәнле имәнсез калган,—
Урман эзе—учаклык...

Табигать биргән байлыкны
Бетерсәңме корытып—
Калырсың син төп башында
Балта сабыңны тотып...

## Кирәк безгә...

Ошый иде өндәү-үгетләр,
Бик ышана идек, егетләр,
Бүгенгесе авыр булса да,
Киләчәктә иде өметләр;

Көннәр-еллар анда яктыдыр,
Тормыш-көнкүрешләр яхшыдыр.
Пыран-заран килеп дошманнар,
Бөтен дөнья безнең яклыдыр.

Сугышларны шулай кичтек без,
Үлән шулпалары эчтек без,
Түзеп еллар, чыдап юлларны
Киләчәккә таба күчтек без.

Күчеш авырлыгы бар икән...
Алга!
Ялга вакыт тар икән.

Рәхәт яшәр килер буыннар,
Артка карамыйча бар икән.

Байракларны биек сузганбыз,
Бара торгач шактый кызганбыз,
Ник караңгы дөнья дисәгез—
Якты киләчәкне узганбыз...

Бүген тагын өндәү-үгетләр,
Бабай булды инде егетләр.
Адашкандыр ахры ышаныч,
Үткәннәрдә калган өметләр.

Хакыйкатьне кирәк танырга:
Киләчәккә нигә барырга?
Үзе килер!
Каршы алырга—
Кирәк безгә исән калырга.

## Безнең хәлләр, безнең горурлык

Элек тел яшергән килен
Каената алдында.
Урыс янында, татарым,
Шундый хәлдә калдың ла.

Тавышыңны эчкә йотып,
Эндәшми аварсыңмы,
Тылмачсыз да төшенерләр,
Ишеттер авазыңны.

Пышылдауга күчкәннәрне
Ташлап китә горурлык.
Соңарма, бүгенге хәлләр
Каравыл кычкырырлык!

## Албасты

Була шулай, кайчак йөрисең,
Авыр уең көчкә күтәреп—
Кайчан килер, дигән көнеңне
Кайчан китәр, диеп үткәреп.

Сыкрый җаның, сызлый бәгырең,
Өмет юлың әллә уптымы,
Синең алда якты йотучы
Каракошлы кара упкынмы...

Кем өчендер кояш сүнгәндә
Бу соңгы уй булып калмасмы?
Төш күңелдән, шайтан коткысы—
Төшенкелек дигән албасты!

## Канында ул, җанында

Тән хәтерли—гомер буе туплап,
Җыеп бара каккан-сукканны:
Яшьлек-дуамаллык картлыгында
Сызландыра әллә юккамы?

Тән хәтерли. Күңел онытамы,
Кагыл гына нечкә кылына—
Тибрәндереп көйләп куя сине
Ничә гасырларның моңына.

Канында ул, җанда газиз аһәң,
Ник кадерле дисәң шул кадәр—
Ерак бабайлардан килә сиңа
Ядкарь-васыятьле моң-хәбәр.

Галәм хәтереннән милли моңнар
Мәңге шулай кайтып торсыннар,
Күңелләргә сүзсез аңлашыла
Зиһен төшенмәслек тылсымнар.

## Тирән таулар

Ерак тауда кеше күренмидер,
Биектәге күрә ерактан.
Шушы таудай көчең үзеңдә дип,
Ходай тауны горур яраткан.

Түбәсенә менеп, әләм элеп:
«Җиңдем!»—диеп мөмкин шауларга.
Кузгатмагыз аның хәтәр көчен—
Вулканнар бар тирән тауларда.

## Ак тәүбә

Мәхәббәттән саклыйм күңелемне—
Яңасыннан,
Саклыйм аның котылгысыз татлы
Ярасыннан.

Күтәрелмәс дәртле ашкынуны
Хәзер йөрәк.
Күрмәмешкә салынуың инде
Хәерлерәк.

Йөрәк тыныч, күңел сабырланды—
Гел тышаулы.
... Йә әйтегез, шушы әкияткә
Кем ышанды?

*Июль, 2000. Олы Бакырчы*

# Çəçmə əsərlər
# Чәчмә әсәрләр



## Нәбирә Гыйматдинова

## АРГЫ ОЧТА, БИРГЕ ОЧТА...

ПОВЕСТЬ

1

Җәнҗал аларны үзе эзләп тапты. Бу дүртәүнең бәхетеннән күптән көнләшә иде ул, күптән аларның арасын бутап ташлыйсы килә иде.

Аның белән таныштырып вакланмыйк, сез Җәнҗалның төс-кыяфәтен чамалыйсыз, тавышын да ишетеп беләсез булыр. «Ничек боларны берберсе белән бозыштырырга да, ничек маңгайга маңгай чәкештерергә икән?»—дип угаланып, кайчакта ул сезнең дус-иш тирәсендә дә бөтерелә, әнә очы кадәр ялгыш тапса—дөя итеп үстерә дә, әй китә шуннан, китә, китә... Җәнҗал капкынына эләгә күрмәгез берүк, ахырдан үкенеп туймассыз.

Ә менә яшьләр әлекте һәм ычкына алмады...

«Һайт» дип, аяк тибеп бер кычкырсаң—күктәге түм-түгәрәк айның яртысы кителеп төшәрлек тымызык төн иде. Дүртәү гадәттәге урынга—авыл башындагы буралы чишмә янына җыелды.

—Клубның таш идәнен тишә-тишә биеп аяклар арыса да—рәхәт. Төне тыныч, матур, башны мендәргә төртсәк, гөнаһ булыр, әллә бүген аяк өсте генә таң аттырабызмы, малайлар?—диде Дамир.

—Укытучы кешегә җәйге каникул җәннәт инде, төн ката хур кызлары кочаклап йөри дә, кояш арт ягын кыздырганчы йоклый. Миңа иртәнге дүрттә, күзне тырнап ачып, нәрәт бирәсе,—дип каршы килеп маташкан Галимне, жилкәсенә сугып, Равия бүлдерде:

—Перси башың белән зарланма әле, халыкны эшләп кинәндергәнең юк, синең дә төштән соң печәнлектә йокы симертүеңне беләбез. Йокы чүлмәге дигән даның таралмагае, кара! Синдә генә нәрәт, синдә генә хуҗалык! Әнә минем эшелоны белән карт-коры авыру, иртә белән медпунктка сыймыйлар, һәрберсенә укол яса, һәрберсенең кан басымын үлчә.

---

Нәбирә ГЫЙМАТДИНОВА—*прозаик, «Ак торна каргышы», «Талпыну», «Кыргый», «Сихерче», «Сәвилә», һ. б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

—Һай, мескен аксөяк нәселе!—Иң ахырдан дүртнең дүртенчесе—Гөлнур тавыш бирде.—Минем кебек иртән алып кичкә кадәр кибеттә әйбер сатсагыз, һәм дә жилкәгездә авыр-авыр капчыклар күтәреп ташысагыз, ничек сайрар идегез икән?!

—Их сезне, малайлар, күл бакалары төсле бакылдашып төннең ямен җибәрдегез. Әйдә, иркәм, өенә озатып куям.

Дамир Гөлнурны биленнән кочакламакчы иде, кыз читкә тайпылды.

—Туктале, ашыкма. Без бит синең тәкъдименә кул күтәрмәдек. Кем дә кем бу төнне йокламыйча уздырабыз ди, шул тамак кыра! Кһым, кһым...

Дүртесе дә тамак кырды, дүртесе дә кычкырып көлде. Равия, кулларын чәбәкләп, сикерергә үк тотынды.

—Ура! Төн безнеке, без төннеке! Әйдәгез, малайлар, кызлар, урманга киттек. Аланда учак ягып, һавадагы кайнар йолдызларны кыздырабыз!

Менә шул чакта шыпырт кына алар янына Җәнҗал килеп басты да: «Мин риза!» дип авыз ачарга җыенган Галимнең кабыргасына төртте. «Чү, рәис туган, бая гына перси башың белән зарланма әле, авылны эшләп кинәндергәнең юк»,—дип теленә салынган бу чикерткә сыйракка иплән кенә каршы дәш әле син!»,—диде ул, пышылдап. «Дөрес сукалыйсың, сөйгән кызың сине тәнкыйтьләсен инде, дөньяда булмаганны»,—диде егет һәм чигенмәслек итеп кырт кисте:

—Урманда черки талый, анда бармыйбыз.

—Нишләп шундый шәп фикергә черкинең ботын кыстырасың, Галим? Учак яксак, төтен исеннән кача алар.

Дамир Равияне якламакчы иде, Гөлнур бөтен көченә егетне үзенә тартты:

—Тукта, чибәр абыйсы, кеше ярларының көен көйләмәле син, төнне кайда үткәрик дип, әүвәл миннән сора! Минем, мәсәлән, кырмыскалы-черкиле урманны женем сөйми! Мин су яратам, күл буена барыйк, су коенырбыз.

—Ә минем борыныма дымлы һава килешми, сулышым кысыла, вәт!—диде Равия, һәм төнлә айдан гайре берәү дә күрмәгән яшьле күзләрен Галимгә төбәде. Нишләп бу сантый бүген аңа каршы бүрәнә тәгәрәтеп көчәнә соң әле? Ничә тапкыр урманда—аланның нәкъ уртасында икәү төн уздырдылар, ә хәзер черки имеш. Юк, сүзне сүз итәргә, мәлҗерәп торырга ярамый монда. Хуҗалык рәисе дигәч тә, бик кукраймасын әле. Өйләнгәч, Равиядән күндәм генә кол ясаудан да тайчынмас бу тәти егет. Гөлнурын кара син, суга сусаганмыни! Әнә, чишмәгә чум, коенам дип бик дәртләнсән.

—Мин урманга барам!—диде Равия.—Кайсыгызда шырпы бар?

Галим кесәсеннән алып аңа шырпы чөйде.

—Мә, рәхәтлән учак дөрләтеп!

Чөелгән шырпыны һавада ук Дамир эләктерде.

—Равия ялгызы гына урманга җилдермәс бит инде, малайлар. Монарчы дүртебез дә аерылмадык, чәчелмәдек, бүген дә төркемне таркатмыйк, әйдәгез Равиягә кушылыйк,—диде ул.—Юкә чәчәге исе иснәрбез, хәзер нәкъ балланган чагы аның...

Гөлнур ачуыннан кайнап, чишмә тирәли әйләнде. Кара, кара бу Дамирны, Равия дип жан ата, ә үзенекен санга да сукмый.

Галим утка коры йомычка гына өстәп җибәрде:

—Нигәдер синең Дамирың да урман дип саташа, Гөлнур. Әллә мәйтәм, парлашып элдертсеннәрме аланнарына?

Дамир кызарганын үзе генә тоеп:

—Синең сөеклең белән нишләп элдертим ди, Гөлнурымны үпкәләтеп,—диде.

Җәнҗалга монда эш калмаган иде инде, ул сөенә-сөенә караңгылык эченә чумды...

—Гөлнурым, имеш. Кеше ярларының капризы кадерлерәк икән,

бар, сине кем тотып тора, дүрт ягың—урман.—Гөлнурның тавышында үпкә катыш мыскыл ишетелде.

Галим үзенә сыланыбрак басып торган Равияне кискен генә Дамирга табан этеп җибәрде.

—Сиңа юлдаш әзер, йөгерегез урманга,—диде ул, ә үзе Гөлнурны култыклап алды.—Син, борчылма, чибәркәй, без күл буена төшәбез. Керфекләрен йомган төн чәчәге җыеп түшләренә кадармын. Дамир, суны өнәмәгәч, гомерендә дә синең өчен төнбоеклар өзмәгәндер. Киттек!

—Китегез, кит!—Равия алар артыннан берәм-берәм нәфрәт ташы очырды.—Олагыгыз су төбенә үк, олагыгыз, күл бакалары, бак-бак-бак...

—Ә сез урман черкиләре, без-без-без!—диде Гөлнур, үртәгәнгә үртәлеп.

Ирләр дәшмәде, хатын-кызга мул итеп бирелгән усал, зәһәр телне Ходай алардан күпсенгән һәм бөтен көч-гайрәтне йодрыкка салган, ачу тирегә сыймаганда шул йодрык белән генә «аңлашырга» кала иде.

Дамир күзе белән тишәрдәй булып Галимнең киң җилкәсен бораулады. Гөлнурны котыртып күл буена әйдәгән өчен берне тамызасы иде дә... белер иде шунда кеше яры белән ни рәвешле култыклашып йөрергә икәнен, алабай! Әллә күл буенда дустыңның сөйгән кызын төнбоеклар белән алдалап, таң аттырырга хыялланасыңмы? Мә, тот капчыгыңны, кояшның сыңар нур бөртеген күрмәссең, хәзер салам сыйрагыңны урман авызыннан әйләндерәм дә, өенә озатам.

Галим дә ярсып үкчәсе белән җиргә кадый-кадый атлады. «Равия ялгызы гына урманга җилдермәс!» имеш. Җилдермәсә ни, нишләп син кычытмаганны кашыйсың әле, кыссаң биле өзелер Нечкәбилең турында кайгырт әнә! Урманда таң атканын көтеп озак утырмассыз, яккан учагыгызны да, үзегезне дә туздырам, менә бу сыланчыкны күл тирәли бер генә зырылдатып алам да...

Һәм шулай булды да. Урман авызына җитәр-җитмәс Дамир, айваена карамыйча, кызны кире борды.

—Кайтып ят син, слуши. Минем дә йокы кибәне ишелә, иртүк болында печән дә чабасы бугай, әни сөйләнгән иде бүген.

Равия кырмавык кебек егетнең беләгенә ябышты:

—Син нәрсә, Дамир?! Аланга кереп чыра да яндырмадык ич! Тегеләр төнбоекларга бәреләә-бәреләә су коенадыр инде, шәрә тән генә...

—Теләсә нишләсеннәр төнбоеклары-ниләре белән, без кайтабыз, Равия!—Егет, көчләп диярлек кызны урманнан каерып алды.

Ә бу вакытта күл буенда Галим белән Гөлнур тарткалаша иде.

—Кайту ягын карыйк, миңа нәрәткә сонарырга ярамый,—диде егет, бөердән чыккан калын тавыш белән. Көнләшү тавышны да үзгәрткән иде.

Гөлнур чәчрәп каршы төште:

—Юк, кайтмыйбыз әле, яме! Син миңа вәгъдә иткән төн чәчәген дә өзмәдең, минем белән су да коенмадың. Тегеләр учаклар дөрләтеп аланда тәгәрәгәндә монда... Нәрәт дип, сүзеңне аста калдырмакчы мәллә син! Дамир мәктәптә балаларны җинеп өйрәнгән, аңа ни...

—Төкердем мин аларга! Тик аунасыннар аланнарында, миңа таң тишегеннән нәрәт җыеп, бригадирларга эш кушасы. Әйдә!

Галим киреләнеп маташкан кызны җилтерәтеп яр өстенә менгезеп бастырды. Күкрәккә ут капкан төсле йөрәк кыза иде. Ул бу ябышкак Гөлнур—Нечкәбил белән бәхәсләшкән арада тегеләр алан уртасында йолдызлар санап ятадыр инде. Дамир телгә оста, сүздән бизәкле челтәр үреп Равиянең иләс-миләс күңелен алгысытып ташласа йөр аннары «кичә кыз минеке иде» дип, теш шыгырдатып.

Үпкәләп авызын турсайткан кызны ул урам башында гына калдырмакчы иде, Гөлнур:

—Мин тиле Шәләйдән куркам, өйгә хәтле илт,—диде.

—Шәләй йоклый, бар инде Гөлнур, йөгер инде, аруым җиткән,

ике адым атласам—егылам,—диде егет. Аның болай алдаша-алдаша берәүгә дә ялварганы юк иде.

—Йокламый Шәләең, йокламый! Дамир белән гел очратабыз без аны. Көрәк күтәреп йә баз казырга бара, йә кайта. Башыңа бәрер дә, чокырына илтеп күмәр. Озат!

—Шәләй безнең күрше, чебенне дә рәнҗетми, акыллы тиле. Аңа күбенгәнче сөт эчәргә генә булсын, синең белән ник кул пычратсын ди ул! Төнлә йокы бүсә, җитмәсә!

Юкка гына сүз көрәштерде Галим, кыз аны ишетергә дә теләмәде:

—Ату сезгә ияреп кайтам, Фәния апаның күзләре шарлансын. Киленлеккә кай төшем ярамаган, хи-хи.

Аның чыпчыкка охшатып, чыркылдап көлүе Галимнең җен ачуларын кузгатты. Ул кызның кулын дорфа гына беләгеннән бушатып:

—Мин әниләрдә түгел хәзер, яңа салган йортымда, бирге очта, ә аргы очта синең Дамирың яши, туры аңа кайт, киленлеккә бик өметләнсәң!—диде.

Авылның икенче очында Дамир белән Равия «аерылыша» алмыйча интекте. Кызның йорты аръякта иде, ә анда бара-бара таң пәрдәсенең бер чите күтәрелә башларга мөмкин.

—Мин сине күпергә кадәр озатам да, аннары үзең генә тәпиләрсең, авыл кызы бит, адашмассың,—диде Дамир, аның гәүдәсе монда, җаны исә күл буенда иде. Шәрә килеш коенсалар бер-берләренә тәннәрен тидермичә узмыйлар инде... Су коймa түгел лә... Тизрәк күлгә барып җитәсе иде бит.

—Һи, Дамир, күпер өч көн элек җимерелде ләбаса! Хәзер басмадан мүкәләп чыга халык.

—Алайса басмага кадәр генә озатам.

—Юк, теге якка кадәр! Басманы иске-москы такталардан гына әтмәлләгәннәр, суга егылсам—коткарырсың.

—Йөзә белгән башың беләнме?!

—Төнлә күзләрем томалана шул минем, Дамир, шуңа начар йөзәм.

Равия вакытны сузар өчен басмадан юри әкрен генә чыгадыр шикелле иде. Аны суга тотып атудан көчкә тыелып калды Дамир.

Ярга аяк баскач, кызның «хуш» дигәненә дә илтифат итмәде, җанфәрманга өенә йөгерде. Мотоциклын кабызып, күл тарафларына очканда хаталарны мәңге төзәтеп бетереп булмас кебек тоелды аңа.

Галим дә машинасын кузгаткан, фараларын сүндереп, урманга табан куа иде. Юлда рәискә олау-олау печән төягән караклар очрады, әмма ул туктап тормады, үлән ел да шыта, Ә Равияне чәчеп үстермиләр, ул бердәнбер алтын бөртеге иде.

Машина белән туп-туры учак өстенә менәм дип гайрәтләнгән егетне буш алан каршылады. Фарасын яктыртып уннан да, сулдан да эзләде, күренмәделәр, учак эзе дә юк иде хәтта. Димәк болар, «йолдызлар кыздырып» вакыт әрәм итмәгән, боларның үзләренеке куәтлерәк булган: урман куесында «эрегән» болар... Аулакта назлашу рәхәтрәк күрәсең...

Гарьлегеннән җиргә ятып аунады егет. Дамир аның Равиясен назлап иркәләгәндә ул, мәми авыз, типкәли-типкәли Гөлнурны өенә кайтарып җибәрде. Кеше яры янәсе!

Әнә, кешенеке дип әдәп сакламыйлар, җае туры килү белән «кармак»ка эләктерәләр! Айка-актар урман дәрьясын хәзер!

... Яр буенда Дамир таптанды. Төннең кап-кара сыңар күзенә охшаган күл: «нишләп йөрисең?» дигән сыман сәерсенеп аңа карый, ә ул ачуыннан өрелеп тулган, күлмәгенә сыймый иде. Адәм затының исе дә юк ич монда, тып-тыныч, ни бака сайрамый, ни балык сикереп уйнамый. Су коена-коена дәртләре кузгалгач, чыдамаган, көймә белән теге якка—таллыкка ычкынган болар...

... Иртән кибетен ачып торган Гөлнур янына Галим туктады һәм сызлануын яшермичә:

—Кичә тегеләр урманда икәүләп ләззәтләнде,—диде.—Дамирын «аш» төрләндерергә ярата икән.

Кыз бер агарды, бер күгәрде.

—Учак ягабыз дип безелдәштеләр ич, черкиләр!

—Беркатлы син, Гөлнур, учакны яккан алар, түлке шырпысыз гына... Иреннәре, куллары, кһым, калган җирләре белән, кһым...

—Шулпаны куертма, Галим! Без бит Равия белән иң якын сердәшләр. Ул алай эшләмәс!

—Без дә Дамир белән җан дуслар. Эшләгән, однако. Шайтан котырткан боларны. Әйдә, без дә сер бирмик, кайда идегез дип сорасалар, таллыкта идек, диярбез. Авызың тулы кан булса да—төкермә!

... Дамир мәктәп капкасына орынмады да, аякларын авыр гына сөйрәп медпунктка юнәлде. Көнләшүдән аның чырае кара янган, танырлык түгел иде. Равия аңа юлда ук очрады.

—Абау, Дамир, чирләдең мәллә син?—диде.

—Чирләсәң, бер терелер идең әле... Хәлләр яманрак шул. Тегеләр ни... Таң атканчы таллыкта рәхәтләнгән...

Равиянең кулындагы бәләкәй сумкасы тамчы кебек тып итеп аяк очына «тамды»:

—Нәр-сә?! Алар су коенабыз дип бакылдаштылар бит!

Егет тузанга буялган сумканы кага-кага:

—Син ахирәтеңнең чуар йөрәк икәнен белмәдеңмени?—диде.—Мин беләм зато Галимне, кочагына утын пүләне сөясәң—яфрак яра. Ә Гөлнур чәчәк үк атмагае. Син алай ук төс салма әле, алда яшиселәреңне уйла. Без инде, малай, алардан көлдертмик, төпченсәләр, төнне ничек үткәрдегез дип, урман ешлыгында аю кудык, диярбез.

—Бездә аю юк,—диде Равия, күңелсез генә.

—Бүре диярбез алайса, бүре мыжлаган аның каравы...

Кичәге шаяруларны дүртәүнең берсе дә уенга борырга теләми, дүртәүнең берсе дә җаннарын кимергән шик кортыннан котылырга ашыкмый, киресенчә, барысы да үз сөйгәненә ачулы һәм каһәрле иде. Шушы нәрсә иртә таңнан ук аларның холыкларын әрдәнә кебек аркылы-торкылы өеп куйды. Моңарчы бригадирларны чакырып сабыр гына эш бүлгән юаш рәисне җен алмаштырган иде. «Чабата» кушаматлы бригадир Әүхәди, аптырап аның каршысына ук килеп басты. «Ул да, ул да түгел, апаем. Күзләре күгәрчен күзе төсле кып-кызыл, кара бөдрә чәчләре чуалган-укмашкан, үзе кырынмаган, яңак сөякләре очлайган... Нинди чебен тешләгән бу рәисне?»

—Якаңнан эләктереп, ботакка асам мин сине, Әүхәди абый!

—Бак, бак, тавышы да тотенләп чыга!

—Ник һаман Батма уентыгының печәнен кырдырмадың, сәләмә чабата?!

—Чү, Галим энем, арткарак чигеним, тавышың башыма каба алайса. Синме соң дип танымыйчарак, күрше авыл чуашы Никәләшкәгә ошатыбрак азапланаием, син икән. Чабата мәсьәләсендә кызма, энем. Яңа чаклары да бар ие аның. Хәзер аңлатам ситуацияне. Тиле Шәләй Батмада өч трактор берьюлы чумарлык баз казыган, ие.

—Күмегез, шайтан ялчылары!

—Соң, энем, башка эш эшләгән дә юк, гел баз күмәбез. Шәләй атна саен берне чәпәп кенә тора. Көч-куәт иншалла икән үзендә, аңа җеннәре булышадыр, тәүбә, тәүбә. Син күршесе, беләсеңдер хикмәтләрен.

Авыл җүләре Шәләй кырда, басуда, бәрәңге бакчасында эреле-ваклы чокырлар казып, халыкның да, күмәк хуҗалыкның да теңкәсен корыта, җәлләп аңа сүз әйтмиләр иде, ә бүген ул Галимнең сабыр буасын ташытты.

—Мин сине төрмәгә яптырам!—дип, үкереп барып керде рәис аларга.

Шәләйнең әнисе, күрәсең, әле генә сыер сауган. Төп кебек юан гәүдәле кырык яшьлек ир, камыт аякларын як-якка аерып баскан да

тум-тулы чиләкне күтәреп, изүенә агыза-агыза сөт эчә, үзе мәче сыман мыраулый да иде. «Төрмә» дигән сүзне ишегалдындагылар ишетмәде, Гамбәр карчык чукрак, ә Шәләй әнә, бик каты тамак ялгау белән мәшгуль иде.

Рәис тиленең бүлтәйгән корсагына карап торды да, йодрыгы белән чиләкнең төбенә сукты.

—Җитәр, лыкынма, шартлыйсың. Куй чиләкне! Кран суы эчәрсең моннан соң төрмәдә.—Аннары «сабыен» яклап: «Улым, улым, тимә, эчсен»,—дип инәлгән карчыкның колагына кычкырды—Утыртам малаеңны, Гамбәр апа! Бөтен басуны чокыр белән тутырды. Тиле дигән саен тигәнәк буе сикерә.

—Алай димә әле, күрше, акыллы бала бит минем малай, гәпләш үзе белән, гәпләш.

Сөт түгелеп, өсте-башы юешләнгән Шәләй чиләген кочаклаган иде, әнисе аны Галимгә табарак этәрде.

—Улым, якынрак кил, күршенең сиңа сүзе бар, бир чиләгеңне, төбендәгесен песи ялаштырыр.

Галимнең иртәнге ачуы чабудан ычкынмаган иде, ул Шәләйнең эчен тибеп агызырдай булып акырды:

—Үтерәм мин сине!

—Кайчан?—диде Шәләй, күзен акайтып.

—Акайма! Үтерәм дигәнне аңламыйсыңмыни?

—Аңлыйм, мин җүләр түгел лә. Түлке башта кайсыгыз үтерә соң мине? Әүхәди абзыймы, синме? Ул да әйткән иде төнә үтерәм дип.

—Әй сине!—Галим өметсез генә кул селтәде. Тилегә янаудан бер файда юк, бу «Алла колы» белән нинди телдә сөйләшергә икәнен дә белгән юк иде.

—Ул баз-чокырны ник казыйсың син, симез йомран?

—Кушалар.

Шәләй авызыннан сөт исе аңкытып кикереп җибәрде.

—Кемнәр куша? Ник куша, мәгънәсез?

Авызы ерылган тиле атсыз бармагын өскә тырпайтты.

—Әнә андагылар, без тимер ярпланнарны бәреп төшерербез, син—Шәләй, аларны таптап-таптап күмәр өчен баз яса, диләр, ие.

—Ул ярплан дигәненә ник тия соң күктәгеләр?

—Һе, күкне тишкәнгә ачуланалар, тити баш!

—Чынлап та, «тити баш» мин, каеш белән сыртыңны каезлар урынга, әкиятеңне тыңлап утырам. Дөрес яралмагансың син дөньяга, сиңа сугышка кадәр егерме ел алдан туарга иде, кинәндерер идең немецларга каршы траншея казып, безнең заманга әрәм кеше син, Шәләй-вәләй.

... Мәктәп бакчасында җәйге практика узган балалар Дамир абыйларындагы үзгәрешне күреп шымайды, иң шуклары да «койрык кысты», чөнки һәрвакыт елмаеп, баштан сыйпап эндәшкән укытучы бүген салкын һәм кырыс иде, түтәлдә йолкынып бетмәгән чүп үләннәре өчен дә ачуланды ул, малайлар коедан чиләкне чайпалдырып су тартса да «агач куллар» дип орышты. Аның элек көлеп кенә торган күзләре бүген һәммә нәрсәгә, гөл-чәчәкләргә, агач-куакларга ачуланып карый сыман иде.

Өченче класс кызлары, авызга авыз куешып чыш-пыш килделәр дә, ана чәчәк букеты китереп тоттырдылар.

—Бүген бәйрәм-фәләнме әллә? Нишләп чәчәкләрне өздегез?—диде Дамир, рәхмәт димичә, битәрли башлап.—Матурлык биреп тора бит алар мәктәп бакчасына. Икенче ялгышыгыз: ир-атларга чәчәк бүләк итмиләр.

Арадан бер кыюрагы аның хәтеренә «төзәтмә» кертте:

—Абый, абый, сез өченче көн мәктәптән чәчкә өзеп апкиттегез, мин күрд-е-ем,—диде.

Күз очы белән генә балалар арасыннан эзләп тапты тәтелдекне

Дамир. Чикерткә төсле яшел күзле кызчык Гөлнурның сеңлесе иде. «Синең хыянәтче апаңа өзгән идем» дип, күнеленнән генә әрләште егет. Ә «яшел күз» уен эченә яшерә белми иде әле.

—Абый, абый, ул чәчкәләр безнең өйдә, пыяла савытта су эчеп утыра-а.

—Аякланып сезгә йөгергәннәр, димәк,—дип, төрттереп, хихылдады өлкән класстагылар.

Укытучы кызарып-бүртенеп учына йөткерде дә:

—Кһым, кһым, йәгез, тел бистәләре, таралышыгыз, бүтенгә эш тәмам!—диде.

... Кызларның да йөзен кара болыт сарган иде. Галимнең гайбәткә тартым хәбәреннән соң Гөлнур, җен ачуы белән шатыр-шотыр ачкыч борды, кузгалырга «иренгән» ишеккә дак-док типте. Кибет ачылганын көтеп бер читтә чүкердәшкән өч карчык бу тамашадан сагаеп-өркеп «әстәгъфирулла» диештеләр. Якты йөзе белән кеше туйдырган кыз нишләп зәһәрләнә, нишләп тора салып таш пулат җимерә, йә?

Башка вакытта:

—Сары сандугачларым, кара карлыгачларым, иртә-зәрәдән үк җим эзләп кибет баскычына кунган бит, күрегезче! Әйдүк, әйдүк, кошкайларым,—дип гөрли-гөрли әби-чәбине үз артыннан иярткән Гөлнур бүген күзен алартып:

—Миннән алдан кая очасыз, ала каргалар, әллә сатучы сезме?—ди.

Кибет эчендә дә чырае төнтек иде аның, сүзсез генә үлчәде, сүзсез генә акча санады. Элек кергән-чыкканнан авыл хәбәрләрен тынлап, мәзәк сүздән шаркылдап көлгән кызның иреннәре бөрешеп, бер-берсенә ябышкан, нәзек кашлар ап-ак маңгайны бозып, дугаланып җыерылган иде.

Гадәттә, хатын-кыз аласын алгач тиз генә өенә кайтып китәргә ашыкмый, кибетче акчага шикәр-тоз сатса, алар бушка ләчтит сата иде. Шул уй, шул исәп белән өч карчык та тәрәзә кырыена елышты. Әмма телләреннән ярты кәлимә сүз тамарга өлгермәде, Гөлнур:

—Болай да колаклар шаулый, урамда каркылдашыгыз,—дип, пырылдатып куып чыгарды.

Аның холыксызлыгы әйтерсең лә дулкын аша Равиягә күчте, медпунктта да «һава торышы» бозылган, эссе җәйдә «боз ява» иде. Бу көнгә хәтле яшенә-картына сыйпап-сыпырып кына укол тишкән мәрхәмәтле шәфкать туташының куллары тәнгә инә түгел, салкын тимер кисәге төртә диярсең, тамырлардан кан кача иде.

—Синеке авырттымы?—дип сорады бу хәлгә гаҗәпләнгән карткоры бер-берсеннән.

—Инәсе дә калынрак, кызыбыз да ачулырак иде ахры,—дигән шелтә ачык ишектән Равиянең колагына чалынды, әлбәттә. Кичә ул: «Их, сезне, наяннар» дип көләр иде әле, ә бу юлысы хәтерләре калыр димәде, тотты да ачуын бөркеде:

—Сул аягыгыз медпунктта, уң аягыгыз кабердә, һаман дәваланасыз. Зарланырлыгыгыз юк инде, тире каплаган сөякнең кай төшенә кадасаң да, авыртыр.

Ә үзенең күзенә мөлдерәмә яшь тулды. Менә аның йөрәгенә—егерме ике яшьлек япь-яшь йөрәгенә—кайсыгыз ярасын төзәтерлек итеп дәва табар икән, йә? Равиянең борын төбендә хыянәт итеп яталар. Кем белән диген син, сердәше-ахирәте Гөлнур белән бит, адәм хуры! Галим кочагында утын пүләне дә яфрак яра диме Дамир? Тикмәгә генә әйтмидер ул бу сүзләрне, бардыр Галимнең кыз сизмәгән этлекләре. Хуҗалык рәисенең үзәктә көнаралаш җыелыш, көнаралаш бәйрәм, машинасы кулында, утыра да чаба. Юлда туктап кемне генә алмый, уңда урман, сулда урман, кер дә югал, кер дә кач...

Дамир шуларга ишарәлидер, мөгаен. Гөлнурың күр син, Гөлнурың, кибеттә эшләп тәмам азды, Дамир гына җитми икән хәзер аңа, инде

Галимгә үрелә. Жүнле кыз ахирәтенең егете белән янәшә дә утырмый, ә бу, бозык, оятсыз, төн ката таллыкта «яфрак ярган». Ничек күзгә туры карар икән?! Хәер, оятсызлар бәхетле халык, ояла белми, битеңне тырнап сөйләшә.

... Авыл өстенә эңгер таралганын дүртәү зарыгып-тилмереп көтте. Берсенең дә башына: «Клубка чыкмыйм» дигән уй кермәде һәм керәчәк тә түгел иде. Җыелып-очрашып кичәге төнге мажараларны тикшерү, бер-берсен гаепләү-тиргәү чишмә янында—аулакта гына башкарылырга тиеш булса да, клуб, ягъни мәдәният йорты «мин бар—син юк» дип, исемлекне барлау өчен иң кулай урын иде.

Авыл яшьләре дүртәүнең арага ятлар кыстырмыйча бер төркемгә оешып биегәненә күнеккән иде, ә бу кичтә, барысын да шаккатырып, дүртәү дүрт почмакта күңел ачты. Дүртесенең дә эчендә мәчеләр тырнашып-чинашып сугышса да, йөзләре шат, сүзләре мул иде.

Равия белән Гөлнур берсен-берсе ишетсен өчен, шүрәле кытыклагандай, клуб янгыратып шаркылдап көлә, ара-тирә, сиздермичә генә, көндәш ягына зәһәр караш ташлый иде. «Минем Дамирымның кочагы килешкән моңа, ничек сөенә-сөенә сикереп бии»,—дип уйлады кибетче кыз. «Моның Галим белән боткасы пешкән, күзләре ничек ялтырый»,—дип нәтиҗә ясады шәфкать туташы.

Галим белән Дамир исә хис-ярсуын бөкләп, йодрыкка төйнәде. Бүген кемдер кемнеңдер танавын җимерер ахрысы...

Мунча күк эсселәнгән бинадан башта җилләнә-жилләнә Равия урамга атылып чыкты, аның артыннан ук Галим кузгалды. Алар чишмәгә җиткәнче кан кыздырып, әрләшеп бардылар.

—Син төнлә урманда ни пычагыма озаклап йөрдең?—дип, көнләшеп бәйләнгән егеткә кыз, ихахайланып:

—Бүре кудык,—диде.

—Нинди бүре?

—Әллә соры, әллә кара шунда, син лутчы Дамирдан сора, аның күзе очлырак.

—Нәрсә, сиңа Дамир белән төн уздыруы күңеллерәкмени?!

—Син дә Гөлнур белән җәннәттә гизгәнсеңдер бит. Таллыкта сандугачлар сайрыймы соң?

—Ишетмәдек, без бүтән нәрсә белән мәшгуль идек.

Көнләшүеннән айга сикерердәй булган Равия «хи-хи» дип, көчәнеп кенә көлде дә:

—Безнең кебек икән, без дә бүре куып аргач ниттек... имән төбендә ял иттек,—диде.

—Имән төбе тап-такырдыр инде...

—Таллыкта да куаклар сынып беткәндер...

Якында гына Дамир белән Гөлнурның тавышы ишетелде. Алар да урамга «ут ягып», талашып киләләр иде.

Чишмә янындагылар тын калып, колакларын торгызды.

—Таң аттырабыз дип кичә син башладың, син! Равия белән алдан ук икәүләп качарга сүз куешкан сез!—дип чәрелдәгән Гөлнурны Дамирның калын тавышы бастырды:

—Минем тәкъдимнән мәкер эзләмә, җавап бир: Галим белән кочаклашканнан соң сөякләрең авыртмыймы?

Калын тавыш арасыннан тагын нәзек тавыш саркыды:

—Ул синең кебек тимер кул түгел. Ипләп-җайлап кына кочаклый, әнә Равияне тикшер, берәр җире сынмаганмы!

—Аның тәне йомшак, гел сөяксез. Бар икән дөньяда кызлар!—диде Дамир, йөрәк астына үрләгән көнчелек утыннан пешеп.

Арттырып җибәрде, арттырып... Әмма йомгак, кулдан ычкынып, сүтелеп киткән, кире җыярга соң иде инде...

—Ярар, мин сөякле икән, моннан ары кагылмассың миңа, үлəм дисәң дә...

Үпкәләде, жанаш, үпкәләде... Ничекләр бәхилләтер аны Дамир?

... Яшьләр дүртесе дә бергә жыелгач, авызына «су капты». Сүзләренен жилеме юк, ябышмый, шуна дәшмиләр дияр иден, ул сүзләр, телдән сикерә башласа, ничек кенә ябышачак иде әле! Барысынын да эчендә ачу шытып бүрткән, барысының да үпкә-рәнжүдән тыны кысылган, әлегә ызгыш-җәнҗал дилбегәсен шулар гына тотып тора иде.

Көрәген жилкәсенә куйган Шәләй килеп баскач кына сулыш алды бугай алар.

—Мин зерә сусадым, сөт эчәм,—диде тиле, иренен лач-лач ялый-ялый.—Сез сүләшегез, сүләш. Мин дә яшь чакта кызлар белән сүләшә идем, кызлар да капка ярыгыннан минем белән сүләште.

Иелә-ята чишмәдән су шапыргач Шәләй ризасыз гына:

—Каймагы әз, ипигә ягып ашагансыз.—диде.—Шыр су икән, мин кайтам итусә.

Галим аягы белән көрәк сабына басты:

—Тагын кайсы кырны тишкәләдең инде, йомран?

—Әнигә әйтәм, сындырма минем алтын көрәгемне?—Тиле еламсырап көрәген тарткалады.

—Бир, бичараны елатма!—Равия без үкчәле туфлие белән егетнең аягына типте. Ул арада Шәләй «алтын корал»ын эләктереп, йөгерә-йөгерә китеп барды.

—Ну, каты тибәсең, кызый,—диде Галим, бер аягында сикергәләп.—Сөягем чатнады ахры. Туйга хәтле төзәлер анысы да... Шәләй, йомран, тычкан, күсе, дөньясын казый, валлаһи.

—Казысын!—диде Равия, ул баядан бирле егетне чеметергә жай эзли иде. Хәер, Шәләй пәйда булып, һәммәсенең дә сулыш юлын ачкан, һәммәсе дә «тел сугышы»на әзер иде.

—Үзенең бакчасында казынсын, минем чокыр күмәргә вакытым юк.

Галим шулай дигән иде, кыз, мыскыллап:

—Әллә кемнәр белән таллыкта таң аттырырга вакыт табасың бит, баз күмәргә дә тап,—диде.

Гөлнур «әллә кем»не йоталмады.

—Берәүдә склероз, исемемне хәтерләми бугай, дип,—песи төсле Галимгә килеп сырпаланды.—Ә минем Гөлнур исемле бик матур атым бар, жаный, ул сиңа ошыйдыр бит, йә?

Галим: «Нишлисең син, артыгын кыланасың шикелле» дигәндәй, бер мәлгә аптырап-югалып, хәтта ки аягының авыртуын да онытып, Гөлнурга карап торды. Аннан Равиягә «сдача» кайтарырга жай чыгуына шатланып, Гөлнурны жилкәсеннән кочты.

—Ошамаган кая! Үзең гөл, үзең нур син!

Көнләшүдән бала йоннарын кабарткан Дамир сөйгәненең жилкәсеннән Галимнең кулын бәреп төшермәкче иде, муенына Равия сарылды.

—Болар таллыкта оятларын адаштырган, безнең алда кочаклашудан да тартынмыйлар, кил, без дә яратышыйк,—диде шәфкать туташы.

Берсе дә: «Житте, кинаян-төрттерүләргә нокта куйыйк, югыйсә ахыры үкенечле тәмамланыр»,—дияргә ашыкмады. Һәркем, егете—кызы, «мин түгел, ул хыянәт итте» дип саный, һәркем «ул»ның гафу үтенгәнен көтә, ләкин берәү дә яшьлек кирелеген жинеп «кичер» дими иде.

—Ник болар белән бәйләнешеп гомер уздырабыз әле, сизмисеңмени, урманга карап угалаалар, кичәгеләрне кабатлыйсылары киләдер,—дип, Равия Дамирны читкәрәк тартты.—Юл бирик, ычкынсыннар!

—Ычкынырбыз да, сезнең чылбыр божрасы түгел без, әйдә Галим.—Гөлнур үрә каткан егетне селкетә башлады.—Әй, син дим, безне куалар, әйдә!

Галим белән Гөлнур уңга, Дамир белән Равия сулга каерды.

Бер-берсенең бәгырен өзгәләр өчен генә теләсә ни лыгырдаган дүртәү, парлашкач, кызуы беткән мунча ташы кебек сүрелеп калды.

—Таллык та, таллык, дидек, әллә чынлап та көймә белән шул якка йөзәбезме? Хет анданиләр үскәнен, нинди кошлар оялаганын күрәсе иде бер...—диде Галим.

Гөлнур сузып-сузып кына:

—Юу-ук,—диде.—Нишләп синең белән җәһәннәмгә йөзим ди! Равияне чакырырга иде.

—Равия синең Дамирың белән шугалак шуа бит...

—Минем эчем поша, Галим, синнән яшермим инде. Дамирдан башка яшәүнең кызыгы юк, сулар тәмсез, кичләр ямьсез... Син дә Равияне яратасыңдыр, әйеме?

Егет айга карап уфырды.

—Уф, ир-атка килешмәсә дә әйтәм, яратмаган кая... Ни бит, гаеп синдә дә, миндә дә түгел, безнең сөекләләребездә. Алар урманда «бүре куды», ә без—ике гөнаһсыз, өйгә кайттык. Ничек буладыр инде ул, башыма сыймый, дустыңның яры белән төн уздыру дим, әле җитмәсә...

—Нәрсә «җитмәсә?» Әйтеп бетер!

—Равия имән төбендә ял иттек, ди, бүре куып аргач. Тел төбеннән аңлашыла инде нишләгәннәре...

Кызның йөрәге чәнчеде. Аһ оятсызлар, оятсызлар! Сукыр кошлар да ярын буташтырмый, ә болар—күзле бүкәннәр, тәмам шашкан икән лә.

—Мин кайтам, Галим. Алар йөрсен парлашып...

—Әйдә, озатам.

—Кирәкми, ай яктысында юлны саташтырмам.

—Шәләйдән куркам дисең бит.

—Әй, курыкмыйм ла, озатма, яме?—диде Гөлнур.

... Сулга каерган Дамир белән Равия дә шактый җир «тел йотып» атладылар. Егет, күзеннән яшь коя-коя барган кызның йөзенә иелде:

—Елыйсың димме соң? Битеңдә яшь тамчысы җемелди.

—Хурлыгыңнан чәчеңне йолкый-йолкый еларсың монда... Алар кичә таллыкта сайрашкан, ә без—туфли очына тузан да кундырмыйча өйләргә йөгердек.

—Урманда бүре кудык дигән ялган даныбызны аклап аланны бер әйләнербез, бәлки?

—Син дә каныма тоз салма әле, Дамир! Әллә сынавыңмы? Сез егетләр моңа мачтыр. Минем Галимемнән башка беркем белән дә урманга менәсем юк! Кыстама!

—Гафу... Минем уемда бозыклык юк иде. Син әйбәт кыз, син Галимнеке, әйе. Туктатырга иде безгә бу мәгънәсез талашуны. Син ничек уйлыйсың?

—Әүвәл алар туктатсын, алар хыянәтче бит,—дип тәкәллефсез генә җавап кайтарды Равия.

—Анысы да дөрес,—диде Дамир, кызның сүзен җөпләп.—Ник без гаепсез башыбызны иярга тиеш ди. Гел сыртларын күрсәтмәсләр, йөзләре белән дә борылырлар, шәт.

—Хәзергә миндә бер генә тәкъдим, Дамир: кайтыйк та юрганыбызны бөркәнеп йоклыйк!

Дамирга да Равия белән урам тузаны таптавы күңелле эш түгел иде.

—Өенә хәтле илтәм, әйдә.

—Мәшәкатьләнмә, адашмам, таныш авыл,—дип кире какты Равия.

—Басмагыз иске тактадан гына дисең үзең.

—Мин җинел, чыдатыр әле. Хуш, Дамир.

—Хуш, Равия!

... Авылның дүрт очында дүрт капка ябылды. Әгәр капкалар җанлы булса: «Нишләп безнең яшьләр ике төн рәттән иртә кайталар икән?»—дип, сәерсенер иде.

## 2

Дүртәү ачу-нәфрәттән газап чиккәндә туй көннәре якынлашты. Жирле үзидарә рәисенең өстәл тартмасында егетләрнең: «фәлән көнне, фәлән сәгатьтә безнең никахыбызны рәсми рәвештә теркәвегезне үтенәбез» дигән гаризасы ята иде. Авыл хужалык рәисе белән шәфкать туташының, укытучы белән кибетченең өйләнешергә жыенуын белә, хәтта балаларга да сер ачык: тыкрык коймалары «Дамир + Гөлнур», «Галим + Равия»ләр белән әледән-әле чуарланып, һәм янгыр юган арты әледән-әле янартылып тора иде.

«Никах көне» турында рәис Гыйльман абзый әүвәл Галимнең исенә төшерде.

—Өч көннән Равия дә, син дә паспортларыгызны китерерсез, документларны тутырып, әзерләп куярбыз,—диде.—Синең фамилиягә күчәдер бит кәләшең?

—Нинди сүз ул тагы! Минекенә, әлбәттә!

—Хәзерге заман хатын-кызларын белмәссең, туган, үзенекендә калуы да ихтимал.

—Минем хатын белән алай булмаячак, Гыйльман абзый.

—Кунакларың болыт кебек ишелсә, ашханәне ал.

—Өйгә дә сыярлар, өй иркен, яңа...

—Өйләнәсе егеттәге дәрт юк синдә, жегет. Буйдак тормышың кызганыч бугай.

«Буйдак тормыш» уйдамыни, уйда—Равия, бердәнбер кеше Равия иде! Әнә ул егетнең мангаена нинди мөгез кадаклады: Дамир белән каядыр таңнар аттыра... Ятлар белән чуалу диләр моны... Йә, нишләргә? Дамирны изеп ташларгамы (ичмасам ачу басылыр), әллә Равия белән араны өзәргәме? Болай авылда кыз-кыркынга кытлык юк шикелле. Галим бер сызгырса—унау жыелыр. А, юк! Акылдан битәр йөрәк бар: дустыңның тешен койсаң да, сөйгән ярыңны югалтма, башкалар белән дә бутама. Егет ак халатлы кызга үзе ялынып килмәс, билгеле. Чөнки ул гаепсез гаепле, кичерү сорый алмый, кичерә генә ала, анда да теш кысып, ир горурлыгын жинеп кенә...

Гыйльман абзый балалар белән мәктәп бакчасында эшләгән, Дамирның да хәтерен янартып үтте:

—Гаризаң тартмамда «туй, туй» дип тыпырдап бии, жегет. Көнен-сәгатен онытма, әзерлән. Гөлнурыңа да тапшыр.

Дамирның кинәт кенә әби йомгагы сыман уй-фикере чуалды, Гөлнурга ни-нәрсә тапшырсын икән ул? Алда туйлар, әйе, туйлар... Кыз аны Галимгә алыштырды түгелме соң инде? Дамирны яратса—сөйгәненең дусты белән таллыкта төннәр уздырыр иде микән, ә? Шуны оялмыйча йөзгә бәреп әйтүең күр син, берәү яшерер, берәү уңайсызланыр иде. Әгәр Гөлнур: «Үкенәм, кичер»,—дисә... Ул чакта, кһым, «юк!» дип мөнәсәбәтләрне шартлатып урталай сындырырга ярамастыр шул, чөнки, чөнки... Әнә карагыдай ябык нечкәбилдән гайре күңел беркемгә дә талпынмый, Нечкәбилнең йөреш-торышларына кадәр якын, кыз мәктәп яныннан узганда да күзләрен алалмый карап кала Дамир.

Кайчакта учка сыярлык нечкә биленнән элэктереп, кычкырта-кычкырта үбәсе килә.

—Абый, абый, сезне «перси» чакыра!—дип эндәште балалар.

Галим урам якта—койма артында басып тора иде. Кул биреп исәнләшү булмады, тамак кыру гына булды. Ике арадан кара мәче йөгергәннән бирле дуслар бер-берсенә салкынайган иде.

—Балалар карый, юкса, койма аша гына сөякләреңне ватa идем,—диде Галим.

—Минем сөякләр арасыннан синекен дә чүпләрләр иде,—диде Дамир.

—Бүген кич Равия белән икегезгә суд ясыйлар.

Галим шаяртмый, йөзе җитди, кара күзләре усаллык исәпләп ялтырый иде.

—Хөкемдарлар кем соң?—дип елмайды Дамир, әмма елмаюы ирен очында гына, ә зәңгәр күзләрдә исә дөрләп ачу кабынды. Һич гаепсез кешеләргә нинди хөкем ди ул! Саташкан!

—Хөкем итүче без—Гөлнур белән мин, Дамир кордаш. Иң беренче бәхәс купкан төндә без аның белән таллыкка йөзеп чыкмадык, өйләргә таралыштык. Миңа нәстәмә кеше кызлары! Соңра сезнең хыянәтегездән гарьләнеп кенә бодай суктырмыйча кибәк очырдык без. Димәк, гөнаһлылар—сез!

—Алдашма,—диде Дамир,—сез таллыкта «сандугач сайратканда» Равия дә, мин дә өйләребездә утыра идек. «Беркатлы ахмаклар» дип сез бездән көлмәсен өчен генә ялганладык без. Димәк, кич рольләр алмашына, хөкемдарлар Равия белән мин, ә җинаятьчеләр—син һәм Гөлнур!

Ике «тәкә» ике яктан койманы китереп кыстылар.

—Куык очырма, сез таллыкта идегез!

—Күзгә төтен җибәрмә, сез урманда идегез!

Тик тәкәләр мөгезләреннән ут чәчрәтеп сугыша гына алмадылар, бакчада егерме пар күз, кызыксынып, аларны күзәтә иде.

—Кичкә чишмә янына кил,—диде Галим, еш-еш сулап.

Дамир маңгаена чәчрәп чыккан тирен кул арты белән сөртә-сөртә:

—Кемнән шөлләргә, килермен,—диде.

Егетләр коры пар бөркеп кайнап-ташыганда кибеттә дә «җанлы әңгәмә» корып яталар иде. Равия, халыкның әзрәк чагын чамалап, кибеткә килде. Тиктомалдан гына Гөлнурга барып ябышсаң, җәнҗалчы кушаматы тагулары бар, шуңа күрә ул туй күлмәкләре эленгән почмакка карап аһылдады да:

—Абау, бу фәрештә киемнәрен складта яшереп тотканнар, ахры, минем туй алдыннан гына, абау!—диде.

Гөлнур он үлчи иде, соскычын ташлап киемнәр бүлегенә йөгерде.

—Ярты ел кибеттә тузан җыя бит инде алар, Ходаем! Әнә, биркаларына ат хәтле хәрефләр белән язылган фәлән числода тегелгәне, әнә, күзеңне ачыбрак укы, күрмәсәң, кешедән сора, укып бирерләр,—диде ул һәм ирония белән өстәде.—Кайберәүләргә ак киясе дә түгел, никах кичено кадәр эше эшләнгәч...

Он үлчәтүче Фәсхия карчык колакка каты иде, ишетмәде, ә Равия ишетте, бу сүзләр ук сыман йөрәккә үк кадалды.

—Мин хет күрше алмасына үрелмәдем, үз бакчам җимешен генә татыдым, ә син Дамирыңа хыянәт итеп, минем Галимем белән дә сыйландың!

—Серләшегез, серләш, ахирәт дусларга сер сыя, мин ашыкмыйм, оланнар, этем ашаган, кәҗәм көтүдә,—диде чукрак карчык.

«Сер» инде кибеткә генә сыймый, иртә кузгалган язгы ташу кебек авыл урамнарына да җәелергә маташа иде.

Гөлнур бот чаба-чаба артка чигенде:

—Үл-ләм, бер ыштыр бите үз бакчам җимешен генә татыдым диме? Тиле Шәләйне ышандыр, яме? Син минем юаш Дамирымны юри урманга апкитеп аздырдың. Мин ул, мин саф, керсез җан! Әйтсәм әйтим, без синең Галимең белән таллыкта чыбык заты да күрмәдек, сез урманга йөгергәч, кайттык та киттек өйләргә!

—Ә-ә, сез безгә шундый матур ялган әзерләп куйдыгызмыни әле? Туй алдыннан акланыйк-пакъланыйк дип уйладыгызмы? Равия белән Дамир—ике җүләр, ике сантый, ышаныр дисезме? Сезнең хәйлә капкына тычкан ботын кыстырган ди әнә!

...Чишмә янында да дүртәү татулашырга ашыкмады. Берсе дөрләгәндә икенчесе су сибәргә теләми иде. Җәнҗалны тирәнгә җибәрделәр, һай! Ул тамыр җәеп, тагын да ныгып үсеп китсә—аны кем йолкып ыргытыр иде икән?—бу хакта баш ватмадылар шул.

Бер-берсен чәнечкеле сүзләр белән кадап-төртеп туйгач, Галим белән Гөлнур гадәттәгечә унга, Дамир белән Равия сулга киттеләр. Бу хәл һәр кич кабатлана, ә туй, гармуннар уйнатып, биеп-җырлап, каршыга йөгерә иде.

Себердән бүләкләрен кыстырып Галимнең җизнәсе белән апасы кайтып төштеләр. «Яраткан энемнең туенда идән такталары сынганчы биемичә, Себергә аяк та атламыйбыз»,—дип гөрләде апа-туган.

Кунаклар урнашып та өлгермәде, Владивостокта яшәүче хәрби абыйсыннан телеграмма китерделәр. «Туйга көтегез, юлга чыгам» дигән хәрби-туган.

Вакыт-вакыт Галимнең башында «Гыйльман абзыйдагы гаризаны ертып ташларга һәм язылышу көнен Равия белән татулашканга кадәр чигерергә»,—дигән уйлар бөтерелә иде, инде төп йортка туганнар җыела башлагач, бу уеннан ваз кичте. Бит һәрберсенә хат язып, гозерләп-гозерләп чакырды, кайтмасагыз, туган санамыйм дип тә кисәтте. Хәзер туй булмый, өйләнмим дип, аларны себерке белән куаргамы?!

Берни эшләр хәлең юк, Равия белән араларны көйләп-җайларга тиеш ул.

Изге ниятемне тормышка ашырам дип, егет иртән үк медпунктка сугылды. Аны күргәч, кызның күз карашы яктырып киткәнен тойды ул, бу аның әрнегән-сыкраган күңеленә май сылап җибәрде. Кыз ана ымлап кына утыр, диде, димәк, кумый, моны да әйбәткә юрарга була иде.

Равия, авыруларын укол кадап озаткач, дару исе сеңгән алгы бүлмәдә икәүдән икәү генә калдылар.

—Чирләдең мәллә?—диде шәфкать туташы, ак тешләрен җемелдәтеп.

Галим әйтәсе сүзләрен хәтереннән барлады. Авыз эчендә ботка пешереп, җебеп утырырга ярамый, кистереп-өздереп әйтергә һәм өзелгән җепне мәңге сүтелмәслек итеп ялгарга кирәк иде.

—Әһә, чирләдем...

—Нинди дару языйм, кай төшең авырта?

—Белгән дә юк кай төш сызлаганны. Йөрәк ахры. Дару дип... Аның даруы син генә инде...

—Гөлнур түгелмени?

—Йә, Равия, акылыңны чәчмә, туктат шул мәгънәсез уенны. Берничә көннән Гөлнур белән Дамирның да, синең белән минем дә туебыз, кеше көлдермик, матур гына барып язылышыйк. Мин сине яратам, син дә ратуыңны инкарь итмисеңдер.

Кыз, чәчәк ясап, иреннәрен бөрештерде.

—Әйе, безнең туй җитә шул. Мин риза, ләкин бер шарт белән...

—Нинди шарт ул?—Галим болай гына сорады, ул теләсә нинди шартка күнәчәк, тик Равия белән кавышсыннар гына иде!

Ә Равия, тиз генә түгелмәде, беркавем түшәмнән нәрсәдер эзләгәндәй, башын өскә күтәреп торды. Аннан соң гына:

—Гөлнур белән икәү аягыма егылып, аяк битемне үбеп гафу үтенегез!—диде.

Егетнең түбәсенә чүкеч белән суктылармыни, чигәләре чатнап куйды.

—Равия, тилермә сана! Без синнән егылыплар гафу сорарлык бер гөнаһ та кылмадык!

—Оныттыгызмыни, тәти егет, Гөлнур белән таллыкта үбешеп-кочаклашып һәм дә...

—Сез ул Дамир белән имән төбендә аунаштыгыз, үз гөнаһыгызны безгә аудармагыз, оялыгыз!—диде егет. «Теләсә нинди шартына күнәм» дип, ашыгыбрак әйткән икән, менә күр, бер гаепсез башыңны дегеткә батыралар...

—Җә, мин гаепле, ди, җә, кичер...—Дамир кызның каршысына тезләнде.—Сал чүәгеңне, сал оегыңны, ун тапкыр ун бармагыңны да үбәм. Яратуым хакына аягыңны юган суны да эчәргә риза мин.

Равия тәкәббер генә өстәл янына килеп басты.

—Чур, җаным, минем шартым яртылаш кына үтәлергә тиеш түгел, сөйрәлчек Гөлнурыңны да чакыр, ул бер аягымны, син икенче аягымны үбәсез!

—Аның тамчы да гаебе юк бит, Равия бәгърем, акылыңа кил, зинһар! Борын төбендә туебыз әнә.

—Алайса миңа хыялыңда гына өйләнерсең инде, Галим, раз сөйрәлчегеңне аклагач,—диде кыз.

—Ярар...—Дамир торып, чалбар балагының тезләрен каккалады.—Ярар, булмагач, булмый икән, хуш,—диде ул, әллә ишекне япты, әллә юк, кулы камыр, гәүдәсе камыр, ә баш, тагын бер тапкыр чүкеч белән орган төсле, үтереп шаулый иде, рәис үзидарәгә юнәлде, анда әллә ни ачылмады, түш кесәсеннән паспортын алып, Гыйльман абзыйның өстәленә ташлады.

—Тутыр кәгазьләреңне, Гыйльман абзый, түлке»хатын» дигән сызыкка язмыйча тор, без шампан шәрабе ачканда да сырлап куярга өлгерерсең,—диде.

Рәис абзый паспортны әйләндерде-тулгандырды да, сирәк сакалын сыпырып:

—Безнең ише карт ишәккә сезнең мәзәк һич аңлашылмый, җегет,—диде.—Аңлат әзрәк.

—Соңыннан аңларсың, Гыйльман абзый, соңыннан...

Карт ян тәрәзәдән күреп калды, егет, эре-эре атлап, кибеткә табан борылды.

*«Туй дөмбесе» Дамирның да яңа йорт капкасын шакыды. Аны әниләре башка чыгарып, өйне бизәп-матурлап куйган иде. Ул сеңлесе артыннан Гөлнурга хат юллады: «Нечкәбилем, без синең белән язмышларны бергә бәйләргә җыенабыз, шәт, көнен-сәгатен онытмагансыңдыр? Соңгы вакыттагы ямьсезләшүләребезне җилгә очырыйк, мин сине гафу иттем, гаилә корып яши башлагач та, кузгатмам, ант! Мәктәп бакчасында—карт алмагач төбендә көтәм, кил. Туй хәстәре турында сөйләшербез.*

*Дамирың».*

Гөлнур мәктәп бакчасына килмәде, шул ук «яшел чикерткә» егеткә шакмаклы дәфтәр бите тоттырды.

—Мә, абый, апа бирде!

«Дамир, туй хәстәре дип юмалама, яме,—дигән кыз.—Минем ак күлмәгем, бүтән кирәк-яракларым да әзер, өйләнешәсе көнебез дә хәтеремдә. Әмма син куанычыңнан түшәмгә сикермә, яме? Карт җегетләр исемлегенә эләгүең дә мөмкин чөнки. Иң элек синең «сулда ужым чемченүләрең» өчен мине бәхилләтәсең бар. Шунсыз чыкмыйм мин сиңа кияүгә! Үзең генә теләнмисең гафуны, Равия белән икәүләп, алдыма тезләнеп, башыгызны җиргә ора-ора сорыйсыз кичерүемне...»

Егет хатны ахырга хәтле укып бетерә алмады, вак-вак кисәкләргә ертып, алмагач төбенә сипте. Ни кылана бу Нечкәбил?! Һаман үчләшеп-үртәшеп туймый, һаман бер гөнаһсыз кешеләргә яла яга. Шулай инде ул, үзе карага буялган бүтәннәрдән дә кер эзли. Ялгышасың, җанкай чибәр кыз, Дамирның аккан-тамган җире юк, ул сау-сәламәт ир бәндәсе, «карт җегетләр» исемлегенә мәңге кермәячәк, син аңа андый киләчәк юрама да!

... Гыйльман абзый аны сагаюлы караш белән түргә әйдәде.

—Уз, энем—җегет, уз. Нигәдер Галим дә, син дә җилкәгезгә болыт ишелгәндәй, сыгылып йөрисез әле. Туй мәшәкате басамы, дим...

—Өйләнү—җаваплы нәрсә шул, Гыйльман абзый. Ну өйләнмичә дә ярамый, бер бездән генә калмаган.—Дамир дулкынлануын йөзенә чыгармаска тырышты, башын аска иеп сөйләште.—Менә, паспорт, тик ни...

—Әлегә «хатын» дигән графага кул тидермәскә, иеме? Шампан шәрабы арттырганда да тутырып була анысын...

Егетнең колакларына ут үрләде.

—Уемны каян сизден, Гыйльман абзый?

—Ике дистә ел никах терки-терки сизмәгәнне сизәрсең, жегетем. Сина да, Галимгә дә бер кинәшем бар минем. Әллә дим, әзрәк кичерәсезме туегызны, примир күзгә, әйе, күзгә. Ямьле чак, ризыкка мул чак, ә, жегет? Кайнар башларыгыз да чак кына суынып иде.

—Юк, мин бер кисеп ике ялгый торган малай түгел, Гыйльман абзый, таш яуса да гаризамда күрсәтелгән көндә өйләнәм!

—Үз күленә чуммаган үрдәк ахырдан үкенә, энем-жегет, һай, үкенә. Уйлап бак, уйла.

Әмма Дамир уйдан гарык иде, ул як-ягына карана-карана медпунктка юнәлде.

... Өч көннән авылда тешсез гайбәтчеләр дә рәхәтләнеп чәйнәрлек вакыйга булды. Ефәк тасмалар белән бизәлгән жинел машиналар, каз-тавык пырылдытып выж-выж урам әйләнде дә үзидарә каршысына туктады, бер машинадан, Галим, икенчесеннән... Гөлнур чыкты һәм култыклашып баскычтан менеп китте. Аларның аяк эзендәге тузанны жил «өф-өф» итеп өргән генә иде, аллы-гөлле тасмаларын жилфердәтеп тагын дүрт машина килеп өстәлде. Боларында Дамир белән Равия иде.

Койма-капкаларга сырышкан бала-чага:

—Саташканнар, саташканнар! Дамир абыйга Гөлнур апа, Галим абыйга Равия апа тиеш,—дип ризасызлык белгертеп кычкырды.

Адәм балаларын куша-аера чәч агарткан Гыйльман абзый язылышу тантанасы алдыннан:

—Һай, кайнар башлар, нишлисез, ә?! Үз күленә чуммаган үрдәк ахырдан үкенә!—дип юкка гына өтәләнде, аны берәү дә ишетмәде, ишетсә дә тыңламады: колаклар чукрак, күзләр сукыр иде. Дүрт якның ата-анасы, туган-тумачалары да әлеге табышмактан тәмам аңгырайган иде бугай. Аргы очта көткән килен бирге очка, бирге очка төшәсе килен аргы очка төшә, аптыраш, валлаһи! Көне-сәгатендә генә беркемгә дә бернәрсә аңлатмыйча парларын алмаштырды да куйды яшьләр.

Икенче көнне Галим, таң белән уянып (дөресрәге, йокысыз төн уздырып) кырга чыгып чапты. Йөрәктәге сызлавыкның әрнүенә чыдарлык түгел иде, аркасын чәнчеп, печән камылында аунады яшь ир. Зөфаф кичендә ул белде: Гөлнур ана «тук» килеш эләккән, алар Дамир белән «тыелган алма»ны бүлеп ашаганнар икән инде...

Рәис кырда, ә укытучы мәктәп бакчасында игәлде. Гомер буе уфырып яшәргә туры килер ахрысы: Равия белән Галим күптән «татлы жимеш»тән авыз иткәннәр, Дамирга коры төше генә калган, төкерсәң—кеше сизә, төкермәсәң—теш ярыгына кысыла. Их кеше ярлары-ы!

### 3

Туй кыңгыраулары чыңы тынып атна-ун көн үткәч, Галим кул изәп кенә Шәләйне чакырды.

—Күрше, кил әле, янәшә утыр,—диде, капка төбендәге эскәмиягә күрсәтте.

—Әләй, куркам, колактан борасың!

Шәләй якын килергә базмады.

—Бормыйм, күрше, утыр инде.

—Шуннан гына сүлә, куркам!

—Серне кычкырып әйтмиләр, Шәләй, колакка гына пышылдыйлар, син акыллы кеше, моны беләсең,—дип, тилене юмалый-юмалый янына утыртты һәм кулын аның жилкәсенә салып.—Хәлләрең арумы?—диде.

Шәләй авызын ерды.

—Төнәгеен базыма ярыплан очып төшеп борыны белән калалган.

—Ярыплан түгел ул, Шәләй, безнең хужалыкның тракторы. Эш ясап ятасың тәки. Жә, жә, куырылма, тимим. Син чокыр казырга өстәгеләр куша дисеңме?

—Ие, өстәгеләр,—дип күзләрен челт-челт йомды тиле.

—Мин бер йомыш кушсам, тыңларсың микән, Шәләй? Синең күршең дә нәчәлник бит, аерма шунда гына, сиңа әмер бирүчеләр өстә, ә мин жирдә яшим.

—Ә-ә, шулаймыни? Әлсә ара-тирә сине дә тыңлармын, ие.

—Син укытучы Дамирлар күршесе Сәрия апаңнарга көн саен барасыңмы, дускай?

—Ҡәжә сөте эчерсә, ие, барыштырам.

—Йомышым шул иде, Шәләй, Дамирлар йортында ни күрсәң, ни ишетсәң, чәчми-түкми миңа сөйләрсең. Шылдымы?

—Шылды, ие.

Тиледән шымчы ясауның түбәнлек икәнен Галим аңлый һәм үзенең икенче «мин»еннән бик уңайсызлана иде. Әмма, көнләшү берни белән хисаплашырга теләми, акылны тышаулый, ә ярсу хисләрне бәйдән ычкындыра иде.

Ул менә: «болар алга табан нинди мөгез чыгарыр икән?»—дип көткән гайбәтчеләргә жим каптырмас өчен (гәрчә хатасына сөрлексә дә) «уф» димичә генә көнне төнгә ялгый, ә теге йортта нишлиләр? Дамир белән Равия нишли? «Ничек яшисез?» дип төпченә алмыйсың, элеккеге дуслыкның әсәре дә юк, бүген авылда алардан да зәһәррәк дошман булмас. Шөкер, урамнар киң, ике көндәш кара-каршы очрашса, караңгы чырайларын көлмәк якасына яшергәндәй итеп, исәнләшмичә генә узып китәләр, әгәр тар басмада булса, тәкәббер тәкәләр кебек бер-берсенә юл бирмәсләр: көн дә мөгез сындырырлар, көн дә суга мәтәлерләр иде.

Шәләй ике көнлек күзәтүенең нәтиҗәсен бөртегенә кадәр Галимнең итәгенә бушатты:

—Ишегалдында утыз бер тавык бодай чүпли, яннарында бер әтәч... Койрыгы йолкынган, гүпчим кыска, тамагына салкын тидергән, карлыккан тавышлы. Ике сыер савалар ике чиләккә... Сарыклары унау... Өчесе мөгезле, жидесе мөгезсез... Мәчеләре аклы-каралы, эт белән уртак савыттан ашый, ие. Үрдәкләре су эчкәч авызын югары күтәрә, су тыгыладыр бугазларына, ие. Тәрәзәләре дә, ишекләре дә ярыксыз ахры, сүз чыкмый өйләреннән. Дамиры бакча казый, Сәрия апалар кырыенда ук, ие. Аңа Равиясе: «Әй син, ашарга кер» дип акырды баскыч төбеннән генә. Дамир кергәч көрәген чәлдердем, баз казырга кирәк ул яхшы көрәк... Минеке искерде, катырак төртсәң—сына...

Галим «чүп-чар» эченнән бер генә җөмләне игътибарга лаек дип санады: «Әй син, ашарга кер!» Дамир да түгел, жаным да түгел, «әй син» икән алайса.

—Ишегалдында йөргәндә Равиясе гел бер жыру жырлый, ие.

—Нинди жыр? Күңелләме, сагышлымы?

—Әй лә, жыру төсле жыру инде.

—Иртәгә отып кайт шуны, Шәләй, отмасаң—колагыңны борам!

Шәләй отып кайтты.

—Һаваларда ике аккош,
Берсе бәйле, берсе буш,
Төшемдә күрсәм—күңелем хуш,
Уянып китсәм—куеным буш,—

дип, кулларын чәбәкли-чәбәкли такмаклап күрсәтте ул.

Чыпчык чыркылдаса да кушылып көлгән шаян Равиянең моңлануы сәер иде. Хәер, нигә «сәер»? Өзелеп яраткан Галимен читкә тибәреп, жиде ятның салкын кочагына чумды бит, шуңа йөрәген сагыш телгәлидер. Жырдагы кебек бер-берсен төшләрендә генә күрергә калды хәзер. Юк, Галим Равиянең хәсрәтләнүенә сөенми, чөнки үзе дә бәхетсез: жаны тартмаган хатын белән түшәк бүлешә, сүз бүлешә, ризык бүлешә... Ары табан болай жан кыйнап яшәүләре шактый арытыр, әллә соң балалар тәгәрәткәнче гайбәтенә дә, туган-тумача үгетләвенә дә карамыйча аеры-

лырга микән? Әйе, әйе, мондый уй вакыт-вакыт ми тәрәзәсенә чиерткәли иде, ләкин озакка түгел. Алар нәселендә бергә берегәләр, бергә табыналар. Аннан чәчәк аткан уй бөре килеш үк коелды да: Нечкәбил чирләде. Чире шул иде: күнеле болгана, ни генә капса да абзар артына чыгып коса, акылдан язган сыман: «ашамасам үләм»,—дип, эссе җәй уртасында тозлы кыяр таптыра.

Галим аптырабрак: «Синдә нинди чир соң ул?»—дигән иде, яшь хатын әче алма кебек түгәрәк яшел бәбәгеннән чаткылар чәчрәтеп:

—Аңгырага сабышма, минем буемда бар!—диде.

Ун көн бер түбә астында яшәү дәверендә йөрәкне җылыткан беренче шатлыклы хәбәр иде бу, яшь әти салынган җилкә-канатын төзәтеп, иелгән башын югарырак күтәреп йөри башлады. Шушы кыска гына вакыт эчендә балага узган (вәт заманасы!) сөйкемсез Гөлнурга яратмаса да, туачак сабые хакына кадер-хөрмәт күрсәтергә тиеш иде ул. Чистай базарыннан мичкәсе белән кыяр кайтартылды, былтыргы уныш (янасы түтәлдә яралып кына ята) булып, эче куышланса да, Гөлнур, иртә-кич, кетер-кетер шуны кимерде.

Әмма бала Галимнең чуалган-буталган дөньясын тәртипкә салып, җанында тынычлык урнаштырмады, сөенечле хәбәрләр баштанаяк күмсә дә ул Равиясен оныта алмый, Равия—төзәлмәс яра, сызлап-әрнеп, «син бәхетсез» дип искәртеп, йөрәк түрендә тора бирә иде.

Икенче очта Дамир тормыш ямен җуйды. Ун көн элек кенә, дуамаллык белән кылынган ялгыш, дөньясын утын пүләне кебек ваклап-тураклап ыргытты. Аның йортында күгәрчен төсле гөрелдәп җан сөйгәне Гөлнур йөрергә тиеш иде. Шуның нечкә билләреннән кочып, татлы иреннәреннән үбеп бер юрган астында назланышып ятар төннәрендә гөберле бака сыман салкын тәнле мөрәүвәтсез хатынга орын имеш. Һай, Гыйльман абзый әйтте аны, әйтте, үз күленә чуммаган үрдәк ахырдан үкенә, диде. Хәзер үкенеп ни майтарасың: эш узган, аладан кола туган...

Үзенә күрә салкын тәнле гөберле генә димисең Равиясен дә, «мин авырга уздым» итенә, әллә юри үрти, әллә җәллләтә. Бала дигәч Дамир санады-исәпләде дә, бераз шикләнеп:

—Бигрәк тиз, диде.

—Нәрсә «тиз»?—Равия кияүгә чыкканнан бирле елак тавыш белән сөйләшә иде.

—Балага узуың дим, бигрәк тиз.

—Вәт сантый, беренче төндә үк нишләдек соң без синең белән? Курчак уены гына уйнамадык шикелле. Өнәмәсәң—алдырырмын...

Дамир балалар ярата, бала аның өчен изге җан иде, Равиягә җикеренеп:

—Алдырып кына кара, мин сиңа әйтим!—диде.

—Йә, йә, гайрәтләнмә!—диде хатын.—Минем кысыр булуымны теләгәнсеңдер әле бәлки.

Монысына ир җавап бирмәде. Әйе, кайчакта: «Равия бала тапмаса, безгә бергә яшәп интегәсе дә түгел»,—дигән яшерен уй җанга сыдырылып үтә иде. Инде хәлләр үзгәрү ягында: өйдә сабый авазы, сабый көлүе яңгырар... Их, Гөлнурдан таптырырга тиеш иде бит ул зәңгәр күзле наяннарны, Гөлнурдан! Уртак куаныч, уртак бәхет иттереп.

Бала белән йомшартып Равиянең ир дигән кемсәне кеше арасына алып чыгасы килә иде. «Тату яшиләр икән, култыклашып кына кунактан кунакка йөриләр икән»,—дигән сүз ирештереп Гөлнурның йөрәген яндырырга кирәк иде ана.

—Өй тавыкларына әвереләдек без, синең дә ял, минем дә ял, үзәккә—апаларга кунакка барыйк, әзрәк кәефләнербез,—диде хатын.

—Үзең генә кәефлән,—диде ир.—Минем эшем күп.

Эше юк иде, билгеле, Равия белән янәшә атлап йөрмәс өчен бер сылтау гына иде бу. Ул ничарадан бичара печәнлек җирен казырга кереште. Монарчы беренче покосны чапкач, икенчесен көтә, аннары

трактор белән сөрдерә иде, ә хәзер үзе «сөрә».

Өйгә кереп тамак ялгаган арада, син күр дә, мин күр, көрәк «аякланды». Аны кем урлаганы көн кебек ачык иде, Сәрия апаның туганы Шәләй ничә көннән бирле, чебеш күзләгән тилгән кебек алар тирәсендә бөтерелә, беркем түгел, Дамирның тимер саплы көрәген шул «сакаллы сабый» гына җыештырган.

Сәрия апаның мунчасы артына качкан тилегә:

—Шәләй, бире кил әле,—диде Дамир.—Мин сине ачуланмыйм, кил, малай. Көрәгемне күрмәдеңме?

Беркатлы Шәләй, күзләрен ялтыратып:

—Күрдем, ул безнең абзарда, нуешкә сөялгән,—диде.

—Кара син, ә! Аякланган икән алайса. Бик каты эшләткәнгә үпкәләгәндер инде.

—Хи, дивана мәллә син! Көрәкнең аягы юк ла. Минем җилкәдә кайтты, шуны да белмисең, үзең укытучы тагы, түлке син аны урлама, ул минеке-е!

—Урламам, миндә запас көрәкләр бар, Шәләй брат. Якынрак кил әле син, кил. Утыр балчык түмгәгенә. Менә шулай. Син рәис Галимнәр күршесе бит инде, күрше күршегә керештерәдер. Ничек соң анда, Гөлнур дим, яшь килен, боекмыймы?

—Боекмый, жу-ук, боекмый, ишегалдында йөргәндә гел тозлы кыяр ашый.

—Нишләп?

Шәләй аңа сөзеп карады:

—Хи, син вапще дивана икән, шуны да белмисең. Эчендәге бәбие сорый!

Дамирның йөрәге дерелдәде. Аның Гөлнуры—Нечкәбиле чит ирдән бала табарга җыенамы?! Йа Хода, кемнәр каргышы төште бәхетсез башларга! «Аның Гөлнуры» диме? Нинди аныкы, Гөлнур уникe көн элек Галимнең никахлы хатыны булды, хәләл иреннән таба ул бала, ач күзеңне, уян йокыннан Дамир!

—Да-а, Шәләй, пешердек без ботканы.

—Хи, Сәрия апа да тары боткасы пешергән ие, кәҗә сөте белән. Сез нәстәнекен пешердегез?

—Сина андыйны ашарга язмаган, Шәләй, бәхетле кеше син.

... Авылда һәркем бер юлдан йөри, чөнки кибете дә, мәктәбе дә, конторасы да уртак, Равия белән Гөлнурның да сукмаклары кисеште. Кыска ялдан соң икесе дә эшкә чыккан иде, Гөлнур әбәткә кибетен бикләп, мудпунктка керде.

—Укол-мазар кадатасың мәллә?—дип кызыксынган хатыннарга ул алгы бүлмәдәге Равия ишетсен дип, юри кычкырып сөйләде:

—Бәби көтәбез, Галимем үзәккә—консультация бүлегенә куа. Күренеп, учетка басып кайт, ди. Синең исәнлегең мина алтын тауларыннан да кыйммәтрәк, ди. Үзенә охшаган малай апкайтам дигәч, нәрсә ашатырга, нәрсә киендерергә белми әтиебез. Менә врачка юлламага керүем иде.

—Бар, бар, без сине чиратсыз уздырабыз,—диеште хатыннар.

Ә Равия ана сикереп торып юллама язарга ашыкмады. Ул озак кына бер карчыкның кан басымын үлчәде, пульсын санады һәм үз чиратында арткы бүлмәдәгеләр тыңласын өчен «тел тегермәнен дә әйләндерде».

—Дамирымның һич эшкә җибәрәсе килми, ял ит, ди. Эшең авыр, өсте-өсте авыруларың, ди. Мәйтәм, балага узу ул бит әле чир түгел, бәхет кенә. Декрет акчасы да ярап куяр гаиләдә, мәйтәм.

Авыл халкына дүртәүнең туй алдыннан гына яр буташтыруы һаман да ачылмаган сер иде, карчык-корчык ике яшь хатынның мактануыннан шушы сернең очын эләктерергә тырышып, яулыгын чиште, колагын тырпайтты, әмма берни дә аңламады.

Юлламага Хәкимова дип язганда Равиянең кулы калтырады. Ул Хәкимова булырга тиеш иде, ул!

Юллама астындагы Еникеева дигән имзаны күргәч, Гөлнурның үт куыгы сытылды. Гөлнур йөртергә тиеш бит бу фамилияне, Гөлнур! Карак, өстерәлчек, икейөзле!

Равия битенә «ыштыр япкан» Гөлнурны һич көтмәгән иде, «даруга ашыгам» дип, халыкны медпункттан этә-төртә чыгарып җибәрде дә, янында дулаган давылында үзе үк кайнап-бөтерелеп өенә чапты һәм чүмеч белән чумырып су эчкәч, юлга чыгып басты. Дамирга: «Әйдә, илтеп куй» дип ялынмады, гараждагы төсе унган иске «Жигули» ярты сәгатьborгаласаң кабына иде бугай, ә хатын ул арада узгынчы машина белән барып та җитәчәк иде.

Гөлнур да юлламасын кесәсенә тыгып китеп бара иде, авыл башында ире очрады.

—Кая юл тоттың?—диде ул хатынына, коры гына.

—Бүлнискә, врачка күренергә.

—Әйдә, илтәм.

—Муеныннан хуҗалык эшенә баттым дисең ич.

—Батсам—калкырмын. Хәзер безнең үзәктә киношмә башлана, кайтканда көтмә, автобуска бар.

Үзәк юлында ялгыз умырзая кебек, җил иркендә чайкалып, Равия басып тора иде, Гөлнур учы белән иренең руль тоткан кулына басты:

—Туктый күрмә, выжылдап узып кит! Кеше хатыннарын төяп йөрергә син колхоз арбасы түгел!

Галим аның кулын читкә селтәп атып, нәкъ Равия кырыена килеп туктады.

—Утыр, Равия...

Алгы утыргычка җәелгән Гөлнур турсаеп, тәрәзәгә табан борылды. Өчесенең дә чырае караңгы, өчесе дә авыр сулый иде. Әзрәк баргач, Галим көзгедән Равиягә карады: хатынның күзеннән бик-бик тырышып та яшерә алмаган газап һәм әрнү түгелә иде.

Өйдә Равия:

—Нәчәлник хатыннары машинада гына җилдерә, ә мин корсаклы килеш җәяүгә калдым,—дип, күз яше белән елады.

Дамирның «мин-минлеге»нә тиде бу. Гараждан машинасын сөйрәп чыгарып атна буе казынды. Машина ачкычын бору белән үк кабынырга «гадәтләнде». Гинеколог-акушер икенче тапкыр билгеләгән тикшеренүгә Равия дә, күкрәк киереп, машинада юырта иде. Йа Хода, алдан сөйләшеп куйган төсле тукталыштагы утыргычка билен кин каеш белән буган Нечкәбил «кунаклаган» иде.

—Машиналар чебен урынына оча, берәрсе утыртыр әле, туктама!—дип боерды Равия.

—Тс-с, әкрен!—диде Дамир, әйтерсең хатынының яшелле-күкле тавышыннан куркып Нечкәбил очып китәчәк иде. Ир әкрен генә тормозга басты.

—Рәхмәт, зур рәхмәт,—дия-дия, Гөлнур утыргычка сеңде. Ир җилкәсе белән тойды: арттан җылы дулкын бәреләә... Нечкәбил дулкынланудан еш-еш тын ала, ә сулышы кайнар, шундый кайнар... Их, аккан суларны кирегә борып булса икән!

## 4

Борынны яз исе кытыклаган көннәрнең берсендә Гөлнур кибән хәтле корсагын уа-уа:

—Башлана-а,—диде.—Мин бәбилим, тизрәк машинаңны кабызып, безне бүлнискә илт!

«Хатын-кыз бит, рәтен-чиратын беләдер» дип бәхәсләшмәде Галим, хатынын иплән кенә машинага чыгарып утыртты. Әмма ул да әз-мәз «рәтен-чиратын» белә иде. Баш төймәләрен чалт-чолт китереп санады: фәлән айда, фәлән көндә өйләнештеләр һәм шул ук төндә: ир белән хатын арасында

була торган эшне «эшләделәр». Аннан бирле сигез генә ай узган, чү...

—Ялган тулгак синдә,—диде ул, бик белдекле кыяфәт ясап.—Ник өтәләнәсеңдер. Берәр айлап бүлнис караватында аунарсың инде.

—Хәзерге космик заман балалары пырдымсыз, жиде айдан да, сигез айдан да сикереп төшәләр. «Ашыкма, иртәрәк»,—дип кире этәлмисен. Бүген котылам. Алла кушса. У-у, эчем ярыла-а, ку тизрәк, ку!

Хастаханә бусагасын атлау белән дежур табиб Гөлнурны бала тудыру бүлмәсенә озатты. «Космик заман баласы» ике-өч сәгатьтән генә туа икән, Галим, көтәргә озак икән дип, авылга кайтып китте. Өйгә кермәде, уң аягын эскәмиягә терәп, кулы белән тезенә таянды. Яппашмалай, ул да әти булырмы! Кичләрен аның каршысына да кара бөдрә чәчле сыбызгы-малай йөгерер микән, ә?

Төбенә генә сөт тамызган пыяла савыт күтәреп Шәләй кайтып килә иде. Күршеләрнең сыеры ташлаткан, хуҗалары түземсезлек белән артым көтә иде.

—Мин сиңа ничә тапкыр әйттем, Шәләй, әнкәң бездән алсын сөт, Гөлнур ике сыер сава, ә син кашыклап апаңнан кәҗә сөте ташыйсың,—дип шелтәләде Галим.

Тиле борынын мыш-мыш тартып:

—Банкам тум-тулы ие, егылдым мин. Дамирның күзе акайган, машинасы белән өстемә менә язды.

—Кая ашыга шулай?

—Бәбәй апкайтырга бүлнискә, ие. Катынының корсагы кабак төсле, зуп-зур.

«Җепкә тезелгән торналар шикелле икән без»,—диде Галим моңсу гына көлемсерәп.—Беребез артыннан икенчебез...

Ул алда тагын ниләр күрәсен чама белән дә чамаламый иде әле...

Дамирның да алдагы көннәре куе томан белән өретелгән иде. Хатынын табиблар кулына тапшыргач, нәтиҗәсен көтәргәме юкмы дип, аптырап, ишек төбендә таптанганда ияген май баскан җирән маржа бәләкәй тәрәзәчектән башын тыгып:

—Хәкимов кайда? Сезме Хәкимов?—диде.

—Мин Еникеев, хәзер генә, хатынны салдым, кайчангарак бәбиләр икән?—дип, тәрәзәгә капланды ир.

—Иртәләгәнсез әле, мужичок, өч-дүрт көнсез бәбиләмәс, ятсын әле хәл җыеп, без аны кире җибәрмибез. Хәкимов күренсә әйтегез, аның малае туды, авырлыгы өч кило ярым...—Маржа «сөенче таягы»н Дамирга тоттырды да, шартлатып капкачын япты.

Авыр бурыч йөкләделәр аңа, кемнән кемнән, ә Галимнән сөенче алырга атлыгып тормый иде Дамир. Бу минутларда малай белән аны түгел, Дамирны куандырырга тиеш иде Нечкәбил! Их тормыш арбасы, утынга ватып, мичкә генә ягасы...

Хастаханә ишеген тутырып ачып, Галим килеп кергәч, ул аңа каршы атлады. Ике ир, карашларын читкәрәк яшереп, кул бирештеләр.

—Синдә дә үрчем мәшәкате ахры,—диде Галим бая гына маржа шапылдатып япкан тәрәзәчеккә ымлап.

—Әйе, китергән идем дә... Җегет өч-дүрт көнгә отгул сораган,—дип шаяртты Дамир.—Синеке әзер, малаең бар, котлыйм!

Галим сөенчене ирләргә генә хас сабырлык белән кабул итте.

—Рәхмәт,—диде,—авыл бер кешегә артты.

Дамир:

—Малаенны юарбыз, шәт,—дигәч, нигәдер ул бу тәкъдимне хупламады. Коры гына:

—Өйләнгәннән бирле эчкән юк... Ташлаган идем. Грузин чәе белән тамак чайкатсак кына. Әйдә, чаттагы кафега.

Кереп утырдылар. Ләкин айлар буе җыйналган ачу-үпкә ташка әверелгән, ә ташны җинел генә урыныннан кымшатырлык түгел, әлегә җөмләләр өтек-төтек, елмаюлар саран иде.

Дамир стаканга балкашыгын шыкы-шыкы бәреп салкын чәен болгатты.

—Малаена нинди исем кушасың?

—Исем? Уйламадым әле. Хатын тапкандыр бәлки... Мин кыз диебрәк өметләнгән идем.

«Кыз туса, әллә Равия дип куштырмакчы идеңме?»—дип сорамакчы иде Дамир, чү инде, диде аннары, хатын-кыз кебек вакчылланма, син ир-ат бәндәсе ласа.

Алай да кафедагы салкын чәй авыр ташны әз генә кырыйгарак шудырды төсле. Хәзер аларга үпкә күпертеп дошманлашып йөрү—соңгы чиктәге җүләрлек иде инде. Моны икесе дә (хатыннарның үз эше) аңлады. Ятка калган ярларым яз булмаса көз әйләнеп кайтыр дип хыялланып яшәүнең дә мәгънәсе юк: ир белән хатынны бер-берсенә ныгытып бәйләргә дип, аргы очка да, бирге очка да бала кайта иде...

Равия дә көндәшеннән дүрт көнә көнгә соңарып малай тапты.

Галим юрганга төргән бәләкәч улы белән хатынын хастаханәдән алып чыга, ә Дамир коридорда—малай туу шатлыгыннан балкып ары-бире йөренә иде, ирләр, дустанә елмаеп, икенче мәртәбә кул кысыштылар.

—Котлыйм, бу юлысы грузин чәе синнән,—диде Галим.

Дамир «ыһы» диде, чөнки җөмлә төзеп сүз әйтергә вакыт юк, ул бал корты сыман Гөлнурга кадалган, гүя иреннәре чәчәк тажыннан сөю-ләззәт шәрабе эчә иде.

Галим аяк өсте оеган хатынына дорфа гына терсәк очы белән төртте:

—Җәтрәк атла, бала уянып, имәргә сорар.

Юлда Гөлнур:

—Дуслашкансыз ахры,—диде.

—Безнең дошманлык юрый-марый гына иде.

—Шулаймыни?—Хатынның йөзенә үтенне сытарлык әче елмаю таралды.—Ә мин тагы...

—Ирләр арасына кысылма, яме? Без үзебез җайларбыз. Малайга исем уйладыңмы?

—Уйладым.

—Ничек кушабыз?

—Әйтермен, арттан кумыйлар,—диде Гөлнур ризасыз тавыш белән.

—Ир балага исемне ата кеше эзлидер бит.

—Башың күккә тимәде әле малай бүләк иткәнгә... Исемне дә үземә уйларга инде болай булса.

—Баш тимәде дип... Шәләй сымак иһаһай-миһаһай килеп сикерергәме синеңчә.

—Малай тәпиен кем грузин чәе белән юа, адәм хуры!

Менә нигә тыртая икән бу хатын.

—Малай туды дип бөтен авылны аракыга коендырырга иде мәллә?—диде Дамир.

Шулай үзара әз-мәз үпкәләшеп, әз-мәз чеметкәләшеп гомер юлыннан атлый-атлый бәлки, аларның туктаусыз болганган тормыш күле йокымсырап, тынычланып калыр иде, әмма, шайтан алгыры, чуерташ кисәкләре сибелеп, күл гел дулкынланып торды шул.

Бәбидән соң агарган чырае алсуланган, көч-дәрт туплаган Гөлнур:

—Мулла абзыйны чакыртып, балага исем куштырыйк,—диде.

Көн-төн «мес-мес» йоклаган, ашыйсы килсә генә уянып шома кәмәшләрен ялтыратып акырган тешсез «төенчек»кә Галим өч-дүрт исем барлап куйган, тик шуларның кайсысы кулайрак икәнен генә ачыклап бетермәгән иде.

—Йә, улым, сиңа кайсы исем ошый, күңелеңә хуш килгәненә елмаерсың,—дип, бер кичне әти кеше бишеккә иелде.—Азамат, Самат, Сөнгат...

Гөлнур янәшәдә генә иде:

—Тукта!—дип бәләкәй йодрыгы белән иренең авызын томалады.—Баланы саташтырма, аның исеме бар! Дамир атлы ул!

—Ә? Нәрсә?!—Галим табанына чөй каккандай катып калды.

—Бүлнистә врач малайны беләгемә салу белән мин аңа Дамир дип эндәштем...

—Алай икән,—диде ир, ниһаять, иренен кыймылдатып.

Хатын кызган түмәрдә һаман үзенең тел-кылычын чүки иде.

—Син мине яраткан кешемнән аертып, бәхетсез иттен. Кибеттә үзең ялындың ич өйләнешик, дип. Инде аның исеменнән дә көнләшмә, истәлек дип кенә куштырам бит. Дамир тек Дамир, үлсәм дә үзгәрттермим, тавыш кына куптар, улымны кыстырам да, әниләргә таям. Перси башы белән хатынын җәберли дисеннәр авылда, сине чәйнәсеннәр.

Әйе, әйе, йодрык белән бу хатынын җинәм дисә, Галим ялгышыр иде. Җайлап-майлап карасаң да тәгәрмәч шыгырдар: сигез-тугыз ай эчендә табигате белән киребеткән һәм үзсүзле Гөлнур ирнең канын шактый гына сыегайткан иде инде.

Дан-доң ишек дөбердәтteләр. Чокырлы юлдан тимер арба тарткан кебек Шәләй генә тавышланып йөри иде:

—Бар, каршы чык, кычкырып нине... Дамирны уятмасын,—диде Гөлнур... Ул Галим күтәрелеп бәрелмәгәч бәхәсне үз файдасына хәл ителгән дип саный, шуңа күрә аның күңеле йомшарган, өнәмәсә дә чакырылмаган кунакка каты бәрелми иде.

—Тавышка күнексен, хан малае түгел,—диде Галим—Әйдә күрше, уз.

Өс-башыннан тирес исе аңкыган Шәләй, урта бүлмә бусагасына чүмәште.

—Бездә бәби бар,—дип төче генә елмайды Гөлнур.

Тиле, каз сыман, муенын бишеккә табан суза-суза:

—Нәстә ашый сон ул?—диде.

—Безнен Дамирыбыз сөт эчә.

—Һе, ике сыерыгызның сөтен дәме? Мин дә сездән сөт сорамакчыием, Дамирыгыздан артмастыр итуса.

—Борчылма, Шәләй, малайның сөт чишмәсе әнкәсендә,—дип, хатыны тулышып кабарган имиләрен сыпырды.—Ә синең өлеш чоланда. Бар, Галим, чиләге белән муенына ас.

Баягы күңелсез сөйләшүдән ирнең йөрәге чәнчи башлаган иде, ул сүзсез генә кузгалды. Бәхәсләшүнең ни файдасы: барыбер очы-кырые күренмәячәк. Ул бит чәергә кунган саескан кебек кызганыч һәм көлкеле хәлдә: томшыгын тартып алса, койрыгы, койрыгын тартып алса, томшыгы ябыша...

Үзен «Ир затыннан чутламаска сине, чүпрәк»,—дип сүкте ул сүгүен, ләкин моңа шунда ук каршы да төште: «мин—ир» дип, гайрәтләнеп, гаилә тагарагын бәреп ватаргамы инде хәзер. Әнә Дамир, шым гына яшәп ята, югыйсә Равия дә фәрештә түгел, аңарда да Гөлнурдагы тискәрелек, үҗәтлек бар. Аларда сыер дулап та, тәртә сындырмыйлар, ә нишләп Галимнәрдәге чыра төтене корым булып, капканы буярга тиеш? Сынатмаска иде.

Кыскасы, баланың яңа исеме бугазны тырнаса да, сусыз гына йотарга иде, йотарга...

... Дамирлар йортында да балага исем кушу мәсьәләсе шартлап өлгергән иде. Бәбидән аруланган Равия, «исемне үзем табам» дип, катгый кисәтмәгән, ире: «малайны ничек атарбыз икән?» дигәч тә: «үзең кара» белән генә чикләнгән иде. Бөтен эшне Шәләй бозып ташлады. Юк, Дамирның тиктормас теле бозды.

«Җегетебезне күрергә туган-тумача агылыр» дип, ир капка төбе себерә, ә Шәләй Сәрия апаларына килеп бара иде.

—Син кәжә сөтеннән бизден ахры, брат, апаннарда сирәк кунаклыйсың,—дип, сүз юктан сүз ясап кына әйткән иде, көр тавышлы тиле урам ярып:

—Миңа Галимнәр сөт эчертә, аларның Дамир бәбиләре әнкәсен имә!—диде.

—Нинди «Дамир бәби» ул?—дип, сагайды ир.

—Аларның кечтеки малайлары Дамир атлы, һи, белмисең дә икән,

үзең дәү генә Дамир,—дип хихылдады Шәләй.

Ишегелдында бала чүпрәкләре элгән Равия ишеткән икән, без кебек Дамирга кадалды:

—Нәрсә ыржаясың?! Шатлыктан эчең җырлыймы? Кәнтәең баласына исемеңне куштырган икән. Хуп, хуп, анда Дамир, бездә Галим үсәр!

Дамир өтер кыстырырга өлгермәде, хатын чатнатып нокта куйды:

—Галим безнең малай, колагыңа киртлә, Галим!

... Аргы очта да, бирге очта да шартына туры китереп бер сабыйга Дамир, икенчесенә Галим дип исем куштырдылар. Инде ике якка да тыныч кына бәби үстерәсе иде, тик...

Беркөнне Дәү Галим «ыгы-ыгы» дип «сөйләшеп» яткан ике айлык улына карап торды-торды да, кинәт кенә ачыш ясагандай:

—Безнең бала минеке түгел,—диде.

«Нечкәбил» токмач кисә иде, пычагын күкрәгенә терәп:

—Абау, ничек була инде ул?! Үзе безнеке, үзе синеке түгел...—диде.

—Ни миңа, ни әтигә, ни бабайга охшамаган. Гомумән, Хәкимовлар нәселендә аксыл чырайлы адәмнәр юк! Сезнекеләр дә кара тутлы!

—Җүләр, бишектәге бала бишкә төрләнә,—дип көлде хатыны, ләкин ир аның ерык авызына тиз йозак «элде»:

—Тач Дамир күчермәсе бу! Еникеевлар нәселе! Зәңгәр күз, почык борын, салам төсендәге чәч!—дип үкерде ул.—Мин дөм сукыр икән, монарчы баланы җентекләп тикшермәдем! Димәк син...—Галим үтәли тишәрдәй булып Гөлнурга карады.—Син... миңа кияүгә чыкканчы ук корсак кабарткансың? Малай бер дә сигез айдан түгел, тугыз айдан туган! «Космик заман баласы» дип, шыттыруың кара моның!

—Мин белмәдем, белмәдем! Синеке дип уйладым тудырганда... Гаеп үзеңдә, син ашыктырдың, Равия белән Дамир язылыша икән, әйдә, без дә өйләнешик, диден бит инде, Ходаем, хәтерлә әле шул сүзләреңне,—дип такмаклый-такмаклый еларга кереште хатын. Кайчандыр өстенлеген сиздереп өйне дер селкеткән аждаһа кереп качарга ярык эзләүче мескен кәлтәгә әйләнде.

Галим йодрыгы белән шап-шоп маңгаен «кыйнады»:

—Нинди хурлык! Миндә кеше баласы! Гайбәтчеләр үлгәнче күзенне ачырмаячак бит! Җиттесәнә сиңа, елама!

—Ә без аны беркемгә дә күрсәтмибез.—Гөлнур яшен сөрткән юеш бармаклары белән иренең кара бөдрә чәчләрен аралады. Хәзер үк ике арада килешү төземәсәң эш харап иде.—Күз тидерәсез дип, бишекнең чыбылдыгын да ачтырмыйбыз лабаса.

—Сарык, бишектән төшкәч нишләтәбез? Урамга да чыгармыйча карават астында асрыйбызмы?

Юашланган хатын:

—Ансы да бар шул,—диде.

Иренең күзендә нәрсәгәдер тәвәккәлләү чагылды кебек. Гөлнур күңеленнән генә Ходайга ялварды: «Аерылышабыз димәсен, андый уй башына керсә, сызып ташла, И Ходайгынам, жәллә мин бичараны, ятим иттермә улымны, сөендермә Равияне!»

Аерылу турында Галим сүз дә кузгатмады, ләкин шул ачыштан соң бөтенләй үз эченә йомылды, иртә китте, ярты төндә кайтып ауды, чәчү, басу-кыр «ардым»га сылтау гына, аның бавырын хәсрәт талкый, хәсрәт күңел капкаларын ябып-бикләп тота иде. Селтәнә-селтәнә дә башка гөрс итеп уй суга: «Дамирның ике малай ызначит... Миндә дә, үзендә дә». Типте, типте дә бу дус, эчәкләрне актарды. Галимнәр йортындагы фаҗигане ишетсә, почык борынын тагын да югарырак чөяр, сары төлке! Өйдә кабарган чүпрә кайчандыр бер авылга җәелер бит...

Ә Гөлнур, юаш кәлтә, төннәр буе иренә сырпаланып, яшь түкте.

—Зинһар, аерылышмыйк, Галим. Мин сине ярата башладым, Дәү Дамир уемда да юк, үкенмим дә сиңа чыкканыма. Зинһар, оланны какма, синең оядагы кош баласы инде ул, җаным...

Ир хатынын ни юата, ни тирги алмый, аның эче-тышы таш иде. Нәселдә чит кан, ят ис... Мондый бәхетсезлекне иң явыз дошманыңа да язма, Ходай. Әнә аргы очтагылар тыныч йоклыйлар, алар кайгыдан бетәшми, чөнки Дамирның оясына күке йомырка салмаган.

... Аргы очтагыларның да моржасыннан кара төтен ургылырга маташа иде. Хастаханәдән алып кайткан мәлдә малай кызгылт чырайлы һәм жыерчыклы иде, ул авызын чәпелдәтеп әнисенең күкрәген суыра да йоклый, төннәрен дә бимазалап жәфаламый иде, шуңа күрә «тәрбия» эшенә Дамир катнашмый, биләүсәгә уралган нарасыена сирәк кенә күз төшергәләп алу белән генә чикләнә иде. Менә балага ике ай тулды, малай исәйде, дөньяда барлыгын белгертеп, игътибар сорап аваз салды, кычкырды һәм читтә генә йөргән әти кешенең вазифалары артты: Равия сыер сауганда әти бишек тирбәтә, «жегет» астын юешләтсә—коры чүпрәк жәя, еласа—имезлек каптыра.

Шулай улы белән якыннан аралаша башлагач, Дамирның күңеленә бер шик оялады: кече Галим аңа охшамаган... Әнкәсенә тарткан дияр идең, әнкәсе дә түгел. Малай нәселдә күрмәгәнне кара бөдрә чәчле, калын иренле, кыска аяклы. Әйтерсең могжиза белән кечерәеп бишеккә Дәү Галим кереп яткан.

Башта ул шиген хатынына сиздермәде. Соңгы арада баш очындагы гауга болыты таралган һәм аны яңадан жыеп-куертып боз яудыртасы килми, тавыш артык туйдырган иде. Ләкин шик малай белән бергә көннән-көн үсте, жанга сыймас булды.

—Равия, синең күзләрең әйбәт күрәме?—диде ул бер кичне.

—Күрә,—диде хатыны, бернәрсә дә аңламыйча.

—Ул чакта яхшылап бак та, әйт: бишектә кем ята?

—Әллә син чөмерденме, Дамир? Күзләрең тоныкланган.

—Чөмермәдем. Син бөгештермичә генә сорауга жавап бир. Бишектә, дим, кем ята?

—Безнең улыбыз, Дамир. Дамир Еникеев. Йә, шуннан?

—Ялганлыйсың! Бишектә Галим Галимович Хәкимов ята! Менә хәзер чөмерсән дә ярый...

Равия ишеккә ыргылган ирнең юлына аркылы басты:

—Дамир жаным, миңа сук, мине кыйна, тик эчеп-нитеп урамда гына шаулама. Баланың ни гаебе... Өйләнешкәндә мин корсаклы икәнемне белмәдем... Үзем дә оланга карап көн-төн ут йотам...

Ир, яртылаш бөкрәеп, идәнгә чүгәләде.

—Вәт, перси тәре, икегезгә дә бала ясаган. Берегезгә өйләнгәнче, берегезгә өйләнгәч. Нинди житез, нинди өлгер!

—Аралар буталмаса һәркем пары белән яшәр иде,—дип, борын мышкылдаткан хатын да хаклы иде. Бер мәгънәсезгә бозылыштылар. Баш чүмечен куптарып миен кырсан—дүртесендә дүрт мыскал акыл тапмаслар иде.

Яфрак төсле калтыранып ире каршысына тезләнде Равия.

—Син безне ташларга ниятләмисеңдер ич? Кеше әле ятимнәр йортыннан алып та бага.

Ир кыргый тавыш белән кычкырырга тотынды:

—Ул кешегә берсе дә бармак төртеп күрсәтми, әнә фәләннең баласын үстерә дип! Ә миңа төртәчәкләр! Галим малаеның әтисе Дамир дип көләчәкләр!

—Бәлки безгә авылдан китәргәдер, Дамир?

—Киткән ди! Үз иркем белән туган жиремнән сөрелергә мин каһәрләнгән мәллә?! Жәгъфәр абзый пенсиядә, бүген-иртәгә мине мәктәп директоры итеп куячаклар. Әнә, Галимең белән икәү олагыгыз!

Равиянең чишмә-күзләре мөлдерәп ташыды:

—Нишләп мин аның белән олагыйм? Минем ирем—син, мин синнән аерылмыйм,—диде ул, шыңшып.

—Аптыраган-жөдәгән, артын мичкә терәгән дип, минем хакта әйткәннәр икән,—диде ир һәм аягына калыкты,—жилләнеп кайтам!

Машинасына утырып жилле генә чыгып китте ул. Башта кибеткә туктады, кеше юк иде, сатучы кызга:

—Акбаштан бер стакан тутырып сал әле, сеңел,—диде.

Кибетче «шифалы су» шешәсенең бөкесен бора башлагач:

—Градуслысын, сеңел, градуслысын,—диде.

—Дамир абый, сез аракы эчмисез ич!

—Ә син бытбылдама, укытучы абый эчте дип. Мин бүтән капмам, әүвәлгесе-актыккысы, сеңел.

... Бу вакытта Галим басуда иде. Рәис тигезле-тигезсез сөрелгән җиргә карап йөзен-кашын җыерды да тракторчыга җикерде.

—Төш әле, Сәйфетдин абзый! Ник син кырны бозасың, ә?

—Кан басымы чаптырып өскә менә дә, чаптырып аска төшә, энем, шуңа прамах бирәмдер,—дип акланган абзыйның бүлтәйгән түш кесәсеннән шешә тартып чыгарды Галим.

—Ә-ә, менә нигә кан басымың үрле-кырлы сикерә икән синең, Сәйфетдин абзый.

Беренче уй—шешәне трактор тәгәрмәченә бәреп вату иде. Кулын күтәргән дә иде инде рәис, икенче әрсез уй тоткарлады: «Эчең яна, эч тә бастыр»,—диде. Икеләнергә соң иде: бишектәге ак чырайлы, салам чәчле, зәңгәр күзле малай күз алдына килде. Авыл тарихында гомер булмаган хәл: ул Дамир малаеның әтисе...

Аракыны су гөлдерәткән кебек иттереп кенә бугазына койды. Рәиснең бу кыланышыннан куркып, тракторчы кабинасына шылды.

... Кибеттән дә шактый кызып чыктылар. Улының рәис атасы кичләрен басу-кыр иңләгәнен белә иде Дамир, машинасын шул якка куды.

Галим дә улының укытучы әтисен еракта ук шәйләде. Ике «Жигули» үкерешеп бер-берсенә каршы йөгерде: машиналарын маңгайга маңгай сөзештереп туктаткач, икесе дә сикереп төшеп, бер-берсенә ташланды.

—Тешләреңне коям, мукәли-мукәли чүпләрсең!—диде Галим һәм көндәшенең яңак төбенә кундырды.

Дамир мәтәлчек атып киткән җиреннән торып:

—Ә мин сине шартлатам,—дип, кушаяклап Галимнең эченә типте.

Озак сугышты алар кыр читендәге чирәмлектә. Яшел төсе белән күзләрне иркәләгән май үләннәре сытылып-тапталып туфрак белән укмашты, күлмәк ертылып, өс-баш пычракка буялды, йөз-бит тырналып буй-буй кызыл таплар белән «бизәлде».

Аннан кинәт икесе дә, атылган кош сыман чалкан ятып, хәрәкәтсез калды.

Беренче Дамир телгә килде:

—Барыбер проблема хәл ителмәде.

Ул зәңгәр күзләре белән һавада очкан зур кошны аулый иде, кош канатларын авыр җилпеп кичке караңгылыкны сеңдергән болытларга күмелде.

Галимнең дә кара күзләре кошны озаткан икән:

—Бөркет иде ахры,—диде.—Проблема хәл ителмәде дисеңме? Ул йодрык белән генә хәл ителсә, без синең белән көн дә тукмашыр идек. Син оятсыз икән, җегет. Ике якта ике бала әвәләдең дә, шатлыгыңнан мине тәпәлисең.

—Ничек ике бала, ничек?!

—Минем йодрыктан миең шулпаланды мәллә? Безнең бишектә дә синең улың тирбәлә. Салам чәчле, зәп-зәңгәр күзле,—диде Галим, авызын кыйшатып.

—Саташма, безнең бишектә ул синеке! Тач син! Бөдрә чәч, шомырт күз...

Дуртаякланган ирләр бер-берсенә карашып, телен йотты.

—Вәт сиңа мә!—дип, әүвәл Галим өн чыгарды.—Нишлибез хәзер?

«Нишләргә?» дигән сорау атналар буе пычак белән җанны телә, ә җавап юк та юк иде. Инде икәү уйларга тиеш алар. Икәү җиңелрәк, чөнки язмыш кусәк белән икесенә дә тиң ора.

—Равия бала белән сиңа, ә Гөлнур миңа кайтып утыра,—диде Дамир да айнып.

Галим бу тәкъдимне шунда ук сызып атты:

—Безнең нәселдә хатын аермыйлар, бер белән картаялар.

—Аптыраганнан суям кәҗәкәем,—диде Дамир.—Мин дә хатынны алыштырмас идем. Безнекеләр дә бер генә никахны олылый.

—Гөлнур-Нечкәбилне уйлап йөрәгең сызламыймы инде?

—Синең хатынны сагынып яшәүдән ни мәгънә. Син дә минекен юксынмыйсыңдыр, шәт?

—Янадан кузгатмыйк,—дип, йөзен чытты Галим.—Хатын-кыз кайгысымыни. Малайлар важныйрак. Карале, ант мәгәр диң, кече Дамир суеп каплаган минме?

—Бетереп син, Галим. Минеке дә шулаймы?

—Синеке дә бетереп.

Ирләр беркавем йөзләренә җәелгән татлы елмаюдан изрәп дәшмичә утырдылар.

—Малайны үзем үстерер идем,—диде Галим,—вчүтеки безнең нәсел жегете...

—Миндә дә аталык хисе уянды, брат. Чын этиләре йортында тәрбияләнергә тиеш безнең балалар. Киләчәктәге фаҗигане̇ң тамырын кисәр өчен. Дөрес, мин синекен үги итмәм, син дә минекен какмассың, әмма да ләкин жегетләр буй тарткач авыл: «уйнаштан туган» дип, кимсетер бит аларны. Мин, мәсәлән, мондый хурлыкны улыма теләмим.

—Тулысынча синең белән килешәм, Дамир. Безгә дә нәфрәтләнер малайлар, картайган көнеңдә хөрмәт тә итмәсләр. Йә, нишлибез?

Ике баш уйлады, киңәште дә, ахырдан бер карарга килеп һәм шул карардан канәгатьләнеп машинасын кабызды.

Ә аргы-бирге очтагы хатыннар җанына урын тапмады. Тормыш көзгесе чатный, нишләргә, ничек төзәтергә? Усаллык белән генә ир-атны җиңәрсең, ди. Әлегә аларга кырын карарга да ярамый, бу хәлләрне посып ятып кына уздырып җибәрсәң дә таман гына әле...

Шуңа күрә Равия кулмәк җиңе умырылган Дамирдан, теле бик кычытса да, «сугыштыңмы әллә?»,—дип сорамады, Гөлнур да иреңең тырналган йөзенә төртеп: «Кем кыйнады?» дияргә базмады.

Ирләрнең кәефе, ни гаҗәп, күтәренке иде.

—Галим белән без икебез дә законлы этиләр,—диде аш чөмергән Дамир.—Анарда минем малай...

Галим дә яңалыгын яшермәде:

—Без аңлаштык, мин Дамир малае кече Галимнең чын этисе икән.

Ике хатынның да башыннан: «Бәлки болай әйбәтрәктер, берсе дә нәүмиз түгел»,—дигән уй узды. Бәлки, моннан соң һәркем үз оясындагы кош баласына разый булып, тынычлап яшәр.

Әмма хатыннарга куанырга иртәрәк иде.

—Иртәгә төнге унбердә алтыбыз да аланга җыелабыз, баланы җылырак төр,—диде Дамир.

Шул ук кисәтү Галимнәрдә дә кабатланды.

Хатын-кыз яртылаш үлде. Шик тә юк, башта ирләр нык кына дөмбәсләшкән, аннары тынычланып серләшкәннәр. Ни-нәрсә турында?

Билгесез. Вакытыннан алда төпченсәң—эшне бозып куюың бар.

Төн житкәнен көтә-көтә Равия белән Гөлнурның күзе күгәрде. Серле сәфәр икесен дә уттан алып суга сала иде.

Унбер тулгандарак аргы очтан да, бирге очтан да машиналар кузгалып урман юлыннан үрмәләде.

Аланда ирләр фараларны сүндермәделәр. Тирә-як тып-тын, беркем берни күрми, берни ишетми, җилпәк имән башындагы карт ябалак кына «чет-чет» каурый чистарта, ләкин аның адәмнәрдә гаме юк иде.

—Кызлар, бала күтәреп беләкләрегез талыр,—тәгәрәшегез,—дип, Галим имән төбенә калын сырма җәйде.

«Кызлар» бер-берсенә яны белән борылып җәймә читенә утырды.

—Башла, Галим, син телгә остарак,—диде Дамир.

—Оста дип... Без театр уйнарга җыелмадык, иң мөһиме—килешү төзү монда, кһым...—Дулкынланудан Галимнең сүзе очлы сөяк төсле бугазына

калалды.—Kһым, kһым...

Шунда Гөлнур, паузадан файдаланып, жан ачысы белән:

—Сузмагыз инде, нинди уй-план кордыгыз, әллә безне имән ботагына асасызмы?—диде.

—Әйтмә дә! Кичә болар жир астыннан юл казыган ахрысы, серләрен белерлеген юк,—дип өстәде Равия.

—Ашыкмагыз, балалар, белерсез!

Сүзне Дамир ялгап китмәкче иде, Гөлнур-Нечкәбил:

—Сабак укытмыйсыңдыр ич, балалар дисең—дип ысылдады һәм Галимнең бугазындагы «сөяге»н төртеп төшерде. Кабынды, ярсыды Галим.

—Авызына үлән тутырам, бикәч! Һаман син чәрелдисең, һаман син түземсез! Без монда сез хатын-кызның ялгышын төзәтмәкче! Йә төзәтәбез, йә кече Дамир белән кече Галимне харап итәбез!

—Кыскасы, иптәшләр,—диде Дамир.—Сабыйлар тач аталары, ягъни безнең күчермә. Минеке Галимдә, аныкы миндә. Бердәнбер юаныч—авыл бу хикмәтләрне ишетмәде, Аллага шөкер диик. Халык арасында чыш-пышлар таралганчы без малайларны... алмаштырырга тиеш, вәт шул.

—Акылдан яздыгызмы әллә, Шәләй сынарлары!—дип чәрелдәде Гөлнур.—Ниткән ахмак сүз сөйлисез?!—Һәм баласын тагын да ныграк күкрәгенә кысты.—Күз нурымны бирде ди ят хатын кулына!

Равия дә ярсып тезде:

—Мин дә улымны чит йортка илтеп тыкмыйм, хыялланмагыз да! Эгоистлар! Гел үзләре турында гына уйлыйлар! Ирлек горурлыклары тапталмасын аларга! Ә без чүп, без жансыз курчак!

Дамир хатыннарга бирешмәде, дәрес аңлаткандай:

—Ялгышасыз, кызлар, без үзебез турында кайгыртмыйбыз, менә үссеннәр генә, сез уйнаштан туган дип, малайларның желеген киптерәчәкләр авылда,—диде.—Ир бала үтә гарьчел ул, мин—укытучы, аз-маз чамалыйм аларның холкын. Сезнең дә хәлне аңлыйм. Тугыз ай карында йөрткән балагыз бит. Ана кешеләр буларак сез дә улкайларыгызның киләчәк язмышына төкермәгез. Минемчә, сез бер-берегезнең жан парәсен үземнеке дип үстерерсез, сез бит акыллы хатыннар.—Нотыгын очлагач, ул Галимнең аркасына шапылдатты.—Әйдә, дус, хәзер кызлар үзләре генә калып киңәшсен, без әйтәсен әйттек, ярты сәгатьтән әйләнеп килербез.

Ирләр, чаштыр-чоштыр үлән ерып алан буйлап китте.

—Булмас ахры, бикәчләр нык тора,—Галимнең өмете сүнеп бара иде.

Дамир да көрсенеп куйды.

—Әйе, нык торалар. Кран белән дә кузгатырлык түгел.

Ярты сәгать бик-бик озынга сузылып, таң инде керфеген дә каккан сыман тоелды. Алар әйләнеп килгәндә имән төбендәге хатыннар елый-елый шешенгән, малайлар да уянып, әниләренең хорына кушылган иде.

Ир-ат шактый вакыт әнкә-улны көйләде. Фара яктысыннан сукырайган ябалак мытырдый-мытырдый икенче агачка күчте.

—Сезнең тәкъдимгә йөрәккә кан саудырып кына ризалаштык, үлемгә тиң адымга этәрдегез безне,—диде Гөлнур.—Килешәбез, ир баланың ата канаты астына сыенып үсүе яхшырак. Тик бер шартыбыз бар...

Бу сүздән ике ирнең дә гайрәте чиккән, чөнки «шарт» былтыр ук кызларның кирелеге сыманрак мәгънә алган иде.

Дамир күнел төпкелендәге үпкә һәм рәнжүләрен кузгатып: «Карале, Нечкәбил, синең бер шартың аркасында без өйләнешмәдек, хәтерлисеңме?»—димәкче иде, тыелды. Тукта, әйтеп бетерсен...

—... Дуслыгыбызны яңартыйк. Малайлар ике очны бер итеп үссен. Без Равия белән шулай уйлаштык, әгәр сез...

—Юк, юк, без риза!—диде ирләр, бертавыштан.

... Зәңгәр күзле малай Дамирның, кара күзле малай Галимнең бишегенә кайтып ятты.

Урмандагы алыш-биреш турында авыл белмәде һәм мәңге беләчәк түгел иде.

*Февраль, 2001 ел.*



## Фәйрүзә Мөслимова

### МӘҢГЕЛЕК ӨН

«Минем кадәр беркем сөелмәгән,
Минем кадәр беркем сөймәгән!..»—
Бер-берсенә пышылдыйлар парлар,
Тын-битараф тора бар галәм.

Аланнарның ак чәчәктә чагы,
Ак өметтә чагы язларның.
Үзгәртергә хәтта сәләтле чак
Язмышларның күктә язганын.

«Безнең белән бәхетледер бу җир,
Без булганга дөнья түгәрәк!»—
Шул сүзләрне тыңлап уянды да
Ай болыттан төште тәгәрәп.

Йолдызларның балкып янган чагы,
Серле чагы айлы төннәрнең.
Йөгерек җилләр тыңлый салмакланып
Чишмәләрнең челтерәп көлгәнен.

Шул дөньяга багып ник соң берәү
«Гөлҗамал»ны көйләп моңая?
«Авыр җан сөйгәннәрнең булмавы»,—ди...
Булган чаклары кая соң,
сөйгән чаклары кая?

Фәйрүзә МӨСЛИМОВА—*шагыйрә, «Ярату яралары» (2001 ел) исемле китап авторы. Казанда яши.*

Айлар, еллар алышына икән,
Мәңгелек өн бары тынмаган:
«Минем кебек беркем сөелмәгән,
Миндәй җаннар әле тумаган!..»

## Вакыт машинасы

Гел кайтара вакыт машинасы
Еракларда калган көемә:
Анда минем әткәй-әнкәй исән,
Бер кайгысыз анда йөрелә.

Каен утын яна чытыр-чытыр,
Тәбикмәкләр пешә ак мичтә.
Күрше-күлән хәл белергә керә—
Рәхәт, җылы безгә бу кичтә.

Ялгышамы вакыт машинасы?—
Мин китәргә никтер ашкынам.
Әткәй, әнкәй, җылы мичләр кала...
Ниндидер юл мине чакыра.

Кая китәм? Нигә китәм? Китәм...
Ерагая еллар арасы.
Алып китә вакыт машинасы,
Калыр өчен юктыр чарасы.

Сеңеп калган һәрбер күзәнәккә—
Чишмә кебек тибә шул көем.
«Вакыт машинасы, тик беразга
Шул чагыма алып кайт»,—димен.

Һәм кайтамын, йөгерә-атлый кайтам,
Каршы ала шундый бүгенем:
Сусынымны басар көйләрем дә,
Пакь чишмәм дә... инде юк минем.

## Балалык

Нинди хурлык: алдадылар мине тагын
Һәм саттылар каһкаһәләп көлә-көлә.
Мин ташбака Тортилладай зирәк идем,
Сукыр бер тиен икән, юкса, минем бәя!

Могҗизалар кырын эзләп йөргәнем юк,
Бакыр күмеп, алтын көтеп ятам мәллә?
Һәркем җирдә ихластыр, дип ышанам да,
Алданамын хисләремдә меңәр кәррә.

Мине саткан бакырчылар уңыш көтә:
Бер сыгылып еласын хет шушы юләр!
Ә мин менә—Буратино, агач курчак!
Таммый яшем рәнҗесәм дә. Чынлап әгәр.

Нинди хурлык: алдадылар мине кабат,
Агач тәнем сиздермичә калтырана.
Күрәсең, мин—әле һаман бала-чага:
Охшаш булгач Буратино, Тортиллага.

## Апрель кары

Ятып ауныйсымы апрель карларына?
Апрель карларыдай әллә каралырга?
Кар сулары кебек язгы җиргә сеңеп,
Умырзая булып кабат яралырга?

Менә нинди хыял, менә нинди ярсу!
Кучкыл карны ябынып, җәйрәп ята басу...

Орлык төшәр көнне көтәсеме озак,
Кайчан кузгалыр, дип, елгаларда ташу?

Кайчан яфрак ярам, ди каенда бөре.
Кояш нурларында бүрткән инде үзе...
Ә син, имеш, шул чак, күзләреңә китеп,
Ямансулап йөре, еламсырап йөре...

Аунар идем, диеп, апрель карларында...
Юләр хыяллар бер тиеш таралырга.
Бөре сыман бүрткән хисләреңне тыеп,
Бик акыллы кеше булып саналырга.

Менә нинди хыял!
Апрель кары эри...!
Ә күзләргә бер дә, бер дә йокы керми!
Шытып чыгачагын умырзая булып
Апрель кары әле төшендә дә күрми...

## Шигърият

Шигърият—чибәр кыз, диләр,
Фәрештәгә тиңлиләр.
Лира тотып, канат җилпеп,
Очкан чагын сөйлиләр.

Сөйлиләр ир-атлар гына,
Сурәтлиләр ир-атлар.
Тагын әле күпме шагыйрь
Шул хыялны кабатлар.

Үзләре шуңа ышанып...
Гаепләмик, бигайбә.
Шигърият дигән могҗиза
Ир затыннан шулай да.

Ир затының иң дәртлесе,
Серлесе һәм көнчесе,
Сөйгәне өчен көрәштә
Мәкерлесе, үчлесе!

Мәхәббәтен бүлешкәнне
Кичерми шигъри иркә:
Сөеклесен—шагыйрәне—
Йә ялгыз, йә тол итә.

И кызыкай, шигърияткә
Багышласаң үзеңне,
Гап-гади җир бәхетеннән
Өметеңне өз инде.

Шигърият—көнчел...

## Мин сугышта булдым...

Мин сугышта йөрдем әткәй белән,
Әткәй белән җиңү яулаштым.
Волхов сазлыкларын кичеп чыктым,
Камалышта калып, адаштым.

Әсирлекнең тойдым ачыларын,
Юкса, каян миндә мондый моң?
Шул хакларда китап укысам да,
Шул турыда кино карасам да,
Җаным белән әрнеп елыймын.

Әткәй белән әсирлектән качтым,
Исән кайттым мин дә сугыштан.
«Мин исән!»—дип әткәй сөенгәнгә,
Мин тормышны сөйдем тумыштан.

Сугыш беткәч, Сталиннар киткәч,
Мин туганмын җиргә, мин—дәвам.
Әнкәйсез дә, әткәйсез дә күптән,
Ничә үлгән, ничә яралган!

Мин сугышта йөрдем әткәй белән,
Күрәсезме, әле мин исән!
Тынычлыкка җыр-мадхия әйтеп,
Язгы җилләр булып мин исәм.

## Феникс

Янам-янам да кабат яралам
Көлдән яралган Феникс кебек.
Күтәрелмәкче булам һавага
Каурыйларыма ярамны төреп.

«И юләр кошкай, әкият бит ул
Кабат яралу, терелү кабат»...—
Кемдер шулай дип эндәште бугай
Мин узган юллар-елларны санап.

Искә төшермә, дәшмә, ят тавыш,
Бу хакта инде мин беләм күптән.
Аһ, мин инди карт, борынгы, диеп,
Япь-яшь көннәрем, гомерем үткән.

Янам-янам да кабат яралам,
Ә бер көн килер—ярала алмам?
—Гомерләр узган, картайганмын,—дип,
Бүтән беркайчан инде зарланмам?

Исән чагында гөнаһ түгелдер
Көлдән яралу Феникс сыман.
Яраларымны канатым каплар,
Күз яшьләремне яңгырлар юар...



# Рәшит Шиһап

## УТЛЫ УЕМ ЙӨРИ КАУДАРЛАНЫП...

Килер буыннарга бер сүзем бар:
Күбрәк утыртыгыз юкәләр!
Чабаталар тагын кирәк булыр,
Кабатланып тора үткәннәр.
Комганнарны алыгыз чормалардан,
Ышкып ялтыратыгыз җир белән.
Сезнең чорда онытылган булыр
Тәһарәтсез йөрү ил белән.
Кабатлана тарих, гасырлары
Узганына юлын бора да.
Үткән белән бер кат тетрәндерми,
Алгарышлар юк ул дөньяда.
Гаҗәпләнәсезме? Юкка гына...
Әнә Кояш чыгышы утравында
Компьютерлар белән беррәттән,
Кибетләрдә комган, чабаталар
Сата бүген япон—хезмәтчән...
Кул арбаларын да һич сүтмәгез.
Күтәреп үк куегыз тезмәгә.
Төрле машиналар белән бергә,
Алар кирәк булыр кемгә дә.
Кеше уйлап тапкан бернәрсә дә
Төшеп калмый тормыш күзеннән.
Үзе китә, әмма иҗат җимеше
Гел хезмәттә җирнең йөзендә.
Артта калган дәвер, йөз үзгәртеп,
Килеп иңгә янә бер баса.
Һәр нәрсәгә әзер булып торыгыз
Һәм белегез: Дөнья—куласа!

### Шигъри фараз

Утлы уем йөри каударланып
Үткән миллион еллар артында.
Эзләнә ул... Ахырзаман дигән

Рәшит ШИҺАП *(1938)—шагыйрь, «Заман белән бәхәс», «Җан авазы», «Юлларда язмышлар» исемле китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Лениногорск шәһәрендә яши.*

Курку калгач дөнья халкында,
Сорау арты сорау: сүнәрмени
Күк йолдызы—гүзәл Җиребез?
Исрафилның сур быргысы тавышы
Белдерерме соңгы көнебез?
Бер буш җисем булып калырмы ул,
Яшәү бетәрмени галәмдә?
Күңелсез бит булыр Тәңрегә дә
Берьялгызы калса әгәр дә?..
Уем кире кайта планетаның
Һәр чорына—туктап, тикшереп:
Юк, яшәгәндер, дим, бу дөньяда
Безгә кадәр бүтән кешелек.
Хәзергеләр кебек, Тәңре каршысында
Гөнаһлары чиксез булгандыр.
Сугыш уты, талау, үтерүләр,
Явызлыклар авыз ергандыр.
Илаһи Зат мондый вәхшилекне,
Кыргыйлыкны, бәлки, тыйгандыр.
Тыйган саен, адәм балалары
Бер-берсенең башын кыйгандыр,
Шуңа күрә Ахырзаман китереп,
Хода каты җәза кылгандыр.
Кеше афәтеннән Җирне, күкне
Саклап калу кирәк, дигәндер.
Тик шулай да кабат сынау өчен
Җиргә янә
Безнең кешелекне биргәндер.
Кояш галактика гөмбәзеннән
Бертуктамый шулай көлгәндер...
Әйе, киләчәктә ни буласын
Алдан абайлаулар сүнгән кешелек
Мирасыннан безгә килгәндер...
Ә Җир исә, тыйнак Ана төсле,
Тәрбиясен биргән, бирәчәк!
Баштанаяк гөнаһларга чумсак,
Ахырзаман тагын киләчәк.
Ярлыкасын мине руханилар,
Дингә ышанам мин—изге эш!
Ләкин Ахырзаман булган саен,
Була торыр башка Яшәеш.
Галәм кебек, Җир һәм Яшәү—мәңге,
Бары матдә булыр төрлечә.
Юкка чыккан цивилизациягә
Алмаш килә торыр безнеңчә.
... Уем кайтып җитеп бүгенгегә,
Күзли усалланган Дәвамны.
Явыз гамәлләрең туктат, Кеше,
Якынайтма Ахырзаманны!

## Синең көчең

Кешеләр өчен Яшен утына каршы
Көрәшкәндә, бәлки, сүнәрмен.
Дөньялыкка гына сүнәрмен мин,
Беләм, синең уйда үлмәмен.

Ләкин кулың сузып ак Кояшка,
Җан өр аңа, диеп сыгылма:
Ул тик табигатькә җан өрүче,
Ә монда бит кеше егылган.
Бер урында—күзләремдә генә,
Яшәү төсе калыр—күреп ал:
Муенымнан җир куенына сал да,
Кайнар итеп күздән үбеп ал.
Бары Изге Туфрак һәм Син генә
Кабат миңа яшәү бирерсез...
Туган Туфрак һәм Мәхәббәт кенә
Бик күпләрне итә үлемсез.
Маҗаралы роман кебек булыр
Тормышыма тагын бер кайту.
һәм язылыр аның баш битенә:
«Нинди көчле Синең ярату!»

## Җиткерегез әле

Фәрештәләр! Сез бит Тәңребезнең
Җиргә җибәрелгән илчесе.
һәр гамәлебезне язып барып
Аның каршысына илтүче.
Тапшырыгыз минем сүзләрне дә:
Дөнья җитми һаман кешегә.
Инде орбитадан янап, Җирне
Бүлешү уе керә көченә.
Бүленәсе күптән бүленеп беткән,
Нигә аны кабат бүләргә?!
Моңа Яшәешнең үзе белән
Туры киләчәк бит түләргә.
Ни сәбәптер, Акыл киңлегенең
Зәгыйфьләнә бара утлары.
Фикерләүдә Гулливерлар кими,
Сан ишәйтә лилипутлары.
Яктылыкка, аны зурлауларга
Игътибарын кимета адәмнәр.
Илгә бизәк өсти хәләлләре,
Шуны каралталар хәрәмнәр.
Төссезләнә бара—Туган халкым,
Үз Ватаным, дигән тәгъбирләр.
Бу кыйммәтләр канына сеңдерелми
Яфрак яра күпме тәкъдирләр...
... Яктылык ул—яшәү чыганагы,
Шуңа якты Җир-Күк арасы.
Җимерү, сүнү түгел, Яктылыкка
Нур өстәсен Хәүва баласы.

# Çəçmə əsərlər
# Чәчмә әсәрләр



## Марат Закир

ӨЧ ХИКӘЯ

### Үзенчә

*«Канлы болыт» хикәясе узган гасырның сиксәненче еллар азагында—туксанынчы еллар башында ук язылган. Ә беренче тапкыр басылу вакыты теге гасыр ахырында икән. Марат Закир—хикәянең авторы—аны укучыдан нигә шулай яшереп тоткан соң? Бәлки, әсәрен кабат-кабат эшкәрткәндер ул. Әгәр шулай икән, яшь әдип әдәбиятның олпатлыгын , димәк, әдәбиятта эштер-өштер эшләү гафу ителмәвен аңлый, димәк. Бәлки, әсәрен сандык төбендә саклавының бүтән сәбәбе дә бардыр, автор хикәясендәге фаҗигале вакыйгаларны онытырга теләгәндер. Әгәр шулай икән, солдат киемнәрен хикәя туганчы күптән түгел салган егетнең әсәрен кабат кулына алмавы аклана кебек, чөнки Марат Закир әфган гарасатларында катнашкан кеше ич.*

*Әсәрен беренче тапкыр бастырганда («Идел» журналы, 12нче сан, 1999 ел), автор укучыга болай искәртә: «Хикәя сугыш тудырган фаҗигаләрне яшь буын китап-журнал битләреннән генә укый алса иде, дигән теләк белән язылган иде...» Шушы теләк яшь әдип һәм карт солдат Маратны дистә ел буена әдәби хәзинәсендәге маяларның берсе булган хикәясен укучыга, ниһаять, җиткерергә мәҗбүр иткән.*

*Биредә мин үземә ошаган әсәрнең эчтәлеген сөйләүне максат итеп куймадым. Бәлки, минем дә андагы вакыйгаларны онытырга, һичьюгы онытып торырга теләвем сәбәптер моңа. Ләкин аларны хәтердән выжлатып куып чыгарып булмый, автор сугыш афәтен күңелгә сыланырлык итеп тасвирлаган. Димәк, укучының аны үзе җентекле укуы кирәк. Ә хикәяне табуы кыен түгел, ул күптән түгел нәшер ителгән «Татар хикәясе антологиясе»нә (ХХ гасыр) кертелде.*

*Шулай да берничә детальгә игътибар итик.*

*Әфган агае әсир егетне кол итеп сатып ала, ягъни ул аны малга тиңли, аның кулына богау сала (кулларын бәйли). Шул ук агай ахшам намазы укый, тәсбих тарта. Кеше дигән олы затның, гомумән, кешелекнең югала-бетә баруга юл тотуы ич бу хәл—гөнаһ җыеп изге җан булырга маташу.*

*Хикәядә кабатлана торган бер тасвир бар. Менә ул: «Һаман бер күренеш (күзен ачса да, йомса да): канлы гәүдәләр, сүнеп барган кояш, канлы болытлар (гел менә*

*шыбырдап кан яңгыры явып үтәр төсле), өркәк җәнлекләр...» һәм соңгы кабатлауда моңа «тезләнгән Җәмлиханның ялварулы карашы» өстәлә. Берәгәйле әйтелгән, шулай булгач, әлеге детальләрнең бер генә тапкыр теркәлүе дә җитәр иде кебек. Җитми икән шул, кабатлаулар фаҗиганең зурлыгын, геройларның чорыбыз корбаннары икәнлеген ачу өчен кирәк икән.*

*Марат Закир хикәяләренең язылу алымы эчтәлекләре таләп иткәнчә төрле, димәк, ул язучылык кагыйдәләренең иң әһәмиятлеләреннән берсен таный, һәм иҗатта үз стилен, калыбын, кальбен салып килә. Әйтик, «Чебен» хикәясендәге геройларның сөйләме үзләренә хас булганча чуар, ара-тирә хәтта чуалчык та тоелып куя. Тасвир-чагыштыруларның җителеге дә, авторның кайчак үтә кырыслыгы да язу алымының төрлелегенә, үзенчәлегенә китерә. Берничә мисал: «чиллә бәйрәме ясаган кояш», «корыган агач ботагында бөре шыттырырдай кыз», «сугыш төрәне маңгаена буразналар сызган»... Соңгысы күп тапкырлар кабатланган кебек, ләкин анда Марат өстәгән «төрән» сүзе бар. Төрән буразналарны ыржайта, ямьсез тирән ерганактай итә, шулай булмыйча мөмкин дә түгелдер—сугыш төрәне салган ич аларны.*

*«Карбыз» хикәясендәге бүгенге матавыклы тормышны хыялы белән бизәүче егет тә, «Шарт» исемле хикәясендәге буй җиткән кыз—карусыз ант биргәндә авыз эчендә балаларча «әйттем исә кайттым» дип әйтүче кыз да (мәхәббәт дигәнең кайчак гөнаһсыз гөнаһларга да этәрә!) ошый миңа.*

*Марат Закир үзе кем соң?*

*Марат Хәлил улы Закиров 1969 елның 27 апрелендә Мамадыш районының Дусай авылында туган. Күршедә генә—Шәйхи Маннурның Тулбае, аннан бераз гына арырак—Рәис Даутовның Шәмәк авылы. Кешеләре туган телнең төмен—аһәңен тоя торган яклар.*

*Тәкәнеш урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, Марат КДПИның тарих-филология факультетына укырга керә. Икенче курста укыганда солдатка алына, Үзбәкстанның Термез каласында снайперлар мәктәбенә эләгә. Аннары—Әфганстан...*

*Армиядән кайткач, институтта укуын дәвам итә, бер үк вакытта яңа ачылган «Шәһри Казан» газетендә әдәби хезмәткәр буларак хезмәт юлын башлый. Сигез елга якын «Идел» журналы редакциясендә эшли. Быелның мартыннан—«Казан утлары» журналында проза бүлеге мөхәррире. Вакытлы матбугатта шигырьләре, хикәяләре басыла килә.*

*Һәм мин соңрак телгә алынган «Шарт», «Карбыз», «Чебен» исемле хикәяләрне журнал укучылары игътибарына, алар да Марат Закирның иҗаты башындагы үзенчәлеген ошатырлар, дигән ышаныч белән тәкъдим итәм.*

**Мәгъсум ХУҖИН**

## Шарт

### 1

Җәй уртасы. Чиллә. Бил тиңентен чишенеп ташлаган биш егет кирпеч суга. Баш очында каһкаһәле генә кояш елмая. Әле салмак, әле узыныбрак искән җил кая керергә урын тапмыйча бәргәләнә. Корыч куллы кайнар кояш абзый нечкә билемнән эләктереп алмагае, дип шүрли бугай ул. Егетләрнең борынгы Рим гладиаторларыныкыдай бакыр сыман тәннәренә уралып үтә дә, тау битендәге яшь урманга ашыга. Чилләдә җил һәркемгә тансык.

—Килә! Килә!—диеште егетләр.—Бу Гүзәлгә карап, валлаһи газим, сәгатьне дөресләргә була!

Карлыгандай кара күзле, дулкынланып торган озын коңгырт чәчләрен иңенә таратып ташлаган кыз егетләр янына килеп тә җитте. Ул әйрән алып килгән иде. Гадәттә, мондый чибәр кызлар бик тә ялындыра торган, кыланчык, иркә холыклы, бераз гына ялганчырак булалар. Ә Гүзәл андый түгел. Әйткән сүзеннән беркайчан да тайпылмас, бик тә төгәл кыз ул. Аның бу төгәллеге артып ук ашмады микән әле!

Әгәр дә син аны кич утырырга чакырсаң, кыз: «Кар яуса, чыгам!»—

дияр. Шулай иттереп, сиңа, бахыркаем, өч кенә юл кала: йә ул карны җәй уртасында яудырасың, булмый икән—яуганын көтеп утырасың, ә инде яумаса, Гүзәлнең кич утырырга чыгуыннан өметеңне өз!

Әлбәттә, бу биш «Рим гладиаторы»ның берсенең Гүзәл кебек чибәргә күзе төшүе тамчы да гаҗәп түгел. Ә инде Гүзәл кызыкай бу биш егетнең берсенә баштанаяк гашыйк икән—монысы да табигый хәл. Инде Гүзәлнең күзе төшкән егет үзе дә Гүзәлгә баштанаяк гашыйк икән—монысы тәмам табигый. Әмма мондый хәл дә бик тә, бик тә сирәк очрый торгандыр...

Илгиз белән Гүзәл—әнә шул бик тә сирәк очрый торган хәлнең каһарманнары була инде. Әлбәттә, Гүзәл алып килгән салкын әйрән генә Илгизнең сусавын баса алмый. Аның сусавын басардай бердәнбер чара—кызның тулышып пешкән чиядәй алсу-татлы иреннәре генә...

Гүзәл алып килгән салкын әйрәнгә гашыйк булучылар да бар анысы. Биш егетнең берсе—Ришатның, әнә, әйрән эчә-эчә тамагы тәмам карлыгып бетте. Соң, нишлисең бит, берәүләр—Гүзәлгә, ә икенчеләр әйрәнгә гыйшык тота бу дөньяда...

Яшь урман янәшәсеннән бормаланып аккан нәни инеш буенда ике гашыйк үбешеп утыра. Бу манзарага биектә—баш очларында тибрәнгән, гүя дә болар бәхетеннән көнләшүдән (әллә оялуданмы?) кып-кызыл булып кызарган япа-ялгыз кояш кына шаһит.

—Унбердәме?—дип кызның колагына пышылдый егет.

—Унбердә!—дип җавап бирә кыз.—Йә, бар инде, бар, кузгал, сезнекеләр эшкә тотынды бит инде...

* * *

Җәй көннәрендә авыл яшьләре кичке унбердән соң «яши» башлый. Бу «яшәү» таң атканчыга кадәр дәвам итә. Таң атканчы ниләр генә кыйланмый икән дә, ниләр генә майтармый икән бу яшьләр!

Көн дәвамында тир түгеп—чүп утап, бәрәңге төбе өеп, түтәлгә су сибеп, печән чабып, көтү көтеп, кыскасы, авылның мең дә бер төрле мәшәкатен кичкән егетләр-кызлар, өлкәннәр арып-талып ятакка егылгач, клубка чыга башлыйлар. Берзаманны кырыкмаса-кырык төрле матай гөрелтесе авылны дер селкетә. Бисмилласын әйтеп кенә йокларга яткан карт-коры «денсез» оныкларын битәрли, талканы коры әтиләр шундук, үзе дә сизмәстән, каешка үрелә, әмма яшьләр «этлектән» кайтканчы үзенең печән чабарга чыгып китәсен уйлап куя да кулын гына селти, бахыр...

Төп-түгәл кичке унбердә Илгизнең матае Гүзәлләрнең капка төбеннән кузгалып китте. Биек тимер капка янында тузан эчеп моңаеп торган, әле укасы да коелмаган өр-яңа туксан тугызлы «Жигули» егетнең уктай очкан матаеннан көнләшеп калды. Мондый затлы, тәкәббер машинага иске матайдан купкан тузанны эчүдән дә гайре тагын нинди зур җәза бар икән, ә?!

Берсекөнгә Гүзәл Алабугага имтихан тапшырырга китәчәк. Нияте—укытучы булу. Егетнең дә хыялы бар. Ул да укырга тели. Әмма дә... Тик менә... Авылдан чыгып китә алмый әле ул. Чыгып китүен дә китәр иде, тик аның әле башта өй саласы бар.

Моннан биш ел элек Илгизнең әтисе үлеп китте. Теге яман чирдән. Яңа йорт салып керергә иде мәрхүмнең исәбе. Язмаган икән. Бу хыялы да тормышка ашмады мескенкәйнең...

Әтисенең әнә шул иске матае һәм яңа йорт салу нияте аңа мирас булып калды да инде. Аның карамагында—хаста әнисе, бәләкәй энесе, тагын да бәләкәйрәк сеңелесе...

Әтидән калып, әтисез генә егет булып җитешкән малайларның хәлен үз башына төшкән кеше генә чамалый торгандыр. Авыр чакта

арттан этәрдәй, аркадан кагардай, терәк булырдай туган-тумачасы да юк бит аның, ш-шайтан алгырысы!

Авыл түрендә олпат кыяфәттә горур калкып-балкып утырачак апак калай түбәле мәһабәт йортын Илгиз бик еш төшендә күрә. Әле арыпталып ятакка егылгач та, тиз генә йокыга китә алмыйча, үзалдына исәпхисап, ният корып ята. Йорт-кураны әзергә-бәзер чагында гына җиткерүе ансат шул аны. Тегесен-монысын юллап көне-төне чапмасаң, «Мә, Илгиз!» дип беркем дә сиңа китереп тоттырмаячак.

Бу арада калаен, агачын, цементын, ташын, газ кертергә торбасын сорашып-белешеп йөрүче егетнең авылда абруе да күтәрелде. Калада җил куып йөрүче оныклары итен-маен-йомыркасын алырга дип кайткан саен, әби-бабай тегеләрнең колагына Илгизне мисал итеп тукый да куя. Агайлар, һәм яшьрәк ир-атлар да, егет белән үзләре килеп күрешә, башлап сүз ката торган булдылар. Берәүләре:

—Измә балчыгын Түбән су буеннан ал, ә комын—Әрәмәлек артыннан,—дип киңәш бирә.

—Цементны алдан алып куя күрмә, катып бетәчәк,—дип тә искәртәләр.

—Йоклап йөрмә! Тимергә бәяләр арта, ди әнә. Кадак белән калаенны хәзердән үк хәстәрлә!—дип ашыктыручылар да бар.

«Ни майтарыр икән бу егет? Башкарып чыгалырмы?»—дип мыек астыннан гына көлемсерәп куючылар да юк түгел.

Егет кирпеч заводына эшкә урнашты. Инде менә ике атнадан бирле ул Гүзәлнең әтисенә кирпеч суга. Хезмәт хакы—кирпечләтә...

* * *

Инешнең теге яры белән бу ярын тоташтырып, озын нарат ята иде. Илгиз матаен шунда туктатты.

—Әйдә, су коенып чыгабыз!—диде ул Гүзәлгә.

—Монда чыпчык тезеннән генә ләбаса!

—Әйдә! Сузылып ятсаң, күмә ул безне!

Тирә-юньне сихри эңгер билəп алган, күктә шаян-шук йолдызлар җемелдәшкән җәйге төн иде бу!

Ай яктысында ялтыраган күгелҗем-көмеш суда Адәм белән Хәва пәйда булды.

Әкияттәге су кызын да көнләштерердәй сылу сынлы иде кыз. Тәнендә жаны булган теләсә кемнең дәртен уятырдай, хәтта корыган агач ботагында бөре шыттырырдай ымсындыргыч халәттә иде ул...

Илгизнең, тораташтай катып, онытылып үзенә карап торуын абайлап алган Гүзәл кинәт кенә аңа су чәчрәтте. Тегесе, тотты да, кызга турылап суга чумды. Чумуы булды, маңгаен учлап судан чыгуы булды! Ике ярда суга тияр-тимәс кенә сузылып яткан наратны мангае белән сөзеп алган икән бит батыркай!

Кыз көлеп җибәрде. Гүзәлнең көлү тавышы белән Илгизнең аңа чәчрәткән су тамчылары бергә кушылып, тирә-юньгә ниндидер бик тә тансык, илаһи бер аһәң җәяләр иде.

Илгиз яр буеннан тапкан озын сайгакка чалкан ятып йөзә башлады. Бераздан аның караңгы инеш борылмасыннан:

—Таһирны сандыкка салып шулай агызганна-а-ар!—дигән тавышы гына ишетелде.

—Әнә, әнә, бакчы, үзеңне хан кызлары да көтеп утыра монда!—дип кычкырды Гүзәл һәм яр читендәге өч бакага таш атты.

Ләкин егет күренмәде.

—Кайда-а-а син? Әллә баттыңмы күгәрчен тезеннән суда?

Җавап килмәде.

—Ау-у! Ил-ги-и-из!

Кайтаваз серле-шомлы гына каракучкылланып утырган бөдрә

талларны урап әйләнде. Әмма Илгизнең тавышы ишетелмәде.

—Ау-у?! Ил-ги-и-из, дим! Кайда-а си-и-ин?!—дип тагын тирә-юньгә борчылып сөрән салды Гүзәл.

Шулай сөрән салуы булды, кинәт кенә кемдер аны кочып та алды. Сон, әлбәттә инде, Илгиз иде бу!

—Чапаланма!—диде егет бер тын дәшмичә торганнан сон.—Син—минем хан кызым!

—Зөһрәң...—дип егетнен иреннәренә җавап бирде Гүзәл.—Ә син—Таһирым!..

Беркавемнән ике гашыйк, авыл очындагы карт тирәк төбендә сандугач сайравын тыңлый-тыңлый, хәтта сандугачның үзеннән дә уздырып чөкердәшә-чөкердәшә таң аттыралар иде инде.

—Ата сандугач бу!—ди Илгиз.—Ана сандугачны үзенә каратасы килеп җан ата, бичаракаем...

—Тегесе аңа карамаса?

—Зарын сөйли торгандыр инде, алайсам...

—Сандугачның зары да матур,—дип килешә аның белән Гүзәл.

—Ана сандугачны үзенә карата алмаганга пошынып, тозлап-борычлап, әй, сүгенә торгандыр әле, баксаң-күрсәң. Ә без шуны синен белән, һай, матур да сайрый инде бу, дип тыңлап утырган булабыз.

—Чут-чут-чут, тиют-тиют, дипме?—дип Илгизнең колагына пышылдый кыз.

—Сандугачка сүгенсә дә килешә!—дип кырт кисә Илгиз.

—Сандугач сүгенәмени, и җүләр!

—Чут-чут-чут, тиют-тиют!—дип егет тә Гүзәлнен колагына пышылдый...

* * *

Матай гөрелтесеннән уянган бозау кадәрле бурзай буылып-буылып өрә башлады. Гүзәл, тимер капканы сак кына ачып, ишегалдына узды. Шул мәлдә өй ишеге ачылып китте. Өй эченнән сирпелгән яктылык, туып килүче таң кукрәген, хәнҗәр сыман, телеп алды. Асты таштан, өсте сап-сары юан нарат бүрәнәдән салынган бинаһая биек йортның сырлап-бизәп эшләнгән затлы болдырында әти кеше пәйда булды.

—Сәгать ничә икәнне беләсеңме син, кызый?!—диде ул. Тавышы кырыс иде.

—Беләм! Иртәнге дүртенче ярты!—дип, Гүзәл, берни дә булмагандай, сәгатьле кулын селкеде.

—Белсәң...—Шул!—диде кызының бу гамәл-кыяфәтеннән чыгыры чыккан әти кеше.—«Моннан ары Илгизне күзем күрмәс, тавышын колагым ишетмәс!» Кабатла!

Кыз дәшмәде.

—Кабатла!—дип янә әмер бирде әти кеше, аның тавышында корыч чыңы ишетелде.

Гүзәл карыша алмады, кабатлады:

—Моннан ары Илгизне күзем күрмәс, колагым ишетмәс...—дип үкседе ул, ә күнеленнән бүтәнчә уйлады.

Төнлә, аеруча таң алдыннан, чылт иткән тавыш та колакка тиз килеп ирешә бит ул: әти белән кызның әңгәмәсе дә, бигрәк тә Гүзәлнең соңгы сүзләре Илгизнең колагын-аңын, әлбәттә, читләтеп үтмәде. Бер мизгелдә егетнең күз аллары караңгыланды. Йөрәк турысын нидер чеметеп, сулкылдатып алды, чигә тамырлары чыңлады. Икенче мизгелдә ул, һушына килеп, матаен кабызырга теләде. Әмма дә... Әмма... Бер типте, ике типте, өч типте—матай кабынмады. Күнеле сүрелгән егеттә матай гаме түгел иде шул. Сүрелү генәме, бу минутларда егет төбе-тамыры белән актарып ташланган, инеш өстенә аркылы ауган теге нарат агачыдай җансыз-битараф иде.

## 2

Челлә. Челлә! Бил тиңентен чишенеп ташлаган биш егет кирпеч суга. Тәмугтай эссе мичтә, тезелешеп, алар суккан кирпечләр «пешә». Янәшәдәге яшь урман исә, җансыз чүлдә бер йотым суга тилмергән Чыңгызхан гаскәредәй, жиргә башын игән, тау битенә сырышкан...

—Килә! Килә!—диеште егетләр. Алар дәррәү-дүртесе тиң сәгатьләренә карадылар.—Төгәл дә соң инде үзе, чукынмыш! Төп-төгәл!

Әмма кыз болар ягына борылып та карамады. Илгизнең матае янына килде дә чүлмәген күләгәгә куйды...

«Ярый соң, килмәсен, күрмәсен, карамасын—атасы сүзеннән чыкмасын!—дип Илгиз бугазындагы төерне йотты.—Бик кирәгең барые, мәми авыз!»

Әйе шул, Илгиз ягына Гүзәл борылып та карамады. Ул казаннарча фырт киенгән егетләр кереп-чыгып йөргән кантурга таба атлады. Атасының кантурына!

«Атаң машиналы бай кияү тапкандыр, берүк ычкындыра күрмә тагын, әй, мәми авыз,—дип ачынды Илгиз, бугазына тула башлаган гарь вә ачуын жиргә черт итеп түкерде.—Вәйт флюгер дисәң дә флюгер бу! Әле кичә генә минем куенда үзе ниләр генә сайрамады, ә бүген, җил бүтән яктан исә башлагач...»

Ниһаять, Гүзәл кантурдан чыкты. Егетнең каш астыннан баккан күзләре кызны эзәрлекләде: «Нишләр?!»

Бу ике гашыйк арасында нидер булганын дүрт егет тә чамалый, әмма Илгиз үзе әйтмәгәч, чамалаганнарын сиздермәскә тырышалар иде.

Кыз, кантурдан чыкты да, болар ягына борылып та карамыйча, туп-туры олы капкага таба атлады.

«Моннан ары Илгизне күзем күрмәс, тавышын колагым ишетмәс, имеш...—дип өтәләнде, сыкранды егет.—Ярый соң, күрмәссең дә, ишетмәссең дә моннан ары! Бездә дә бар ул горурлык! Әле ниндие! Китәм, бүген үк китәм! Алабугага, юк, Чаллыга! Юк-юк, Казанга ук китәм! Укырга! Бүген үк китәм!»

Ул арада матай күләгәсеннән салкын әйрән алып килгән Ришатның карлыккан тавышы ишетелде.

—Эчегез, мин эчмим!—диде Илгиз.

«Минем өчен бу әйрәннең һәр тамчысы—агу!»—дип уйлады ул.

—Жә, монысына ни диярсең?!—Ришат, дүрткә бөкләнгән шакмаклы дәфтәр битен баш очында уйнатып алды да, Илгизгә сузды.—Чүлмәккә таш белән бастырып куелган иде. Бусы моның, яшьти, безгә түгел инде... Курыкма сәнә, укымадым ла!

Кинәт кенә (ни хикмәт!) җил исеп куйды. Илгизнең кулында жилфердәгән хуш исле кәгазьдә каралып пешкән шомырт тәлгәшедәй ымсындыргыч, тәмле, бик тә таныш-якын язу җәйрәп ята иде:

«Караңгы төшкәч тә су коенырга кил, яме! Кичәге урынга... Йортыбызны салу турында киңәшербез, яме!..»

*1999*

## Карбыз

### 1

—Тот!—ди Данияр.

—Һап та һоп-шапылт!—ди өстән очып төшкән карбыз-ядрәне эләктереп алган Наил.—Башка төшерәсең бит—ипләп ат! Ат, әйдә, ат!

—Тот!

—Ат!

Идел камышына төренеп машина әржәсендә жәйрәп яткан буаз карбызлар әнә шулай иттереп жиргә төшәләр. Жиргә төшкән карбызларны итәге тезеннән югары юка күлмәкле кыз берәм-берәм үлчәп бара. Анын эшен каратут йөзле, карбыз төшедәй коңгырт күзле, кара мыеклы егет күзәтеп тора. Бу егетнең исеме—Танбәк.

Әстерхан өлкәсенең Идел белән Каспий дингезе кавышкан төбәгендә берничә зур авыл бар. Бу дингезне борынгы бабаларыбыз «Кәсеп дингезе» дип хаклы атаганнар. Монда карбыз, помидор үстерүче нугай татарлары—карагашлар яши. Танбәк—әнә шул кавемнән.

... Карбыз төялгән «ГАЗәл» тагын юлга кузгала. Чираттагы сату ноктасы Казан су буендагы урам чатына урнашкан.

Инде жәй азагы якынлашып килә. Әмма чиллә әле. Чиллә! Елга буйлап сузылган көнбагыш маедай сап-сары кин комлыкта карбыз түгел, хәтта алма төшәрлек тә урын юк. Кешеләр, кәлтә еланнарыдай, комга сарылганнар, әйтерсең лә көнбагыш мае ялый-ялый кызынып яталар...

Сөзәк борынлы зәңгәр «ГАЗәл» каланың эреле-ваклы машиналар белән шыгрым тулган ыгы-зыгылы озын урамыннаң салмак кына элдерә.

Инде менә иртәдән бирле Данияр белән Наил карбыз ташып, карбыз бушатып мәш киләләр. Ташуын, анысы, машина ташый инде аның, ә «ГАЗәл»не Танбәкнең абыйсы Сәет «иярли». Танбәк үзе кабинада—абыйсы янында гына утырып йөри. Данияр белән Наилнең урыны—әржәдәге карбызлар арасында. Хәер, алар уенча, иң хозур, иң рәхәт, иң жиләс, тагын да мөһиме—иң тәмле урын—әржәдә!

Менә хәзер дә, иң зур карбызны урталай ярып, тәмләп кенә ашап баралар.

Барган саен, торган саен әржәдә ярык карбызлар күбәя. Танбәкнең абыйсы ипләбрәк йөрсәме—бу бичара карбызлар һич тә бер мәгънәсезгә генә ярылмаслар иде, әлбәттә. Әмма нишлисең бит—карбызлар ярыла. Ярылу аларның язмышына язылган, күрәсең...

Иң кызылын, иң сусылын сайлый-сайлый егетләрнең тенкәләре корый. «Инде монысы—иң шәбе!»,—дип иләнгә орулары була—ак тешләрен ыржайтып пешмәгән карбыз килеп чыга. Моның ише карбыздан кыяр тәме генә килә шул. Юк ла, юк, юк, кыяр әле тәмлерәк тә!

Әнә шулай карбызга атланып карбыз ашап барган бер мәлдә Наил такмак әйтеп ташлады:

—Бу тамашаны күрсәме—
Казан халкы ни дияр?
Хан ияренда утыра
Әйтерсең лә Данияр!

—Әллә син шагыйрьме?—диде Данияр, учы белән астындагы карбызга шапылдатты.

—Шагыйрь!—дип, Наил яшел кәпәчле йомры башын югарыга чөйде.—Шагыйрьлеккә укыйм ләбаса.

—Кайда?

—Универда!

—Кайсысында?

—Кайсы дип... Самай зурында!

—«Казан дәүләт»мени?! Соң, мин дә...

—Нәкъ үзе!—дип Наил, жәт кенә аның сүзен бүлдерде.—Ә син, яшьти, кайсы бүлектә?

—Татфакта!—диде Данияр.

—Ю-юк, мин анда түгел,—дип Наил нигәдер йөзен чытты.—Мин—юрфакта! Читтән торып... Казанныкы мин, укыйм да, эшлим дә.

«Юрфакта шигырь язарга да өйрәтәләр микәнни?»—дип, Данияр тагын да төпченмәкче булган иде, тик Наилнең карбыз шикелле йомры башына күзе төшеп, көлеп жибәрде. Карбыз да—карбыз, бу да—карбыз! Валлаһи, карбыз! Өстәвенә, козырегы артка каратып киелгән кәпәчбейсболкасы да буй-буй яшел!

—Нигәköләсең, кöлмә!—дип үртәлде тегесе.—Шалкан күргәч көләрсең!

—Причем әле монда шалкан?—диде Данияр.

—Безнең авылда шулай диләр...

—Авылда?

—Әйе, авылда!

—Әле генә үзең, Казанныкы мин, дидең бит.

—Без үзебез Казанныкы,
Казанда тумасак та.
Башта—кипке,
Борын—киртле
Камсамул булмасак та!—

дип тезеп китте Наил.—Авылда туып, Казанда үстем мин, яшьти. Шылдымы?

—Шылды,—дигән булды иптәшенең бу кадәрле дә йөгерек-шома теленә хәйран калган Данияр.—Шылды, шылмыйни...

## 2

—Тот!

—Ат!

Бүген Данияр—җирдә, Наил—әрҗәдә. Атуы—рәхәт, тотуы читен. Атна-ун көн дигәндә егетләр тәмам карбыз профессорларына әйләнеп беттеләр бит, әй! Иң кызыгы, иң сәере—карбыз ашамый башлады болар. Сәер, дигәч тә... Көн саен ашый башласаң, кара уылдык та туйдырадыр ла ул.

Инде болар карбыз ашамый дип кенә карбызлар ярылудан туктамады. Мона Танбәкнең кинәше сәбәп булды.

—Бусы—ата карбыз, монысы—ана карбыз,—дип аңлатты ул егетләргә,—ана карбыз тәмлерәк тә, сусылрак та була.

«ГАЗәл»ләре чираттагы сату ноктасына кузгалып китүгә, йә Данияр, йә Наил күңеленә хуш килгән берәр карбызны сайлап ала.

—Атамы?

—Юк, ана!

Тимер идәнгә тупылдап төшкән карбыз урталай ярыла, эченнән ак төшләр чәчелә.

—Ана сиңа, пычагым!

Һай-валлаһидыр, ну кызык та соң инде бу карбыз дигәнең! Анысы, бу тормыш-бу дөнья үзе дә кайчагында карбыз шикелле тоела башлый. Әйе, кайчагында кып-кызыл карбыздай татлы-сусыл ләззәтне көтеп күзеңне йомуың була... Ачып җибәрсәң... Ә ачсаң, әрем тәме вөҗүдеңне куырып ала.

Ярылып яткан карбызларны күргәч, Танбәктән битәр Сәет «аһ» та «уһ» килә. Аның әрнүле кыяфәтенә карап:

—Соң, үзең бит әнә теге борылышта кинәт кенә тормозга бастың! Ана карбыз ярылмыйча нишләргә тиеш? Саклык кирәк!—дигән була Наил.

—Менә ошолай итеп тәгәрәтеп беләләр аны!—дип, аптырагач, үзе кинәш бирә Сәет.

Һы, тәгәрәтеп кенә карбызның эчендә ни барын белерсең, пычагым!

—Менә ошолай сабагы саргаеп торганы—иң өлгергәне!—дип тә карый Сәет.

Әмма монысы да әле еш кына туры килми.

Көнозын чиллә бәйрәме ясаган кояш кинәт кенә болытлар артына кереп качты. Шуны гына көтеп торган, диярсең—күнелләрне ямансуландырып, көз җиле пәйда булды.

—Көз—кызлар күнеле төсле:
Бер елмая, бер—төксе,—

дип, Наил, үзалдына сөйләгәндәй генә шигырь әйтеп куйды.

—Беләсенме, карбыз кемгә охшаган?—диде Данияр.

—Кемгә?

—Муллага!

—Причем монда мулла?

—Тыштан яшел, эчтән кызыл!—дип аңлатты Данияр.

—Юк ла, ю-юук!—дип каршы төште аңа Наил.—Кагылма син муллага, яме! Түрәгә, дисәң, бер хәл әле. Сүздә бер төрле, эштә—икенче төрле... Татар түрәсе!

—Яшьти, әллә мәчеткә дә йөрисеңме син?—дип Данияр сизелер-сизелмәс кенә көлемсерәп куйды.—Кабыгы яшел, эче кызыл муллаларны мактыйсың ату...

Икесе дә тынып калдылар. Әллә нинди генә уңайсыз, читен тынлык иде бу. Данияр үзен битәрләде. Сүзен сүз итәр өчен генә әйткән иде бит ул аны, кызык өчен генә. Авылларындагы элекке партком Айзат абыйның хәзер мулла булып йөрүен күз алдына китереп кенә әйткән иде лә...

—Көз—кызлар күңеле төсле: Бер елмая, бер—төксе,—дисеңме? Шәп бит бу, ә! Валлаһи, шәп! Менә диган шагыйрь чыга синнән, болай булгач, яшьти, чын әгәр!—дип Данияр жепне ялгарга тырышып карады.

Әмма Наил дәшмәде, сүз җилеме ябышмады, гәп жебе өзелгән иде. «Син нәрсә, Наил дус, үзең әйткәндәй, кызлар күңеле төсле үзгәреп киттең әле, сөмсерәнне коеп, койрыгын кабарткан мәче шикелле утырасың»—димәкче иде дә... базмады. «Бабалары мулла булып, аларны теге чакта Себергә сөргәннәрдер. Ә мин, исәр, әнә шул ярасына кагылганмындыр,—дип фикер йөртте ахыр чиктә Данияр.—кеше күңеле дә карбыз шикелләрәктер шул, эчендә ни ятканын тыштан-кабыгыннан гына белә торган да түгел...»

## 3

—Тот!

—Ат, әйдә, ат!

—Тот!

—Ат!

Әйтерсең лә болар иелә-бөгелә «ат!»-»тот!» дип кабатлый торган роботлар. Ходайның кем өчендер бик тә тансык тоелган тәгаменә егетләр шулкадәрле дә күнектеләр ки, алар өчен карбыз әллә таш, әллә туп, әллә ядрә—барыбер.

Әйе, Данияр белән Наилнең инде карбызга әлләни исләре дә китми. Хәзер егетләр өннәрендә генә түгел, төшләрендә дә карбыз күрә башладылар. Данияр карбызларның борау койрыклы симез чучка балаларыдай мыркылдашып-чинашып ятуларын күрә. Наил исә... Хәер, аныкы да шул чамадыр ла. Әмма үзенең сөйләгәне юк.

Көн азагында егетләр берәр карбыз сайлап алалар. Үзләренә—өйгә алып кайтырга. Даниярга теләсә кайсы ярый. Тик зуррагы. Чөнки ул тулай торакта яши. Тик бу вакытта ни дуслары, ни йөрештергән кызлары, ни таныш-белешләре—берсе дә юк. Барысы да—каникулда.

Наил менә... Ә менә Наил карбызны сайлап та карый инде, ичмасам! Чөнки аның сеңлесе бар. Назлыгөл исемле. Назлы Гөл!

Наилнең әнә шул назлы сеңлесенә тиешле карбызны сайлый-сайлаша барысының да теңкәсе корып бетә. Әмма бу вакытта ни Таңбәкнең, ни Сәетнең кинәше эшкә ярамый. Кысылмавың хәерлерәк. Наил карбызны чиртә-чиртә, шакый-шакый, тыңлый-тыңлый сайлый. Ашыкмыйча, озак итеп сайлый. Тәмләп сайлый.

Үтеп баручы бер әби дә ярдәм итеп карый:

—Алла куәт бирсен!—ди әбекәй.

—Анаң кияүгә бирсен!—дип кырт кисә Наил.

Мескен әбекәй исә, тешсез авызын бер ача да бер яба, үзалдына

нидер мыгырдана, аннары кәкре башлы таягы белән асфальтны кыйный-кыйный, үз юлына кузгала.

Икенче көнне иртән эшкә килә-килешли үк Данияр Наилгә сәлам урынына сорау бирә:

—Ну, ничек?

—Во!—дип тегесе баш бармагын күрсәтә.—Шәп!

Бу инде: «Мин сайлаган карбыз сеңелкәшкә ошады!»—дигәнне аңлата.

Инде менә, ниһаять, Данияр тотына. Инде, ниһаять, Даниярның чираты! Назлыгөл исемле үзе чибәр, үзе бик тә серле, сөйкемле сеңелкәше хакында сораштыра-сораштыра, ул Наилне интектермәкче-измәкче була. Әмма тегесе һич тә интегергә-изелергә ашыкмый, киресенчә, тәмләп, ләззәтләнеп җавап бирә.

—Аның күзләре—карбыз төше кебек, бераз гына кысынкырак та,—ди ул.—Гел нурланып тора торган, оялчан...

—Акмыни?—ди Данияр.

—Ничек инде ак?!—дип аптырый Наил.

—Күзенә ак төшкәнмени, дим. Соң, карбыз төше ак була бит ул.

—Вәт аңгыра син, вәт аңгыра!—дип үртәлә Наил.—Карбыз төше коңгырт була, ахмак.

—Ә иреннәре?

—Иреннәреме? Иреннәре—текә, мут!

—Ничек инде—текә?

—Текә булгач, текә инде!

—Нигә—мут?

—Чөнки алар гел елмаеп кына торалар.

—Ну, яшьти, әйтсәң-әйт инде, күкрәкләре ничек? Алары да текәме? Карбыз кебекме?—дип авызын ера Данияр.

—Текә, текә!—ди тегесе, бу юлы үртәлми.—Ни пычагыма дип көләсең әле син? Көлмә! Шалкан күргәч көләрсең!

Шулай ди дә бу, үзе дә көлеп җибәрә. Боларның көлүләре, салмак кына юырткан юаш «ГАЗәл» гөрелтесен җиңеп, озын урамның шау-шуына кушыла. Бу шау-шуга Сәет белән Таңбәкнең нидер әйткәләгәннәре дә, кабинаның ачык тәрәзәсеннән очып чыгып, өстәлә тора. Ике туганның «шымылдык», «калым», «той», «жаушы» кебек төтек-өтек сүзләре генә колакка исән-имин килеп ирешә.

—Таңбәк өйләнергә җыена,—дип Наил серле генә күзләрен кысты.—Акча турында ызгышалар...

—Кемдә кемдә, ну болардамы—боларда акча дигәнең басу тулы бит инде ул, яшьти,—диде Данияр.—Карбыз сатып та акчалары булмаса...

—Һы, аларда туй атна буе гөрли ди. Ак жол болсун, дип тели-тели, әле ике атнага да сузыла ди. Өстәвенә—калым! Калымга—затлы машина!

—Ну да?!—дип, Данияр кашларын күккә чөйде.

—Элек кенә ул болар ягында калымга биш-алты капчык кипкән җимеш биргәннәр дә—и бетте-китте, вәссәлам. Әттәхиятеңне укыта ул хәзерге туй!

—Әле ярый бездә карбыз үсми,—диде Данияр.—Калым, дип, атна буе туй, дип, без дә эшерелгән булыр идек ату.

—Беләсеңме, яшьти,—диде Наил, бик тә зур серен ачарга җыенган шикелле,—кичә кич белән Назлыгөл сине сорашты бит әле...

—Соң?!—Даниярның каны кайнап торган суга салынган термометр баганасыдай югарыга сикерде.

—Сон, мактадым инде сине!—дип көлемсерәде Наил.—Кулдан килгәнчә. Ни әйтсәң дә, яшьти бит син, пачти дус кеше.

—Шуннан?

—Утырган да шуган!

—Ничек?

—Ничек инде—ничек?

—Мине ничек итеп мактадың, дим!

—Үтереп мактадым! Озын буйлы, акыллы, шәп егет, дидем.
—Ярый... Тагын?
—Тагынмы? Үзе тыйнак, үзе шаян, бик тә юмарт, дидем. Кызык-мызыклар уйлап табарга ярата, дидем.
—Ну-у, бусы кирәкми иде лә инде...
—Нигә?—Наил, аптырап, Даниярга карады.
—Тилемсә икән бу, дип уйлавы бар тагын.
—Син нәрсә, яшьти?! Кызлар бит кызык-мызык ярата. Көләргә генә булсын аларга. Көлдерә белденме—син хан!
—Үзе нәрсә диде соң?
—Улмы? Һм-м...—Наил серле генә итеп читкә карады.
Ул арада «ГАЗәл»ләре чираттагы сату ноктасына килеп туктады.
—Җә?
—Аннары әйтермен...
—Аннары—тәмәке амбары!—дип түземсезләнде Данияр.—Ялындырма, әйт инде!
—Юк! Соңыннан,—дип кырт кисте Наил.
Валлаһидыр—кызык та соң инде бу карбыз дигәнең! Чилләдәме? Чилләдә кар белән боз инде мәгәр! Карбыз... Тәңренең татлы могъҗизасы!
—Бу дөньяда иң зур җиелмыс—карбыз!—ди Таңбәк, аның җиелмысы—җимеш була инде ул.
—Юк, кабак!—ди Данияр.
—Кабак яшелчәгә керә, ә карбыз—җиләк-җимешкә!—дип Наил Таңбәкне хуплый.—Шылдымы?
—Алайсам, кабак—иң зур яшелчә!—дип әле һаман да сер бирмәскә маташа Данияр.
...«ГАЗәл» тагын юлга кузгала.
—Җә, әйт инде! Ни диде?
—Кем ул?
—Кем-кем! Назлыгөл!
—Һә-әй, кемгә-әлбә, кемгә-хәлвә!—диде Наил, һәр сүзен вәкарь белән генә сытып чыгара, әле җитмәсә, үзе уклау йоткандай катып утыра, ялындыра...
—Нәрсә, колбаса йоттың мәллә?—дип Данияр дорфа гына иптәшенә текәлде.—Бик кирәге бар ие...
—Кемнең?
—Назлыгөлеңнең!
—Һә-ә-әй, күнел күзең күрмәгәч, маңгай күзең борын тишегендә була инде ул, яшьти,—дип Наил җан җире әрнегәндәй йөзен чытты, кара көйдә.—Аның бит сине күрәсе килә, синең белән очрашасы килә бит аның! Ә син?! Мокыт! Сөмсез...
—Кайчан?—диде Данияр, сабыры тәмам бетеп.
—Киләсе җомгада!
—Давай иртәгә!—дип гөлт итеп кабынды Данияр.
—Ну, пырдымсыз тәре!—диде ана Наил.—Һы... Соң, барыгыз, бүген үк очрашыгыз, миңа димәгәе... Унсигез яшьлек сып-сылу, бер чиләк суга салып йотардай кыз гомерендә күрмәгән кешене күрергә җиена! Ә син, иртәгә дә иртәгә, дисең...

## 4

Бүген җомга! Җомга бүген, җомга! Җәйнең соңгы көне... Данияр эшкә ашыга. Аякта җемелдәп торган, чын күннән тегелгән әр-яна затлы җинел ботинка!
—Кызлар иң элек аяк киеменә карый,—дигән иде аңа Наил. Данияр карбыз бушаткан акчасына кыйбат аяк киеме алды.
—Кызлар чәчәк ярата!—дигән иде Наил.
Монысын ул үзе дә би-и-ик тә яхшы белә!

—Кызлар кызык ярата!—дигән иде аңа Наил.

Бүген аның башы тулы кызык-мызык кына...

Күңел очына! Әллә кая очына күңел!

Данияр тулай торак коридорында тәмәке пыскытып утыручы авыл кызларын да искәрми.

—Әй, Данияр!—диләр алар.—Баедың мәллә? Борының күккә менгән бит, яшен суга күрмәсен!

Данияр дәшми. Данияр ашыга!

Җомга! Җомга... Әмма иртәдән бирле яңгыр ява. Әйе, валлаһи газим, «Көз—кызлар күңеле төсле: бер елмая, бер—төксе» икән шул ул...

Сөзәк борынын җыера-җыера, иренеп-чирканып кына, зәңгәр «ГАЗәл» тагын юлга кузгала.

Яңгыр исә, бермәлгә күбекләнеп-киңәнеп ала да, пыскып-тотәп ява башлый, ә икенче мизгелдә отыры көчәеп, борчак-борчак тамчыларын җиргә сибә.

Көз яңгыры бу. Әйе, бу яңгырны нәзберек-иркә «ГАЗәл» дә өнәми бугай, сату ноктасына би-ик зарланып кына, чыелдап-чинап туктый.

—Монае-кешкен, зурларын ташлагыз!—дип әмер бирә егетләргә Сәет.

—Тот!—ди Данияр.

—Ат!

—Тот!

—...

...Асфальтка килеп төшкән түгәрәк-симез карбызның кып-кызыл кисәкләре, коңгырт төшләре тирә-юньгә чәчелә. Авызын ачып катып калган Данияр, аптырап, Наилгә карый. Наил исә... Ә Наилнең... Әйтеп бетергесез күп нужа күргән кешедәй, чырае сүнгән, сытылган Наилнең.

—Анай үлде. Атай-исерек. Абый-төрмәдә!—дип ачынып-ярсып тезә башлады ул.—Беркайда да укымыйм мин! Бернинди дә сеңелем юк минем! Беркемем дә юк!

Авызын йомып катып калган Данияр, әсәренеп, Наилгә карый. Әле генә чырае сытылган Наил исә хәзер инде нигәдер көлә, ә үзенең күз төпләрендә борчак-борчак тамчылар җемелди...

*2000*

## Чебен

1

Туk гәүдәле, шакмак ияклe егет ашыкмыйча гына тоник тәрәзәле кара джипка кереп утырды.

—Син нәрсә, Бизон, әллә бозауладыңмы анда?—диде артта утыручы сакаллы егет һәм ризасыз гына учын учка сукты.—Ун минут үтте. Җә, булдымы, юкмы?

—Булды!—диде тегесе.—Соң, онытa язганмын, чәчәккә дип кире керергә туры килде. Мә, иң шәпләрен генә, классныйларын гына алдым!

—Кузгалдык! Кая... сәмәнне...

Джип, кинәт кенә чыелдап, урыныннан купты, сакаллы егет исә Бизон биргән акчаны саный башлады.

—Мулла, Кенәз кайчан кайта?—диде машина йөртүче егет.

«Биш мең бер йөз, биш мең алты йөз»,—дип авыз эченнән генә акча санап утырган Мулла сүгенеп куйды.

—Бл-лин! Башны бутадың!—диде ул.—Ә?! Бүген сәгать икедә. Төнге! Син, Фид, әзер тор, самолет каршыларга барасың бар!

—Мулла, син нәрсә—баралмыйм! Настя белән төнге клубка җыендык бүген!

—Арт саның белән уйламыйча, башың белән генә уйласаң барырсың!—дип сүзләрен теш арасыннан кысып чыгарды тегесе.

—Кенәзен әйтерием... Тапкан бит вакытын... кайтырга... Анасын саткыры...—дип сукранды Фидель.—Җүнле кешеләр, әнә, Яна ел каршыларга чит илгә йөрми, минем шикелле үз чыршыбыз төбенә генә ятып йоклый...

—Катырак ниткән иден мәллә?—дип көлемсерәде Бизон.

—Син нәрсә?! Эчмим бит мин!—дип кырт кисте тегесе.—Настяның күнелен күрә-күрә, тәки йоклап кителгән...

Егетләр көлешеп куйдылар.

Кала урамнарын өч тиенлек сагыз шикелле тиз сыланучан, ябышкак-бәйләнчек, төтеннән ысланган тозлы-комлы пычрак кар күмеп ташлаган иде. Әнә шул карны тирә-якка сиптерә-сиптерә, бу соры баткаклыктан тизрәк котылырга теләгәндәй, машиналар алга ыргыла.

—Фид, тормозни!—диде Мулла.

Очып диярлек барган джип кинәт кенә тизлегән киметте, супермаркет төбенә килеп туктады.

Кибет хуҗасын ит чабучы бүлмәсеннән эзләп таптылар.

—Жук бит әле, жегетләр, жук!—диде хуҗа һәм каймак ялаганда тотылган мәченекедәй гаепле күзләрен таш идәнгә текәде.—Тере акча жыюлары авыр бит хәзер, бик авыр...

Бизон үткен йөзле ялтыр балтаны бүкәннән кубарды.

—Ике атна гына булса да вакыт бирегез инде...—Хуҗа мөлдерәмә тулы күзләре белән кыяр-кыймас кына Муллага карады.

Мулла исә, ләм-мим дәшмичә, Бизон кулындагы балтага үрелде.

—... Тагын бер атна!—диде хуҗа.

—Ботарлар идем мин сине, тик дуңгыз ите ашамыйм. Ярый, өч көннән сәмән әзер булсын! Ярты-морты маташма, бөтенесе әзер булсын! Ниһаять, балта бүкәнгә чабылды.

Машинага чыгып утыргач, Фид:

—Төнге клубны үзем генә кәшәләрмен инде,—диде.

—Һы... Кәҗәгә—кәбестә... Анда сина ярамый! Сүзен үтми!

—Ничек кенә үтә әле! Җә, ярар инде, Мулла, карышма санә—«Шүрәле» кафесына Жаннаны жайладың бит әле.

—Жанна түгел—Җәүһәр!

—Исем алыштырудан сумма үзгәрми!—диде Фид.

—Урын алыштырудан, диген, томана «математик»,—дип кушылды сүзгә Бизон.

—Әгәр дә син ул наркотаңны ташламасаң, бетәсең, малай!—Мулла сүзне икенчегә борды.—Үзең дә, дәрәҗәң дә...

—Тормаячак та!—дип кысылды Бизон.—Точно тормаячак!

—Бүген генә! Бер көн! Бары—бер көн... Соңгысы... И все!—диде Фид.—О, кей?

—Соңгы тапкыр!—диде Мулла.

Шуның белән гәпкә нокта куелды.

Тубык тинентен шакшы соры карны тирә-юньгә сибә-чәчә джип алга ыргылды.

... Төнге өчләр тирәсендә Бизон Муллага сугылды.

—Булдымы?—дип сорады Мулла.—Кенәзнең кәефе ничек?

—О, кей! Самолет кына бераз соңарды соңаруын. Тик минә... Карале, әй, Фид тагын юкка чыкты бит...

—У-у, анасын корт чаккыры!

—Җавап та бирми...—дип Бизон кесә телефонын чыгарды.—Төнге клубта булабыз, дигән иде дә...

—У-у, бабаңның кабер тактасы!—дип улады, аты-юлы белән сүгенде Мулла.—булмый болай! Шартлатырга што-ли инде ул төнге клубны?!

Фид-Фидель-Фидаилнең әкренләп наркоманга әверелә баруын егетләр бик авыр кичерәләр иде.

...Кинәт сугудан төнге клуб директоры бөгелеп төште.

—Фид кайда?—дип кабатлады Мулла.

—Бел-мим...—диде өзек-өзек сулыш алган директор.—Бүген озак утырмады, тиз тайды бугай ул...

—Җиде ел бушка эшләтәм әле мин сине, с-сука! Соңгы тапкыр кисәтәм: Фидельгә тагын наркота бирсәң... Ул анаша-манашаңны арт тишегенә тыгып куям әле мин синең, падла!

Шулчак ишек ачылып китте, Бизонның шау-шулы, яшелле-күкле музыка белән чәбәләнгән тавышы ишетелде:

—Таптым, Мулла! Настя—кече залда!—дип сөрән салды ул.

Кече залда сигез кызый, дүрт егет шашына-шашына бии, чиный, очына-сикерә, бер бөгелә, бер турая, кыскасы, җан фәрманга ду килә иде. Җирнең тарту көче дигәннәре бу кызыйларга бөтенләй кагылмый иде ахрысы—әйтерсең лә алар, тәмәке төтенедәй, йөзә-чайкала биек түшәмгә тартыла, болай да кыска итәкләре исә, аска төшәсе урынга, һаман саен өскә күтәрелә бара иде.

Бизон Настяны шәрә беләгеннән эләктереп алды да җилтерәтеп кенә Мулла каршына китереп бастырды.

—Фид кайда?

Әллә боларны танымады, әллә ишетмәде, кызый, калайланган күзләрен уйнатып, сакаулана-тотлыга кычкыра башлады:

—Нәсә карап торасың? Щ-щас как дам по х-х-харе!

—Мәгънә юк... Күкнең җиденче катында йөзә бу!—диде Бизон.

Клубтан чыгышлый аларга бер танышлары очрады һәм ул Фидның, такси тотып, берничә егет белән тимер юл вокзалы ягына китеп баруын әйтте.

—Беткән икән бу Настя тәмам...—дип Мулла уйчан гына башын чайкады.—Баш-аягы белән сазлыкка чумган. Чыгалмас.

—Фидны да бетерәчәк, кәбих! Шул гына өйрәтте бит аны, өстерәп кертте, сучка!—дип җөпләде Бизон.

Менә сиңа Настя-Нәфисә... Нindидер бер йөз яшьлек карт аның турында роман да язган бугай әле. Унтугыздагы бу кызыйны, кем әйтмешли, бер кашык суга салып йотарлык иде. Карап торышка... Ә күңеле? Күңеле—бөкре карчык.

Фидны тимер юл вокзалы янәшәсендәге төнге казинодан эзләп таптылар. Тәгәлрәге, казино ишегалдыннан. Тагын да тәгәлрәге, әнә шул ишегалдында басып торган Ленин һәйкәленнән!

Кайчандыр бу бинада партия райкомы урнашкан булса кирәк. Ул заманда таш сынның бинага юнәлтелгән кепкалы кулы үзенә күрә бер мәгънә дә аңлаткандыр әле. Йә матур, якты-бәхетле киләчәккә әйдәгәндер. Хәзер дә аңлата. Әйтерсең лә ул, бөгәрләнеп беткән кепкасын сузып, казинодан хәер сорый...

Фид, ике метрлы постаментка менеп басып, бер кулы белән Ленин бабайның таш ботын кочаклаган да... пес итеп тора иде.

Әйе шул, валлаһидыр, әйткәннәре хак икән: әле бит саф-аек баштан да сине кайчагында шундый бер тыелгысыз теләк биләп ала ки, югарыга менгән саен аска—өстән аска—түбәндәгеләргә төкерәсе килә башлый!

Фид, анысы, арттырыбрак җибәргән. Җитмәсә, ул чәптергән нәзек фонтан һәйкәл төбендәге машинаның түбәсен юа иде!

—«Мерс-600»!—диде Бизон мәгънәле генә.

—Кемнеке?

—Әллә тагын... Мәскәү номеры белән...

—Әйдәле, бу әтәчне тизрәк йолкып алыйк та эзне суытыйк! Зурга киткәнче...—диде Мулла.

Әмма алар Фидельне «кунача»сыннан өстерәп төшерергә өлгермичә калдылар. Казинодан өерелеп, ду килеп биш егет йөгереп чыкты. Бишесе тиң ләх исерек иде. Бизон, тагын да мәгънәлерәк итеп:

—Болар шаяра торганнарга бер дә охшамаган...—диде.

Дөрестән дә, аты-юлы белән пыр тузып сүгенешкән тавышларга корал корган аваз—затвор чыңлавы кушылды.

—Шул гына житмәгән иде!—дип Мулла касыгындагы пистолетын капшап куйды.

Үзенә төбәлгән көпшәләрне күргәч, Фид та айнып китте. Әмма бер мәлгә генә, икенче мизгелдә исә ул шашынып-шашынып көлә башлады.

—Күзләре калайланган монын,—дип уйлады Мулла.—Коралга ябышса, бетте баш!

Ниһаять, Фид көлүеннән туктады. Акаеп аска карады.

—Пистолетын тартып чыгарса, бетте баш, атыш китәчәк, тетмәсен тетәчәкләр монын,—дип өтәләнде Мулла.

Бер. Ике. Өч... Дүрт! Тын. Тып-тын. Һай, нәни генә бер жил чалымы да, хәтта тамак кыру да утлы давылга сәбәп булачак! Тынлык. Йөрәк—дөп-дөп...

Мулла, сак кына атлап, уртага чыкты.

—Гаеп бездә, егетләр,—диде ул.—Әйдә, килешик!

—Ух, син, мразь!—дип тегеләрнең берсе кинәт кенә алга талпынды.—Шалканыңны чәчәм бит хәзер!

—Бетте баш! Буран кубачак...—дип Мулла пистолетына тотынды.—Ярый, беткән баш—беткән, Флүр булсам да, флюгер түгел әле мин!

Шул мәлдә казино ишеге төбеннән:

—Ба! Муля! Нихәлләр? Отбой, егетләр!—дигән көр тавыш ишетелде.—Үзебезнекеләр!

Таныш тавыш! Сон, бу бит детдомда бергә аунап үскән Кефир ләбаса! Валлаһи газим, үзе! «Муля» дип аңа ул гына эндәшә ала...

Кефир белән Мулла кочаклашып күрештеләр.

—Амбалларыңны ал!—диде Мулла.

—Ә син—бу сигәгенне!—дип көлде Кефир.—Әле генә Мәскәүдән алып кайткан өф-өр-яңа «Мерседес»ны шулай мыскыл итсеннәр инде, йә!

—Чебен гомере... Өреп төшерергә дә өлгермисен, инде эрегән була,—дип Бизон борын очына кунган кар бөртегенә өрде.—Чебен гомере...

Фид-Фидель-Фидаил исә, таш сынның ботыннан кочаклап, йокыга талган иде.

## 2

Һай, бу кинлек, зурлык—хозурлык! Әйтерсең лә мең чакрымнан мең чакрымга сузылган бу ап-ак дөньяда алардан гайре һичбер жан иясе дә юк! Әйтерсең лә йоклап яткан биниһая зур ак аюның сырт йонында нәни генә бер кара борча тыпырчына... Бу кара борча—машина.

Флүр тизлекне арттырды. Фәлән хәтле ат кынамы—фәлән кадәр жен көченә ия булган куәтле «БМW», отыры ашкынып, тайгак бозлы юлдан алга ыргылды. Янында утырган Җәүһәр, ләм-мим дәшмичә, гөләп бәйләмен күкрәгенә кысты, арткы утыргычта исә торт-морт ише тәмтомнар биеште.

Һай, бу хозурлык, һай, бу нарат урманы! Төз, алтын баганалар иксез-чиксез зәңгәр күк гөмбәзенең үзен терәтеп торалар иде сыман.

Флүр янә тизлекне арттырды. Инде болай да куркып кына, күзләрен чытырдатып йомып кына барган Җәүһәр түзмәде, егетнең беләгенә ябышты:

—Үтерәсең бит! Әкренрәк барчы...—дип ялварды ул.

—Сон, бахбай тыңламый. Ташбака түгел бит ул сиңа! «БМW»!—дигән булды тегесе.

Башта берән-сәрән генә төшкәләгән ябалак кар хәзер инде бөтен тирәлекне билэп алып, кинәнеп ява иде. Хәтта бурап-бурап ук ява.

—Менә кайда ул хозурлык!—дип сокланды егет.

Эрләп бәйләсәң, бу кардан менә дигән үтә күренмәле өрфия шәл

чыгар иде! Шулай дияр иде әбисе. Бәлки, әнисе?

Әбисен түгел, әнисен дә күргәне юк аның. Бер яше тулар-тулмас чагында кемдер аны балалар йортына китереп ташлаган ташлавын. «Флүр Хисамов» дигән язуны муенына тагып... Менә шуннан бирле аның гомере башы өзеп ташланган аклы-каралы кинофильм тасмасыдай тәгәри дә тәгәри. Исән микән аны тудырган кеше? Күрергә иде бер шуны! Юк, кирәкми! Кирәкми!

Ул тагын тизлекне арттырды. «БМW» артын сикертеп чапкан юргадай кылана. Ни хикмәт, Җәүһәр тып-тыныч, хәтта күз ачып, сагыз чәйнәп бара иде. Аңламассың бу хатын-кызны...

Ап-ак кар бозлы юлга келәм җәя. Калада да явадыр инде бу кар. Тик анда тотеннән ысланып, тозлы-комлы сазга әйләнеп бетә бит ул, бахыр. Аңлатып кара син—инде пычранып, каралып, тапталып беткәч кенә—әле туганда һәм яуганда да ап-ак идем бит мин, саф-пакъ идем лә мин, дип... Һичкем ышанмас, сине хәтта тыңларга да теләмәсләр!

Флүр янә кызыйга карап алды. Укалы чытыртыйга төрелгән алсу гөләп чәчәкләрен Җәүһәр өч айлык корсагына кыскан. «Чәчәген сайлый белгән дә соң инде, молодец, Бизон!—дип уйлады ул.—Кызык: малай микән, кыз микән?..»

Җәүһәр—назлы, татлы, затлы исем. Алты хәрефнең бишесен урысчага аудара торган түгел. Аударның исә—бетә, сытыла, югала исем. Флүр түгел инде һәрхәлдә. «Мөгаен, Актаныштан булгандыр,—дип уйлады ул әнисе турында,—сәер исемнәрне ул якларда бик яраталар. Их, Флүн, Флүс кебек энекәшләрем булсамы хәзер?!»

Алдавыч кар келәме каплаган юл үргә күтәрелә башлады. Зур тизлектә бозлы тауга менүе дә, бозлы таудан төшүе дә вөҗүденә татлы, иллә дә шәп—үтергеч шәп, газаплы ләззәт бирә. Төшүе—төшү әле аның, ә менә һәркемнең югарыга менәсе килә, беркемнең дә аста каласы килми бит, шайтан алгыры!

Җәүһәр түзмәде:

—Саграк кылан! Каршыга машиналар очраса...—дип янә егетнең беләгенә ябышты.

—Тик кенә утыр әле!—дип Флүр тагын газга басты.

Өйләнү турында сүз Җәүһәр балага узгач килеп чыкты. Озын-озак уйлап тормады егет, «ярар» диде, килеште. Әнә шул «ярар»дан соң, инде менә, ниһаять, ике айлап вакыт үткәч, Җәүһәрнең әти-әнисеннән кыз сорарга кайтып барышлары.

—Вакыт юк әле. Язга кайтырбыз...—дигән иде дә...

—Юк-юк, аннары соңарабыз, беленә башлый,—дип тәки чат ябышты бит, чәчби, кем әйткәндәй, шүрәлене шундук мөгезеннән алды.

Менә шулай иттереп, Флүр утыз өч яшендә өйләнергә булды.

... Гайсә пәйгамбәр яшендә ягъни. Өч бүлмәле фатирым, ике машинам, үзем, кашым да күзем, дип кенә йөрисе чакта. Менә шул. Утыз өчтә! Адәм рәтле, юньле бер эш тә кырмаган килеш... Такташ, әнә, утызда ук ычкынган. Император Нерон инде бу яшьтә дүрт ягына да ут төртеп Римны яндырган, абыйсының башын чаптырган, анасын мендәр белән томалап үтергән. Һы... Ә менә син, утыз өч яшьлек мокыт җан: «Бу кызый баласын тудыргач та читкә-чүпкә ташлап калдырмас,—дип шөкер итәсең.—Флүр булсам да, флюгер түгел әле мин!—дип үз-үзеңне тынычландырасың.—Миңа да, бәлки, передача илтерләр әле»,—дип өметләнәсең... Ә бит Җәүһәр белән син—янәшә бара торган менә шушы ике юл—ике тәгәрмәч эзе кебек кенә. Алар мәңге кисешмәячәк. Алар кушылмаска яратылган. Анысын да беләсең. Каян? Китек күңелең төпкеленнән күтәрелгән сиземләвең шулай дип әйтә! Өч көнлек бу дөньяда һәр минутның, һәр мизгелнең кадерен бел! Һәр чүптән дә тәм, шатлык, ләззәт тап—монысын да чамалыйсың. Тик ни житми сиңа, Мулла—Флүр, әбекәең с-суга төшкере!..

...Ниһаять, кайтып життеләр. Карурман куенына поскан ике урамлы кечкенә генә бер авыл иде бу.

Аларны каршыларга әниләре чыкты.

—Әйдүк, балакайлар, исән-саулар гына кайтып життегезме!—дип ул башына бөркәнгән ак яулыгының чите белән күзен сөртте.

Күчтәнәчләрне күтәреп өйгә керделәр. Флүр, чишенеп, түргә узды, тәрәзәдән ишегалдына карады. Валлаһидыр, көн матур бүген! Ап-ак, йомры йомшак кар ява... Шул аклыкны күнелле генә төрләндереп, чуар тавыклар нидер чемченеп йөри, дәү генә гаярь әтәч алар каршында кәпрәйгән була, ирлек бурычын үтәргә маташа. Ул да түгел, тәрәзә пыяласына (менә сиңа—вәйт!) чебен килеп кунды. Чып-чын, тере чебен! Безелдәгән дә була үзе, каядыр талпынгандай да итенә. Бәргәләнә. Карале син, ә! Бу чебен дигәнен язы-җәе-көзе буе тәмам эчне пошырса да, кышларын тансык бер җан иясенә әверелә дә куя икән бит, әй!

Кинәт капка ачылды. Урамнан сәнәге белән салам күтәргән ир керде. Агайның күз төбе күгәргән иде.

—Әби кундырган булса кирәк,—дип көлемсерәде Флүр.—Ә, бәлки... Бәлки, сыер сөзгәндер...

Ул да түгел, өйалдыннан әнисенең:

—Малларга печән салдыңмы? Чибәркәйгә башак болгатырсың! Мунчаны томаларга онытма!—дигәне ишетелде.

Күз төбе кара көйгән ир, ләм-мим дәшмичә кулына сәнәген тотып, янә капкасына таба атлады.

«Телсез што-ли бу?—дип уйлады егет.—Мин булсаммы?! Каяле, чыгып керим әле...

...Салам күтәргән агайны ул машинасы янына чакырды. Тегесе дә, шуны гына көтеп торган сыман, сәнәген саламы-ние белән капка төбендә калдырып, егет янына килде. Исәнләштеләр. Таныштылар.

—Тотасыңмы... әзрәк?

—Сың... Ни инде, булса—каршы килде юк!—дип агай ләззәти генә кеткелдәп куйды.

Флүр бер шешә аракы, чәркә, банкалы шампиньон гөмбәсе чыгарды, савытны тутырып хәмер салды.

—Ә үзең?

—Эчмим. Ярамый.

—Ә-ә, алай икән. Сың... Ни... Дөрес эшлисең, кем... Кияү! Менә мин дә ташларга ниятләп торам бит әле. Сың... Ни инде... Бер дә юнһегә-нигә чыгара торган нәмәрсә түгел инде. Яшь чагында яшьлекнең кадерен...

Колач җәеп фәлсәфә куертырга керешкән бабай кешенең әйтеп бетергәнен көтеп тормады егет, болай диде:

—Ярый, мин өйгә керәм. Теләгең булса, машина бикле түгел, үзең карарсың!

Өялдыннан кереп барышлый, ярым ачык ишектән (әллә песи чыккан, әллә көйгән коймак исе таралсынга ачып куйганнар) кыз белән әни кешенең гәбе ишетелде:

—И-и, әдәм тәганәсе, өч айлык корсагың белән...

—Ән-ни, дим! Җитте инде сиңа, яме!

—Җитте шул! Җитмәгән кая ул... башыма җитәсез бугай инде. Әдәм хуры! Нәсел-нәсәпсез бәндәгә кал инде менә... Чыраена чыккан бит анын—бандит ул, бандит! Күңелем дә сизенә... Йә, Раббым!

—Ну, әни, житте, дим! Кереп тә килә бугай әнә...

—Карале, кем диеп әйтим сың мин аңа?!

—Менә сиңа—мә! Кияү, диген!

—Йә, Раббым...

—Флүр, Флүрчик?!

—Әү?

—Кайда йөрисең, әйдә, чәйләп алабыз,—диде Җәүһәр.—Әти маллар карый торгандыр әле анда—соңрак керер.

—Әтиегезне сыер сөзгән иде,—диде әнисе һәм чәй ясый башлады.—Чирләштеребрәк йөри әле бу арада.

Чәй кайнар иде. Егет иренен пешерде.

—Сөт салыйммы—суыныр,—диде Җәүһәр.

Әмма тегесе дәшмәде, чәен чөмерә бирде.

—Әй, балалар, исән-сау гына йөри күрегез инде. Заманалары да бик буталчык бит аның хәзер...—диде алар янына килеп утырган әнисе.

...Чебен, тәм-томнар куелган тәлинкәләрне бер урады, өч урады, биш урады да, урап әйләнүләреннән туйган сыман гына иттереп, бал савытына килеп кунды.

—Бу да балны ярата, хәйләкәр,—дип елмайды егет.—Акыллы чебен.

—Аш та житешә хәзер. Чәй өстимме, кем... кияү? Менә, коймагыннан житеш!—диде әнисе һәм балга кунган чебенгә тастымалы белән селтәнде.

Чебен исә бал савыты читеннән өстәл почмагына кунды. Шап!—Кызыл чуклы тастымал чебенне идәнгә сыпырып төшерде.

—Менәтерә, и Ходаем, кыш уртасында өйдә чебен чыксын инде, йә!—диде гажиз калган әнисе.

Флүр, рәхмәтен әйтеп, табыннан кузгалды, янә тәрәзә янына килеп, тышны күзәтте. Күз төбе күгәргән агай инде салам ташымый иде. Бер-ике мәртәбә машина тирәсендә әвәрә килде дә бөтенләй юкка чыкты бу. Һәркемнең бәхете үзенчә, фәкать үзенчә генә шул. Салам... Алтын салам бөртеге, имеш. Жәен балыгыдай төпкә-ләмгә чумарга туры килсә, авылына да кайтмагаең... Шушы агай кебек саламын да ташырсың, тиресен дә түгәрсең, ә Жәүһәрбикәң сыер савар. Тырнакларының кызыл буявы тиз уңар, куллары-бармаклары, уч төпләре бирчәеп, бөрешеп бетәр... Шулай шул... Бәхетеңне бер сыер сөзсә, гомереңбуе салам ташыйсың икән ул.

Менә сиңа—вәйт! Чебен исән икән бит әле! Имгәнгән канатларын өстерәп, тәрәзә пыяласына үрмәләп маташа.

«Урамга—кар күбәләкләре янына чыгасы килә моның!—дип уйлады егет.—Шулай ул, жәйнең жылылары гына жылытмагач, кыштан жылы эзлисең. Бу дөньяда син дә, вакытлы-вакытсыз чыккан шушы кышкы чебендәй, кемнәрнеңдер бик тә, бик тә эчен пошырасыңдыр. Ә язмыш дигәннәре сине кая кунсаң, шуннан сыпырып төшерер, сытып үтерергә дә күп сорамас!»

Аш бүлмәсендә тәлинкә-кашык, чынаяк шылтыраганы ишетелде. Бераздан кыз егет янына килде, аның иңенә сарылды.

—Көн матур бүген, иеме, Шүрәлем!—диде Жәүһәр һәм кызылга буялган озын тырнаклары белән тәрәзәдәге чебенне сытты.

### 3

Тонык тәрәзәле кара джип зират капкасы төбенә килеп туктады. Мулла, машинасын бикләп, култык астына ике бәйләм гөләп чәчәген кыстырды да эчкә узды.

Кыштан бирле, Бизон белән Фидельне күмгәннән бирле килгәне юк иде. Менә килде. Хәер сорап утыручы карчыктан гайре зиратта бүтән кеше күренми. Мулла, шыгырдап торган яшел акча чыгарып, хәерчегә сузды. Тегесе, калтыранган кулы белән акчаны алды да, авыз эченнән генә нидер мыгырданып, бер-ике мәртәбә битен сыпырды. Карчыкның күзләрендә бәгырьне чеметтереп ала торган ниндидер бик тә нәзек, бик тә серле-тансык, бик тә үз-якын бер чалым пәйда булды. «Зиратта хәерчеләр дә изгегә әверелә ахрысы»,—дип уйлады Мулла. Ул карчыкка жентекләбрәк, текәлебрәк карады. Теге чалымны эзләве иде. Әмма дә хәерченең күзен мәгънәсез бер томан пәрдәсе каплаган иде инде.

Кала яулап алырга әзерләнгән гаскәр кеби кабер ташлары тезелеп киткән. Гүя дә бу ташлар: «Мондагы тынлык—тынлык түгел әле ул, менә чыгыйк кына, тыкрыкларны, урамнарны басып алырбыз. Менә шуннан соң Тынлык башланыр!»—дияләр иде кебек.

Бередә—Мулланың яшьтиләре. Күбесе таныш. Йә Хода, никадәр кеше кырылган! Әфган, Кафтау сугышында да түгел. Монда. Якында гына.

Кук-ку, кук-ку, кук-ку... Зират күкесе кычкыра. Елны саныймы, айнымы, көннеме?..

Әнә, алагаем мәһабәт кара мәрмәр кабер ташларыннан аңа дуслары

карап тора. Бизон да, Фидель дә сурәткә гел елмаеп кына төшәләр иде. Әмма дә бу ике сурәт аның күңеленә бүген шом йөгертте. Әйтерсең лә болар: «Без сине кыштан бирле көтәбез инде, браток, монда сиңа да урын житәрлек»—дип аны үз яннарына чакыралар иде.

«Ашыктырмагыз! Әле миңа иртәрәк!»—дип уйлады ул. Нәрсә ул гомер? Башта менә шуңа төшенәсе бар! Ә синең гомерең, Мулла-Флүр, башы да, азагы да кисеп ташланган аклы-каралы кинофильм тасмасыдай түгелмени?! Әнә, урам этләре генә ул, бүгенгесе белән яшәп, бүгенгесен генә хәтерли...

Кичә ул күрәзәче карчыкка барды. Мезозой чорында дөньяга килгән диярсең: күзе кысылып, теше коелып, бөкрәеп-шәлперәеп беткән әбекәй ана серле генә болай диде:

—Башы да, азагы да бер икән, олан, бер икән...

Егет аңышмады.

—Мин монда кроссворд чишәргә килмәдем. Турысын әйт—кайчан?!—диде ул төксе итеп.

—Кызыл күлмәкле зат белән очрашырсың,—дип (әллә аны ишетте, әллә юк) сүзен дәвам итте карчык.

—Кем ул?!

—Якын кешең. Хатын-кыз...

—Кайчан?!

Карчык дәшмәде.

Егет куен кесәсеннән бер төргәк акча чыгарды. Йөзәр долларлык ике яшел кәгазьне әбинең итәгенә салды. Әмма күрәзәче дәшмәде. Ул тагын чыгарды, тагын салды. Тик файдасыз. Ахыр чиктә төргәге-ние белән тегенең аяк астына ташлады. Вәләкин әби дәшмәде. Аның күзләре йомык, ул әллә йоклый, әллә мәрткә киткән, әллә үлгән үк иде...

Менә шул.

Кем икән? Кем икән ул кызыл күлмәкле хатын-кыз?! Җәүһәр түгел! Бердән, аның кызыл күлмәге юк. Аннары, аның белән очрашып торасы да түгел—болай да гел бергә. Кем икән соң ул алайсам? Элегрәк чуалган чәчбиләрен дә күз алдыннан үткәрде. Тик аларның берсен генә дә «якын кешем» дип әйтеп булмый иде шул.

Мулла зират капкасына табан атлады. Нигә дип кенә киләсе итте соң әле ул монда?! Ни тартты? Инде череп таркалган дусларымы? Үлемнән курку хисен үлем иленә килеп бетерү теләгеме?

Саилче карчык баягы урынында иде. Егет аның күзләреннән теге чалымны эзләде. Әмма бу юлы да томан упкыны гына иде бу күзләрдә. Ул янә кесәсеннән яшел акча чыгарып хәерчегә сонды. Тегесе исә, дерелдәп торган нәзек куллары белән битен сыпыргандай итенде дә, нигәдер тиз-тиз генә китү ягын карады. Ул да түгел, артта саллы адымнар, һәм бик тә таныш, тонык «пылт»-«пылт» иткән тавышлар ишетелде. Бу тонык тавышларның ни икәнлеген яхшы чамалый иде егет. Шуңа күрә дә бер мизгел эчендә киерелеп алга атларга, борылырга, качарга теләде. Тик... соңарды. Арттан тишкәләнгән аркасы, башы, бар вөҗүде инде кайнар утта яна иде аның. Ул җиргә ауды. Юк, җиргә түгел, куркуыннан тротуар ташына абынып егылган карчыкның йомшак җиренә барып төшкән иде ул. Зират күкесенең тавышын ишетергә барыбер өлгерде егет. Күк-кү, күк-кү, күк-кү... Елны да, көнне дә, сәгатьне дә, минутны да түгел, секундны санный торган күке иде бу...

Һушына килгән карчык, торып, шундук агачлар ешлыгына чумды.

Егетнең иягенә кунган чебен исә, талпынып, аның баш очында бер-ике мәртәбә әйләнде дә, югарыга—инде сары төс иңгән каен яфраклары арасында кайнашкан кардәшләре янына кереп югалды.

Бераздан карчык, качкан урыныннан чыгып, мәет янына килде, «Әй, апаем, әй, апаем»,—дия-дия, аның кесәләрен актарырга кереште. Әллә кайчан, инде мең былтыр элек үк төсе уңып киезгә әйләнгән, әйтерсең лә дөньяның бар булмыш кара керен үзенә җыйган коңгыртсыман бу күлмәктә, бик тырышсаң, кызыл төс чалымнарын шәйләргә була иде.

*2001*



# Фәнәвис Дәүләтбаев

## КЫСКА ШИГЫРЬЛӘР

Тик бер карыш үткән юлым -
Иллегә дә җитмәгәнмен.
Яшьлеккә дә, картлыкка да
Билләһи лә чит адәм мин!

Күңелемә һәрчак тансык
Бу эшем һәм ашым, диям.
Кирәк булса, мең тапкыр да
Шигъриятькә башым иям!

Вакыт карынында гасыр.
Тулгак тота галәмне.
Шомлы, билгесез киләчәк...
Юк, юатмый адәмне.

Ходайны диләр күктә,
Шуңа күңелдә үпкә.
Җирдә булса безнең тормыш
Яхшырыр иде күпкә.

Фәнәвис ДӘҮЛӘТБАЕВ *(1951) - шагыйрь, «Суз җырыңны, былбылым!» исемле китап авторы. Актаныш районында яши.*

Ходайга табынган кеше
Җирдә гөнаһ җыймас...
Үзем тыймасам үземне,
Мине беркем тыймас!

Үзәндә кое казыдым,
Чыкты суым ереккә.
Үземнең дә ерексезлек
Үткән иде җелеккә.

Барс каршы торалырмы
Ике башлы бөркеткә?
...Халкы тырнак астындагы
Ил язмышын ни көтә?

Ярым ай өстендә тәре
Тырнагын батырган да,
Гүя сөенә калҗаның
Симезен каптыргангa.

Кан койганга - акча,
Җан кыйганга - акча.
Үкенү юк башкисәрнең
Мәете илгә кайтса.

Ташла эшең, турай да бер
Әй, милләтем, күккә кара.
Синең өстән Рәсәйнең
Ач бөркете очып бара!

Күккә бактым - анда син юк.
Җирдән эзләп тапмадым.
Шул газаплы, татлы уйдан
Юктыр әмма кайтканым.

Син дә сөю баласы,
Мин дә сөю баласы.
Яратам, дип әйтергә
Әйт: кемнән оясы?

Синнән дә якын юк иде
Кайчандыр йөрәгемә.

Инде хәзер әверелдең
Мәхәббәт өрәгенә.

Башны идермәкчеләр,
Камыт кигермәкчеләр.
Бу илдә без болай да
Коллар һәм хезмәтчеләр!

Кала һәрчак бер кырыйда -
Колның фикере колча.
Ишәк булырга да риза
Алдында тәгам булса.

Иксез-чиксез офыккача
Шигърият даласы.
Мин фәкыйрьгә уйга батып
Барасы да барасы.

Горур буласы килә лә,
Көчле буласы килә.
Бәхетен көрәшеп тапкан
Кеше буласы килә!

Иҗат итәр өчен килдем,
Җимерер өчен килмәдем.
Җиңеп китәр өчен килдем,
Җиңелер өчен килмәдем!

Шыңшый торгач ирексездән
Елакка әвереләдем.
Көн дә тукмаклап яшәгән
Мин колы дәверемнең.

Үз-үземә коры тордым,
Авышмадым, туры тордым.
Булмадым ялагай эте
Болганчык вә соры чорның.

Без дә шөкер исән әле,
Җир дә үз кучәрендә.
Гасыр башы... Аллаһының...
Ни икән исәбендә?..

# Çəçmə əsərlər
# Чәчмә әсәрләр



## Фәрит Яхин

## АТ УЕНЫ

хикәя

**1912** елның икенче сентябрендә тиз йөрешле «Меркурий» пароходы, Нижгар шәһәреннән Казан каласына юл алды. Сәфәрләренең чалт аяз көннәр белән озатып, шулай ук матур кичләрдә Идел елгасы буйлап дәвам итәчәге юлчыларның күңеленә зур сөенеч өсти иде.

Атаклы байларымыздан Гатауллин Шаһимәрдан Гатаулла улы да, бәракаллаһ, шушы рәхмәтле көймәдә иде.

Озакламый байлар ресторанга җыела башлады. Гатауллин да шунда юнәлде. Һәр тарафка йөз балкытып торган зур-зур тәрәзәле ресторан залы гүяки аны киң күңел белән каршы алды. Гатауллинның күзе нигәдер түргә, кадими киемле, елгыр күзле, тимер бәдәнле, җирән сакаллы кешегә төште. Теге дә карап куйды. Гатауллинның колагы чынлап, йөрәге юктан гына жу итеп алды. Затлырак урын булсын, дип, үзе дә түргәрәк атлады, өч кешелек өстәл янына килде. Шактый гына санга җыелырлык халык рәхәтләндереп татарча сүз куерта, арада хәтта шешәле сыра алдыртучылары да бар иде. Мосафирларның шушы кадәр үзләрен иркен тотулары Гатауллинның күңеленә хуш килеп, баягы адәмнән шомлануы озак та үтмичә юкка чыкты. Ул арада килеп тә житкән ак пинжәкле, кара чалбарлы официант, баскан урынында бераз таптанып алганнан соң, түбәнчелекле кыяфәттә урыс акценты белән татарча сорады:

—Ни боерудасыз?

Әмма Гатауллин аның кыенлык белән әйтелгән сүзләрен аңлый алмады. Официант җитез генә кабатлап өлгерде. Гатауллин шунда гына урыс авызыннан чыккан татар сүзенең матурлыгына игътибар итте һәм:

—«Йолдыз» гәзитәсе юкмы?—дип сорады.

—Бар, әфәндем!—диде официант.

Гатауллинның күңеле хушланып, тагын да чәй китерергә кушты.

—Аннары тагын да әмер итәрмен!

---

*Фәрит ЯХИН (1961)—шагыйрь һәм прозаик, «Пәйгамбәребез Мөхәммәт», «Ак әбиләр догасы» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

«Йолдыз» гәзитәсе үткән атнаныкы иде. Казан һәм Рәсәй хәлләре белән бергә, дөнья йөзендә булып яткан вакыйгаларга да бәяләр бирелеп, базар хаклары һәм башка шуның ише вак-төякләргә игътибар юнәлтелгән. Танышып чыккан мәкаләләреннән Гатауллин канәгать калып, «Болгар» кунакханәсендә люкс нумерларның күпме торганлыгын исенә сендерде. Бер кич кунып чыгу өч сумга бәяләнә икән. Ярый-ярый, элекләрне кандалалары белән бергә бишкә кадәр иде, хәерсезләрнең! Белдерүләреннән аңлашылганча, яхшы тәрбия күрсәтәчәкләр, милләтне сөендерәчәкләр, имеш.

Гатауллинның хәтерендә биш-алты ел гына элгәре булып узган вакыйгалар яңарып, күнеленә куаныч белән бергә дәрт һәм минминлек вәсвәсәсе тулды. Атасыннан калган мирас янына үзенең туктаусыз тоткан сәүдәсеннән кергән табышының кадерен дә белә, теләгәнчә сарыф та кыла торган иде. Казанның татарлар телендә «Искәндәр сарае» дип йөртелгән «Александр пассажы»на җигүле ат белән кереп, түтәйләр янында атналар буена калып, ахырда ак ыштаннан гына чыгып качкан вакытлары да аз булмады. Ә килеп керүләре, һәй... Дөнья малы белән шаярды да инде! Татарга биш хатын да фарыз, дигән сүзләрне аз әйтмәде. Арчадан чыгуга, алдан иярдә атчы Галәвине җибәреп, Казан пәлисәсенә әйттерә иде дә, бар ашкыну белән кала урамнарына томырылып, алдан юырттыручының коерыгына бастырып чаптырта иде. Хәтта «Искәндәр сарае»ның да капкаларын ачып:

—Гатауллин үзе килә!—дигән шау белән каршы ала иделәр.

Бар иде заманалар, бар иде атларны баштанаяк киендереп, яхшы чана белән тарантасларны ел эчендә туздырып ташлаган чаклары!

Кичкә ресторанга дип күтәрелгәнендә халык кәефенә хәйран калырлык иде. Дуслары һәм көндәшләре булган Казан сәүдәгәрләре Гатауллин белән эре генә исәнләштеләр. Тик сыра түтененнән башы әйләнгән тиречe Янбаш Гыйльметдин белән Кече Камалетдин гына, аның җилкәсенә кулларын салып, яннарына әйдәкләп утырттылар.

—Шаһимәрдан... Шаһимәрдан... Утыр әле, сөйлә әле... Ак атыңны әйтәм...—дип борчый ук башладылар.

Әмма сүз ак юртак хакында түгел, бәлки Мәкәрҗә хәлләрен искә төшерүгә күчеп, татар театрын сүгүгә, татар мәдәниятын җиргә салып таптауга, хәтта кечкенә күренгән вакыйгаларны олы сәясәт итеп сөйләшү мәсьәләләренә кереп китте, һични аңламаган, надан һәм ахмак кешеләрнең зурдан кубып гәп оруларына охшап калды. Бу тиречеләрнең бөтен хәсрәте кадими ыштанга һәм җиләнгә күңел баглау гына булса да, ахырыл-әмер, соңгы елларда җәдитләнеп китүләренә хәйран итәрлек иде. Хәтта башларына Аурупа эшләпәсен кию, ак яка өстеннән төсле бант тагу, кәчтүмнән йөрүне дә дөрескә чыгарганнар, житмәсә, үзләре дә шулай киенеп алганнар. Сөйләшүләре дә хикмәтле булып киткән: Шаһимәрдан, имеш, маржаның кызыл битлесе яхшымы, әллә бераз гына алсуы әйбәтме? Нәрсә диләр, кара инде боларны! Кичәге Янбаш Гыйльметдин белән Кече Камалетдинне бүгенге җәдитчә кыланмыш Кәчтүм Гыйльметдин белән Эшләпә Камалетдин янына утыртсаң, билләһи, талашып, якалашып, кыйнашып, канга батышып бетәчәкләр.

Шаһимәрдан сүз сандугачын акыл читлегендә каплап кына тотарга булды, дөресен әйтеп тавыш чыгарганчы, эшләргә күзеңне йому хәерлерәк иде. Шуңа да:

—Маржасына карап инде, Гыйльметдин, маржасына карап, Камалетдин,—дип, мыек астыннан гына көлемсерәп, шаярткандай җавап бирде.—Мин үзем, ни, бик алай белеп бетермим, әмма да ләкин, әйе, түгәрәгрәге, йомшаграгы әйбәтрәк була икәнен әфарин егетләрдән ишеткәләгәнем бар...

Тиречеләр рәхәт табып көлешкән арада Шаһимәрдан тагын да өстәп куясы итте:

—Көя төшмәгән булса!

Шунда гына тегеләр анын шаяртуын һәм хәтта, юри жайга торып, мыскылларга маташуын төшенеп алдылар. Хахылдаган авызларын:

—И хәсис, хәерче!..—дигән Көфер почмагы әһеленә хас сүгенү белән йомарга ашыктылар.

Шаһимәрдан, эшнең ахыры зурга китәчәген шәйләп, ул арада икенче өстәлгә күченергә өлгерде. Әмма тиречеләрнең аны болай гына калдырмаячакларын ул әлегә белми иде.

Ризыкның затлысын, милли байларның карынына хуш килерлеген китерделәр. Кайда-кайда, әмма «Меркурий» көймәсендә татарларның азык-төлекне мулдан куллануларын, сырага күнел салуларын, камырлы һәм итлене май кызганмыйча пешерергә кирәклеген яхшы белә иделәр. Шаһимәрдан кыздырылган каз ите, сумса, шулпа, пәрәмәч, коймак, каймак һәм бал янына, авыз тәме өчен, дигән булып, бер шешә сыра соратты. Китереп өлгерүләренә, үз нәфсесенең ияренә атланып, тагын бер балык ите кыздырырга кушты. Сәүдәсе яхшы барганлыгын аңларга өлгергән официант:

—Баш өсте, әфәндем!—дип елмайды.—Тагын ни дә кирәкмиме?

Мондый сорауларны Шаһимәрданның күәсе күтәрми иде. Карыны әлегә һаман ач икәнлеген тойган хәлендә юктан гына жене килеп:

—Балыкның ике ягы да яхшылап кыздырылган, кылчыгы төшерелгән булсын!—дип әмер бирде.

Официант «баш өсте» белән китеп барды. Хәер, монысына «баш өсте» сүзләре бик тә ятып тора иде. Мөгаен, Казан мәдрәсәләрен күп күреп тә гыйлем биштәрен тутырырга өлгермичә калган Сергач мишәре булса кирәк! Кибәнне югары куярга яратадыр.

—Рәхимегез, әфәндем!

Сумса белән шулпаны бетереп, казга күчкән Шаһимәрдан күтәрелеп карады. Ә, сыра китергән икән. Бик вакытлы.

Күрше өстәлдә шаулашып алдылар:

—Сез, әфәндем, жәдит, дисез, ягъни дә мәсәлән, гәжит, дисез, мәжәлләс, имеш...

—Шулай дим шул!..

Өстәлләре ризыктан бушау сәбәпле бераздан әфәнделәрнең күбесе жиңел аяктан кузгала тордылар. Гыйльметдин белән Камалетдин дә шаулашып чыгып киттеләр. Аларны бүтәннәр алыштырды. Электән сыра эчүдә һәркемне хәйран калдырган әһеле Көфер почмагы һәм дә яшереп кенә булса да, яхшырак эчемлек белән сыйлануны читкә куймаган жәдитләр жыела башладылар. Кайсысына сыраны бүз шешә белән китерсәләр, икенчеләренә чәйнекләп өстәлгә куйдылар. Гадәт һәм йолага хилафлык итүләр юк иде. Шаһимәрдан бу вакытта матур гына кәефләнергә өлгергән иде. Ресторан түрендәге караңгыланып торган тарафка ихтыярсыздан күзе төшеп, инде әллә кайчан күргән-күрешкән, бурсык йөзле, калын, әмма кечкенә итеп кистерелгән сакаллы, туп кебек шома итеп кырдырган башының сул тарафына авыштырып эленгән сай түбәтәйле кешенең анда күзләрен очландырып утыруын яхшы шәйләде. Үзара бик таныш кебек булсалар да, бер-берсен белүләре бары тик көрпә тел—саңгырау колактан һәм анда-санда, бу адәм фәлән бәндә түгелме, дип белешкәләүләрдән генә иде. Һәрхәлдә Гатауллин да, ул кеше дә бер-берсен таныйлар булырга кирәк.

Күрше өстәл әһелесе үз эше белән мәш килде, чәйнектән чынаякларына кызыл шәраб бушатты. Араларыннан берсе, Шаһимәрданның карап алуын күреп, аны карашы белән сөзеп узды да, иптәшләренә нидер әйтте. Түгәрәк мишәр агае, карбыз шикелле селкенеп, өстәлдәше сүзләренә колак куеп, ресторандагы кәефле кавем арасыннан төртеп аталган кешене каранып эзләде. Шаһимәрдан анын арка тарафында иде. Шунлыктан аны таба алмады.

—Кемне әйтәсез, тәкъсир?..

—Кая карыйсың, бире бак!..

Аның соравына күрә Шаһимәрдан әфәндегә теге сөйләүче адәм бармак белән төртеп күрсәтте. Мишәр барыбер күрмәде. Аның монда утыруын һәм барлыгын шәйләп тә тормастан, карашы караңгы өстәл ягына төбәлде. Йомры мишәр, кинәт артка табарак тәгәрәп, тавышын яшермичә әйтеп тә куйды:

—Ба!.. Шәкүр карак нишләп йөри монда?

Аның сүзләрен ишетергә өлгергән һәр әһеле татар вә башкорт, вә казакъ-кыргыз каерылып диярлек шул якка карадылар. Ат карагының гына керфеге дә селкенмәде, бер яраны беләнме нидер сөйләшкәләп утыруда булды. Шунлыктан һәркем, аңа текәлүдән бигрәк, юктан кызарып алган Шаһимәрдан әфәндене тикшеренделәр. Аңа җайсыз, уңайсыз, хәтта ачуын кайтарырлык халәт иде. Эчкән сырасының парын күзләр кайнарлыгы гүя һавага очырды. Чыгып китмәкче иде, калын гәүдәле, баһадир чырайлы, буйга өч аршыннан артык булырлык берәү аның каршысына килеп басты. Минзәлә сәүдәгәрләренә хас рәвештә зәңгәр чалбар, кызыл чапан, ак чалма, йомшак читек кигән бу адәмнең тавышы да колакларны кисәрлек иде:

—Син, Шәкүр агай, бер дә галәмәт, бездең кеше икән!

Шаһимәрдан һичбер сүз белән дә җавап бирә алмады. Борчылудан селкенгәләп куйды. Ат белән бәйләнеше зур булса да, ат караклыгына һичбер бәйләнеше юк иде аның. Тутый кош сурәтеннән бер дә ким булмаган бу адәмне, ияк астына биреп, чөйдереп кенә җибәрәсе килсә дә, берни эшли алмады. Ярый әле шул арада Шәкүр карак алар янына үзе килеп басты. Буйга әллә кем түгел икән! Һәммә шөһрәтнең үзеннән читтә калмавын теләүдәнме, әллә Шаһимәрданны кызгануданмы шулай эшләде? Һәрхәлдә вакыйга шушы рәвешле булды. Минзәлә сәүдәгәренең күзләре уйнап алды. Болай да ерык авызы тагын да киңәеп, башының яртысы артка ишелде:

—Ха-ха-ха!

Аның көлүе саңгырауны да колаклы итәргә мөмкин иде. Шаһимәрданнан гафу үтенеп тормастан, ат карагына борылды һәм баягы сүзләрен кабатлады:

—Һи... Шәкүр агай, синмени инде ул? Бер дә галәмәт, бездең кеше икәнсең!

—Бездең-бездең...—Шәкүр каракның Минзәлә сөйләшенчә сүзләрне оста авыштыруы иләмсез сәүдәгәрнең кәефен тагын да күтәрде булса кирәк, сабый балаларча бар күңелен тышка чыгарып көлде. Инде боларның ни-нәрсә сөйләшүләре колаклы татарны да кызыксындырмый башлады. Көймә әһелесе үз табыннарына борылган иделәр. Өстәлчеләр йөгерепйөгереп ризык ташый тордылар.

—Шаһимәрдан, монда буш бугай?

Шәкүр каракның бу сүзләреннән бигрәк, исемен төгәл белеп эндәшүенә Гатауллин үз кулындагы сыралы савытын төшереп җибәрә язды:

—Ни?..

Шәкүр үзен хуҗаларча тотты. Мәгърур йөзен түбәнәйтмичә генә сүзләрен капчыкка тыгызлап тутыргандай кабатлады:

—Монда буш бугай?.. Монда буш...

—Әйе, тәкъсир...

Ул арада Шәкүр карак урын алырга, хәтта янәшәсеннән Минзәлә баена тәкъдим итәргә, яранына да монда күченергә ишарә итәргә өлгерде. Шаһимәрдан исә:

—Сез мине, Шәкүр, каян беләсез?—дип, аптыраулы күз карашына гаҗәпләнү һәм соклану катышкан соравын бирде.

Шәкүр игътибарлы кеше иде. Ул арада өстәлендәгеләрен монда күчерергә өлгергән яранына нидер әйтте дә, туктап тор әле, дигәндәй, Минзәлә баеның беләгенә бүрәнә бармакларын куеп, тыныч кына сөйләп тә бирде:

—Кемнәрне-кемнәрне, әмма ат яратучыларның һәммәсен дә исемләп беләм, хәтта Әмерикәнең Томсонын да...

Бу Томсон әфәнденең кемлеге Шаһимәрдан өчен дә, Минзәлә баена да караңгы иде. Шәкүр моны яхшы белә, шунлыктан үзенең мәртәбәсен тагын да арттырып, бер башка югары булып күренде.

Яшермәде, Әмерикә баеның ничек кара аргамагын яратуын, аңа хәтта вафат әнисенең исемен бирүен, башкаларны һәм бүтән барныюкны сөйләп алды. Бу вакытта Минзәлә бае хәйранга калып, хәтта авызын ябарга да онытып утыра иде. Сүзенең ахырында Шәкүр аңардан:

—Исемең ничек әле?—дип сорап куйды.

—Мөхәммәтҗан!—диде тегесе.

—Юктыр, алай гына булмас. Безнең татарда исемне катлы-катлы йөртергә яраталар. Ин кимендә Хаҗимөхәммәтханхафизҗандыр әле!

Шәкүрнең бу сүзләре дә Минзәлә баен хәйран иттеләр. Ул:

—Әйе, тәкъсир, нәкъ шулай,—дип Шаһимәрданга да оялгандай карап алды.—Әмирелхаҗимөхәммәтханхафизҗан булам, атам белән мәрхүм муллабыз кушкан исем. Болай бала чактан Мөхәммәтҗан атап йөртәләр, сүз җае өчен, Миҗан, диләр. Миҗан бай, әйе!

«Әйе»дән башлап, «әйе» белән бетергән Мөхәммәтҗан әфәнде көтелмәгәнчә оялып куйды. Аның бу кадәр иләмсез һәм озын исемен мулла бабай да гомерендә бер генә, колагына кычкырганда гына әйткәндер, митрикәсенә алай ук озын итеп язып тормагандыр. Әмирелхаҗимөхәммәтханхафизҗан... Үзе бер җөмлә. Ягъни, гарәптән, фарсыны да исәпкә алып, татарга тәрҗемә иткәндә болай булыр: Хаҗ кылучыларның җитәкчесе Аллаһы Тәгаләнең сөеклесе хан гыйлеме җан... Моның белән генә бетсә?

Шәкүр һаман да тыныч иде. Бүре күзләреннән чагылып куйган очкыннарны шәйләүдән генә аның көлемсерәгәнен сизенергә мөмкин булды. Сүз арасында яраны юкка чыкты. Монысы да берәр хәйлә түгел идеме икән?

Мөхәммәтҗан әфәнде табак битендәге шактый олы бәрәңге борынын урыныннан кузгатырга теләгәндәй боргалап куйды. Аннары Шәкүргә карады. Бу вакытта аңа баласыманрак кыяфәт кереп, нәрсәнедер тәфсилләп сорарга җыенганы аңлашыла иде. Һәм шулай булып чыкты да. Шаһимәрдан әфәнде каз ботына ябышканда, Мөхәммәтҗан бай сорау арты сорау яудырырга тотынды:

—Шәкүр агай, Шәкүр агай, дим? Минзәлә яниралының ак айгырын ничек урладың? Сөйлә әле! Эзеңә дә төшә алмадылармы? Әстерханга илтеп саттым, диген, ә?..

Шәкүр эндәшмәде. Бүре күзләре канәгатьлек белән йомылып алдылар. Аскы ирене кырыкмыш мыегына кадәр күтәрелеп маңгае коры көнне яргаланган кара туфрак кебек сырга-сыр килде. Җавап көтеп томаланган Мөхәммәтҗан, сабырлыгын югалтып:

—Сөйлә инде, Шәкүр агай! Билләһи, беркемгә дә әйтмәм!—дип үтенүендә булды.

Бу вакытта куркынган кыяфәтле Шаһимәрдан шомлы Шәкүргә карап утыра иде. Кулыннан каз боты төшеп китте, тәлинкә, чәнечке, кашыклар кузгалышып-шалтырашып алдылар.

—Бәрәч, син урладыңмы аны да?

Шаһимәрдан әфәнденең белмәгән кеше кебек болай әйтүеннән Шәкүр үртәлеп куйды һәм, яшереп тормастан:

—Мин идем ул, кана-а...—дип сузды.

—Әйттем бит!..—дип, Мөхәммәтҗан үз борынын әвәләде, ул сөенә иде.

Шаһимәрдан әфәнденең бу арада йөзе туксан тугызынчы тапкырын кызарып чыкты. Гомере буе ат яратып, хәтта кочаклап яткан хатыннарыннан да шул дүрт аяклы хайваннарны өстен күрде ул. Күп вакытта, тегеләренә җикеренсә дә, башкаларга чыбыркы селтәнергә дә беркемгә ирек куймавы һичбер яшерүсез һәр кешегә яхшы мәгълүм иде. Дөньясы

уң белән сулын бутаса да иң ахырдан базарга чыгарганы шушы атлар булачак аның. Менә иманы камил. Шиһабетдин Мәрҗанидән гыйлем тәслим кылып, шушы олуг мөдәрристән фән каймагын чумырып алып кала алмаса да, ахунлык мәртәбәсенә ихластан кызыгып, алтын сәгать йөртүне һәм атларга мәхәббәт хисен анардан үзенә йоктырды тагын. Дәрес барышында Шиһабетдиннең «Яхъя» гыйлеменә кушып, баш ял итсенгә диптер инде, абзарындагы соры айгыры турында, аның ничек Ашут базарында арт аякларында биюе белән халыкны хәйран калдыруы турында тәфсилле-хисле озын һәм озак хикәяләүләре вакытында һәр шәкертнең ач күзләрендә очкыннар уйнарга тотына иде. Шаһимәрданга шуннан бирле «ат чире» йогып, тәмам кибеп, урын өстенә ятып, бу зәхмәттән үлем хәленә житкәндә атасы Гатаулла, авылдан килеп, жиде кат толыпка төреп, зур кәрван сандыгына салып, үзе белән алып кайтты. Им-томчыларның кыңгыраулысы да, думбралысы да, кабаллы-тәлинкәлесе дә калмады. Һәммәсе аның желеген суырды, атасының малына кинәнде, әмма файдалары булмады. Гатаулла абзый кул селтәде:

—Бу баладан кеше чыкмас, тизрәк үлсен дә илтеп күмәрбез!—дип йорттагыларның болай да качкан котын алды.

—Әстагъфируллаһ!—диделәр бар да авызларын учлап.

Әмма Аллаһның рәхмәтеннән узмыш юк икән ул! Малай көтелмәгән жирдән сихәтен тапты. Төнлә белән саташып, хәлсез гәүдәсен сөйрәп абзар-кура ягына чыкты. Атлар, пошкырып, солы кемертәтә иделәр. Шаһимәрданның сулышы ачылып китте. Ат исе аның баш авыртуын да, күнел укшуын да бетерде. Әмма тәнен калтырану каплады. Хәл алыйм, дип утырган урыны әле кичтән генә өеп калдырылган жылы тирес булып чыкты. Ул шунда чумып, тәмам онытылган хәлендә йокыга китте. Иртәгесен аны тирес эченнән табып алдылар. «Бала харап булган!»—дип елый-елый, урын өстенә кертеп салдылар. Әмма Шаһимәрдан шул көннең ахшам вакытында аягына басты, үз кодрәте белән тәһарәтен алды, намазга ниятләде.

—Бала китәргә жыенды,—диделәр сүзне колактан колакка күчергәләп.

Гатаулла абзый, анардан өметен күптән үк өзгәнлектән:

—Хәерле булсын!—дип сузды.—Ходаның бирмешеннән узмыш юк!

Ни хикмәт, төне буе Шаһимәрдан убыр кебек ашап чыкты, ярты казан ашны бушатты. Моннан соң да аягына камил басмаса, жен токымы булачак иде. Аллаһының рәхмәтеннән уза алмады.

Ул елны яз иртә килде. Март ахырында ук яшел үлән чыгып, апрель урталарына көтү куарлык булды.

Нәйсән житсә—дөнья күрке,
Куба суның ташкыны...
Чибәр кызлар егет сайлый,
Һич уйламый башканы,—

дип жырлап узган егетләргә Шаһимәрдан да кушылырлык иде. Әмма бусаганы атлап чыгарга рөхсәт булмады. Кыш буена им-том итеп, тәрбияләп-асрап яткан ата-анасы һәм инәкәйләренә ул да үпкәләмәде. Абзар-кура арасында йөреп, әтисе белән бер-ике тапкыр сәүдә эшенә барып кайтты. Шаһимәрданның учы майлы булды. Ни сатылмыйча яткан товар да базарда үз хужасын тапты.

—Баланы укытудан файда юк, сан саный белсә, безгә шул инде!—дип әтисе Гатаулла аңа махсус кәрван жиһазлады.

Аларның эше төгәл барып чыгасына иманын камил тотмаса да, күрше авылдагы карендәше Сәйфулланы күз-колак өчен килештереп куйса да, Шаһимәрданы аны аягыннан екты. Сәүдәнең беренче көнендә үк илчесен жибәреп, товарының бетүен, керемнең бергә өч булуын, әгәр рөхсәт икән, маклер Жамали Хафизының үтмәс малын аз бәядән алырга жыенуын белдереп хәбәр салды. Гатаулла, болар хакында ишеткәч, ашыктырып ат жиктерде:

—Балага калган көн—таң атмаган төн!—дип Арча базарына буран кубарып килеп керде.

Аны бугазлап становой туктатты. Тәртипне бозу, сүгенү, дуамаллану, бушбугазлану кебек әллә ниткән хулиганлыклар тагып, Гатаулладан адәм мәсхәрәсе ясап, танга чаклы рәшәткә артында йокысыз тотты. Ахырда: «Өч көнсез Арчага керергә ярамый!»—дигән тыюлык кәгазен тоттырып, жиде сум егерме биш тиенлек штраф салып, авылына кире озатты. Юлда таныш калган кешеләрдән оят иде. Күрше авылгача ияреп килгән кылычлы атлы казак Сәмигулла анардан тәки бер мәгъричлек акча кысып, төн авызына кереп югалды. Тәмам тугарылып, өч хатынын бер итеп сүгеп ташларга әзер булып кайтып кергән Гатаулланы капка төбендә мыек сыпырып торган улы Шаһимәрдан каршы алды. Сүз бер генә иде:

—Атай, Жәке мулласы Гарифның кызы инде, Бибисәрвәржәмиләне никахласак, Ходай Тәгалә колачын жәяр кебек!—диде.

—Бибисәрвәржәмиләң белән бергә үзеңне жәһәннәмгә олактырыйм!—дип Гатаулла жикереп, инде генә сүгенмәкче иде, кинәт тартылып куйган хәерсез атының арбасыннан артка мәтәлде.

Телен тешләп, авызына кан тулды. «Адәмне Ходай йөртә, Шайтан—котырта!»—дигән гыйбарәне башына кертеп караганы булмаса да, әллә кайдан гына шул әйтем исенә төшеп, колагы чыңлый башлады.

Усаллыкны чыгару тиеш гамәл түгел иде. Гатаулла атларны тугарырга боерды. Авырткан һәм имгәнгән жирләрен юк сыман тойды.

—Кая, ни майтардың?—дип янында куыклы шәм күтәреп торган улына күз агы белән ишарә итте:—Сөйлә!

—Керем—биштән,—диде Шаһимәрдан, өйгә таба юнәлеп, кесәсенә яшергәнен әйтергә теләмәде.

—Алдыйсың.

Ата келәт ишеген ачты, кече утта янган лампаның яктысын арттырды. Сәүдә кенәгәләре гадәтчә шушында саклана иде. Хәзер санап чыгарачак! Шаяртма Гатаулла белән, ул сарык түгел!

—Экономда, кенәгәсе белән!

Улы, үпкәләп, болдыр төбеннән генә хәбәр салды һәм, әтисенең тагын да әмерен көтеп, шунда утырды.

Гатаулла кабаланды. Кирәкле кенәгәне ачып, саннарны чут төймәсенә салып тикшерде. Келәтендә унлы лампа балкып янса да, Сәйфулла маклерга чыккан һәм анардан кергән акчаны таба алмады. Ахырда Шаһимәрданын чакыртып:

—Илчең хаталы кеше булды!—дип сүз башлады.

Әмма улы кырт кисте:

—Сәйфулланың малын сатып бирдем, мең биш йөз кырык бер тиен табыш алдым. Анысын үземдә калдырдым, кесә акчасы булыр,—диде.

Гатаулла әүвәле өнсез калды, аннан соң сөенеч белән үзен басып, улы белән килеште. Сәүдә эшендә Шаһимәрданның маһирлыгы аны хәйран иткән иде. Барлык үтмәс товарын төяп жибәреп тә аларны мал итү үзе үк көтелмәгәнрәк бәхет шул. Ә ул, житмәсә, кеше эшенә дә катнашып, үз кесәсе жаен да караган.

Мондый хәлне Гатаулланың гомерендә күргәне булмаганлыктан, бу сәгатьтә улы өчен сөенеп, күңеленә камиллек инде. Аңа хәзер тыныч кына да яшәргә мөмкин. Кәсебен ышанып тапшырыр кешесе бар!

Шул көннән бирле Шаһимәрданның эшләре унда булды. Аның хакында: «Кулына май буялган!»—дип сөйли иделәр. Әмма алай гына түгел икән шул, хәтта авыз-борыны да майга тәмам буялып беткән, үзе дә май чүлмәгенә әверелгән ул...

—Кара әле,—дип төртеп алды аңа Шәкүр карак, онытылып киткән жиреннән аны дөньялыкка кире кайтарды,—Шаһимәрдан, мин әйтәм... Сиңа да ат жене кагылган, диләр. Ак айгырың хакында күп ишетергә туры килде. Ай-һай акыллы, имеш, төрекмән аты, диләр.

Кемнән-кемнән, әмма Шәкүр карактан үзенең бәгыре мәртәбәсенә күргән аты хакында Шаһимәрданның ишетәсе килми иде. Ул зимагурның кызыгуы бер дә юньлегә түгел, хәерсез!

Шаһимәрдан ишетмәмешкә сабышты. Китергән сыраны шунда ук бүлә башлаган Мөхәммәтҗанның кулына үрелде, шешәсен алып, салышырга тотынды. Шәкүр карак исә аның җанын үчекләвен дәвам итте:

—Яхшы айгыр, дип мактыйлар. Һай бер күрәсе иде үзен, җилдәй җилдертәсе...

—Сатмыйм, сатыла торган мал түгел!—дип кырт кисәргә мәҗбүр булды Шаһимәрдан.

Бу хакта сөйләшүне озынга сузасы килмәде. Ачуы тәмам кузгалды. Гүяки аның хатынына хезмәтчесе кул сузган да, хуҗасыннан көлмәкче булып маташа, имеш, оятсыз!

Шәкүрнең хәйләкәр күзләре ялтырап-ялтырап алдылар. Ул үзенең тыныч калуын сиздерергә теләсә дә, эче Шаһимәрданныкыннан кимрәк кайнамый иде.

—Мин ат сатып алучы түгел, мин—ат карагы Шәкүр булам.

Аның болай ачу белән кайнарланып һәм үртәп әйтүенә күрше өстәлләр янындагы сәүдәгәрләр, әңгәмәләреннән туктарга мәҗбүр булып, борылып-борылып карадылар. Һәммәсе колак салып тын калды. Шаһимәрдан исә Шәкүрнең сүзләрен җавапсыз гына уздырып җибәрергә тиеш түгел иде. Шунлыктан, алдын-артын уйламыйча:

—Миндә урлата торган ат юк!—дип әйтеп салмасынмы.

Мөхәммәтҗан абзый тизрәк кыяклау ягын карамакчы иде, Шәкүр карак аның кулыннан эләктерде:

—Утыр, кузгалма!—дип әмер бирде.

Минзәлә татарының учы сытылды, бавыры ташка әверелде.

—Агай, дим, агай... Минем ни катнашым бар?

Суган суы сыгарга җитеп кызарып бүртенгән Мөхәммәтҗанга Шәкүрнең исе дә китмәде. Юктан гына килеп чыккан бәхәсен тизрәк ахырына җиткерергә ашыкты:

—Шул ак айгырыңны бер ай эчендә урламасам, исемем Шәкүр булмасын! Белдеңме энем!—дип Шаһимәрданның акылын алды. Әмма аның бирешәсе килмәде, үчләшүендә һәм киреләнүендә булды:

—Миндә урлата торган ат юк!—диде ул сүзен сүзгә кабатлап.

Бу вакытта Шаһимәрданның йөзе кызган күмер кебек ут чәчеп, кечкенә күзләре елгыр энә тишегенә әверелеп калган иде.

—Урламасам, исемем Шәкүр булмасын!

—Урлатсам, бер мең тәнкә миннән!

Халык шаулашып алды. Шаһимәрдан өчен бу акча берни дә түгел әлбәттә, әмма ул шушы бәя бәрабәренә дә ак айгырын абзарында саклап калырга өмет итте. Шәкүр карак аның кармагына кабарга тиеш иде. Бер мең тәнкә кемнең аяк астында аунап ята ди әле? Андый заманмы? Бер тиен өчен адәм балалары бугазга-бугаз киләләр. Ә монда—мең тәнкә! Кирәксә, хәзер кесәсеннән чыгарып сала!

«Урлатмасаң миннән мең тәнкә!»—Бу сүзләрен әйткәндә Шәкүр карак сикереп басты, имән бармагын югары төбәп, уннан сулга һәркемнең күзенә күрсәтеп узды.—Мең тәнкә,—дип, кабатлады,—әгәр урлый алмасам, исемем...

Халык гөж итеп, «Бу кем, бу кем?»—дип чуалган арада Шәкүрнең юкка чыкканын күрмичә дә калдылар. Шаһимәрданның эченә ут оялап, акылы шашына, җаны кайный бирде. Янында Шәкүр каракны таба алмагач, иярченен күзләде, анысы да юклыктан бөтенләй дә сабырын югалтты. Чабаксарны узуга, бөтенләй дә сабыры төкәнү сәбәпле, ярга чыгып чапты, ат ялладьı. Таң беленгәндә, дусты Константин Дудовның бусагасында иде инде.

Аларның дуслыгы күптәннән килә. Дудов, Семеновкада кызыл мал

сәүдәсе тотып, Казан белән ике арада исә агач дегете һәм сагыз сатудан узмаган, майлы йөзле, җирән сакаллы, ни чирмеш, ни урыс һәм дә ни татар байларыннан иде. Тәрәзәсенә капланып, Шаһимәрданны танып алуга, ак ыштаннан йөгереп чыкты ул.

—Нәрсә, кенәз, таладылармы әллә?—дип борчылуын белдерде.

Шаһимәрдан:

—Хуже,—дип ат сорады.

Дудов аһ-ваһ итте. Чәйгә дә керәп тормаслыгын белгәч, келәт башында йоклап яткан улы Семенны уятырга, ат җиктерергә боерды. Кукмарадан Чодраялга чыгасыларын, аннан Дөбьяз аша авылына кайтып ирешәчәген ишеткәч, юлның кимендә атна ярымнар булачагын әйтте. Шаһимәрданның чыдамы бу кадәргә үк җитмәячәк иде. Атларны ияртеп барырга булдылар. Дудов ана үзенең иң яхшы дип белгән соры биясен атады. Семен белән каударланып чаптырдылар. Дудов исә:

—Кенәз, атны харап итмә, атны яндырма!—дип кычкырып калса да, сүзләрен ишетмәделәр. Берни эшләрлек түгел иде.

Ак айгыры бәрабәренә дусты Константинның йөгерек биясен яндыру Шаһимәрдан өчен берни дә түгел иде. Шунлыктан азга да тукталып ял алдырырга уйлап бирмәде. Тайга сукмакларында юлсызлык һәр адымда диярлек көтеп торды. Инде кайтып җитәрлегенә ышанычы калмады, бу урманның бетәчәгенә, татар далалары башланып китәчәгенә өмете югалды. Шулай да алты көн дигәндә, тәмам буталып, адашып йөрүләреннән соң, утлап узган көтү эзенә туры килеп, шуннан тайпылмыйча барып, Җәке авылына килеп чыктылар. Бабасы Гариф муллага куна төшеп, аның Казандагы Күлбуе мәдрәсәсендә гыйлем эстәүче шәкерт улы Шәйхулла мәхдүмгә аталган яшь айгырын иярләттерде. Семенны җиде алтын акча биреп, озатып җибәрде һәм юлын ялгызы гына дәвам иттерде. Бабасының:

—Кияү, ни булды, коймактан, балдан, каймактан, каздан авыз итмәдең,—дип, бераз кунак булырга кыставын да кабул итмәде. Кыш урталарында гаиләсен төяп килеп чыгарга нияте барлыгын әйтте, галәмәт бер маһирлык һәм омтылыш белән чаптырып, авылдан чыгып та китте, үрләр-сулыклар аша турылап юл алды.

Аның болай ашкынуында һичкемнең эше булмады, каршысына һичкем очрамады.

Авылында да аны көтми иделәр. Күбеккә батырып кайткан айгыры, нәкъ капка төпләренә килеп җиткәч тукталуга, егылып аяк сузды. Янган иде, бахыр, хараплар гына булган. Кайнеше, мәхдүм Шәех үпкәләр инде. Ярар, бу бәладән исән-сау котылса, үзенә туры атны багышлар.

—Нәрсә булды?—дип, утлар йотып каршы алган хезмәтчеләренә һәм хатыннарына, бала-чагаларына да игътибар итеп тормастан, ашкынып ишегалдына атылды һәм ак келәтләре, таш пулатлары артындагы атлар аранына бәреп керде.

Малкайлар дерт итеп куйдылар. Ак айгыры, тыныч кына солы күшисе урынга, ишекле-түрле тузынып йөри иде. Хуҗасын күрүгә, аңа таба пошкырынып килде. Араталык аша сузылып, кочагына башын тыкты.

—Казанның иң кәттә марҗасы да синең кебек назлы булмас, бахыр!—дип Шаһимәрдан йомшап китте.

Алар бик озак бер-берсен иркәләделәр, бер-берсеннән иркәләнделәр. Болай онытылып җанга җан, муенга муен берегүләре йорт халкы өчен гаҗәп хәл түгел иде. Ишегалды яныннан хатынының көнләшүдән:

—Чукынды инде шул аты белән! Тәмам җенләнде. Үзен харап итмәгәе. Монда аунап, бер аты үлеп ята, ә ул анда икенчесен кочкан!..—дип, имтом иткәндәй төкеренгәләп, сукрануы гына аны айнытып җибәрде.

Хаклы иде хатыны, бик хаклы иде...

Шәкүр карактан урлатмас өчен шушы айгырын Шаһимәрдан бер ай буена абзарында кочаклап ятарга да риза шул! Тик менә алай гына булыр микән?

Шаһимәрданның акылы һушланып, шунда ук бер фикергә килде:

күрше-тирә авылларга хәбәр салырга, юлга, чокырларга, әрәмәлекләргә каравыллар куярга тиеш ул!

Кайтканнан бирле өч атна узса да, Шаһимәрданга Шәкүр карак хакында һичбер хәбәр ирешмәде. Инде бер ай вакыт хәерсезлеге һәм борчулары белән үтеп бара иде. Шаһимәрдан әфәнде дә бу арада тынычланып, җанын урынынннан кубарган бәхәснең кызып китүдән генә булганлыгын төшенде. Шулай да күңел тойгыларының бер кылы һаман тартылып-тартылып куйгалады. Шәкүр карак тәрәзәдән килеп керер сыман тоелды аңа.

Айлы кич иде. Җиргә салкын сыкы инде. Шаһимәрданның йорт тирәсен саклаган авыл агайлары кичтән үк тергезгән учаклары тирәсендә гәп корып, көлдә күмелгән бәрәңге ашап, падишаһ хәзрәтләрендә егерме биш ел хезмәт иткән солдат Гыймадетдиннең ничек Дунайда татарча сөйләшеп йөрүләрен, күз күрмәгән, колак ишетмәгән Әдрән дингезе буйларында да татар сүзенең яхшы үтемле булуын, йөз дә беренче тапкыр булыр, кимендә, тәмләп һәм йотлыгып тыңлыйлар. Ара-тирә:

—Анысын әйтми калдырдың... Һич югы монысын сөйләп уз инде!..—дип ризасызлыклар да белдергәләүләре белән төнне уздырып маташа үзләре. Шунда ук араларында малай-шалай йокы таба алмыйча йөри. Аллаһы боерса, бүген-иртәгә бәхәс көне чыга, Шаһимәрдан җинүче булып, Шәкүр карак оятка каласы. Инде ничәмә авыр көннәр һәм төннәр узды. Күбесенә түзелде. Азга калгач кына уяулыкны югалту юк! Менә кызык итәчәкләр әле үзен, адәм көлкесе ясаячаклар угыры Шәкүрдән!

Шаһимәрдан учак янына якынлашты. Әле яңа гына келә-йозакларын, тәрәзәләрен һәм тупсаларын тикшеренеп чыккан чагы, әмма келәтләр һәм абзар-куралар ягыннан шырт итеп агач сынган тавыштан сискәнеп китте. Аның нәрсәнедер абайлавын сизеп, барысы да колакларын торгыздылар. Чебен очкан тавыш та ишетелергә тиеш иде.

—Урладылар... Урладылар... Тот... Тот!—дигән тавыш ишетелгәч, каравыл кычкырган якка барчасы бердәм ташландылар.

Аяк асларында бөтерелеп йөргән бала-чагалар читкә очты, алар кайгысымы хәзер.

Ул да түгел, якты ай нурында ак айгырның ялтырап-ялтырап алган гәүдәсе суда уйнаган чабак төсле күренгәнләп алды. Бакча артлап ул хәйран тизлек белән ераклаша бара иде.

—Атларны чыгар!—дип җикерде Шаһимәрдан.—Атларны чыгар! Артыннан төшәргә! Артыннан!

Татарга әмер кирәк. Ул шуны сөя. Кемнең алга чыгып дәшүе булса, артыннан калганнары иярә, аны-моны уйлап маташмый.

Елгыр егетләре, кулларына утлы кисәүләр алып, атларга атланып, каракның артыннан дау күтәреп ташландылар. Бакча коймалары һәм читәннәре авып-ватылып калды. Шаһимәрдан үзе дә ат өстенә ничек менеп атланганын, кулына шахтерлар лампасы тоткан хәлендә чаптырып барганын сизмичә дә калды. Мәтәлеп китә язганда гына айнып, атын тыярак төште. Кемнәрдер иярләреннән коелышып, атлар астында калдылар. Ул да түгел, Шаһимәрдан һәммә кешене узып алга чыкты. Тулган ай яктысында юл буйлап чаптырган Ак айгырның сырты һәм көмеш яллары ялтырап күренделәр. Болай булса, куып тотасылар иде.

Шаһимәрдан тагын да атын куалады. Әмма алдында чокыр иде. Аты кинәт туктауга, башы аша китеп, шунда чумды. Сырты белән килеп төште. Күзләреннән утлар чәчрәде. Баш чүмече янгырап куйды. Чигәләре кинәеп алдылар да чатнап авырта башладылар. Ул аңында иде.

Торып басты. Күктә тәмам жиде тулган ай бер-берсенә тагылышып әйләнә иделәр. Чаптырып килгән кешеләр чокырның яныннан гына узып киттеләр. Шаһимәрданны еккан ат, ни хикмәт, аларга иярмичә, гүяки гаебен таныган хәлендә пошкырып алды. Аллаһыга рәхмәт димичә, нәрсә әйтәсең инде!

Шаһимәрдан, чокырдан күтәрелеп, атның йөгәненә ябышты. Һаман

да башы әйләнүе бетмәгән, инде укшыйсы килә иде. Шулай да ияренә менә алды. Кешеләре артыннан атын юырттырды. Әмма моннан хәле тагын да авырлашты. Атланып кына барырга мәҗбүр иде. Баш сөяген ачып, су тутырганнар диярсен. Болгады да болгады. Чайкалган саен гүяки түгелеп китәдер сыман. Ул ак айгырын да уйламас дәрәҗәгә житте.

Күрше авылның башында аны кешеләре көтә иде. Алар:

—Мәрдан абзый, авылны уратып алдык. Ат эзе монда кергән, әмма чыкмады,—диделәр.—Авылда гына ул. Бер дә әллә кайда түгел! Шушында гына! Урап алдык! Таңгача сак торыйк! Иртәнге сәгать белән якты күз тиз табарбыз!

Бу тәкъдимнәрнең барчасын да кабул итәрлек иде.

—Шулай эшләгез!—дип әмерен житкерде ул.—Айгырны тапкан кешегә мең тәңкә бирәм!

—Мең тәңкә!.. Мең тәңкә!..—диештеләр кешеләре.

Бу кадәр акчаны гомер буена да эшләп казана алмаулары һәм алмаячаклары аларның хыялларын тагын да хушландырды.

—Мең тәңкә!..

Ялгыш ишетмәдекме, дигәндәй, алар бу сүзләрне тагын да бер-берсенә кабатладылар. Шул арада Шаһимәрдан атыннан төште. Алар күрсәткән тояк эзләре чыннан да юл тузанына кунган сыкыда аермачык диярлек ярылып ята иделәр. Танымыйммы соң, бик таный, шуныкы, айгырының эзләре. Тоякка тояк, эзгә эз китереп баскан. Һәркайсысы бердәй, һәммәсе тигезләр, муенса кебек!

Шаһимәрдан шул эзләр артыннан авыл урамына кереп китте. Бу вакытта каны кайнарланган, башының мингерәве тәмам басылган, хәле яхшырып киткән кебек иде.

Эзләр аны авыл урамына алып кереп, мәсчет яныннан уздырдылар да тыкрыкка таба бордылар.

Айгыр монда бераз таптангалап торган. «Әһә, арттан куучылар юкмы икән, дип Шәкүр карак тынлаштырып маташкан инде»,—дип уйлап алды Шаһимәрдан. Ул да түгел, эзе кабат урам уртасына чыккан, юлын дәвам иткән. Әнә, атланып кына барган.

Шаһимәрдан урам буйлап киткән эзләрне карый-карый, тынлана-тынлана атлавында булды. Янарак кына узганлыгы ярылып яткан һәм сизелеп торган арба юлына очрады. Кемдер югары як тыкрыктан төшкән, төнлә салам алып кайткан икән. Ул, борылып, сул тарафка кереп киткән. Саламы һаман да коела барган.

Айгырының эзен югалтмас өчен, Шаһимәрдан һаман да алга атлады. Әмма бераздан эше хөртиләнде. Тыкрыктан күтәрелгән ат көтүе барлык эзләрне бутап бетергән иде. Һай хәерсезләр, капка төпләре саен кереп киткәннәр. Житмәсә, урам уртасына диярлек салам ишелеп калган. Монысы тагын каян? Теге йөк кереп киткән иде бит!

Шаһимәрдан чарасыз калды. Шулай да авыл башына кадәр килле. Чыгып киткән ат эзе юк иде.

—Бакча башларыннан сыптырмаганмы?—дип кинәште ул үзе белән.

Әмма шунда ук аны ике елгыр егет эләктереп тә алдылар:

—Ә, каптыңмы, хәерсез!

Шаһимәрдан аларны унга-сулга эткәләп куйды:

—Сез нәрсә, абзагызны танымаска!

Алар, аптырашып, аны шунда ук жибәрделәр.

—Белмәдек... Белмәдек!—диештеләр.

Бу аларның гафу үтенүләре иде. Авылча.

—Шәкүр күренмәдеме?

—Саклыйбыз, узган-киткән булмады!

Егетләр чыннан да уяу иделәр.

—Бакча башлары, су буйлары ничек?

—Анда да безнекеләр,—диделәр болар, Шаһимәрдан абзыйларын сөендереп.—Авылдан чыкмады ул. Шунда булыр. Без уратып килдек.

Каршысына төшәргә, дип монда ашыктык. Күрше авыллар да килеп життеләр. Ул, безнең уратып алганны сизенеп, авылга кереп качты!

Шаһимәрдан бар халыкның да бу төндә уяу булуына хәйран итте һәм мең рәхмәтләр укыды. «Авыр чакта халыкка таян!»—дия иде атасы, хаклы нәсыйхәт әйткән икән! «Җинел чакта—дусларга!» Дуслар алар рәхәттә генә яхшылар шул, рәхәттә генә, акчаң барлыгын белгәндә генә!

Шулай да Шаһимәрдан бу каһәр суккан авылны кабат өч әйләнеп чыкты. Су буйларын да, бакча артларын да таң беленгәнчегә чаклы егетләре белән кат-кат тикшеренде, иснәнде. Кешеләрен даим уяу тотты. Һәм дөрес эшләде. Хәер, вәгъдә ителгән мең тәңкә берсенең күзенә дә йокы кертмәде.

Шәкүрнең чыннан да чолганышта калуына һичбер шик юк иде. Әгәр дә шушы хәлдә эш дәвам итсә, падишаһ хәзрәтләренең жиде йозаклы тимер читлегенә хәерсез ат карагы ябылачак түгелме?

Шаһимәрдан, болар хакында уйлап, Шәкүр карак өчен бераз борчылып, хәтта хәсрәтләнеп тә алды. «Андый кешене харап иттерергә ярамас, яхшы түгел!» Бу фикере урынлы булып чыкты. Чөнки халык арасында:

—Ул каракны акылга утыртырга кирәк! Капчыкка үзе килеп керде. Беркая да китә алмас, түрәне, урәтникне, пәлицәйне чакыртыйк!—дип гауга купты.

Бу сүзләрне Шаһимәрданның үзенә житкерделәр. Ул исә:

—Ашыкмыйк, жәмәгать! Сабыр итик, көлкегә калмагаек!—дип бу кисәтүенә үзе дә хәйран итте.

Чыннан да, көлкегә калырга мөмкин иделәр. Капчыкка кергәнең төлке түгел, мәче баласы гына булса, ни әйтерсең? Даның илгә таралачак!

Шаһимәрдан унбиш таза ирне сайлап алды. Калганнарны авыл тышында сакта калдырып, болары белән урамга таба атлады. Йорт саен кереп, тикшерену-эзләну эшләрен башларга тиеш иделәр. Мөәзин авыл башында гына тора икән. Беренче булып аларга ул очрады. Шаһимәрданны танымый идеме, әллә кыланмышы шундый, башын кайтарып-кайтарып, маңгаена һич кирәкмәсә дә кулын куеп, озаклап карап торды:

—Кемнәр килә?—дип каршы алды. Төнге вакыйгалар хакында ул берни дә белми иде. Шулай да:—Кичә ахшам вакытында авылга чегәннәр кергән иделәр. Зимагур Гыйльметдиндә куна калганнарын гына ишеттем!—дип сорауларга берьюлы жавап бирде һәм үзенең шиген белдерде.

—Кайда яши ул зимагурыгыз?

Шаһимәрдан бу соравын биргән арада мөәзин мәсчеткә таба юл алган иде. Соңга калуы да бар шул, намаз вакыты керде. Халыкның әле кузгалганы да юк!

—Мәсчеттән арырак, тыкрык эчендәге йортта,—диде мөәзин, баруында булып. Шаһимәрданны егетләре белән бергә артыннан ияртте.—Күрсәтермен!

Зимагурның йорты—яхшы, каралты-курасы ныклы һәм биек читән белән уратылып алынган иде. Төнлә күргән арба эзенең дә анын капкасыннан кереп киткәнлеген Шаһимәрдан чамалап-күреп килде. Менә, болары анын үзенең эзләре.

Шул арада мөәзиннең ягымлы тавышы авыл өстенә азан авазын җәелдерде. Озак та үтмичә ишекләр, капкалар ачылганы, халыкнын уянганы ишетелә башлады. Бары тик зимагур Гыйльметдин йортында гына хәрәкәт сизелмәде. Капкасын этеп караган иделәр, шайтан хәерчесе, ачылды да китте. Терәү дә салмаганнар икән үзләре.

Зимагурның ишегалды уртасында көлтә төялгән зур арба тора иде. Арырак—келәте, печән кибәне, тирес өемнәре. Ныклы һәм иркен тормыш белән гомер сөргәне күренеп тора. Каян килеп зимагур атаганнардыр?

Ике егете, каралты-куралар ягына кереп китте. Шаһимәрдан үзе, тирес өемнәре янына килеп, биек итеп куелган печән кибәне янына атлады. Дәртләнеп кукырайган әтәч кукыртап алды, кетәклегендә күршенын

чыкканын да көтеп тормастан, вак-төяк тавыкларын ияртеп, орлык чүпләштерергә ашыккан. Чит кешеләрнен йөргәненә исе дә китмәде. Ул арада, Шаһимәрдан ун-сулны караштырганда, тирес өстенә менеп басты. Кукыраеп тавыш бирде. Шаһимәрдан көнчыгыш якны күзәтте. Әле һаман да кояш чыкмаган, шулай да каурый болытларда алсулыгы сиземләнә иде. Төньяктан суык җил исеп, көннең җылы булмаячагын сиздерде. Каян ди инде октябрь аенда эсселек? И хәерсез гомер! Нибарысы дүрт ае җылырак булган кебек, аннары бозыла да бетә. Агачлар да яфракларын коярга тотына. Тапканнар бабайлар җәннәт асты туфрагын, кинәндергәннәр! Ярты дөньяны басып алып та юньлерәк урын-биләмәләргә хуҗа була алмаганнар шунда!

—Шаяртма!.. Дурак, дигәч тә!..

Йорт ягыннан ишетелгән тавышка Шаһимәрдан янына җыела башлаган егетләре дә игътибар иттеләр. Кайсыберләре хәтта сискәнешеп тә куйдылар. Хуҗаларнын йокламавы аңлашылырга тиеш иде. Шаһимәрдан тәрәзәләргә якынрак килде. Ул да түгел, абзар-кура эченә тикшеренергә кергән ике кешесе дә аннан хәбәрсез чыктылар. Айгырнын монда эзе дә юк иде.

Йорт эчендәге сөйләшүчеләрнен сүзләрен Шаһимәрдан аермачык диярлек ишетте. Араларыннан кемдер караштырып торган икән:

—Ишегалдында йөриләр!—дип бүтәннәргә белдерде ул.

—Йөрсеннәр, айгыр—әллүр!—диде икенчесе, бу—Шәкүр карак тавышы иде.

Тәрәзәләргә эчтән капланган чүпрәкнең кадак очы кадәр тишегеннән Шаһимәрдан өстәл тирәли утырган кешеләрне күреп алды. Аннан сон болай йөрүнең мәгънәсе юклыгын аңлап, ишеккә килде. Тартты. Ачылды. Керде.

Аны көткән иделәр.

—Сәлам, Шаһимәрдан!—диде Шәкүр, өстәл түренә утырган җиреннән кузгалып та тормады.

Әмма кайтарып сәлам бирелүне көтмәде, әйләнәсендә утырган чегән кыяфәтле адәмнәренә:

—Әйдә, булмаса, өләш берәрдән!—дип әмер бирде.

—Атны син урладыңмы?!—дип Шаһимәрдан аңа таба атлады, әмма юлына тәрәзә янында торган камчат бүрекле адәм аркылы төште.

Шәкүр карак кесәсеннән олы күн кенәгә чыгарып, аннан бер мең сумлык бияләй кадәрле кәгазь акчаны алды һәм өстәлгә салды.

—Үзең бәхәсләштең! Менә, мең тәңкә акча! Бүген бер ай вакыт чыкты. Айгырыңны тапсаң, бу акча да, айгыр да синеке! Юк икән, бигайбә! Риза-бәхил! Шарт малдан да, акчадан да өстен! Эзлә, айгырыңны тап!—диде, исе дә китмичә кәртләрен карады.

Ул хаклы иде. Шарт үтәлергә тиеш! Ә юк исә, Шаһимәрданның дәрәҗәсе дә, байлыгы да һичнәрсәгә тормый, бәяләре сукыр бер тиен! Үзе күнде, Казан байлары шаһитлык иттеләр.

Шәкүр карак һәм адәмнәре кәртле уйный калдылар, Шаһимәрдан, үз егетләрен чакырып, бөтен авылны тентергә, базларны да калдырмаска, чокыр-чакырын һәм сәндерә-түбә асларын да тикшерергә әмер бирде. Шул сәгатьтән дөньяның астын-өскә әйләндерү башланып китте. Шәкүр каракның аларда эше булмады, һаман да өстәл янында кәртле уйнап утыра бирде. Хәерсез!

Шаһимәрдан үзе үк базларга кадәр төшеп, идән-сайгакларны каертып, ду китереп айгырын эзләтте. Печән өемнәре һәм эскертләр урыннарыннан күчерелде, кош-корт һәм мал-туар куркышып бетте. Авылдан хәтта көтүне дә чыгармадылар һәм читтән дә һичкемне кертмәделәр. Көн кичкә авышканда бәрәңге бакчалары, яшертен базлары булмагае, дип, башаяк актарылып, әрәмәлекләр кат-кат ергаланды. Әмма ак айгырның кыл бөртеге дә табучы булмады. Эзләүне дәвам итүдән мәгънә юк иде. Һәммә халык тәмам арып һәм йончып бетте. Шаһимәрдан да, айгыры да, мең тәңкә акчасы да кирәк түгел кебек иде инде.

—Әллә кайчан Әстерханга илтеп житкергәннәрдер әле!—дип, Шәкүр каракның булганлыклары хакында риваятьләргә әверелгән вакыйгаларны бер-берләренә сөйләп, шуның белән күнелләрен юатырга тотындылар.

Халык акрынлап авыл башына җыелды. Кайсыберләре, кулларын селтәп, кайту юлына ук чыктылар. Шаһимәрдан аларны калырга, төне буе сак торырга өндәп карады. Әмма монардан файда булмады. Ак айгырны авылда табуга ышанмыйлар иде инде.

—Юк эш артыннан йөрибез,—диештеләр авыл агайлары.—Эскерт астындагы энә дә табылыр иде бу кадәр актарынуга, бу кадәр эзләүгә!..

Шулай да берничә егет кичке сакка калырга килештеләр. Ә төн тыныч узды. Иртәнгә җирне катырып җибәрде. Суык аларның желекләренә үтте. Шаһимәрдан суйдырып китерткән сарыкның сөякләре генә калды.

Таң беленгәч тагын авылга керделәр. Бу юлысы мөәзин инде мәчет манарасыннан азан әйтеп маташа, халык аякка басарга өлгергән иде. Шаһимәрдан һаман да шул зимагур йортына килде. Ишегалдына сибелгән кош-кортлары аңа игътибар да бирмәделәр, әтәче һәм тавыклары кыткылдый-кыткылдый тибенгәли, орлык чүпли иделәр.

Шаһимәрдан ишекне киң ачып йортка узды. Ул күз алдына китергәнчә Шәкүр карак үз адәмнәре белән өстәл янында һаман да кәртле уйнап утырырга тиеш иделәр. Әмма берсе дә күренмәде. Бу бушлык аны кергән жирендә һушын алып туктатты. Ятак өсләре дә буш, мич артындагы сәндерәдә һәм сәкедә дә адәм заты күренми иде. Шаһимәрдан артыннан зимагур Гыйльметдин авыр адымнары белән килеп керде. Ак ыштанын юантык корсагына таба күтәреп:

—Суытып жибәрде. Ай-һай, кыш салкын килер!—дип сөйләнеп алды, гүяки алар бергә гәпләшеп көн кичергәннәр, имеш; исәнлек-саулык та сорашып тормады.

—Ат караклары кайда?!—Шаһимәрданның болай ачу белән дәшүендә Гыйльметдиннең һич эше юк иде.

—Киттеләр, йокларга ятканда юлга чыккан иделәр инде!

—Ничек?

—Шулай... Җыендылар да китеп бардылар.

—Ә айгыр кайда?—Шаһимәрдан шунда зимагурның бугазыннан алды:—Айгыр кайда?.. Зинданда черетәм үзеңне!..

Гыйльметдиннең бу сүзләргә дә исе китмәде. Шаһимәрданның кулын, якасыннан кубарып, читкә алды.

—Ни өчен зинданга? Айгырыңны урламадым, падишаһ хәзрәтләре алдында гаебем юк!..

—Каракларны, ат каракларын яткырганың өчен, өеңдә асрап...

Шаһимәрдан икенче тапкыр якаламакчы иде, Гыйльметдин бу юлысы аның сузылган кулын тагын читкә этеп куйды.

—Үзең күрдең... Берсен дә яшереп яткырмадым. Кем килсә дә ишегем ачык, рәхим итсеннәр! Юлчыларга, кунакларга ишек ачарга Аллаһы Тәгалә үзе кушкан. Ә айгырыңны урлауларын күрмәдем. Анда минем катнашым юк. Шәкүр карак белән үзең шарт куешкансың...

Бу сүзләр хак иде. Шаһимәрдан чарасызлыгыннан һәм тинтәклегеннән хәлсез калды. Хушлашмыйча чыгып китте. Анда көтеп торган егетләре аның артыннан иярделәр. Айгыры урланган, ат каралары качкан, эш узган иде инде. Барлык тырышлыклары әрәмгә калды. Шаһимәрдан вакыйгаларның барышы, язмышының рәнжетүе белән килешергә мәжбүр булды.

* * *

... Герман сугышы тарихны бөтәнчә борып алып китте. Падишаһка тел-теш тидерү гадәти әйбергә әйләнде, байларга көпә-көндез, курыкмыйча йодрык күрсәтүләре дә эчне пошырмый. Дөньялыкны хәерсез битарафлык һәм мордарлык баса башлаган чор иде.

Казанга килеп, Шаһимәрдан сыраханәдә гамьгә бирелеп утыра иде, аның өстәленә бер тавык белән савыт китерделәр.

—Рәхим итегез!

—Сез нәрсә?—дип аптыраулы карашын төбәде ул.—Мин боларны сорамадым!

—Юк,—диде китерүче,—моны сезгә сыйланыр өчен юлладылар...

—Кем?

—Әнә теге, җирән сакаллы әфәнде! Без—яхшы танышлар, диде.

Бу җавапны ишеткәч, Шаһимәрдан шул якка борылып карады. Зур өлгеле тәрәзә янында Шәкүр карак үзе генә елмаеп утыра иде. Сәламләшеп баш кагыштылар. Бу мизгелдә Шаһимәрданның ана карата саклаган ачуы-үпкәсе юкка чыкты. Ничә елга беренче тапкырдыр күнеленнән гаме юылып төште. Күптәнге якын дустын очраткан кеше кебек балкып күтәрелде һәм аның өстәленә бар ризыклары белән күченде. Кул кысышулары бик җылы, дустанә булды. Дөрес икән—этнен койрыгын кем киссә, шул яхшы!

Шаһимәрдан кесәсеннән калын кенәгәсен чыгарды, Шәкүрнең алдына мең сумлык акча салды:

—Бирәчәгем калган иде!.. Рәхим итегез!..

Алар бер-берсенә карап тордылар. Шунда Шәкүр карак елмаеп җибәрде. Бераздан соң тыелгысыз көлүгә күчте, ана Шаһимәрдан кушылды. Сыраханә халкы аларга күтәрелеп, борылып, аптырашып карап-карап алгаладылар.

—Былтыргы акча быелгы акча түгел шул!—диде көлүдән тукталган Шәкүр карак, бәяләрнең үзгәрүен, акчаның бетә баруын искәртте.

Ул хаклы иде. Хәтта Шаһимәрдан да элеккеге гаярь, гамәлдә алдын-артын уйлап тормыйча эш итүче шашкын адәм түгел инде.

—Былтыргы акча быелгы акчага артык түгел,—дигән булды ул, үзенең кемлеген һич тә киметергә теләмәде. Хәер, Шәкүр карак шунда ук сүзне икенчегә борып:

—Сәүдәләр нишли? Эшләреңне бик тәгәри дип сөйләмиләр. Башына бәла алма, булган эш—беткән эш!

Аның әңгәмәдәшен бу рәвешле әле суга, әле утка чумдырып-чумдырып алуы үзе үк хәйләкәрлеге һәм акылы билгесе иде.

—Айгырым белән кул артым да китте, бәхетемне урладың!..

Шаһимәрданның болай зарланырга хакы бар иде. Соңгы елларда, чыннан да, ни сәүдәсендә, ни гаиләсендә, ни иманында тотрыклык булмады. Бохарага киткән кәрванын казакъ даласында таладылар. Сынар энәсен дә коткарып кала алмады. Вәкиле Миннегалинең кисек башын Өрә каласындагы таш мәсчет ишек төбендә, күн капчык эчендә аунап ятканда табып алдылар. Зәйнулла ишаннан алган «Фатиха кәгазе» мангаена чәпелгән, теле киселгән, колакларына «тавык тәпиләре» эленгән иде. Моны кемнәр эшләргә мөмкин, дип озак баш ваттылар. Имеш, казакълар арасында әле урыска, әле иманга күчеп, тәмам бозылып беткән бер кавем бар икән. Ни Коръәннән, ни Инҗилдән курыкмыйлар, ди. Үзләре шигырь әйтеп, җыру майтарып шайтан чакыралар, аракы эчүгә бик хирыслар, күкрәк сугышып:

—Мокыт-быкыт, акыт-бакыт!—дип баш болгап, җаннарын Иблис карамагына юллыйлар икән. Шаһимәрданның казакъ ханнарына барырга ниятләнеп йөргәннәрендә күнелен кайтардылар.

Дөньялыкта мал бетмәскә тиеш иде. Җаен белсәң кулга үзләре керергә торалар. Мокыт кавем белән ярышып яталар ди мени!

Шаһимәрдан бер-бер артлы ике кәрван мал алып, аның башына үзе менеп, хаҗ кылу нияте белән төрекмәннәр арасына чыкты. Ана һәркайда калер-хөрмәт күрсәттеләр. Нугай ата исеме белән Һиратка, аннан Һиндстанга юл алды. Һәркайда сәүдәсе уңыш белән гөрләп барды. Малы ишләнде. Нинди илгә-җиргә килмәсен, үзеннән алда Нугай ата исеме ирешкән, кемлеген күрер өчен биш күз белән көтеп ала иделәр.

Һиндстанда кәсеп юлын туктатып, кәрванын зур маллар белән йөкләп, иленә кайтырга чыгарып, озата калды. Үзе хаҗиләр җөббәсен киеп, кулына Коръәнен алып, асыл мөэминнәр гамәленә төште. Көймә белән Җиддәгә юнәлде. Аның кебек хаҗиләр арада галәмәт күп иделәр.

Әмма бәхетен, чыннан да, сыер сөзгән иде. Мөхит дингезенең кара дулкыннар айгыры тезгеннәреннән ычкынды. Иләмсез су тешләре тау-тау көйменең өстенә килде.

—Арабызда гөнаһлы бәндә бар, юкса хаҗилар юлын боздырырга Аллаһы Тәгалә рөхсәт бирмәс иде,—дип шобага тотыштылар.

Тәкъдир әмере Шаһимәрданга чыкты.

—Нугай ата, «Фатиха» укы, иманыңны яңарт, диңгез сине корбанга сорый!—диделәр аңа.

Аны-моны уйлап өлгергәнче күтәреп алдылар һәм тау булып килгән дулкынга чумдырдылар. Аллаһының теләге шул идеме, Шаһимәрдан җаны белән хушлашырга да житешмәде, аны шунда ук бирән диңгез йотты. Әмма бугазына сөяк кебек аркылы килгәнме, әллә Шаһимәрданның ризыгы бетмәгәнме, диңгез аны комлы эссе ярга төкерде.

Шаһимәрдан, күзен ачканда, бер алачыкта бизгәктән шабыр тиргә батып ята иде. Аңа кайнар кахвә эчерттеләр. Иреннәре пеште, тамагына кайнар кургашын койган кебек тоелды. Ул тагын да аңын югалтты. Хаҗиләр җөббәсеннән булуы файдага иде. Кемлеген белеп, һәртөрле хөрмәтне күрсәттеләр, Коръән укып өшкерделәр, үләннәр кайнатып эчерттеләр. Бу кешеләр әле җәннәтнең фәрештәләре, әле тәмугның җеннәре кебек тоела иделәр. Шаһимәрдан үзен һичшиксез үлгәннәр исемлегендә дип уйлады. Шулай да җәннәтле буласы килә, янында булучыларны да шунлыктан фәрештәләр сыйфатында күрергә тели иде. Бу кешеләрнең кара тәнле, җен кыяфәтле икәнлекләренә аптырап, житмәсә казан астында ут көйрәвенә дә күзе төшеп, чыннан да гамәле хараплыгын, тәмугка эләгүен уйлап, ара-тирә бөтенләй хәле китеп, файдасы тияргә мөмкинлектән иман кәлимәләрен укып, тәүбәләр әйтеп елаштыра башлады.

Аның янына ике адәм килде. Аяк-кулларыннан тотып күтәрделәр дә казан өстенә китерделәр. Ул кайный, быгыр-быгыр килеп эссе пар ата иде. Шаһимәрдан үзен анда салуларын теләмәде. Бәргәләнде, тартылды. Әмма көче житмәде. Казан пары аның бугазына утырды, ул тончыкты, буылды. Хәле китте. Тәне көядер кебек тоелды. Шунда кабат аңын югалтты. Тәмугка төшүендә һич шик юк иде!

Әмма Шаһимәрдан барыбер бирешергә теләмәде. Бар белгән догаларын һәм Коръән сүрәләрен күңеленнән туктаусыз укып, бу бәладән иртәме-соңмы котылу өметендә калды. Телендә бу сүзләр иде:

—Аллаһ Тәгалә барча колларына да рәхмәтле, мәрхәмәтле!

Йокылы-уяулы укынуларын ишеттеләр булырга кирәк, аны бүтән бер тапкыр да казан янына кабат китермәделәр. Аягына басканда, үзен сихәтләнгән итеп тойды. Аның алдында һәркем тез чүкте.

—Юныс! Юныс! Әлхамдулиллаһи!—дип сәлам бирделәр.

Шаһимәрдан бу сүзләрнең мәгънәсен төшенергә өлгерде. Балык авызыннан чыккан Юныс пәйгамбәр хакындагы кыйссаны ул бала чагыннан ук белә иде. Халыкның ялгышуы аны куркытты. Мөмкин булса, тизрәк китеп барыр, качар иде. Шулай да ул монда тәмам ныгып житкәнче калырга мәжбүр. Кешеләрнең аңа мөгамәләсе яхшы, холыклары тигез һәм хөрмәтчел иде. Үз мәкаме белән Коръән дә укып җибәргәч, яше-карты, күзләреннән яшьләрен чыгарып:

—Йа рәсүл, йа Аллаһ!—дип сәҗдәләр итә башлагач, Шаһимәрданның тагын да коты очты, артка чигенде.

Шунда кулына Коръән китереп тоттырдылар. Коръән аның үзенеке иде. Хәтере яңарып, исенә төшерде: юлдашларының көймәдән ташлаган чагында күкрәгенә кыскан шул Казан басмасы «Кәләм-Шәриф»е иде.

Ана һәммә әһеле изге олуг затка өмет белән караган кебек могжиза теләп күз текәделәр. Шаһимәрдан алай ук арбадан төшеп калганнардан түгел иде. Әмма әле генә башы да эшләп житкермәде, шулай да күнеленә килгән фикеренең жебе очына ябышты. Коръән ачып укый да башлады. Аның тавышы халыкка могжиза булып ишетелде. Күзләренең яшьләнүен сизенде. Аллаһының рәхмәте, Юныс пәйгамбәр хакындагы аятьләргә туры килеп, иш өстенә куш, дигәндәй, хикмәт янына хикмәт иде бу.

Аны күтәреп кенә алмадылар. Әллә кайлардан ишетеп, әле аксакаллар, әле сукырлар жыелыша, гарип-гораба балаларын күтәреп килә башладылар. Шаһимәрдан:

—Мин рәсүл түгел, мин пәйгамбәр түгел! Нигә киләсез?—дип аларга үз телендә мөрәжәгать итеп карады.

Әмма күңел чиләкләренә өмет суы тутырып килгән халык аның бу сүзләрен әллә ниткән бер дога-өшкерү, Аллаһының хикмәтле сүзе сыйфатында кабул иттеләр. Егыла-түнә:

—Аллаһу әкбәр! Аллаһу әкбәр! Аллаһу әкбәр!—дияргә тотындылар.

Аларның сәжделәре Шаһимәрданны куркуга салды. Ике кулын да күтәреп артка таба чигенде, үзе:

—Мин—Нугай ата, мин—Шаһимәрдан! Нишлисез? Нигә мине жәберлисез? Мин беркем дә түгел!—дип коты алынган хәлендә сөйләнде.

Гарип-гораба халык тезләрендә ана таба якыная торды. Ул диварга барып терәлде. Ахырда:

—Лә иләһи Илләллаһ, Мөхәммәд—рәсүлүллаһ!—диде.

Аның сүзләрен халык бердәм кабатлады. Йөзләрендә шатлык һәм сөенеч иде. Һәр сүзен дога һәм Аллаһының хикмәте дип кабул итүләре сәбәпле, Шаһимәрдан чарасыз калды. Гарәпчә сөйләшә белмәвенең жәфасын менә шушында барча тулылыгы белән татыды. Хәлсезләнеп егылды. Һичкемне күрәсе килми иде.

Халык аның яныннан сихәтен табып китәр дип башына да китермәде. Әмма язмыш аңа бәхет сукмагына юл күрсәтте. Шаһимәрданның даны Юныс әүлия исеме белән еракларга таралды. Ул үзенең ата-анасыннан мирас итеп алган татар сүзенең никадәр сихри һәм тәэсирле икәнлеген бары тик шушында, чит илдә, ят халыклар каршысында таныды. Югыйсә кешеләр, илләреннән аерылып, ана телләреннән башканы белмичә хафада калалар, ә ул тулы бәхеткә төкәнде. Әүлиялеген үзе дә танырга мәжбүр булды.

Ана көннән-көн кешеләр күбрәк килә, барысы да сәламәтләнү өметендә алдына егыла, тынычлык табып, гүяки әбел-хаят суын эчкәндәй балкып китә иделәр. Шаһимәрданның хужасы да күзгә күренеп баеды. Һәрдаим аның өчен жан ата, гомерендә һичкемнән тапмаганны аңардан казанганга урынын да түргә кучерергә мәжбүр булды. Әмма монда торып калу Шаһимәрданның исәбендә дә юк иде. Юлга чыгар өчен кулында малы булса, һич тә тоткарланмаячак ул!

Шушы уйлар белән йөргәнендә, ул үзенең күңеле тутыга барганлыгын тойды. Байлык жыярга керешүе моңа сәбәпче икәнлеген уйлап та карамады. Ә көннәрнең берендә агач күләгәсендә ялгызы гына утыра иде, ике кешенең кочаклашып, жырлашып һәм тәрткәләшеп килүен күреп хәйран калды. Ни кайнар канлы гарәп халкында ком чүленең эсселеген якалашу белән сүндерергә омтылу хисе барлыгына инде сәерсенми иде югыйсә. Әмма, болай ук булырлар, мондый хәлне дә тамаша кылырга туры килер, дип башына да китермәгән иде. Исенә Казан шәһәре килде. Андагы бурлак урысларның артыгы белән эчеп алып, әүвәле урамнардан кочаклашып жырлашып узуларын, аннары тыкрык һәм чатларда каннарга батып калай әтәчләрдәй сугышуларын-чәкәләшүләрен хәтеренә китерде. Бу вакытта аңа шул якташлары, нинди генә юньсез булмасыннар, бик якын һәм үз булып тоелдылар. Шуңа да күләгәдән чыкты, кочаклашып, сугышып һәм дәгъвәләшеп килүчеләргә таба атлады. Шушы дөнья читендә дә урысларның пәйда булуы сәеррәк иде.

Аралары якынлашкан саен Шаһимәрдан үзенең буе кечерәя баруын тойды. Бу ике кеше дигәне гәүдәгә олы булып чыктылар. Шушы Йәмән илендә мондый кешеләр юклыгы аңа яхшы мәгълүм иде. Әмма болар да гарәпчә сөйләшә, тарткалаша, Шаһимәрданга игътибар да итеп тормастан, бер-берсенең башларына субай чүкечедәй олы йодрыклары белән тондырыша иделәр.

Шаһимәрдан таңга-гаҗәпкә калды. Бу ике кеше дигәнең һич тә камил дәрәҗәдә ике зат дип булмый иде. Дөресрәге, һәркайсысында икешәр аяк, икешәр кул, берәр баш, ә гәүдәләре—уртак. Кеме беренче булып төртсә дә, шунда ук үзе үк кычкырып җибәрә, авыртуны беренче булып үзе тоя иде.

Моның ат кәмите түгеллеген аңлаган Шаһимәрдан алар янынннан тизрәк качу җаен карады. Иләмсез олы гәүдәле бу мәлгуньнәр аны таптап китәргә дә мөмкин иделәр.

Халык йорт түбәләрендә шушы хәлне тамаша кылганда, Шаһимәрдан өй биеклеге зур таш тавы өстенә үрмәләде. Ә тегеләр ул арада төртешүдән сугышуга, сугышудан елашуга, елашудан дөмбәсләшүгә күчтеләр. Ахырда икесе дә тәмам арып, аунаган җирләрендә ятып калдылар. Аларның шушы хәлдә гырлап йокыга китүләре бик сәер иде. Шаһимәрдан бу күргәннәрен ничек аңларга да белмәде. Исән чагында таш тавыннан төшеп, алачыгына таба ашыкты. Кайтып ишеген ябуга, түбәдән хуҗа сикерде һәм:

—Әэҗүҗ-мәэҗүҗ!—дип теге адәмнәр яткан якка төртеп күрсәтте.—Дәҗҗал...

Ул хаклы иде. Бу хәл, чыннан да, Әэҗүҗ-Мәэҗүҗ галәмәтеннән булырга тиеш, башкача аңлату мөмкин түгел!

Шаһимәрдан тагын да хәтерен яңартты. Дөбъяз ягы Җәке авылының атаклы мулласы, бабасы Гариф хәзрәткә, атын харап иткәннән соң айгыр вәгъдә ителеп тә, алмашка бия китерә килгәч:

—Безнең татар кавеме Әэҗүҗ-Мәэҗүҗдән булырга кирәк! Искәндәр падишаһ безне тәрәккый иткән кавемнәрдән аерып куяр өчен Кытай илендә биек дивар төзеткән,—дип әллә нинди бер тарих китабын укуын, Шәкүр каракның исә моңа дәлилле мисал икәнлеген сөйләгән иде.

Ялгышкан хәзрәт, ялгышкан! Менә нинди була икән ул Әэҗүҗ-Мәэҗүҗ!

Әмма Шаһимәрданга озак уйланып утырырга насыйп булмады. Авылның олы агайлары ишекне күтәреп керделәр. Йорт каршысына барча халыкның җыелганлыгын Шаһимәрдан да алар тупсадан атлаганда ук күреп калды. Керүчеләр шунда сәҗдәгә киттеләр.

—Йа Мәһди, йа коткаручы!—дигән сүзләрен аңларга өлгереп калды.

Аны хәзер Юныс дип һичкем атарга җыенмавын төшенде. Борынгыдан килгән хәбәрләрне, Коръән аятьләрен ул үзе дә белә иде. Ахырзаман житсә, Дәҗҗал кубар, Әэҗүҗ-Мәэҗүҗ чыгар, әмма аларга каршы Аллаһы Тәгалә Мәһди пәйгамбәрне җибәрер!

—Юк, мин—ул түгел, Мәһди түгел!—диярgә ирек бирмәделәрме әллә әйткәннәрен дога дип кабул иттеләрме, барысы да «Аллаһу әкбәр» сүзләре белән тагын сәҗдәгә киттеләр.

Вакыйгаларның һаман да шулай халыкка кирәкчә борылыш алуына ул күнегеп беткән иде. Әмма Дәҗҗал һәм Әэҗүҗ-Мәэҗүҗләр белән алышырга кодрәте житмәячәк! Моны гына яхшы аңлый. Ялган пәйгамбәрлек, ялган әүлиялек үзен ахырда һичшиксез харап итәчәген дә күзаллый. Тик нишләргә мөмкин? Качып китсә генә инде!..

Шаһимәрдан шушы фикереннән тыш башкача чарасы юклыгын яхшы аңлый. Тик менә кая, ничек качып китү җаен гына белмичә интегә. Барыбер мәсьәләнең ахыры килеп чыгасы, оятлы булачагы аны куркыта иде.

Нәкъ шул вакытта Дәҗҗал дигәннәре кабат купты. Үкерү авазына борылып караса, ул ара өстенә кулларын болгап килә иде. Куркынган

халык, гүяки тавык чебешләре тилгәннән ташландылар, тузан, гауга купты. Шушы мәхшәрдә Шаһимәрдан тезгененә бәйләнгән, унга-сулга тартылып-дулап та ычкына алмаган жирән бияне күреп алды һәм ана таба йөгерде. Атка утырырга өлгермәде, дөяләр артыннан алып китте. Малкайлар шулкадәр дә куркышкан иделәр ки, күбеккә батканчы чаптылар да чаптылар. Кичкә дөяләр үзләре Шаһимәрдан тирәсенә елыштылар. Инде аларга ул үзе хужа иде. Йорт хайваннары шундый жаннардан инде алар, үзләренә адәм баласының баш булуын яраталар, аңа сыеналар, ана буйсыналар.

Шаһимәрдан кире кайтырга теләмәде. Калкулыкка күтәрелеп һәр тарафны күзәтте. Дөяләрне жыеп бетерде. Нукталарын бер-берсенә бәйләде һәм ятып йоклады. Аллаһының рәхмәте, төн тыныч узды. Аның артыннан куып та, эзләп тә килүчеләр булмады. Икенче көнне, еракта̧н узып баручы кәрванны күреп, артыннан иярде. Ялгышмады. Юл аны Йәмән иленнән читкә алып китте.

Шам илендә Шаһимәрданның телен аңлаучы төрекләр күп булып чыкты. Кырык бер баш дөясен сатып шактый гына акча юнәтте. Калган сигез дөягә товар йөкләп, Һират һәм Бохара тарафына озатучы хезмәтчеләрне яллап юлга чыкты. Сәүдәсе һәр базарда уңышлы барды. Кәрвансарайларда халык авызыннан Йәмән илендә яшәүче әүлия хакында гажәеп хәбәрләр, риваять һәм хикәяләр ишетеп, күңелендә хәтта шул кешене күрү теләге дә кузгалды. Әмма аңа бары тик көзгегә генә карау кирәк, сүзләрнең үзе хакында барганлыгын башына да кертеп карамады бит ул...

Шаһимәрданның кулы мал кергәнне ярата иде. Никадәр күбрәк булса, шулкадәр сөенечлерәк. Ул гына да түгел, мал үзе дә аның кулы аша узуны сөя иде ахрысы.

Шушы исәпләр белән Шаһимәрдан Бохарага килеп житте. Әмма бу вакытта кыш фасылы кереп, коры һәм суык һавадан гажизләнгән шәһәр халкы арасында һәртөрле авырулар башланып, аңа да йокты. Тора алмас хәлгә төшеп, урын өстендә атналар буена юньле тәрбия күрмичә, тәмам ябыгып, үлем хәлендә ятты. Товарына-малына күз-колак булучы юк иде. Ни иманлы мөэмин-мөселман халкы саналган бохаралыларның нәфсесе бозык, калебләре сафлыкны онытканлыгын танырга мәжбүр ителде. Ун көн дигәндә мал-туарларына яна хужалар табылып, күп өлеше әмирнең хәзинәсенә алдырылган, Шаһимәрданның үзенә тамгасыз сәүдә иткән дип гаеп тагылган иде. Ялангач калып та, Аллаһы рәхмәте белән кабат тернәкләнеп киткән, янадан аякка басып та йөзтүбән мәтәлгән кешенең күңеле тулы сабырлык булырга тиеш иде инде. Үз малын кабат кулына кайтару өчен, Шаһимәрдан ничәмә тапкыр әмирнең бусагасына килеп карады. Әүвәле камчылап сөреп чыгарсалар, ахыргы килүендә зинданга салып, язга кадәр тоттылар. Бу зиндан дигәннәре үләксә базыдай чокыр булып, анда гаепле дә, гаепсез дә бер үк түбәнлеккә ыргытылган иделәр. Ризык та юк дәрәжәсендә, этләргә ташлана торган коры сөяк һәм чүпле арпа бөртекләреннән генә гыйбарәт исә дә, Шаһимәрдан бирешмәде, үз өлешенә теше-тырнагы белән ябышты. Шунда ул үзенең ахмаклыкларын уйлап, безнең мөселман хужасы, безнең падишабыз дип ышанып йөргән Бохара әмиренең Исламга, гаделлек һәм хаклыкка һичбер катнашы юклыгын, гадел кәфер белән чагыштырырлыгы да юклыгын төшенде. Әмма терсәк тешләргә соң иде инде.

Аларның кайсыберләрен вакыты житеп чыгара, хөкемгә тарта тордылар. Берсе дә кире кайтарылмады. Нәүбәт Шаһимәрданга да бүген-иртәгә житәргә тиеш иде. Әмма һаман да аны искә алучы булмады.

Адәм баласыннан барысы да йөз чөерсә, бәла ярдәмгә килә, әгәр дә Аллаһы кушса, дигәннәрен ишеткәне бар иде аның. Нәкъ шулай булып чыкты да.

Зиндан эченә баскыч төшергәннәр иде. Югарыдан кемнедер дәшеп кычкырган вакытта кинәт жир кузгалып, тетрәнеп куйды. Зилзилә кубарга тиешлеген һәркем аңлап югарыга атылды. Шаһимәрдан алардан

калышмады. Берләре түбән очтылар, сытылдылар, харап булдылар. Якты дөньяга борын төртүгә, ул бер почмакка сенде. Тавыш-гауга, буталыш дәвам итте. Жир тагын бер калтыранып, диварларны ярды, бозды. Анда да, монда да үлем иде. Шаһимәрдан ничек тә Бохарадан чыгып, төрекмән арасына, көнбатышка таба юл алды. Казакъ даласына ышанычы юк иде.

* * *

... Мең газап һәм гаделсезлекләр аша үтеп, иленә кайтып егылган ирнең кадерле булырга хакы бар! Әмма Шаһимәрданны монда да мыскыллау һәм түбәнлекләр көтеп торган икән. Аны һәлак булган дип белешеп, хатыннары җәһәтрәк яшь хезмәтчеләренә чыгып, башлы-күзле булып беткәннәр, малларын бүлгәләшеп, йортын-жирен туздырганнар.

Шаһимәрдан кайтып төшүгә, ярты авылы йокысыннан калды, ярты авылы тавыш-гауга коткысына бирелде. Кеше малына кул сузарга һичкемнең хакы юк иде. Кайтарып бирергә теләүчеләр дә күренмәде. Шаһимәрданның бәхетенә, Җәке мулласы Гарифнең кызы Бибисәрвәрҗәмилә, карт хатыны, әле кияүле булырга өлгермәгән, таланганнан калган малы белән сукранып яши бирә иде. Анысы да:

—Хатын өстенә хатын алып, бала өстенә бала таптырып, әллә кем булмакчы идең. Үзең олагуга, барысы таралып беттеме?!—дип Шаһимәрданны мыскыллаудан узмады.

... Үлеп котылган кеше генә мәсхәрәнең авырлыгын күрми. Шаһимәрдан сер биреп торырга, тавыш-гауга куптарырга ниятләсә дә, ахырда: «Бу җәфалардан, хәсрәт капчыкларыннан котылдым әле!»—дип эчтән куанды, тыштан үзен ачулы күрсәтеп, һичкем белән исәнләшмәс һәм исәпләшмәс булды. Яңадан да сәүдәсен яңартып, Казанга мал белән килер дәрәҗәгә житте. Тәүге базарыннан соң әл-хәл алгач, сыраханәгә аяк басты. Шәкүр карак белән очрашуы да нәкъ шушы керүендә булды. Бу вакытта илдә—сугыш, Германның күтәрелгән, халыкның гажизлеккә төшкән еллары иде.

Шаһимәрдан өстәлгә җәеп салган мең сумлык акчасына кызганып карап алды һәм:

—Шәкүр агай, ал моны...—дип үтенде.—Дөнья читеннән шушы бирәчәгемне тапшырырга кайттым. Алачак тотмый, бирәчәк тота икән!.. Шулай да ничек урладың ул айгырны?.. Эзеңнән килеп тә алалмадым шул!..

Шәкүр карак күзләрен елтыратып елмайды да:

—Бүтәнгә булса, сөйләмәс идем. Ярар, сиңа әйтим инде,—дип сүзен башлады.

—Эш болай булды, кем, энем хәзрәт... Шактый газапладың син мине, билләһи! Ай буе урманда яттым. Егетләрем тузына башладылар. Төннәрен төшә идем. Ә авылыңны әйләнә буена кат-кат уратып саклыйлар. Ихатаңа да керерлек түгел. Шулай да сәндерәңә менеп яттым. Көне буе күзәтеп, белешеп, җай эзләп аптырап беттем. Минем бәхеткә, синең көенечкә, яшь хатының белән ат караучың печәнлектә шаяргалыйлар икән. Берсе әйтә: «Кирәкми, Ярулла, эшебез сизелсә, адәм хуры булырбыз»,—ди, икенчесе: «Йә инде, Гыйззебану, бер кочканнан гына кендек чишелми»,—дип тегене үчекли. Онытылып киттеләр дә ачкычларны төшергәннәрен сизмичә калдылар... Ишетеп беләм, башлы-күзле булганнар икән!..

Шаһимәрданның сабыр гына тыңлап утырудан гайре чарасы юк иде. Шәкүр карак исә сүзен дәвам итте:

—Шуннан, шул ачкычларны алып, үз кесәмә салдым да, эшнең ахырын уйлап, бераз йокыга талдым. Әй кыштырдыйлар, әй печәнне болгаталар. Уянып китсәм, Яруллаң ачкычларын эзли икән... Мин айгырны урлаган төндә килә тең бикле түгел иде. Егетләрем белән күрше авылдагы

Гыйльметдингә төштек. Ана аны-моны белдермәсәк тә, халыкта сүз булган икән инде, ул да барысыннан да хәбәрдар иде.

Айгырны аларга урлап кайтардым... Ялганчы йозак: «Килегез, кил, мин—ачык!»—дип көтеп тора иде. Атны чыгаргач, шалт, бикләп куйдым. Ачкычларны шунда, нигез буена ыргыттым. «Бикле ишектән дә Шәкүр карак атны алып чыга!»—дип сөйлиләрме? Юк сүз ул! Юк сүз...

Сөйләгәннәренең шушы кадәресеннән вакыйганың ничек булганлыгы аңлашыла иде. Шаһимәрданның җөпле хәбәрне бик алай ук ваклап тынлыйсы килмәде, әллә күңеленә борчу инеп, сабырын югалттымы:

—Артыннан бастырып киддек, авылга керден, чыкмадың. Туздырмаган җир калмады, бәрәнге бакчаларына кадәр һәммәсен казып-болгатып чыгучылар булды. Айгыр табылмады. Кайда иде?—дип Шәкүр каракка күзен дүрт итеп төбәде.

—Бер дә әллә кайда түгел иде, тирес астына тыктык без аны. Тирес астына!.. Чаптырып кайткан мәлгә арбага салып китердек тә, аякларын-башын бәйләп күмдек тә куйдык. Ә тирес өстенә орлык сиптек. Таптылар инде, дигән идем дә һичкемнең башына килмәде. Ә тавыклар, шул орлыкларны җыеп, рәхәтләнеп тибенеп йөрделәр. Менә шулай булды эш. Тирес астында атка бернинди зыян юк, яхшырып кына китә ул!

—Әйтәм ул тавыклар рәхәтләнеп тибенәләр иде.—Шаһимәрдан үзенең ахмаклыгына үзе үк хәйран калды. Моңа кадәр күпме мал күреп, дөнья белән шаярып һәм болганып яшәгәндә дә, бүтәннәрнең ахмаклыкларыннан көлеп йөреп тә, үзенең шундый ук ахмаклар рәтеннән булганлыгын тануы ана җинел түгел иде.—Адәм көлкесе!..

—Ярар, вәгъдә—иман! Үпкәләштән булмасын, Шаһимәрдан, очрашырга язсын!

Шәкүр карак аның өстәлгә салган мең сумлык акчасын алды да кесәсенә бөтәрләп тыгып, артына да борылып карамыйча чыгып китте. Аның җинел һәм йомшак адымнары бу ирнең кемлегенә бер дә бәрәбәр түгел сыман иде. Ул авыр басып, кукраеп йөрергә тиештер дә, әмма бераз бөкерәеп, каранып кына атлавы тәкъва картларны хәтерләткәнлектән, һичкемнең игътибарын җәлеп итмәде.

Шаһимәрданның исенә теге күп сүзле Минзәлә бае Мөхәммәтҗан килде. Нигәдер аны күрергә уйлады.

—Минзәләгә кәрван җиктерергә!..—дип әйтеп куйды.

Бу аның үз-үзенә әмере кебек иде. Һәм ул шулай эшләр дә!..

Шаһимәрданның монда озаклап, кайберәүләр кебек калгып утырырга исәбендә юк иде. Өстәлдәге ризыклардан кайсыларын юл азыгы өчен үзе белән җыеп алды да китеп барды. Казанда эше беткән, гүяки уңышсулы тигезләнгән, күңел борчулары сүнгән кебек иде. Һичкемгә күтәрелеп карамыйча, атын җинел генә йөгертеп барды. Көннең кичкә авышуы да аны ашыктырырга тиеш иде. Әмма моңа исе дә китмәде. Казанны чыккач, күңеле моңланып, бераз җыр сузды. Дәрвишләр бистәсеннән соң юл чатланып киткән урында күңеленә кайнарлык инеп, аһ авазын чыгарды һәм, арбасыннан төшеп, җиргә ятып елады да елады. Бу вакытта хәтере саташкан идеме, әллә дөньялык аның барлыгын бер мәлгә онытып тордымы, һични уйламас хәлендә шактый озак ятты. Аны йокы да алмады, күңеле генә чиксез галәмнең бушлыгында адашып йөргән шикелле һаман да утырып җитмәде...

Гомернең узулары берни түгел, хәере белән үтсен! Әмма җан тынычлыгын югалту бик хәтәр нәрсә икән ул. Аны эш белән дә, мәшәкать тартып та җаена китереп булмый.

*Дөнья әдәбияты җәүһәрләре*

# БАЙРОН ҺӘМ АНЫҢ «ТӨШ»Е

*Бөек инглиз шагыйре Джордж Гордон Байрон (1788 - 1824) иҗаты бөтендөнья әдәбияты романтизм чоры белән бәйле гаҗәеп бер күренеш булып кереп калган. Ул бөтен гомере буена хөрлек һәм азатлык идеяләрен, халыкларның ирек һәм бәйсезлек өчен көрәшләрен яклап яши һәм иҗат итә, изелгән милләтләрне бәйсезлек өчен ахыргача көрәшергә өнди. Шагыйрь үзенең иҗаты белән дә, шәхси тормышы белән дә, чын мәгънәсендә рухи хөрлек символы булып кала. Аның бөтен кешелек дөньясын бербөтен итеп күзаллавы, халыклар дуслыгын алга сөрүе бүгенге көндә дә искиткеч актуаль. Бу шагыйрьне, хәзергечә әйтсәк, «Бөтендөнья гражданины» дип атарга да булыр иде. «Милли язмышлары күбесенчә эре державалар һәм дәүләтләрнең тышкы сәясәтенә бәйле булган төрле халыкларның тормышы белән танышу аның сәяси офыкларын тагын да киңәйтә, иҗтимагый фикерләвен үткенләндерә», - дип яза Байрон иҗаты белгече Р. Усманова үзенең «Джордж Гордон Байрон» дигән хезмәтендә (Байрон, Избранное. Москва, Издательство «Правда», 1982). Берара ул Англиянең лордлар палатасы составында да тора. Ләкин аның парламент эшчәнлеге озак дәвам итми, чөнки ул анда үзенең япаялгыз булуын сизеп ала... Озак та үтми, аның зур талантыннан көнләшүчеләр һәм бигрәк тә, бәйсез рухын күрә алмаучылар күбәеп китә. Аңа каршы төрле сәяси һәм шәхси гайбәтләр таратыла, чөнки шагыйрьнең гаделлеккә омтылуы югары катлау аристократларга һич тә ошамый. Нәтиҗәдә, ул Англияне бөтенләйгә ташлап, чит илгә китәргә мәҗбүр була.*

*Башта ул Швейцариядә яшәп ала. Соңрак Италиягә китә һәм анда төрле сәяси хәрәкәтләрдә актив катнаша. 1823 нче елда исә ул грек халкының азатлык хәрәкәтендә турыдан-туры катнашу максаты белән, Италиядән Грециягә китеп бара. Гомумән, Греция аны үзенең антик әдәбияты һәм сәнгате белән әсир иткән иң яраткан иле була.*

*1824 нче елның язында ул каты авырудан соң, Грециядә вафат була. Аның җәсәден үз ватанына алып кайтып җирлиләр. ...Швейцариядә торганда, ул «Төш» дигән лирикпсихологик әсәрен яза. Бу әсәр 1816 нчы елда басылып чыга. Анда Байронның үз тормышыннан алынган кайбер вакыйгалар, аерым алганда, 15 яшеннән гашыйк булып яратып йөргән кызы Мэри Энн Чавортка булган хисләре чагылыш таба. (Сүз уңаенда, Байроннар гаиләсе Мэри Чаворт гаиләсе белән дус булмавын да искә алып үтик. «Төш» әсәрендә моңа бер кечкенә генә ишарә дә бар...) Шуның белән бергә, әсәрдә шагыйрь үзенең эчке рухи газапларын, төшенкелек кичерешләрен дә чагылдыра. Бу хисләрен ул төш күрү рәвешендә, гаҗәеп образлы итеп күз алдына китерә, символик сурәтләү чарасы сыйфатында «төш» халәтен кешенең чын реаль тормышын чагылдыруда кулланып, укучыга аеруча тирән тәэсир итүгә ирешә.*

*Байрон поэзиягә бөтен кешелек дөньясының фәлсәфи һәм сәяси идеяләре белән тыгыз бәйләнештә торучы сәнгать чарасы итеп карый. Үзенең бөтен иҗатында изгелекнең яманлыкны җиңәчәгенә, саф күңелле кешеләрнең акыл куәтенә тирән ышаныч белән яши.*

*...Мин бу әсәрне тәрҗемә иткәндә, М. Зенкевичның русчага шигъри тәрҗемәсеннән (Байрон, Избранное, Москва, 1982), шулай ук Байрон иҗаты белгече Рауза Усманованың инглиз теленнән татарчага юлга-юл ясаган тәрҗемәләреннән файдаландым, һәм аларга үземнең рәхмәтемне белдерәм.*

**Лена ШАГЫЙРЬҖАН**

*2000 ел, июнь.*

# Байрон

## Төш

### I

Тормыш безнең ике катлы. Йокы—
Үлем белән Яшәү чигендәге
Бер халәт ул, диеп ялгышалар...
Йокы һәм Төш—үзе бер дөнья ул:
Тормыш сулышы, Галәм чынбарлыгы.
Төш ул—Хәтер рухы. Үткәннәрдән
Хәбәр бирә, яисә Киләчәкне
Күрәзәли—Сивиллалар сыман.
Ул идарә итә безнең белән,
Җаныбызны гүя икегә бүлә
Мәңгелек һәм Бүген үлчәвендә.
Дәвамыдай кичереш, уй-хисләрнең
Елата ул безне, йә көлдерә,
Өндәге күк газап, ләззәт эчереп.
Йә кузгатып әллә кайчангыны—
Шәүләләре белән тетрәндерә.
Әллә соң ул шәүлә түгел микән?
Алай булгач, нәрсә соң ул Төш?
Акыл иҗатымы? Булыр да...
Акыл бит ул планеталарны да
Нурлы затлар белән тутыра,
Мәңгелекнең тыны белән өретеп.
...Бер төш күрдем. Бәлки, хыялдагы
Йокымсырап яткан уемдыр ул?—
Йокы йомгагына сыя еллар,
Бер сәгатьлек төшкә—гомер юлы...

### II

Ике яшьне күрдем мин—янәшә
Яшел тау башында басып торган.
Бу тау сөзәкләнеп җәелә ерак,
Диңгез эченә кереп барган сыман.
Тик тау итәгендә диңгез түгел,
Дулкынланып җәйри урман-кырлар.
Анда-санда сибелешкән йортлар.
Тутыгып беткән түбәләреннән
Борыла-сарыла күтәрелә төтен...
Калкулыкның очын муенса күк
Каймалаган агач тезмәләре.
Тик табигать уенынан түгел,
Хасил булган кеше уеннан ул.
...Бу ике яшь карап тора шуннан:
Кыз—сокланып гүзәл манзарага,
Егет исә күзен алмый кыздан.
Икесе дә яшь-яшь. Тик бу яшьлек
Икесендә ике сыйфат алган:
Кыз—Ай төсле яңа туып килгән,
Хатын-кызлык инде беленеп килә.
Егет яшьрәк күренә, ә йөрәге
Үз яшеннән күпкә өлкәнрәк...
Кызның йөзе—гүя Таң Йолдызы:

Текәлгән дә, тынсыз калган егет,
Югалтырмын диеп курыккан кебек.
Әсир иткән аны кызның тавышы,
Тыңлый сүзсез—калтыранып әчтән.
Тирә-юньнең гүзәл сурәтен дә
Шәйләп кала тик аның күзеннән.
Ул ваз кичкән күптән үз-үзеннән,
Бөтен фикере юнәлгән тик аңа,
Елгалар күк—аккан океанга.
Орынып китсә, ут күк яна башлый,
Үләр хәлгә җитеп яратудан...
Әмма кыз битараф бу мәҗнүнгә,
Күрсенүләре дә бүтән өчен.
Малайга ул карый энесе итеп—
Бала чакта җуйган бер туганы...
Шул якынлык хисе фәкать аны
Бәйләп тора гашыйк үсмер белән.
Кыз—борынгы затлы бер нәселнең
Соңгы буыны. Егет күңеленә
Никтер, ошап бетми бу гаилә,
Серен моның ул соңыннан белә...
Сизелеп тора: кыз башканы сөя.
Менә хәзер дә ул тау башыннан
Түземсезлек белән күзли аны,
Күренмәсме атта сөйгән яры—
Китәр иде очып каршысына...

III

Кинәт шунда алмашынды төшем.
Күрәм бер борынгы утар эчен:
Иярле ат—дивар катында.
Теге егет ялгыз. Арлы-бирле
Йөренә иске гыйбадәтханәдә.
Агарынган... Менә, каләмен алып,
Утыра да, тиз-тиз яза башлый,
Хатмы—белмим... Калтыранып кисәк,
Йөзе белән учына каплана ул.
Сикереп торып, кабат, дерелдәгән
Бармаклары, хәтта теше белән
Язуын ул ботарлап ук ташлый.
Аннан бераз тынычлана төшә,
Кулга алып үзен. Шул чагында
Килеп керә янына сөйгән яры:
Ул бик тыныч, көләч—белә чөнки
Яшь гашыйкның өзелеп ратканын.
Егет моны төшенә—җан газабы
Чыга төсенә. Кызга кызганыч ул:
Күреп тора... Күреп бетерми дә...
Салкын гына шунда егетебез
Кулын бирә кызга, әдәп саклап
Һәм йөзеннән аның каттый бер уй
Чагылып үтә яшен тизлегендә.
Аннан, җибәрә дә кулын кызның,
Чыгып китә акрын гына атлап,
Көтми хәтта «Сау бул» дигәнен дә.
Елмаешып кына айрылалар.
Үз юлына китә егет атта.
Ябыла капка. Йорт та кала артта—
Бусагасын кермәс бүтән атлап...

## IV

Кинәт шунда алмашынды төшем.
Ир-ат булып җиткән егет кешем.
Сыеныр урын тапкан ул чит илдә,
Торган җире—эссе киң далада.
Йотылып эчә җаны кояш нурын,
Тәне изри җиләс күләгәдә.
Илләр гизеп, кичеп диңгезләрне,
Мәңге сәйяр, юлчы булып калган.
...Күңелемнән дулкын-дулкын йөгереп
Хатирәләр узды... Бит бу егет—
Бер кисәге минем үз җанымның...
Ул ял итеп ята, исемнәрен
Тарих кына белгән мигъмарларның
Җимерек биналары—борынгылык
Сеңгән хәрабәләр арасында...
Ерак түгел дөяләр утлап йөри,
Фонтан кырлап атлар тора бәйдә.
Купшы кием кигән сәер бәндә
Юлчыларның йокысын саклап утыра.
Зәңгәр күк гөмбәзе шундый аяз—
Бер Алла тик аннан карап тора.

## V

Кинәт тагын алмашынды төшем.
Күрәм—иргә чыккан сөйгән кызым.
Шул утарда, имеш, көн итәләр.
Бала-чага тавышы күмгән йортны—
Үсеп килә монда гүзәл буын...
Ә чын гашыйк читтә, бик еракта.
Ник соң боек яшь ананың йөзе?
Чыраена чыккан сагыш-борчу,
Керфекләрен игән, яшьле күзен
Яшерә, кеше-кара күрмәсен, дип.
Ник хәсрәтле? Бары да янында иң.
Юк шул... Кайда икән ул яшь егет,
Тынычлыгын аның җуючы зат,
Өметләнеп, дөрләп, янып-көеп.
Ник хәсрәткә баткан? Үзе бит соң
Мәхәббәткә җавап бирмәде ул.
Җылытмады догалары белән.
Нәрсә кимерә җанын? Нинди шаукым?..

## VI

Кинәт тагын алмашынды төшем.
Чит җирләрдән юлчым кайтып төшеп,
Шул ук гыйбадәтханәгә килгән—
Мөлаем һәм яшь кәләше белән.
Тик егетнең ник караңгы йөзе?
Сүнгән мәллә мәңге Таң Йолдызы?
Сизелеп тора—тыныч түгел җаны:
Теге чакта хушлашкан көн төсле.
Шул мизгелдә янә чыраеннан
Чагылып үтте яшен камчысыдай
Сәер бер хис—сөйләп бирәлмәслек,
Чагылды да, шундук сүнде үзе.
Инде каушамыйча, тиешенчә
Ант сүзләрен тезде, әмма үзенең

Тавышын ишетмәде. Тирә-ягы
Чайпалышмы китте—оныттьы ул
Кайда торуын һәм ни булачагын.
Күз алдында пәйда булды шул йорт,
Күреп ияләнгән шул бүлмәләр,
Шул ук урын, кояш, шул күләгә,
Шул көн—әлеге кызның бар мохите—
Һәммәсе дә кайтып басты кабат
Ике арага, каплап изге нурны.
Каян гына килеп чыкты алар?..

VII

Кинәт тагын алмашынды төшем.
Ах! Ни булган гүзәл яшь ханымга?
Галиҗәнаб Мәхәббәтем минем
Саташкан ич, чиргә сабышкан ла...
Карашында—җансыз битарафлык,
Зиһене качкан—үз дөньясын ачкан:
Патшабикә булып калган шунда...
Аңлап булмый сүзен, фикере таркау—
Ах, акылдан мәллә тәмам язган?..
Хәер, артык акыллы булу да—
Шул ук саташу ич—тагы да тирән.
Акыл—бәла... Акыл арткан саен,
Кара сагыш баса адәм җанын.
Акыл —телескоп ул, Чынбарлыкны
Ялган-уйдырмадан аера торган.
Япа-ялангач калдыра ул Кешене
Салкын, кырыс Галәм кочагында...

VIII

Кинәт тагын алмашынды төшем.
Элеккечә ялгыз һаман юлчым.
Якыннары киткән ташлап, кайсы
Сугыш ачкан аңа һәр тарафтан:
Хөсет, җәнҗал, һөҗүм, рәнҗетүләр
Көн-төн агулады аның җанын.
Түзәлмаслык агу-газапларын
Ул борынгы Понт патшасы сыман,
Басмак булды—бүтән агу эчеп...
Тик берсе дә аны егалмады,
«Азык» булды фәкать үлмәс өчен...
Мондый шартта бетәр иде күпләр.
Ярдәм итә аңа таулар-күкләр,
Җитез Галәм рухы—шулар белән
Ул сөйләшеп йөри... Серле көчләр
Төн китабын аңа ачып куя,
Ирештерә төпсез упкыннарның
Сихри өн-авазын... Бирсен Ходай!..

IX

Юкка чыкты шунда сәер төшем.
Нәкъ өндәге кебек—ике кешенең
Язмышын мин күрдем бер үк төштә:
Берсе аның язды акылыннан,
Ә бәхеттән язды—икесе дә...

Лена ШАГЫЙРЬҖАН *тәрҗемәсе*



**Илфак Шиһапов**

## АКЛЫ-КАРАЛЫ ГЫЙШЫК

САТИРИК КЫЙССА

### Кара чутыр

Әле яңа гына өченче иреннән аерылып кайткан Сәхап Әминәсе, шәһәргә базарга баргач, негр күреп кайтты. Озын буйлы, бөдрә чәчле, ләкин мескенрәк кыяфәтле бу кара ир Әминәнең нечкә күңелен шулкадәр тетрәтте ки, ул базарга нәрсә алырга килгәнен дә онытып, авылга буш кул белән әйләнеп кайтты. Өйдә ашык-пошык кына чәй эчкәч, ул җан дусты Сәрияләргә кереп чыгарга булды. Сәрия әз генә яшьрәк булу сәбәпле, әле ике генә тапкыр кияүдә булган иде. Әминә кергәндә ул көзге алдында керфекләрен буяп мәтәшә иде.

—Кара әле, кызый, беләсеңме мин нәрсә күрдем... Вәт күрдем!..

—Нәрсә күрдең?—Сәрия ялт итеп ахирәтенә таба борылды.

—Нигыр күрдем, кызый.

Әминә «лап» итеп урындыкка утырды.

—Вәт менә монысы мужик дисәң дә мужик! Ул буе, ул чәчләре. Бездәгеләр ише генә түгел инде.

—Нәрсә, таныштыңдамы әллә?—Сәрия Әминәгә көнләшүле караш ташлады.—Ул якка бик өлгер бит син.

—Юк, кызый, курыктым. Ну, шә-әп нәрсә күренә үзе,—Әминәнең күз карашлары томанланып куйды.

—Һи, куркытырсың сине ир белән. Артык бер нәрсәсе дә юктыр әле. Күргән-күргән танышып та кайтырлар аны. Кием-мазар кигәнме соң үзе, нигырларны бит гупчым шәрә йөри диләр?

—Кызый, чалбары тучны бар иде.—Әминә күзен йомып, шәһәрдә күргән кара ирне күз алдына китерде.—Күлмәге дә бар иде бугай.

—Әле кичәге гәҗиттән укып утырдым.—Сәрия ашыкмыйча гына чәй

---

Илфак ШИҺАПОВ *(1968)—журналист, республика матбугатында басылып чыккан күпсанлы мәкаләләр, шаян хикәяләр авторы. Лениногорск районының Тимәш авылында яши.*

әзерли башлады.—Безнең илдә бит хатыннар ирләргә караганда дачуртага күп икән.

—Соң шулай булмыйча,—Әминә өстәл янына күчеп утырды.—Әнә, авылны гына күр син. Кая карама хатын-кыз, шул Җәмилне санамасаң бер юньле ир-ат юк.

—Әйе, эчә торган булса да әле ярый шул Җәмил бар.—Сәрия чынаякларга чәй агызды.—Ул да булмаса, саргаеп үләсең бу авылда.

Хатыннар дәшми генә, һәркайсысы үз уйларына чумып чәй эчтеләр.

—Кара әле, кызый,—диде Әминә, чынаягын каплап куйгач,—Соң ул нигырлар үзләрендә чыннан да гел ялангач йөриләрме икән?

—Чын инде, чын,—Сәрия дустына табарак иелде.—Беркөннәрдә телевизордан үзем күрдем. Бөтенесе анадан тума, кызый.

Ике ахирәт тагын әзрәк дәшми тордылар.

—Вәт кешеләр яши, диген, ә,—дип тынлыкны бүлде Әминә.—Кием дә кирәкми, газга түлисе дә юк. Банан, әфлисун ише нәрсәләрне дә агачтан гына өзеп алышлы. Без ятабыз монда интегеп. Бер нәрсә күрергә юк.

—Кара әле, кызый,—Сәрия ничектер җанланыбрак китте.—Вәт шул нигырны авылга алып кайтырга, иеме?!

—Шәп булыр иде ул,—диде Әминә дә ниндидер үз уйларыннан көлемсерәп.—Андый гәүдә белән печәнне дә шәп чабадыр ул.

—И-и, син бигрәк инде, кызый. Кем инде андый ирдән печән чаптыра? Аннары алар, гел теге банан гына ашарга өйрәнгән булгач, гупчым печән чапмыйлардыр. Әллә филләргә дә печән әзерлиләрме икән?

Сәрия филгә күпме печән кирәклеген күз алдына китерде дә, башын чайкап куйды. «Әле дә ярый, бездә сыер гына асрыйлар, Ходайның рәхмәте», дип уйлады ул.

—Сәрия,—диде Әминә, кинәттән генә,—иртәгә шәһәргә барам да алып кайтам мин аны үзебезгә.

—Кит әле моннан,—Сәрия кулын гына селтәде.—Әллә синең белән безнең ишегә карый дисеңме шундый шәп мужикны?

—И-и, сине тыңласаң,—Әминә көзге янына барып чәчләрен рәтләштерде.—Син гел шулай диган буласың. Рафаэльне дә карата алмыйсың, дигән идең дә... Карады бит әле. Пачти бер ел тордык ир белән хатын булып. Ир-ат дивана бит ул. Кирәкле кылларын чиертә белсәң, бөтенләй акылын югалта. Бу кара нәмәрсә дә ир-ат затыннан булгач, шундыйдыр әле...

—Соң, авыл халкы нәрсә әйтер?—диде Сәрия, күзләрен шардай ясап.—Син бигрәк инде—кап-кара бит ул...

—Булса соң,—Әминә көлеп куйды.—Бездәгеләр әнә эчә-эчә зәңгәрләнеп беткән дә бит... Кара түгел җәһәннәм төсле булсын, чын ир генә булсын ул. Барам да алып кайтам. Өем зур, бакчам бар—торырбыз әле. Ике дә уйламыйм, алам да кайтам үзен. Өйдә өченче мужиктан калган кием җитәрлек...

Әминә тагын шәһәргә китеп барды. Ә бер көннән, алагаем буйлы, бөдрә чәчле чем-кара ир, Әминәләрнең ишек алдында нидер майтарып йөри иде инде...

## Ак бәхет

«Сәхап Әминәсе кияүгә чыккан икән», дигән гаҗәеп хәбәр авылга тиз таралды. Берәүләр гаҗәпләнде, икенчеләр көлде, ләкин тулаем алганда Озын Улак халкы артык шаккатмады. Авыл халкының фикерен, гомумиләштереп Гариф әйтте: «Әминә зәһәр хатын ул. Нигырга түгел, шайтанга чыкса да гаҗәпләнәсе юк монда».

Нәрсә булса да табып, баш төзәтергә исәпләп кибет янына чыккан Җәмилгә дә бу хәбәрне Гариф җиткерде.

—Әминәләргә барабыз,—диде Җәмил, кырт кына.—Кияү балакайны күрергә тиештер бит инде без. Бәлки Әминә минем беренче мәхәббәттер һәм дә минем йөрәгем янадыр.

Башы төзәлеп җитмәсә, Җәмилнең шулай китапчарак сөйләү гадәте бар иде.

—Әминә—синең мәхәббәтме?—башы төзәлгән Гариф көлеп куйды.—Син,

ни, бигрәк инде. Кара әле, Җәмил, соң ул нигыр татарча беләме икән? Белмәсә уңайсыздыр бит инде Әминәгә.

—Әллә син Әминәгә тел белгече кирәк дип уйлыйсыңмы?—Җәмил көлемсерәп дустына карады.—Кирәксә, өйрәтер.

—Чыннан да,—диде Гариф, нидер исенә төшкән кешедәй.—Чуртынамы Әминәгә аның теле... Кара әле, килеп җиттек.

Алар чыннан да Әминәләрнең капка төбендә басып торалар иде.

—Хәзер мин керәм,—диде Җәмил Гарифка.—Бер биш минуттан син дә керерсең...

Ләкин керергә насыйп булмады. Аларны тәрәзәдән күреп өлгергән Әминә үзе капка төбенә чыкты.

—Нәрсә бар,—диде ул, тузыбрак торган чәчләрен рәтли-рәтли. Аның иреннәре кызарган, битләре алсуланган иде.

Җәмил игътибарлы караш белән Әминәне баштанаяк карап чыкты.

—Да,а, кызый,—диде ул бераздан,—сиңа әллә кайчан шул нигыр гына кирәккән икән...

Әминә оялгандай башын иде.

—Ярар инде, Җәмил,—диде ул.—Кызгандым бит мин аны. Казанга укырга дип килгән булган да дакументларын югалткан. Ул арада туган илендә сугыш чыккан. Хәзер кире кайтырлык түгел, ди. Аптырап йөргән җиреннән алып кайттым инде. Һаман ялгыз яшәп булмый бит...

—Син ялгыз тора алмыйсың шул,—диде Җәмил, җитди генә.—Эш анда түгел, торсын нигырың, бер сүзем дә юк. Ну, без кияүне күрергә тиештер бит инде. Туй-мазар булмас дип уйлыйм мин, ну, никах фурмысын китерик әйдә. Үзем укырмын...

—Юк-юк,—диде Әминә, йөзенә куркылган кыяфәт чыгарып.—Ул бит мөселман кешесе. Көнендә биш намазын калдырмый. Әбрәкәйгә дә комган белән йөри. Исеме дә безнеңчә—Мөхәммәт Вәлиулла. Шуңа күрә никахны Мөнир абзыйдан укытырмын дип торам. Тәмәке, аракы кебек нәрсәне гомерендә дә якын китергәне булмаган. Аларда эчкән кешене ботыннан тотып агачка асып куялар икән.

—И-и, Ходаем, әле дә без анда тумаганбыз иеме, Җәмил,—диде, моңа кадәр дәшми торган Гариф.—Коргаксып үләр идең шунда.

—Син аның белән ничек сөйләшәсең соң?—диде Җәмил, Әминәгә карап.

—Аңлашабыз инде,—Әминә тагын башын аска иде.—Инде татарча да өйрәтә башладым үзен.

—Өйрәнәме соң?

—Өйрәнә. Тик сүзләре генә мишәрчәрәк чыга.

Шулчак Әминәнең капкасы шыгырдап ачылды һәм аннан яшь кияү үзе күренде. Үз гомерендә каравылчы Рәшиттән дә карарак кеше күрмәгән Гариф артына утыра язды. Җәмил исә селкенмәде дә, киресенчә ул гомере буе Африкада яшәгән кебек, нигырга киң итеп елмайды, беренче булып, аның янына барып, ике куллап күреште:

—Әссәламегаләйкүм, баҗа,—диде ул, күптәнге танышын очраткандай. Ни гаҗәп, нигыр да «Вәгаләйкемәссаләм»—дип җавап бирде. Тик ул баҗа сүзен генә аңлап бетермәде бугай, сораулы карашын Әминәгә юнәлтте. Гариф ул-бу була калса дигәндәй, арткарак чигенде. Ул «кияү»нең калын беләкләренә бәя биреп өлгергән иде инде. Ну, берне «сыпырса» әз тоелмас, дип уйлады ул. Ләкин гәүдә ягына Җәмил дә нигырдан калышырлык түгел иде.

—Тә-әк, Әминә,—диде Җәмил, күзен кыса төшеп.—Киявеңне сручны юарга кирәк, сүзем шул. Бөтенләй каралып китүе бар. Йөгер бер литрга. Баҗа белән танышу хөрмәтенә дә кирәк...

Әминә авыр сулап акча алырга кереп китте.

—Әйдә, Вәлиулла туган, Әминә кибеттән әйләнгәнче без керә торыйк,—дип, Җәмил дә капкадан атлады. Мөхәммәт Вәлиулла бернәрсә аңламаса да, ап-ак тешләрен күрсәтеп елмайган килеш Җәмилгә иярде. Әзрәк шикләнсә дә, Гариф та керергә булды. Бу нигыр эчмәгәч, Җәмилнең бер үзенә күп булыр, дип уйлады ул.

Әминә кибеттән бик тиз әйләнде. Нигәдер яшь кияven Җәмил белән берүзләрен генә озакка калдырырга курыкты ул. Хатын кайтканда ирләр өчәүләп йорт баскычында утыралар иде. Әминә сумкасын Җәмилгә тоттырды

да тиз генә аның колагынарак иелде.

—Мөхәммәткә күрсәтмәгез инде, яме,—диде ул, пышылдап кына.—Аларда йортка аракы кертү дә гөнаһ икән. Кичә Сәрия белән кич утырганнан калган шешәбезне дә бакча башына илтеп томырды. Аннан соң, аның намаз вакыты да җитеп килә.

Әминәнең күз карашы ялварулы иде.

—Син бар,—диде Җәмил, әкрен генә,—йә Сәрияләргә менеп төш шунда. Мөселман гаиләсендә хатыннар ирләр арасында буталмаска тиеш.

Сәрия баш кына какты да урамга таба атлады. Җәмилне күргәннән бирле күңеле нигәдер тыныч түгел иде аның. Ләкин яшьтән үк Җәмил сүзен тыңламый булдыра алмады ул.

... Авыл өстендә халыкны кичке намазга дәшеп Мөнир мулланың азан кычкырган тавышы таралды. Азан тынарга да өлгермәде, Озын Улакта җыр яңгырады. Югары очтан Түбән очка таба юнәлүче өч ир «Күбәләк»не әйттерәләр иде. Кызу. Африканың бер почмагында туган ярымкыргый кабилә малае Мөхәммәт Вәлиулла үзенең ике җан дусты белән яңа тормышка аяк баса. Яшь килен Әминә акчасын учлап тагын кибеткә йөгерде.

## Кара көнчелек

Участковый Харис авылга кич белән кайтып төште. Казаннан Озын Улакка кадәрге ара, әллә махмырдан интеккәнгә, әллә чынлап та туган яклар сагындырганга, бу юлы бик ерак тоелды аңа. Хәер, сагындыруы да бардыр, ни дисәң дә бер ай шактый вакыт шул ул.

«Йөртәләр инде картаеп беткәч, укытабыз, дип»—машинадан төшеп, авылга таба атлагач, Харис төкереп куйды.«—Ай буе җыелып эчеп яту булды укытулары. Әллә шушы яшьтә болай да миңгерәп беткән башка белем керә инде».

Ниһаять, Озын Улакка кайтып төшүенә, Харис чыннан да бик шат иде. Шат булмыйча соң, монда аның үз җире, үз биләмәсе. Кем каршы төшә ала монда участковыйга?! Теләсә кайсысына статья табам, кирәк булса, дип уйлады Харис үзатына елмаеп. Тиле Сабирҗаннан алып, персидәтеленә хәтле минем кулда...

Яшьрәк чакта, әле милициягә эшкә кергәнче, Харисны авылда кешегә дә санаучы юк иде. Әллә егет булып җиткәнче анасының итәгенә тагылып йөргәнгә, әллә мәктәптән үк үтә дә әләкче булганга, аны яшьтәшләре үзләренә ияртмәде, авыл кызлары аңа көлеп кенә карады. Алай гына да түгел, ни гаҗәп, солдат хезмәтеннән исән-имин кайткан егетне, колхозга эшкә алмадылар.

—Иркә, синең кем икәнеңне беләм,—диде ул чактагы калхуз рәисе Нургаян абзый.—Сиңа ышанып тапшырырдай эш юк миндә. Сарык көтүен бирер идем, анда әнә, Сабирҗан абзыең бар. Мужыт шәһәр тирәсендә берәр эш табарсың...

Шулай итеп, Харис милициягә эшкә керде. Керде генә түгел, монда ул чистый кешегә әйләнде. Һәм эштән эшкә күчеп йөри торгач, көннәрдән бер көнне, аны туган авылына участковый итеп куйдылар. Яшьрәк чагында үз шәүләсеннән үзе куркып йөргән Харис, хәзер Озын Улакта бер нәрсәдән дә курыкмый торган кешегә әверелде. Форма бар, пистолет бар, нигә куркырга? Аннары бу авылда яшәү аны шактый чыныктырды. И-и, нәрсә генә күрсәтмәде инде аңа авылдашлары. Хәер исә, авылда шикләнерлек бер Колга Җәмиле генә калды диярлек. Башкалары кайсы утыра, кайсы шәһәргә тайды.

Харис авылга кергәндә караңгы да төшеп өлгерде. Бу юлы караңгы авыл ничектер шиклерәк тоела иде. Бер ай байтак вакыт шул. Әнә теге тирәк артыннан берәрсе чыгып башыңа тондырса, дип уйлады Харис һәм гадәттә пистолеты эленеп тора торган җирне капшады. Шулчак ул чайкала-чайкала үзенә таба атлаучы шәүләне абайлады. Кем булыр бу? Харис адымнарын әкренәйтте, як-ягына карап алды. Ул нәкъ күптән түгел янган мәчет янына килеп җиткән иде. Шәүлә якынлашты.

Харис җиңел сулап куйды. Нидер мыгырдана-мыгырдана атлаучы—авылдашы Гариф иде.

—Кая эчтең болай лыкынганчы?..—диде Харис, үзе янына килеп җиткәч кисәктән генә җиргә таба ава башлаган Гарифны җилкәсеннән тотып.

Тегесе авырайган башын Хариска таба күтәрде.

—Кая булсын, туйда инде,—диде ул, әзрәк дәшмичә торгач. Гарифтан үкертеп самогон исе килә.

—Нинди туй тагын?—Харис маңгаен җыерды.—Сишәмбе көнне кем туй үткәрә ди.

—Әминә кияүгә чыкты.—Гарифның башы тагын салынып төште.—Кияү мировой егет, үзе чибә-ә-әр...—Гариф хырлый башлады. «Махмырдан холкы ниндидер бит моның—белеп булмый,—дип уйлады ул, үзенең кап-кара сөйгәне турында. Берне алып куярга кирәк. Их, дөньясын...»

Харис әллә нишләп китте. «Чукынчык хатын тагын кияүгә чыккан. Әйттем бит мин аңарга бүтән ир алып кайтасы булма дип»... Харис тешләрен шыгырдатты. Киң күңелле Әминә аны вакыт-вакыт ятагына яткыручы авыл хатыннарының берсе иде. Шуңа күрә дә Харис Әминәнең бер ирен фермадан дуңгыз урлаганы өчен «утыртты», икенчесе, яшәр әмәле калмагач, Әминәне дә, авылны да ташлап үзе чыгып качты.

—Ну, ярар,—дип мыгырданды ир, инде рәхәтләнеп йоклаучы Гарифны җиргә яткырып.—Монысы да озак тормас. Табарбыз берәр әмәлен. Хәзер, пистолетны гына кереп алам да өйләренә барып килəм. Баштан ук авылда кемнең кем икәнен күрсәтергә кирәк «яшь кияүгә»...

... Әминә чын мәгънәсендә бәхетле иде. Соң, янында шундый ир булсын да бәхетле дә булма, имеш. Хатын-кызга тагын нәрсә кирәк соң. Мөхәммәтемне эшкә дә җибәрмим, исән генә булсын, дип уйлады хатын, көзге алдында юеш чәчләрен тарый-тарый. Яшь пар әле генә мунчадан кайткан һәм биленә ап-ак сөлге генә ураган «яшь» ир чәй эчә иде. Чистый, татарча да аңлый башлады үзе. Әминә Мөхәммәтне баштан аяк күздән кичерде. Шулхәтле мунча чабынып, шул хәтле юынып та агармады бит, дип уйлады ул. Хатынның үзенә караганын сизгәндәй, тегесе дә Әминәгә таба борылды. Борылды да, ап-ак тешләрен күрсәтеп елмаеп алды.

Бүген алар кичкенә генә туй мәҗлесе сыман нәрсә ясадылар. Теге көнне Җәмилләр белән эчкәннән соң, чак кына үлемнән калган Мөхәммәт Вәлиулла үз туенда эчмәде. Хәер, туй дип, Әминә шул Сәрияне, Җәмилне, Гарифны, Зәйтүнәне генә җыеп, шыпырт кына ясады бу мәҗлесне. Нигырга кияүгә чыкканын кешегә артык ишеттерәсе дә килмәде. Нишлисең, авыл авыл инде. Җитмәсә Мөнир мулла никах укудан да баш тартты: «Сеңелем, кияүвеңне күргәч тә тәһарәтем бозылды, юньлегә булмас бу»,—диде ул.

Әй санә, дип уйлады Әминә, миңа никах кирәкмени, әнә, Җәмил каршы килмәде кияүгә чыгуыма, шул җиткән. Алар Гариф белән икәү бүген дә «дөм булдылар...»

Әминә тагын Мөхәммәт Вәлиуллага текәлде.

—Кара әле, Мөхәммәтчик,—диде ул, ирнең таза гәүдәсенә сокланып.—Ә синең илдә, чыннан да, гел шәрә йөриләрме?

Ир елмаеп баш какты. Әминә аны анадан тума килеш учак янында сикереп-сикереп биегән итеп күз алдына китерде. Менә учак яна, аның тирәсендә әле генә уңышлы аудан кайткан ирләр. Барысы да шәп-шәрә, бар да Мөхәммәт кебек матур гәүдәлеләр. Йөрәкләргә дәрт өстәп барабан тавышы яңгырый... Хисләргә бирелгән хатын тирән итеп сулап куйды.

—Мөхәммәт, җаным,—дип пышылдады ул, күзләрен йомып,—миңа үзегезчә биеп күрсәт әле, ә?

Мөхәммәт Вәлиулла җилкәләрен сикертеп куйды... Нигә биемәскә... Бу ак тәнле сәер хатын аңа торган саен ныграк ошый иде. Ә мунчасы-ы...

Ул үрелеп, өстәлдән зур гына аш кәстрүлен кулына алды, аның төбенә суккалап карады. Мөхәммәт күзләрен йомды. Аяк астында туган джунглиның җылы җире урынына сыгылмалы такта идән, кулында «там-там» барабаны урынына тирән аш кәстрүле булса да, ул кинәт үзен туган илендә дип хис итте. Ул кәстрүл төбенә суккалап, борын астыннан үз ыруының яраткан көен көйли-көйли, башта әкрен генә, аннан тизләнә-тизләнә бии башлады. Менә маймыллар сикерешә, менә ач шакал сикереп улый, менә джунгли хуҗасы юлбарыс ырлап корбанына сикерә...

... «Әле туй һаман бара икән,—дип уйлады Харис, Әминәнең ишек төбенә

килеп җиткәч.—Әнә ничек дөбердәтеп бииләр. Үзләре «күбәләк»не әйттерә бугай. Ничава, хәзер тәртип салабыз аны. Белсеннәр авылга кем хуҗа икәнен».

Өенә пистолетын алырга кергәч, Харис бер йөз илле грамм капкан иде. Ул батыраеп, киң итеп өй ишеген ачып җибәрде. Аның ачулы күзләре өй түрендә чәчләрен тузгытып басып торучы Әминәгә төшеп өлгергән мәлдә генә, участковый үзенең өстенә анадан тума шәрә, кап-кара бер кешенең ямьсез ырлап сикергәнен күрде. Ул: «суйдылар!»,—дип әйтергә дә өлгермәде, аңын югалтып идәнгә авып төште...

## Ак сыерлар мөдире

Әминәнең шәһәрдән ияреп кайткан, Мөхәммәт Вәлиулла исемле нигыр мужигына кияүгә чыгуы, тарихы еллар томанына төренгән Озын Улак авылы халкын әзрәк сискәндереп алса да яшәешенә артык йогынты ясамады. Шулай ук көтүләр куылды; сыерлар савылды, шулай ук ирләр эчте, аларны хатыннары сүкте, кыскасы, авыл үзенчә яши бирде.

Үз гомерендә беренче тапкыр нигыр белән көрешүдән акылына зыян килгән участковый Харисны Казанга тиләләр больнисына озаттылар. Ул анда: «Яшәсен иптәш Гитлер әфәнде»,—дип, кычкырынып, бөтен мескен тиләләрнең котын алып йөри икән дигән имеш-мимешләр йөрде. Соңгы вакытта авылны «дерелдәтеп» алган тагын бер генә хәбәр булып алды—Җәмил әз генә эчүеннән туктап торды. Ләкин бу аңлаешсызлык та авыл халкы өчен гади хәл ителде—ул тагын эчә башлады.

Хәер, гади кешене суламый торган итеп күз алдына китерү мөмкин булмаган кебек үк, Җәмилне дә эчми торган итеп күз алдына китерү мөмкин түгел.

Әминәне бер мәсьәлә борчыды—бер генә документы да булмаган Мөхәммәт Вәлиулланы ничектер рәсми итеп теркәү, ягъни мәсәлән, пропискага кертү, паспорт алу. Үзе әйтмешли, сыер койрыгына карап үскән авыл хатыны гына булса да, ул үзенең янган коймак төсле ирен, Арслантау чуашы итеп тә, Аксубай мишәре итеп тә күрсәтеп булмаячагын һәм иртәме-соңмы чит ил кешесенең закунсыз рәвештә Озын Улакта торып ятуына игътибар итәчәкләрен аңлый иде. Ләкин участковый Харис вакытлыча «иптәш Гитлер»га әйләнгәч, ә яңа силсәвит рәисе Сабирҗан абзый авырып яткач, бу мәсьәләгә тотыну мөмкин түгел иде. Сүз уңаеннан шуны да әйтеп китәргә кирәк, авылда Әминәнең кара бәхетеннән көнләшүчеләр дә булмады түгел. Чыннан да, атналар буе эчмичә тора алган, ат кебек таза ирне «эләктерүче» хатыннан көнләшерлек тә иде шул. Әминә үзе дә соңгы вакытта ничектер яшәреп, матураеп китте. Бу себеркегә шул нигыр гына кирәккән икән, диеште хатыннарның усалраклары.

... Көннәрдән бер көнне Мөхәммәт Вәлиулла, чираттагы кайнар мунчадан соң, Әминәгә: «Эшлисем килә»,—диде. Хәер, мондыйрак сүзне ул элегрәк тә әйткәли иде. Ләкин Әминә яшь ирен кайда да булса эшләтү турында уйлап та карамады. Син бер эшне җиренә җиткереп эшлисең инде, шул да бик җиткән җаныкаем, дип, ул бу юлы да котылмакчы иде дә Мөхәммәт каты торды. Әминә уйга чумды. Озын Улакта шул ел саен алышынып тора торган исәр рәисләр таратып бетерә алмаган колхоздан эш табуы мөмкин түгел иде. Колхозда нинди эш бар? Әминә колхоз идарәсенә китте. Эшнең нәрсәдә икәнен аңлаткач, колхоз рәисе Сафа Вафич озак уйлап та тормыйча: «Фермага барсын!»—диде.

Беренче көнне Мөхәммәтне фермага эшкә Әминә үзе озатып төште. Алар, кайчандыр Мөхәммәттән чак кына аграк шабашниклар салып киткән абзарга килеп кергәч, бер сәбәпсезгә үзатына мөгрәшеп торучы ак сыерлар, кылт кына тынып калдылар. Мөхәммәт, башын боргалап, бу ят хайваннарны күздән йөртеп чыкты.

—Амина-а, диде ул, хатынына карап,—нигә алар шундый нәзекләр?

Сөйгәненең сөйләменә өйрәнеп өлгергән хатын көлеп җибәрде.

—Нәзекләр түгел, ябыклар алар Мөхәммәтчик,—диде ул, көлеп туйгач.

—Ә нишләп?

—Нишләп булсын, юньләп ашатмаганга. Черек саламнан башка ризык күргәннәре юк бит аларның. Ач булгач, әнә, нәсел үгезенең дә хәле юк.

Мөхәммәт Вәлиулла муенына чылбыр тагылган үгезгә карады. Аның күзләре сагыш белән тулы иде. Африка малаена сыерлар бик кызганыч тоелды.

—Ә нишләп ашаргалары юк соң аларның?—Мөхәммәт үгез янына барып басты.

—Һе, нишләп, имеш,—Әминә иреннәрен бөрде.—Урлап бетергәнгә юк. Фуражны скотниклар сатып эчә, печән белән силосны авыл халкы үз малларына ташый. И-и, мескенкәйләрем. Карале, Мөхәммәт, әйдә, ферма мөдирен табыйк, аңлатсын эшне сиңа...

Шулай итеп, Мөхәммәт Вәлиулла Озын Улак фермасында терлекче булып эшли башлады.

Авыл халкы башта, «бу корымга баткан нәстә»нең сыерлар арасында кайнашуына көлебрәк кенә караса да тора-бара хәлләр тамырдан үзгәрде.

Иң беренче эш итеп, Мөхәммәт Вәлиулла силос, печән урларга өйрәнгән авыл халкын фермага якын килмәслек итте. Эш болай булды, көннәрдән бер көнне, үз атын җигеп фермага печән алырга төшкән Күзлек Гамиры Мөхәммәтнең печән өеме янында нидер кычкыргалап сикереп-сикереп биеп йөрүенә шаһит булды. Гомере буе китап укыган Гамир, билгеле инде, Мөхәммәттән аның нишләвен сорады. «Вуду»,—дип җавап бирде тегесе. Чәчләре үрә торган Гамир атын чыбыркылый-чыбыркылый авылга чапты. Шул ук көнне «Әминәнең нигыры фермы курмысын каргаган икән, аны ашаган мал шунда ук үлә икән», дигән хәбәр бөтен авылга таралды. Моңа артык ышанмаса да, авыл халкы «бәладән башаяк» дигәндәй, фермага йөрми башлады. Ә үзе белән эшләүче терлекчеләргә Мөхәммәт мал чөгендере хәтле йодрыгын гына күрсәтте—бүтән көрпәгә тиюче булмады.

Мөхәммәт Вәлиулла эшли башлагач сыерлар күзгә күренеп көрәйде, хәтта ки үгезгә дә җан керде. Сыерларга ашау яхшыру уңай тәэсир итсә, сыер савучыларга Мөхәммәт Вәлиулла үзе берәр ничек тәэсир итте ахрысы—алар эшкә вакытында килә башладылар. Алай гына да түгел, эштә соңга кадәр калып эшләүчеләре дә табылды.

Колхоз рәисе Сафа Вафич, савылган сөт күләменең артуына ышанмыйча, гомер булмаганны фермага үзе төшеп карады. Чыннан да, сыерлар көр, сыер савучылар да матураеп киткән, ә сыер абзары чиста иде.

Район газетында басылган сводкада элек терлекчелек буенча күрсәткечләре иң артта булган «Якты юл» хуҗалыгы икенче урынга менде. Күзлек Гамиры моны сенсация дип билгеләде. Берничә көннән элекке ферма мөдире Наилне эшеннән алып, аның урынына Мөхәммәт Вәлиулланы куйдылар. Авыл «аһ» итте.

Җитмәсә, нәкъ шул көннәрдә авылда яңа имеш-мимешләр таралды...

## Каймак караңгыда икән...

Мөхәммәт Вәлиулла әкрен генә авыл тормышына күнекте. Бу яктан аның ферма мөдире булып эшли башлавы да зур ролен уйнады, әлбәттә. Хәзер инде Мөхәммәт авыл буйлап атлаганда, чәңгелдек авыл этләре элеккеге кебек тилереп чыкмый. Сабый балалар да үкереп еламый иде, диярлек. Авыл халкының күпчелеге аны үз итте.

Әминә моңа сөенеп бетә алмады. Хәзер инде ул урамда—фәлән хатыннар белән сөйләшкәндә: «И-и, җаныкаем, кичә минеке дә фирмыдан әт булып кайтып керде»,—дигәнрәк җөмләләр кыстырудан да оялмый иде инде.

Мөхәммәтнең авыл тормышына тиз яраклашуының бер сәбәбе Озын Улак халкының аны үз итүендә булса, икенчесе—ярымнигырный кабиләдә туып үскән ирнең, бу авыл тормышы белән үз кабиләсе тормышы арасында артык аерма күрмәүдә иде.

Яшәешнең төп кануннары тегендә дә, монда да бер үк иде диярлек. Дөрес, бананнан бәрәңгегә күчү бик җиңел булмады булуын, ләкин Мөхәммәт артык талымлылардан түгел иде.

Мөхәммәт Вәлиулланың авыл тормышына җайлы гына яраклашып китүенә аның Озын Җәмил белән дуслашуы да сәбәп булды. Сер түгел, Җәмилгә «кара малайны» кайбер күңелсезрәк хәлләрдән коткарырга да туры килде...

Фермада эшли генә башлаган көннәрдә булды бу хәл. Иртән эшкә килүгә Мөхәммәт, малларны барлап чыгу нияте белән, сыер абзарына керде. Сыерлар бар да үз урынында, савучылар иртәнге эшләрен тәмамлап киләләр иде. Инде абзарны урап чыгам дигәндә, ул үгез улагына капчыктан көрпә бушатып торучы бер абзыйны күреп алды. Кара әле, дип уйлады Мөхәммәт, монда сыерларга ашарга җитми, ә ул үгезгә көрпә ашата...

—Сез кем?—дип сорады ул абзый янына килеп.—Бу нигә?

—Нигә түгел, энем, үгезгә,—диде абзый Мөхәммәткә карамыйча гына.

—Ә нигә аңа шылай күп?

—Үгез булганга,—абзый көрпәдән бушаган капчыгын каккалап җилкәсенә салды.—Ә мин ассиминатор Гомәр абзыең булам. Бүген бүлнистан соң беренче көн эшкә чыгуым. Әнә шул заразы сөзеп үтерә язган иде мине.

Абзый күрешергә дип кулын сузды.

—Ә син ызначит яңа завфирмы инде безнең?

Мөхәммәт баш какты.

—Сез нәрсә эшлисез соң?

Әле яңа кеше булганга, Мөхәммәт ферма эшенең бөтен нечкәлекләрен дә белеп бетерми иде.

Гомәр шаркылдап көлеп җибәрде.

—Менә шушы үгезнең эшен эшлим инде, энем.—Ул тәмләп көрпә ашаучы нәсел үгезенә ымлады.—Шуның өчен сөзде дә бугай инде ул мине.

—Ничек алай?—Гаҗәпләнүдән Мөхәммәтнең болай да зур күзләре йодрык хәтле булды.—Сез..., сыерларны... Ә нигә?

—Ничек инде, нигә?—Гомәр йөзенә гаҗәпләнү төсмере чыгарды.—Бозаулар булсын өчен.

Үз гомерендә генетика дигән фән турында ишеткәне булмаса да, Мөхәммәт болай булырга тиеш түгеллеген аңлый иде. Ничек инде кешедән бозау тусын?

Мөхәммәтнең нәрсә уйлаганын Гомәр дә сизде бугай, ул тагын шаркылдап көлеп куйды.

—И-и, син, энем, бигрәк инде. Аның бит җайланмалары бар үзенең. Сыерларга бозау ясый торган. Ну җайланма-җайланма инде ул... Сыер җенесе чын үгез дә күрергә тиеш, шунсыз булмый. Ягъни мәсәлән, нәкъ хатын-кыз кебек инде. Аңлыйсыңмы?

Монысын Мөхәммәт Вәлиулла Әминә белән торганга гына түгел, гомумән, ир кеше булганга да аңлый иде.

Гомәр исә үз уен дәвам итте.

—Ә үгезгә шуның өчен көч күп кирәк. Ашамаган малда каян көч булсын. Шуңа мин аңа менә көрпә бирәм дә инде. Ир затына, калорияле ризык кирәк ул энем, печән-салам белән генә булмый. Син менә үзеңнән генә ал...

Гомәр, кинәт нидер исенә төшкән кеше кебек сүзеннән бүленеп, башына «шап» иттереп сугып алды.

—Туган, синең хатын да яшь, ызначит сиңа да көч күп кирәк. Менә, мәсәлән, син үзең нәрсә ашыйсың?

—Соң, нәрсә, дип инде,—Мөхәммәт, оялгандай башын аска иде.—Амина нәрсә бирсә, шуны ашыйм.

Гомәр кеткелдәп көлеп куйды.

—И-и, энем, алай гына булмый ул. Хатын биргәнгә генә карап... Яңа өйләнгән иргә каймак ашарга кирәк аңа, каймак.

—Аминаның, безнең сыер юк бит...

—Һе, сыер юк, имеш. Менә бит сыерлар.—Гомәр ферма эченә ымлады. Аннары Мөхәммәтне баштанаяк күздән йөртеп чыкты.—Нәрсә, син көн саен бер литр каймак эчкәннән калхуз ярлыланыр дисеңме әллә?

Аптырабрак калган Мөхәммәт җилкәсен генә сикертте.

—Әйдә әле, энем,—Гомәр сыер абзарының аргы ягына ымлады,—күрсәтим әле мин сиңа каймакның кайда икәнен.

Гомәр һәм аның артыннан Мөхәммәт, савылган сөт җыела торган будкага атладылар. Анда яңа савылган сөт, бидоннарга тутырылып, салкын сулы зур тимер савытка батырылган иде. Килә-килешкә үк Гомәр бер бидонның капкачын ачты.

—Менә кайда каймак,—диде ул, сөтне иснәп карагач.—Самый өстенә җыелган чагы.

—Аны ничек эчәргә соң?—диде. Гомәрнең кызу-кызу сөйләвеннән, кеткелдәп көлүеннән миңгерәбрәк калган Мөхәммәт.

—Һе, ничек имеш.—Гомәр йөзенә аптыраган кыяфәт чыгарды.—Кирәксә эчәсең инде аны, малай.

Мөхәммәт Вәлиулла, Әминәнең көннән-көн кызурак ягыла торган мунчаларын уйлады да әйтеп куйды:

—Кирәктер инде ул.

—Соң, кирәксә, башыңны тыгасың да бидонга, эчәсең инде туган. Бер катлаулылыгы да юк аның. Мин, ...ни, үзем дә әле вакыт-вакыт эчкәлим...

Мөхәммәт бүреген салып бер тирән итеп сулыш алгач, бидонга башы белән чумды. Чыннан да, сөт өстенә җыелган каймакны болай эчү артык уңайсыз түгел иде үзе. Мөхәммәт һәр йотым белән үзенә көч кергәнен тоя башлады. Ләкин шулчак сыерлар абзарында бик каты дөмбердәү тавышы ишетелде. Кабаланып ишекне ачкан Гомәр, нәсел үгезенең чылбырны өзеп, абзар уртасында торган су багын төртеп аударганын күрде. Ә тәмләп каймак эчүче Мөхәммәт исә, тавыштан кинәт сискәнеп, бидоннан башын алырга талпынды. Ләкин баш бер дә чыгарга теләми иде...

... Мөхәммәтнең, аннан да битәр Гомәрнең изалануларына да карамастан, баш сөтле бидоннан чыкмады. Ярты сәгатьләр чамасы азаплангач, бөкрәеп торудан гаҗиз булган Мөхәммәт, бидон эчендә чеп-чи татарча итеп сүгенә иде инде. Ә Гомәр сварка-мазар эзләргә китте.

Бәхеткә, каравыл йорты янында аңа Җәмил очрады.

—Нәрсә, тагын үгез куамы әллә?—диде ул, акны-караны күрмичә йөгерә-атлый баручы Гомәрне күргәч.

Гомәр аңа хәлне аңлатты. «Кара малай»ны үз итеп өлгергән Җәмил ашыга-ашыга фермага китте. Ул килеп кергәндә Мөхәммәт инде сүгенми, ә ыңгырашып кына тора иде.

—Үзең болай ничава гына басып торасың, брат,—диде Җәмил, дустын күргәч.—Ничек, каймак тәмлеме соң?

Мөхәммәт аны-моны дәшмәде. Җәмил җиңнәрен сызганды да идәндә аунап яткан тимерчыбыкны үрелеп алды. Алды да аны-моны әйтмичә генә, кизәнеп торып Мөхәммәтнең арт ягына берне сыдырды...

... Сөтле бидон бер якка, яктыга чыккан негр икенче якка тәгәрәде...

Бу хәлдән соң Мөхәммәт белән Җәмилнең дуслыгы тагы да ныгыды. Якынлашып килүче Яңа елны да алар бергә үткәрергә булдылар.

—Бездә утырабыз,—диде монда килгәч кенә чыршы дигән агач барлыгын белгән Мөхәммәт. —Амина да каршы килмәс.

Җәмил сүзсез генә ризалашты. Былтыр шул ук Әминәләр белән ничек Яңа ел каршылаганын онытмаган иде әле ул.

## Кыш бабай кара булаʔ..

Яңа ел бәйрәме якынлашкан көннәрдә Җәмил өчен күңелсезрәк бер хәл килеп чыкты—аны колхоз тракторы белән күрше чуаш авылына көмешкәгә йөргәне өчен трактордан алып, фермага каравылчы итеп куйдылар. Хәер, кайгыруын артык кайгырмады Җәмил, аракыны аны өйдә эчсәң дә шул, эштә эчсәң да шул, дигән фәлсәфи уй белән күңелен тынычландырды.

Җәмилнең хәләл җефете Гамилә исә шатланып кына куйды: «Ичмасам, бәйрәм кичләрен бу исереексез генә уздырам икән,—дип уйлады ул.—Утырсын, әнә, каравыл йортында маллар саклап, тамагын тыя белмәгәч. Юкса, ел да бик шәпләп бәйрәм итә иде Яңа елны...»

Чыннан да, Җәмил нишләптер Яңа ел бәйрәмен үтә дә кәтеп ала иде. «Елны ничек каршыласаң, ул шулай үтә», дигән сүзләрне ул беркайчан да исеннән чыгармады һәм нәрсә генә булса да Яңа ел өстәленең тәм-том, аннан да бигрәк эчемлек белән тулы булуын алдан ук кайгырта иде. Бәлки шуңа күрә чын-чынлап айныганы да булмагандыр аның.

Гамилә исә, аулак өйдә, үзе генә, тәгәлрәге, бер-ике күрше хатынын дәшеп, Яңа ел бәйрәмен уздырырга уйлаганга, алдан ук хәстәрен күрә башлады. Әзрәк Җәмилдән яшереп җыйган акчасы булганга бу эш авыр тоелмады аңа.

Ике-өч шешә аракыга, кәнфит-мазар іше вак-төяккә әллә ни күп акча кирәкмәячәк. Берәр тәмле әйбер пешерергә булыр, дип уйлады хатын, Аллага шөкер, бәрәңге җитәрлек, ит бар.

Ул Яңа елны бездә уздырабыз, дип җан дуслары Сәрия белән Әминәне алдан ук дәшеп куйды. Сер түгел, Гамилә дә нәкъ Җәмил кебек үк, Яңа елны ничек каршыласаң, ел шулай үтә, дигән сүзгә ышана иде. Җәмил каравылында айнык утырса, шат киләсе елны эчмәс, дигән уе да бар иде хатынның.

Бергә Яңа елны каршыларга дип дәшелгән Әминә белән Сәрия кичке тугызга килергә тиешләр иде. Бу хатыннар да әз-мәз пешеренеп килергә тиеш булганга, өстәл бик мулдан булыр дип уйлады Гамилә.

Сәгать тугыз тулгач, ул телевизорны кабызды, ашка барганда гына кия торган күлмәген киде. Көзге алдында чәчләрен рәтләгәндә, Гамилә тагын Җәмилне исенә төшерде. «И-и, утыра бугай каравыл өендә кукраеп,—хатын көлемсерәп куйды.—Ничава, утырсын, сакласын сарыкларын».

Сәгать унга якынлашты. Нишләптер Сәрия белән Әминә һаман күренмәде. «И-и, ул карт алашалар җыенганчы соң,—дип уйлады Гамилә.—Әле унбергә килеп җитсәләр рәхмәт әйтерсең».

Ләкин ахирәтләр унбердә дә, уникенче яртыда да күренмәде. Гамиләнең бөтенләй кәефе төште: «Кара син аны, тол хатын кебек утыр инде берүзең Яңа ел каршылап. Теге ике убыр киләбез дип вәгъдәләр бирделәр бит үзләре. Соң, кая йөрерләр икән, ә?..» Сәгать телләре уникегә якынлашты. Гамилә авыр сулап куйды да, берүзе булса да өстәл артына утырырга булды. Аның нигәдер өстәл тулы тәм-томга да исе китми иде инде. Хатын ачу белән, бер «ярты»ның бөкесен каерып ыргытты да бокалга аракы койды.

Сәгать уникене суга башлады. «Эх, җитмәсә Җәмилем дә өйдә юк,—дип уйлады Гамилә, тамагын яндырып төшеп киткән аракы артыннан кыздырылган тавык ите чәйни-чәйни.—Ул әле Яңа ел җиткәнен дә белмидер, мескен. Сәгате да юк бит аның».

Гамилә тагын бер чәркә салып эчте. Эчми эчкән нәрсә хатынның башына барып җитте, ахрысы. «Карале,—дип уйлады Гамилә,—соң, Җәмил янына барсам? Анда аңардан башка беркем юк. Утырырбыз икәү яшь чактагы кебек.—Хатын елмаеп куйды.—Сәке-мазар бар бугай каравыл йортында. Әминәләр йөрсен аптырап, ир хатыны ла мин...».

Гамилә сумкага ике шешә аракы, кабымлык тутырды да ашыга-ашыга киенә башлады...

Каравыл йортының авыр ишеген ачу белән Гамиләнең күзләре камашып китте. Өй эче халык белән тулы иде. Яхшылап себерелгән идән уртасында ашамлык-эчемлектән сыгылып торган өстәл артында ул бик кәефле Җәмилне, аның җан дусты Гарифны, ниндидер Кар кызы киеменә киенгән Әминәне, кыш бабай кыяфәтен китергән Мөхәммәтне, инде «кәкрәеп» өлгергән Сәрияне күреп алды. Җитмәсә өй түрендә «гөлт» иттереп бизәлгән чыршы да балкып утыра иде.

## Ак яулыклы көндәшләр...

Авыл белән шәһәрне бик нык аерып торган бер нәрсә бар—ул да булса беренчесенең һәрчак күз алдында булуы. Ягъни, мәсәлән, турырак итеп әйтсәң, авыл хатыны авылдашыннан яшереп бернәрсә дә эшли алмый.

Авыл хатыннары кемнең табак-савытны икешәр көн юмавын да, кайнанасы белән җан талашуын да, кемнәрнең ире белән аерым йоклавын да белеп торалар. Ә шәһәрдә эш бүтәнчә. Анда күрше—күршене, якташ якташны белми. Бәлки авыл кызларының соңгы елларда күпләп шәһәргә ыргылу сәбәбен нәкъ менә шуннан да эзләргә кирәктер.

Ахирәте Әминә, дүртенче ир итеп үзенә шәһәрдән Мөхәммәт Вәлиулла исемле нигыр мужигын алып кайткач, Сәрия, ничектер, боегып калды. Юк-юк, сәбәп монда көнләшүдә генә дә түгел. Сәрияне, Әминәнең үзеннән читләшүе борчыды. Мәхәббәт килә дә китә—дуслык мәңгелек, дигән принцип белән яшәгән хатын, ахириен аңлый алмый иде. Ничек инде яшьлек дустыңны нинди булса да ир кочагына алыштырырга мөмкин? Ярар, таза да булсын, кара да

булсын, ләкин ир-ат бит инде ул! Нәрсәсе бар икән соң бу Мөхәммәтнең шулкадәр? Сәриягә шул сорау тынычлык бирмәде.

Кеше тормышы күп кенә, очраклы хәлләр, очраклы эшләр тарафыннан үзгәрә. Шуңа күрә дә, Мөхәммәт Вәлиулла ферма мөдире итеп куелгач, Сәриянең шул ук фермага бозау караучы итеп урнашуын без очраклы хәл дип саныйк. Шулай аңлаешлырак та булыр.

Сәрия төбе-тамыры белән авыл кызы. Бозау карау аңа күптән күнегелгән эш булып кына тоелды. Алай гына да түгел, яше инде утыз тирәсендә булып та, ана булу бәхетенә ирешә алмаган хатын, бозауларны чын мәгънәсендә үз балалары кебек яратты. Ул эшли башлагач, моңа кадәр артык карау эләкмәгән яшь бозаулар күзгә күренеп диярлек үсә башладылар, аларның һәрвакыт аслары чиста, улаклары тулы иде. Сүз дә юк, Сәрия бозауларга гына түгел, көн саен бозау абзарына кереп, тикшереп торган яңа ферма мөдиренә дә сирәк кенә карашлар ташлаштырды. Ләкин Озын Улакның иң үткен хатыннары рәтендә йөрсә дә, Сәрия, нишләптер, Мөхәммәткә авыз ачып сүз дәшәргә базмады. Алай гына да түгел, ул кергәч, аның битләре ирексездән алсулана, сулышы ешая иде.

Бозауларның киләчәктә сыерлар булачагын аңлагангамы, яисә башка сәбәптәнме, Сәрия эшли башлагач Мөхәммәт тә бозау абзарына ешлады...

Нәкъ шул вакытта, авылда Әминәнең йөрәгенә тоз салган төрле имеш-мимешләр таралды да шул. Бу имеш-мимешләрнең көн геройлары, әлбәттә, Сәрия, Мөхәммәт һәм Әминә үзе иде. Иң аянычы шул, бу сүзләр яңадан кайтып Бәдәр Җиһаны авызына да эләкте. Авылның тагын бер үзенчәлекле ягы бар, анда күңел ачу чаралары аз булганлыктан, сүз йөртү гадәти хәл санала. Бер иш халык исә, булмаганны да булды, дип, ә булганны, ике тапкыр булды, дип сөйләп йөрүне үзенең изге бурычы итеп саный. Шуңа күрә дә вакыт үтә торды— Әминәгә, Мөхәммәткә һәм Сәриягә кагылышлы имеш-мимешләр йөри торды. Сүз, әлбәттә, Җәмилгә дә ишетелде.

—Кара әле, Җәмил,—диде аңа беркөнне дусты Гариф, алар икәү «баш төзәтеп» утырганда.—Теге кара малай Әминәне кыерсыта, дип сөйлиләр бит әле.

Җәмил сискәнеп китте. Гомер булмаганны ул инде авызына тидерергә өлгергән чәркәсен яңадан җиргә куйды.

—Ничек кыерсыта,—дип сорады ул Гарифка чәнечкеле күз карашын төбәп.—Кыйный диме әллә?

Сүз уңаеннан шуны әйтеп китәргә кирәк, холкы әллә ни йомшаклардан булмаса да үз гомерендә хатын-кызга бармак белән дә чирткән кеше түгел Җәмил. Алай гына да түгел, вакыт-вакыт хәләл җефетләренә «акыл өйрәтергә» яраткан ирләрне ул кешегә дә санамый иде.

—Юк ла,—диде, дустының болай сискәнүен яхшы аңлаган Гариф.—Ни ди бит, Мөхәммәт, имеш, теге... ни..., Сәрияне дә...

Гарифның бу сүзләреннән Җәмил шаркылдап көлеп җибәрде.

—И-и, Гариф,—диде ул көлеп туйгач һәм чәркәдәге аракыны йотып куйгач.—Әллә шул Әминәне кыерсыту була инде? Хатын-кызны, ул сораган әйберне бирмичә генә кыерсытып була аны, беләсең килсә. Ә Мөхәммәтнең исәнлеге бар, кайгырма. Әминәгә дә җитәр, Сәриягә дә. Әле әзрәк башкаларга калса да гаҗәпләнәсе юк.

Шуның белән сүз тәмамланды.

Әминәгә килсәк, ул да артык озак кайгырмады. Дөресен генә әйткәндә, ахирие Сәрия белән уртак яшәү аның өчен яңалык түгел иде. Ягъни, мәсәлән, искә төшерсәң: Сәриянең икенче ире, Сәриядән киткәч, Әминәнең өченче ире булып торды. Участковый Харис булмаса әле бәлки бүген дә торган булырлар иде. Ләкин шулай да Әминә хәлне төгәлрәк белергә булды. Бер кичне, Мөхәммәт эштән гадәттәге вакытта кайтмагач, ул Сәрияләргә менеп төшәргә карар итте.

Ул килеп кергәндә Сәрия эштән кайтып чишенеп кенә мәтәшә иде әле. Әминәне ул бик ачык йөз белән каршы алды. Тиз генә чәй куйды да өстәл тирәсендә кайнаша башлады.

Өстән-өстән хәл-әхвәл сорашкач, Әминә, озын-озакка сузмыйча, төп мәсьәләгә күчте.

—Кара әле, кызый,—диде ул, өстәл артына утыргач,—ни бит, авылда әллә нәрсәләр сөйләнәләр. Инде ышанырга да, ышанмаска да белмим. Мөхәммәтнең үзеннән сорарга да кыенсынам...

Әминә сөйли башлагач ук, сүзнең ни турында булачагын аңлаган Сәрия авыр сулап куйды. Аннары әзрәк читкә карап торгач, Әминәгә таба борылды.

—Дөрес, кызый,—диде ул тагын көрсенеп.—Бөтенесе дә түгелдер-түгелен, ну кайберсе дөрес. Баштан ук шуны әйтеп куям, мин Мөхәммәтне синнән тартып алырга җыенмыйм.—Сәрия тагын әзрәк дәшмичә торды.—Аннары, ни, кызый, мин бит авырлы да әле...

Әминә ни әйтергә дә белмәде.

—Соң... соң...—дип мыгырданды бераздан.—Ни бит кызый, ... мин дә ни бит, синең кебек...

Алдан сүз куешкандай, кинәт ике хатын берьюлы көлеп җибәрделәр.

—Соң, нишлибез, инде, кызый?

—Мин табарга булдым,—диде Сәрия җитдиләнеп.—Үземә иптәш тә булыр...

Бу кичне ике хатын тагын нәрсә сөйләшеп беткәннәрдер—анысы билгесез, ләкин шул көннән соң аларның дуслыгы тагын да ныгыды. Иң гаҗәбе шул, авылдагы имеш-мимешләр дә үзләреннән-үзләре азаеп, бүтән йөрмәс булды...

## Кара чутыр агарган

Көн артыннан көн үтә торды, кызу Африканың куе урманнары арасында дөньяга килгән кап-кара Мөхәммәт Вәлиулла, Озын Улак авылының үз кешесенә әйләнә торды.

Озын Улакта кеше гомумән кушаматсыз яши алмаганга, Мөхәммәткә дә үзеннән-үзе кушамат табылды. Авыл халкының олысы-кечесе аны хәзер Чуаш Мөхәммәт дип кенә атый иде.

Кушамат, Мөхәммәткә, алар Колга Җәмиле белән икәү күрше чуаш авылы Арслантауга, Җәмил әйтмешли, «экскурсиягә» менеп төшкәч тагылды. Арслантауга Җәмил дустын, аның карышуына карамастан, «Мин сиңа настоящий хатын күрсәтәм!» дип, алып менгән иде. Ике иргә дә, ягъни Мөхәммәткә дә, Җәмилгә дә әллә «экскурсия» нык ошады, әллә башка берәр нәрсә, ләкин аларны Арслантаудан ике көн үткәч кенә көч-хәл белән табып алып кайттылар.

Җәмилгә берни булмаган, ә менә Мөхәммәт бик ябыккан, хәтта ки ничектер агарыбрак та киткән иде кебек. Шуннан соң аның исеменә Чуаш кушаматы өстәлде дә инде.

Кушаматлы ферма мөдире Мөхәммәт тиз арада ачы итеп сүгенергә, моңарчы биш вакыт намазын калдырмый торган хак мөселман булса да, җаны уйнаганда «Идел» тәмәкесе тартырга һәм кичләрен әзрәк кеше күреп керим әле дип, аягына галуш киеп, капка төбенә чыгып керергә өйрәнде.

Хәзер инде ул нәкъ Аксубай мишәре кебек чеп-чи итеп татарча сөйләшә, әчебал куя, ат җигә һәм кирәге чыкканда хәләл җефете Әминәне Җәмилдән өйрәнгән рус сүзләре белән сүгә белә иде. Кыскасы, каралыгын исәпкә алмаганда, Мөхәммәт гап-гади авыл мужигыннан бернәрсәсе белән дә аерылмый иде инде.

Озын Улак тормышында Мөхәммәт аңлый алмаган бер генә нәрсә булды—ул дин мәсьәләсе. Язмыш шаяруы үзен мөселман авылына китереп ташлаганын аңласа да, яшьтән кыргый кабиләдә үскән һәм ислам дине кануннарында тәрбияләнгән Мөхәммәт баштагы мәлне моңа күңеле белән ышана алмады. Ничек инде бер генә хатын белән торган, аракы эчкән, тәһарәтнең нәрсә икәнен дә белмәгән һәм намаз укымаган халык мөселман була алсын?! Юктыр, болар безнекенә ошаган дин генә тоталардыр, дип уйлады пәйгамбәр исеме йөрткән ир. Мөнир мулла әйткән азанда егерме җиде хата санагач, аның бу уе ныгыды гына. Ләкин янган урында төзелеп килүче яңа мәчет, халыкның изге рамазан аенда ураза тотмаса да авыз ачарга йөрүе аны гел икеләндерә башлады. Ахырда ул бу турыда җаен китереп дусты Җәмилдән сорады.

Сорау бирелгән мизгелдә коточкыч махмыр оянәгеннән интеккән Җәмил җавап урынына кул гына селтәде.

Шуннан соң Мөхәммәт бу турыда бүтән сүз кузгатмады. Аллаһы Тәгаләнең кодрәте киң, дип уйлады ул. Боларда ислам диненең мин белмәгән берәр тармагыдыр күрәсең...

... Кыш артыннан яз житте, бәрәңгеләр чәчелде. Авылның изге бер йоласына әйләнгән бу эш вакытында, Мөхәммәт сука тотарга, һәм инде җылы җиргә чыгып өлгергән колорадо коңгызын чын-чынлап танырга өйрәнде...

Соңгы вакытта шактый түгәрәкләнеп киткән Әминә, ниһаять, җәй җитүгә бик шат иде. Җәй көне бар халыкның да кояшта янып каралуы һәм Мөхәммәт Вәлиулланың артык күзгә бәрелеп тормаячагын ул үзе генә аңлый иде. Ләкин җәй авыл кешесенә бетмәс-төкәнмәс эш алып килсә дә, болай да рәхәт вакыт бит. Сабан туйлары, печән өсләре үзе генә дә ни тора...

Сабан туеның нәрсә икәнен Мөхәммәт башта аңламады. Ахырда ул аны үз кабиләсендәге кебек мәҗүсилектән калган берәр бәйрәмдер дип уйлады.

—Яңа елдан кала иң зур бәйрәм инде бу безнең,—диде аңа Гариф.—Бу көнне күпме эчсәм дә беркем бер сүз әйтә алмый...

Үз гомерендәге беренче Сабан туе, Мөхәммәтнең мәңгегә исендә калды—чөнки ул анда һаман шул Гариф котыртуы буенча мәйданга чыкты... һәм инде ничәнче ел рәттән берәүгә дә бил бирмәгән егетне—Бүдәнә Фатыймасының шәһәрдән кайткалап йөрүче кияве Расихны җиңде. Бер иш халык моның белән риза булмыйча Африкасына кайтып керәшсен ул, диешсә дә, беренчелек барыбер Мөхәммәтнеке булды.

Җиңеп алган тәкәне шул ук көнне чалып, кич белән учак ягып шашлыкка киттеләр.

Авыл читендәге әрәмәлектә чи сарык ите кимереп утырганда Мөхәммәт үзен нәкъ туган джунглиендагы кебек хис итте. Күктә тәгәрәгән ай да нәкъ андагыча елтырый, баш өстендә иелгән тал ботаклары да андагы агачлар сыман тирбәлә иде. Җитмәсә, кыргый җанварлар авазы белән тирә-юньнән чын-чынлап бәйрәм иткән авыл яшьләренең акырышуы ишетелә иде.

«Эх, бер генә көнгә кайтып киләсе иде,—дип хыялланды Мөхәммәт.—Үзем генә түгел, Әминәне дә, Сәрияне дә, Җәмилне дә, Гарифны да алып кайтасы иде безгә».

Туган иле, нәсел-ыруы сагындырса да, Мөхәммәт инде үзенең тормышын авылдан, фермадагы сыерлардан, Җәмил белән Гарифтан, Әминәдән... һәм... һәм, кыскасы, бик күп яңа өйрәнгән нәрсәләрдән башка күз алдына да китерә алмый иде.

... Эх, без уйлаганча гына барса икән ул. Язмыш безнең теләкләрне, уй-хыялларны үз планнарына кертеп кыса икән. Ләкин ни генә булса да тормыш дәвам итә. Аяусыз, вакыт-вакыт хаксыз булса да, дөнья матур, дөнья киң ул...

## Акка караны кушкач

Печән өсләре җиткәч, Мөхәммәт Вәлиулла өчен кызу көннәр башланды. Озын Улак кояшы быел Африка кояшыннан бер дә ким кыздырмый иде. Малларга кышлык печән кайтару, силос салырга әзерләнү кебек эшләр артыннан көне буе чабып, кич белән арып-талып кайтып барганда Мөхәммәткә Сәрия очрады. Табигате белән бик үк җыйнаклардан саналмаган хатын бөтенләй түгәрәкләнгән иде соңгы вакытта.

—Исәнме, Мөхәммәт,—диде башка чакны чатнап торган Сәрия, ничектер, кыюсыз гына.—Эштән кайтып барышмы әле?

—Эштән, Сәрия,—диде Мөхәммәт, эре тешләрен елтыратып.—Синең хәлләр ничегрәк соң?

Сәрия башын аска иде.

—Бүген-иртәгә корсак ялына барырмын инде,—диде ул, бераз дәшми торгач.—Мөхәммәт, ... ни, ... син ничек булса да бер генә тапкыр минем янга килеп китәрсең инде, яме. Минем бит бүтән беркемем дә юк.

Мөхәммәт үзләрен берәрсе күрүе мөмкин икәнен дә уйламыйча, Сәрияне кочаклап алды.

—Килмимме соң,—дип пышылдады ул калын иреннәрен Сәриянең колагына тидереп.—Киләм, Сәрия, киләм. Әле менә Әминә дә...

Чыннан да, Әминә шушы араларда бәбәй табу йортына китәргә җыена иде.

... Ике хатынның да күңелендә нәрсәләр булганын белүе авыр, ләкин

игътибарлы кеше соңгы вакытларда Әминәнең дә, Сәриянең дә, ничектер, сагаебрак киткәнен сизми калмагандыр. Хатыннарның билләре калынайган саен, авыл халкы да аларга ничектер бүтәнчәрәк карый башлады. Авыл урамнары буйлап төрле сүзләр йөрде. Берәүләр акка караны кушкач нинди төс килеп чыгуын юрады, икенчеләр: юньле булмас бу, диюдән узмады. Җитмәсә, авылда Сәрия белән Әминәнең бу хәлдә үзләре генә түгел икәне дә ачыкланды, һәм Гариф сүзенә ышансаң, күрше чуаш авылы Арыслантаудан да шикле хәбәрләр ишетелде...

—Вәт булдыра ичмасам бу малай,—диде Җәмил Арслантаудан Питрау бәйрәменнән кайтканда.—Болайга китсә озакламый хатыннарның безне куып чыгара башлавы да бар. Әллә эчүне ташларга инде...

Чыннан да, соңгы вакытта, авыл ирләренең күбесе, хатыннарына, ничектер, шикләнебрәк карый башлаган иде. Моның сәбәбен, Мөхәммәт Вәлиулла авылда пәйда булгач, хатын-кызларның үз килеш-килбәтләренә игътибарны арттыра төшүләре белән дә, соңгы вакытта авылда телевизордан Африка турында күрсәтә торган тапшыруларның бик популярга әйләнүе белән дә аңлатып була иде...

... Ләкин җәйнең кызу бер көнендә көтелмәгән хәл килеп чыкты—авыл Советына Казаннан чылтыраттылар.

Төшке аштан соң йокымсырап утыручы җирле үзидарә рәисе Сабирҗан абзый, телефонның кинәт чылтыравыннан «дерт» итеп китте, аннары ашыгып трубкага үрелде...

Берничә минуттан, ул җил-җил атлап фермага таба атлый иде инде. Кара син аны ә, кара син аны, дип мыгырдана иде ул үз атына, ничек була инде бу, ә. Вәт, каенын еккыры!..

Калганы тиз арада булды. Шул ук көнне кичкә таба авылга моңарчы Озын Улакта беркемнең дә күргәне булмаган, мүгәлдәк арбасыннан да озын, ике чем-кара машина килеп төште. Алар, кая барырга икәнне алдан ук белгәндәй, туп-туры Әминәләр янына барып туктадылар. Машиналарның берсеннән килеш-килбәте нәкъ Мөхәммәтнекенә охшаш бер ир, ә икенчесеннән нәсел үгезеннән чак кына калышлы өч егет чыкты. Мөхәммәт аларны күргәч егылып китә язды. Башта ул берни әйтмичә тораташтай катып калды, аннары йөгереп килеп, үзенә охшаган кара ирне кочаклады. Аны бу мизгелдә күрүчеләр Мөхәммәтнең күзләре яшьле икәнен абайладылар. Шул арада Әминәләр тирәсенә халык җыелды. Этләр өрде, хатыннар елашты. Силсәвит Сабирҗан абзый, җыелган халыкка, Озын Улакка Мөхәммәт Вәлиулланы эзләп аның бертуган абыйсы килгәнен аңлатты. Күзлек Гамиры исә шул арада җыелган халыкка шатлыклы да, кайгылы да хәбәр җиткерде—Мөхәммәтнең туган илендә сугыш беткән һәм анда ил башына Мөхәммәт Вәлиулла ыруы килгән икән. Бу турыда, имеш, узган атнада ук Мәскәү гәҗитләрендә язган булганнар, тик печән чабу белән мәтәшкән Гамир бу гәҗитне кичә генә укыган ди.

Ике машина да авылда төн кунды. Иртә белән исә аларның Мөхәммәтне алып китәчәкләре билгеле булды.

Авыл «аһ» итте. Бар да диярлек Әминә белән Сәрияне жәлләде.

Мөхәммәт Вәлиулланы озатырга Озын Улакның бар халкы да диярлек килде. Тетрәнгән, сүзсез халык төркеме дәһшәтле тоела иде. Машинага утырыр алдыннан Мөхәммәт күзләре белән халык арасыннан Җәмилне эзләп тапты. Әминә белән дә, Сәрия белән дә ул инде саубуллашып өлгергән иде. Авыл халкына рәхмәт әйтелде.

—Җәмил,—диде Мөхәммәт, дустының җилкәсенә бөдрә башын салып.—Онытмагыз мине, Җәмил... Әминә белән Сәрияне ташлама инде туганым!

Халык төркеменнән елау авазлары ишетелде.

Машиналар кызулый башлагач, җыелган халык аның: «Мин кайтырмын әле, сыерларны карагыз!»—дигән сүзләрен ишетте.

—Кайтырсың,—дип мыгырданды башын аска игән Җәмил.—Әлбәттә, кайтырсың.

Аннары ул башын күтәреп Гарифка карады.

—Әйдә, Гариф, берәр нәрсә табып басыйк йөрәкне...

Кояш болыт астына чумды. Авыл, ничектер, караңгыланып, моңаеп куйды...

*Дин һәм тормыш*

# ТУГРЫ ЮЛГА ЧЫККАНДА...

***Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.***

ТАТАРСТАН мөселманнары бөтендөнья мөселман өммәтенең аерылгысыз бер өлеше. Күп гасырлар элек бабаларыбыз үз ихтыяры белән Ислам динен кабул иткән. Мин моның белән горурланам. Бала чагымда әниемнең әйткән сүзләре искә төшә. Ул: «Бар таккан дин, бар тапкан дин»,—дип әйтә иде. Кешегә динне ихтыярына каршы, көчләп таксалар, ахыр чиктә ул барыбер беренчесенә, рухи яктан аңа якынрак булганына кайта. Безгә исә беркем дә динебезне көчләп такмады. Әлхәмдүлилләһ, мең елдан артык вакыт үтсә дә, без аны беренчел сафлыкта һәм чисталыкта саклап кала алдык. Безнең күренекле дин галимнәребезнең, фикер ияләребезнең исемнәре җөмһүриятебез чикләрендә генә түгел, ерак төбәкләрдә дә билгеле.



Без бүген авыр, борчулы, гыйбрәтле заманда яшибез. Дистәләгән еллар буена җыелып килгән проблемаларның һаман да хәл ителмәве, икътисади торгынлык, соңгы сәяси вакыйгаларның шаукымы болай да авыр тормышыбызны тагын да катлауландыра бара, халкыбызның рухи халәтенә тискәре йогынты ясый.

Безгә бүген иң мөһиме—рухи яңарыш өчен мөмкинлекләр ачылу, җәмгыятьнең әхлакый яңарышында динебезнең әһәмияте көннән-көн арта бару, халкыбызның милли аңы белән бергә дини аңы үсү, ата-бабаларыбыз традицияләренең, рухи мирасыбызның кыйммәтен аңлау һәм шуларны истә тотып яшәргә тырышуыбыз. Шул ук вакытта, замана үзенең таләпләрен дә куя: бүгенге көнгә хас үзгәрешләрнең асылына төшенеп, киләчәккә перспективаны аныклау, халкыбыз һәм киләчәк буыннар алдында торган җаваплылыкны тоеп, гасырлар буенча килгән традицияләрне дәвам итү, шул ук вакытта динебезгә хилафлык китермичә эшләү.

Бүген авыл-шәһәрләребездә 1 меңнән артык дини җәмгыять эшләп килә. Әгәр дә аларның саны соңгы ун ел эчендә 50 мәртәбә артканлыгын исәпкә алсак (1989 елда теркәлгән 19 мөселман җәмгыяте генә бар иде), бу санның шактый югары икәнлегенә инану авыр булмас. Бүген шулай ук дистәдән артык мәдрәсәбез дин әһелләре һәм мөгаллимнәр әзерли. 1992 елда оешкан Татарстан мөселманнарының Диния Нәзарәте җөмһүриятебез мөселманнары тарафыннан сайланып куелып, аларны берләштерә торган берданбер рәсми орган дәрәҗәсенә күтәрелде.

Шуны да әйтергә кирәк, соңгы елларда эшчәнлегебезнең хокукый нигезен ныгыту өчен Татарстанның дәүләт органнары да шактый зур эш башкарды. Иң беренче чиратта 1999 елның июль аенда кабул ителеп гамәлгә кергән «Вөҗдан ирege һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы законын күрсәтергә мөмкин. Бу законның 18 нче маддәсендә дини оешмаларның вакыф мөлкәтенә ия булулары танылды. Октябрь инкыйлабына кадәр татар дөньясында зур урын тоткан бу милек

формасы, алга таба да икътисади, матди-техник проблемаларыбызны хәл итү өчен яңа хокукый нигез булдыруга үзенең өлешен кертер дип өметләнәбез. Законның дини әдәбият һәм дини билгеләнеш предметларына кагылышлы 22 нче маддәсе дә дини һәм гыйбадәти әдәбият бастыруны тиешле югарылыкка күтәрергә ярдәм итәр.

Дини яңарышның, үсешебезнең, эшчәнлегебезнең яңа этабы башлана. Татарстан мөселманнары Диния Нәзарәтенең 1998 елгы берләштерү съездында кабул ителгән уставы нигезендә формалашкан структурасы алдыбызда торган бурычларны үтәрлек дәрәҗәгә күтәрелде. Мөхтәсибәт системасы, казыят, Диния Нәзарәтенең уку-укыту, дәгъвәт, фән бүлекләре иң мөһим проблемаларны хәл итәрлек бердәм органга әверелде дип саныйм. Дөрес, тиешле дәрәҗәдә эшли торган вертикаль идарә структурасын булдыру өчен күп эшләргә кирәк әле. Чөнки саны 1 меңнән артып киткән дини җәмгыятьләребезнең һәрберсе белән без турыдан-туры Диния Нәзарәте аша гына эшли алмыйбыз. Ләкин аларның һәрберсенә мөфтинең, Нәзарәт президиумының, пленумының карарлары барып ирешергә тиеш. Алай гына да түгел, без һәрбер дини җәмгыятьнең ихтыяҗларын белеп, аларны хәл итү юнәлешендә эшләргә бурычлыбыз. Бу безнең төп максатларыбызның берсе. Урыннардагы дини җәмгыятьләрдән аерылган очракта, Диния Нәзарәте эшчәнлегенең мәгънәсе югала, фикер аерымлыклары, фетнәләр өчен җирлек туа. Шуңа күрә, шәхсән үзем дә, Нәзарәт аппараты хезмәткәрләре дә мөмкинлек булган саен район-авылларга чыгабыз, урыннарда эшнең торышы белән танышабыз, кулдан килгәнчә ярдәм итәбез. Төбәкләрдә, аерым дини җәмгыятьләрдә эшне оештыруда мөхтәсибләрнең роле бермә-бер артты. Эшнең торышы бүген бу төбәкләрдәге дини җитәкчеләрнең оештыру сәләтенә, гыйлем дәрәҗәсенә, халык арасындагы абруена, район хакимияте җитәкчеләре белән уртак тел таба алуына турыдан-туры бәйле.

Алдыбызда торган бурычларны тиешле дәрәҗәдә, үзебез теләгәнчә тормышка ашыру һәрвакыт диярлек кадрлар мәсьәләсенә барып терәлә. Шуңа күрә дә, дини кадрлар әзерләү мәсьәләсе бүген Диния Нәзарәтенең игътибар үзәгендә тора. Җөмһүриятебездә мәдрәсәләрнең саны шактый күп булса да, әлегә бу мәсьәлә тиешле дәрәҗәдә хәл ителмәгән. Аның төп сәбәпләреннән берсе—дини мәгариф системасының зәгыйфь булуы. Ниһаять, без җиң сызганып бу проблеманы хәл итәргә тотындык. Иң беренче чиратта, без дини уку йортларының статусын билгеләүне мөһим дип таптык. Уку-укыту, матди-техник мөмкинлекләрдән чыгып, аларны дүрт категориягә бүлдек:

1. Башлангыч дини белем бирү мәктәпләре
2. Урта махсус дини белем бирүче сәнәвия мәдрәсәләре
3. Югары дини белем бирүче галия мәдрәсәләре
4. Иң югары дини белем бирүче ислам университетлары

Бу уку елыннан башлап икенче һәм өченче баскыч уку йортлары, ниһаять, барысы да уртак, галимнәр һәм мөгаллимнәр тарафыннан бер системага салынган программалар нигезендә укыячаклар. Бу уку-укытуның профессиональ дәрәҗәсен күтәрү, аның торышын даими тикшереп тору һәм методик ярдәм күрсәтү юлында беренче, әмма бик мөһим адым. Дини мәгариф системасының тиешле дәрәҗәдә түгеллеге, укытучы кадрларның җитмәве, булганнарының белем дәрәҗәсе шактый түбән булуы—болар мәдрәсәләребездәге хәлнең торышын бик ачык тасвирлый. Аларда, кызганыч ки, әлегә кадәр милли, тәрбияви-әхлакый рух хөкем сөрми. Дини белем алу беренче планга куелып, уку процессының икенче мөһим ягы—тәрбия мәсьәләләре арткы планга этәрелә. Шәкертләребездә, бүгенге татар җәмгыяте проблемаларыннан аерылып тәрбияләнгәнгә, мөгаен, тәкәбберлек, мин-минлек кебек тискәре күренешләр дә сизелә. Ә бу дини даирәләргә һәм белем эстәүчеләргә хөрмәт белән караучы милләттәшләрдә аеруча зур гаҗәпләнү уята. Аллаһыга, халыкка хезмәт итәргә алыну шәкерткә дә, аны тәрбияләгән җәмгыяткә дә зур бурычлар йөкли. Бүген, атеистик карашлардан яңа гына аерылып килә торган җәмгыятьтә, дини эшне оештыру, дәгъвәт алып бару өчен тирән дини белем генә дә җитми. Шәкертләребез татар халкының тарихын белергә,

милли җирлектә ислам диненең үзенчәлекләрен, бүгенге көндә аның нинди рәвештә сакланып калганлыгын ачык күзалларга тиешләр. Рәсәйдә соңгы сәяси вакыйгалар, кайбер дин әһелләренең татар дөньясын ваһһабичылык идеяләре басып китте дип лаф оруллары, үзебезнең дини мәгариф системасын булдыруның нинди мөһим эш икәнлеген тагын бер мәртәбә искәртте. Бу фикерне мин бүген генә туган димәс идем. Чөнки татар зыялылары һәм дин әһелләре моңа инде XIX йөз уртасында ук килгәннәр. Безнең ата-бабаларыбыз Рәсәй империясе шартларында тормыш таләпләренә туры килерлек һәм югары дини белем бирә алырлык мәгариф системасын оештыра алганнар. «Мөхәммәдия», «Галия», «Хөсәения», «Рәсүлия» кебек татар мәдрәсәләрендә бөтен төрки дөньядан шәкертләр укыган. Бу уку йортларында татар зыялыларының элитасы тәрбияләнгән. Гомумән, татар мәдрәсәләре күп гасырлар буе халкыбызның рухи терәге булганнар. Татар халкының мәнфәгатен кайгыртучы, аның киләчәге турында уйлаучы зыялылар нәкъ менә шул мәдрәсәләрне тәмамлаганнар. Бүген дә бу традицияләрне яңартуның әһәмияте һәркемгә аңлашыладыр.

Дини мәгариф системасының мөһим бер чылбыры буларак, без бүген Россия Ислам университетына зур өметләр баглыйбыз. Әйтергә кирәк, дини мәгариф системасы өчен ул принципиаль яңа күренеш. Университет оешканда ук иң югары укыту йорты һәм фәнни үзәк итеп фаразланды. Шуңа күрә дә, аны оештыручылар арасында дәүләт органнарының һәм Татарстан Фәннәр Академиясенең Тарих Институты булуы очраклы түгел. Без, чыннан да, Ислам университеты киләчәктә югары квалификацияле ислам белгечләре, дини мәгариф системасы өчен кадрлар әзерләүче уку йорты булу белән бергәттән, дин галимнәрен, бигрәк тә күп гасырлы тарихка ия татар дин гыйлемен өйрәнүче галимнәрне туплаган фәнни үзәк булыр дип өметләнәбез. Мин, ректор буларак, фәнни тикшеренүләр алып бармаган уку йортының университет дәрәҗәсенә күтәрелә алмаганлыгын бик яхшы аңлыйм. Шуңа күрә дә безнең шәкертләребез беренче уку елыннан ук курс эшләре яза башладылар. Шушы юнәлешне күз алдында тотып, бу уку елында университетның эш планына «Татарларда ислам гыйлеме тарихы: узганы һәм бүгенгесе» дигән темага шәкертләрнең фәнни-практик конференциясен дә керттек.

Дини мәгариф системасын оештыру һәм аннан нәтиҗәле файдалану өчен уку йортлары эшчәнлегенең хокукый нигезләрен ачыклау зарури. Бу өлкәдә без хөкүмәт органнары, бигрәк тә мәгариф министрлыгы белән тыгыз элемтәдә торырга тиешбез һәм без шуңа омтылабыз да. Уку йортлары өчен тиешле лицензия алу һәм вакыты җиткәч аккредитация уздыру безнең өчен бик мөһим. Мөселманнарның берләштерү съездында Президентыбыз Минтимер Шәймиев әйткәнчә, дин дәүләттән аерылган булса да, «дини оешмалар җәмгыятьтән аерылмаган». Без дини уку йортларында укучы шәкертләрнең һәм аларны тәмамлаган яшь белгечләрнең җәмгыятебездә тулы хокуклы шәхес булуларын телибез. Ләкин лицензияле мәдрәсәдә 4-5 ел укып чыгып, дәүләт тарафыннан танылмаган дипломлы белгечнең эчке халәтен һәм хокукый хәлен күз алдына китерү авыр түгел. Әлбәттә, без бу мәсьәләнең четереклелеген аңлыйбыз. Җөмһүриятебез дәрәҗәсендә генә хәл ителә торган мәсьәлә булса, ул бәлки бу кадәр проблемалар да тудырмас иде. Кызганыч ки, аккредитация мәсьәләсе бүген Россия министрлыклары тарафыннан хәл ителә. Алар тәкъдим итә торган белем бирү стандартларын кабул итү—дини мәгариф системасын юкка чыгару дигән сүз. Бу мәсьәләгә, минем фикеремчә, киңрәк карарга кирәк. Без бит үзебезнең шәкертләребезне мәчетләрдә намаз укуны оештыручы имам яки шул ук мәдрәсәләрдә укытучы мөгаллим итеп кенә әзерләүне күз алдында тотмыйбыз. Татарларда дин әһелләре, руханилар инде күп гасырлар буе зыялыларның бер катламы булган, имам мәчеттә генә түгел, бөтен мәхәлләдә абруйлы үзенең яшәеш рәвеше, гыйлеме, әхлакый йөзе белән үрнәк булып торган. Без бүген дә шуңа омтылырга тиешбез. Әгәр дә мәдрәсә тәмамлаган яшь белгеч авылга кайтып имамлык вазифасын башкару белән бергәттән яшьләрне тәрбияләү эшенә актив катнашып китсә, алар арасында бүген киң таралган, әмма татар халкы өчен гайре табигый эчкечелек, фәхишәлек һәм башка

тискәре йогынтыларны бетерү юнәлешендә эш алып барса, авыл-шәһәрләрдә әхлакый вәзгыять, һичшиксез, уңай якка үзгәрәчәк, ата-бабаларыбызның гасырлар буе сыналып килеп, бүген дә әһәмиятен югалтмаган яшәеш рәвеше яңадан тормышыбызга кайта башлаячак. Димәк, дини уку йортыбыз алдында торган бурычлар халыкның дини ихтыяҗларын канәгатьләндерүче белгечләр әзерләүгә генә кайтып калмый. Безнең максатыбыз—совет хакимияте елларында үзенең асыл нигезен югалту дәрәҗәсенә җиткән татар җәмгыятен яңадан торгызуда актив катнашучы татар зыялыларының яңа буынын укытып чыгару һәм тәрбияләү. Бу дин әһелләре өчен генә түгел, бөтен җәмгыять өчен бик актуаль һәм мөһим проблема. Барыбыз да күреп торабыз, җәмгыятебезнең барлык өлкәсендә әхлаксызлык хөкем сөрә, беренче планга аерым шәхеснең, яисә аерым бер төркемнең матди-икътисади мәнфәгатьләрен канәгатьләндерү чыкты. Рәсәйдә дәүләт дәрәҗәсендәге сәяси проблемаларны да шушы күзлектән чыгып хәл итү тенденциясе көчәйдә. Алай гына да түгел, бүген пычрак сәясәттә «ислам факторы»ннан файдалану омтылышы бермә-бер артты. Төньяк Кавказда Дагстан җиренә басып керүчеләрнең барысына да «ваһһабичылык идеологиясе белән коралланган исламчылар» дигән ярлык тагу моның ачык мисалы. Турысын әйтик, XX гасырда сәясәттә һәм аның иң тискәре чагылышы булган сугышларда «ислам факторы»н бик еш файдалана башладылар. Ләкин без теге яки бу сәясәтнең, сәяси вакыйгаларның максатыннан Ислам диненең асылын аера белергә тиешбез. Иң югары әхлакый нормаларны үз эченә алган бөтендөнья диннәре, шул исәптән Ислам да, пычрак сәясәтнең нигезе була алмый. Ислам дине әхлакый чисталыкка өнди, җәмгыяттәге проблемаларны башкаларга зыян китермичә генә хәл итәргә омтыла. Идел буенда Исламның 1 мең еллык тарихы бар. Татар халкы нинди генә авыр шартларда яшәсә дә, Ислам динен агрессив көч итеп кулланмады. Киресенчә, динебез аша татар халкы цивилизацияле, алдынгы яшәеш рәвешенә омтылды. Идел буе мөселманнары тормышы мисалында без башка халыклар, башка конфессия вәкилләре белән үзара тыныч яшәү принципларының тормышка ашырылу юлларын ачык күзаллый алабыз. Урыс һәм башка халыклар белән 450 ел янәшә яшәү дәверендә бер генә дә җитди дини каршылыклар туганы булмады. Ә бит халкыбызның зирәклеге, түземлелеге нигезендә ата-бабаларыбызның гореф-гадәтләре булып, Әлхәмдүлиллаһ, Ислам дине ята. Татар дөньясында Ислам үзенең тынычлык дине, нинди генә шартларда да асылын югалтмый һәм көннән-көн үзенең потенциаль һәм интеллектуаль мөмкинлекләрен ача бара торган дин икәнлеген күрсәтте.

Мәдрәсәләребез проблемасына яңадан кайтып, шуны да өстәр идем: тәкъдим ителгән стандарт уку программалары арасында дөньяви фәннәрдән иң беренчеләрдән булып, без татар теле һәм татар тарихы белән беррәттән, «Татар халкының рухи мәдәният» дигән фән дә тәкъдим иттек. Без бу фәннәрне мәдрәсәләребезгә татар рухын, халкыбызга хас югары әхлак принципларын кайтарырга ярдәм итәрләр, шәкертләребез татар халкының тарихын, телен, рухи мәдәниятен өйрәнеп, җәмгыятебездә Ислам нурын таратырлар дип өметләнеп кертәбез. Мәсьәләнең гамәли ягын да истә тотарга кирәк. Халкыбызның тарихын, совет хакимияте елларында ата-бабаларыбызның нинди шартларда гыйбадәт кылуын белгән яшь имам мәчеткә йөрүче авыл картларына беркайчан да каты бәрелмәс. Аларны беркайчан да ачыктан-ачык бидәгать гамәлләрдә гаепләмәс. Сабырлык, түземлелек белән авыл картларына хакыйкый дин кануннарын үзләштерергә ярдәм итәр. Практикага кайткан шәкертләр, яшь имамнар тарафыннан мәхәллә картларына карата тупас мөгамәлә, аларны дини гыйбадәт тәртипләрен белмәүдә гаепләү очраклары булмады түгел. Бу очракта бит яшь имамнар кешенең дингә ихлас күңелдән бирелгәнлегеннән чыгып эш итәргә тиешләр. Дини гореф-гадәтләрне, гыйбадәт тәртибен тиешле дәрәҗәдә белмәүләре аларның гаебе түгел. Заманасы шундый булганга күрә туган ул вәзгыять. Күңелдәге дин чаткыларын үстерә, аларга тирән дини мәгънә өсти белергә тиеш яшь имамнар. Үзенең эшчәнлеге, үз-үзен тотышы, гыйлеменнән файдалана белмәве белән дин чаткыларын яңарту

урынына сүндерүче, Ислам диненә карата күңелдәге шикләрне бетерү урынына яңа шөбһәләр салучы имам дингә зыян гына китерә.

Мин яшь имамнарга куелган таләпләргә шактый тукталсам да, дөресен әйтим, хакыйкый вөзгыять, кызганыч ки, бөтенләй башка. Бу таләпләргә туры килә торган имамнар гына түгел, гомумән, яшь дин белгечләре юк дәрәҗәсендә аз. Без бер яктан мәдрәсәләребезнең саны арта дип кинәнсәк, икенче яктан яшь имамнарыбызның булмавына офтанабыз. Ни өчен болай була соң әле ул? Кая китә безнең кичәге шәкертләребез? Мәдрәсәләребездә очраклы яшьләр күп, ләкин алар имам булып эшләргә теләмиләр дисәм, хакыйкатьне тулысынча ачып бирү булмас иде. Кызганыч, вөзгыять күпкә катлаулырак. Мәхәлләләребезнең бүген имамнарны тотарлык матди-икътисади мөмкинлекләре юк. Авылга килгән имамны йорт-җир белән тәэмин итәргә, аңа эш хакы түләргә кирәк. Бу шартлар үтәлмәсә, авылда яшь имам тормый. Октябрь инкыйлабына кадәр татар җәмгыяте тулысынча мөселман җәмгыяте булган. Шуңа күрә мәхәллә үзенең имамнарын да, мәдрәсәләрен дә тота алган. Бүген исә мәхәлләләребез дәһрилек дәрьясындагы утраучыкларны хәтерләтә. Җәмгыятьтәге хәлләрнең мәхәллә тормышына тәэсире зур. Бу шартларда оешып кына килүче мөселман җәмгыяте үз проблемаларын үзе мөстәкыйль рәвештә хәл итә алмый. Мәчетләр төзүдә җирле хакимият органнары зур ярдәм күрсәткән булсалар, имамнарны тоту мәсьәләсен алар тулысынча үз өсләренә ала алмыйлар билгеле. Мәсьәләнең икенче ягы да бар. Дин дәүләттән аерылган. Димәк, мәхәллә дини мәсьәләләрне мөстәкыйль хәл итәргә тиеш. Дини кадрларны матди-финанс ягыннан тәэмин итүне Диния Нәзарәте тулысынча үз өстенә да ала алмый. Дин әһелләренең саны 2 меңгә якынлашып килгәндә, аларны төрле яктан тәэмин итүне, үзе дә төрле, даими булмаган чыганаклардан алган ярдәм хисабына яшәүче бер оешмага, ягъни Нәзарәткә йөкләү мәсьәләне хәл итү була алмый. Бу проблема дини аспект белән генә чикләнми.

Мәхәлләләр проблемасы җәмгыятьтәге проблемаларның үзенчәлекле бер чагылышы ул. Соңгы вакытта җөмһүриятебездә бераз шау-шу куптарып алган вакыйгаларны да шул күзлектән карарга кирәк дип уйлыйм. Җөмһүриятебездә безнең мәзһәбебезгә туры килми торган юнәлешләрне дәгъвәт итүче дин әһелләре, миссионерлар күренә башлаган икән, бу проблеманы Диния Нәзарәтенең тиешле дәрәҗәдә эшләмәвенә генә кайтарып калдыру дөрес булмас. Җәмгыятькә ниндидер, аңа хас булмаган, традицион җирлекне җимерә торган агымнар үтеп керә икән, димәк, җәмгыять үзе авыру, аның чит-ят идеологик йогынтыларга каршы тору иммунитеты юк. Әйдәгез, бу хакта бергәләп уйлыйк. Диния Нәзарәте дәрәҗәсендә генә түгел, хөкүмәт дәрәҗәсендә, бөтен җәмгыять дәрәҗәсендә уйлыйк. Әгәр дә мәдрәсә бетергән шәкертләребез, дини белем белән бергә дәүләт аккредитациясе үткән, дәүләт тарафыннан танылган, дәүләт учреждениеләрендә эшләргә рөхсәт бирә торган диплом алып, авылга кайтсалар, имамлык вазифасын башкару белән берреттән башка дәүләт оешмаларында да (беренче чиратта мәктәпләрдә) эшли алырлар иде. Мөселманнарның дини ихтыяҗларын тиешле дәрәҗәдә, үзебезнең мәзһәбебез нигезендә канәгатьләндергән мәхәлләләрдә чит агымнар таралу мөмкинме? Минемчә, юк. Шуңа күрә кабатлап әйтәм, бу проблемаларны дәүләт дәрәҗәсендә хәл итик. Дини җәмгыять дәрәҗәсендә хәл ителмәгән проблема, барыбер тора-бара бөтен җәмгыятькә тарала, башка өлкәләргә дә үтеп керә башлый. Шуңа күрә, дәүләтнең дин өлкәсендә үз сәясәте булырга тиеш. Татарстанда, шөкер, Президент та, хөкүмәт органнары да дин проблемаларына җитди карыйлар. Диния Нәзарәте белән дәүләт органнары арасында фикер каршылыгы да, аңлашылмаучанлыклар да юк диярлек. Бүгенге көндә иң мөһиме—үзара аңлашу стадиясеннән үтеп, ул проблемаларны даими, көндәлек хәл итү дәрәҗәсенә чыгарга кирәк. Күргәнегезчә, хәл итәсе проблемаларыбыз бик күп. Әлбәттә, дөньяви һәм төрле конфессия вәкилләре яшәгән дәүләт шартларында дини проблемаларны берниндu каршылыкларсыз гына хәл итү җиңел эш түгел. Ләкин иң мөһиме—ул проблемаларның күбесенең дәүләт, бөтен җәмгыять өчен дә әһәмиятле

икенлеген аңлау, шул юнәлештә конструктив диалог алып бару, үзара ярдәм кулы сузу. Менә шушы мәсьәләләргә җитдирәк карар өчен, аларның асылына төшенү максатыннан без «Татарстан Ислам дине» концепциясен эшләргә кирәк дигән фикергә килдек. Диния Нәзарәте каршындагы Голәмәләр Шурасы һәм аның тирәсендә тупланган галимнәр бу эшкә керештеләр дә инде. Аны өзерләү процессында бик күп мәсьәләләр яңача куелыр, аларны хәл итү юллары да төгәен анықланыр дип өметләнәбез.

Бүгенге шартларда алда торган проблемалар хакында җитди, профессиональ югарылыкта фикер алышу, кирәкле мәгълүматның, яңалыкларның мәгънәсен бозмыйча мөселманнарга, киң җәмәгатьчелеккә җиткерү өчен массакүләм матбугат чараларының булуы бик мөһим. Тагын шуны да искәртеп узарга кирәк, матбугат чаралары бүген көчле идеологик көрәш коралына әйләнде. Алар аша киң җәмәгатьчелеккә Ислам хакында нинди генә эчтәлектәге мәгълүмат таралмый. Кызганыч ки, күбесенең динебезгә мөнәсәбәте уңай түгел. Басылган материалларның кайберләре Ислам дине өлкәсендә наданлыкның чагылышы булса, кайберләре исә махсус заказ белән язылалар, Ислам дөньясындагы вөзгыятьне бозып күрсәтәләр. Шуңа күрә дә, бүген дини матбугат булдыру һәм булган дөньяви мәгълүмат чыганакларын мөселманлаштыру, рухи традицияләребезне аңлату проблемасы да җитди тора. Шулай да бу юнәлештә уңышларыбызның да булуын билгеләп үтик. Татарстанда чыга торган үзәк татар газеталарының барысында да дини сәхифәләр бар. Затлы «Казан утлары»ның да дини сүзгә ихтирам күрсәтүе зыялыларыбызның милләтне ахырзаман афәтләреннән сакларга, рухи байлыкларыбызны кайтарырга теләвен искәртә түгелме?

Вакытлы матбугат белән беррәттән дини китаплар бастыру мәсьәләсе дә безне борчый. Ун елга якын эшләп килгән «Иман» нәшрияты, бу мәсьәләне уңышлы гына хәл итә башлады. Дини китап нәшер итү дәреслекләр бастыруга гына кайтып калмый, билгеле. Бу өлкәдә мөһим юнәлешләрнең берсе—рухи мирасыбызны, дин гыйлеме өлкәсендәге хезмәтләрне укучыга кайтару. Бүгенге көнгә кадәр дини мирас тулысынча диярлек китапханә шүрлекләрендә тузанланып ята. Гарәпчә, өлешчә иске татарча язылган бу хезмәтләр укучыларыбызга барып җитми.

«Дин—ул нәсихәт» диелә пәйгамбәребез хәдисендә. Бәндәгә нәсихәт итсәң, ул дингә килә. Әмма бүгенге көндә динне ничек итеп аңлатырга соң? Динне колакларыбызга, күңелләребезгә ирештерү өчен нәрсәләр эшләргә кирәк? «Бер кермәсә, бер керер», дигән ният белән телевидение, радио аркылы да вәгазь-нәсихәт кылабыз. «Мәңге яшәр кебек дөньяңны кара, бәлки иртәгә үләрмен дип ахирәтеңне кайгырт» дигән сүзләр белән безнең аларны дөрес тормыш юлына өндисебез килә. Бу тормышта да көчле, бай, таза, гайрәтле бул. Тормышың матур, ихатаң чиста, йөри торган машинаң да яхшы булсын. Балаларың да тәүфикъка ия булсыннар. Ләкин дөньяга гына бирелеп бетмик, ахирәтебезне дә кайгыртыйк. «Дин үләр алдыннан гына кирәк, картайган көндә гыйбадәт кыларбыз»,—дип әйтүләр зур хата. Беребезнең дә пенсиягә кадәр яшәүгә гарантиябез юк. Бүген исән булсак та, иртәгә үлеп китәргә мөмкинбез. Пәйгамбәребез, «ахирәткә алдан хәзерләнеп куйсаң, үлем куркыныч булмый»,—дип кисәткән. Үлем—дөньяның ахыргы, ахирәтнең беренче көне. Үлү—бер халәттән икенче халәткә күчү генә. Һәрбер кеше үләчәк һәм Аллаһ хозурына барачак. Тәүлектә булган егерме дүрт сәгатьнең күпме өлешен дингә, күпме өлешен мәгыйшәткә багышладык соң? Кызганыч ки, күбрәк мәгыйшәтебезне кайгыртабыз шул. Әби-бабаларыбыз иң авыр вакытта, яшерен булса да, гыйбадәтләрен кылдылар, каберлекләрдә качып булса да гаетләрен укыдылар. Алар динне тыелганда да саклап калып, безгә тапшыра алдылар. 1985 еллардан соң заманалар үзгәрде. Татарстанда ирек, зур мөмкинлекләр вакыты булды, шуның кадерен белсәк иде. Безгә җәмәгатьчелек тә, хөкүмәт тә зур мөмкинлекләр ачып бирә. Мондый сәяси уңайсызлыкларны күп кенә мөселман илләрендә дә таба алмассың. Шулардан файдаланмасак, Аллаһы каршында ничек җавап бирербез?!

**Госман ИСХАКЫЙ,**

*Татарстан җөмһүрияте Диния нәзарәте рәисе*

**Дания Заһидуллина**

# “АЛБАСТЫЛАР” яки татар прозасында яңа сыйфатлар

**XX** гасырның 80 елларыннан башлап татар әдәбиятында реализм яки романтизм иҗат юнәлешләре кысаларына сыеша алмаган, үзенчәлекле һәм үзгә әсәрләр пәйда булды. Ф. Бәйрәмова, З. Хәким, Н. Гыйматдинова, Р. Зәйдулла һ.б. авторларның аерым әсәрләрен күздә тотып, шушы чорда татарларда да постмодернизм күренешенең мәйданга килүен билгели алабыз.

Гасыр башында ачылган татар модернистик әдәбияты кебек үк, бездә постмодернизм да һәм фәлсәфи-эстетик, һәм поэтик-стилистик яклардан билгеле бер милли сыйфатларга ия булып, Европа яки рус әдәбиятларындагы шул исемдә аталган агымнардан аерылып торды. Парадоксальлеккә түгел, ә реальлеккә омтылу, синтетик төсмерле булу татар әдәбиятындагы мондый әсәрләрне танып-бәяләү эшен авырайта. Ләкин соңгы вакытта язылган әсәрләр, бигрәк тә Г. Гыйльмановның “Албастылар” романы *(Казан утлары, 2001, № 1-2)* әлеге күренешләрнең урынын билгеләр вакыт җиткәнне искәртә. Чөнки бу әсәр— татар постмодернизм әдәбиятындагы беренче дулкынның (рус әдәбияты бүген өченче дулкынның күтәрелешен кичерә, диләр) югары ноктасы, аның үзгәреш юлын һәм поэтик үзенчәлекләрен күрергә ярдәм итүче берәмлек.

Шушы урында “татар әдәбиятына карата, молага ияреп, “изм”нар тагарга кирәкме?” дигән сорау туарга мөмкин. Аңа җавап бирү өчен, әлеге терминнарның мәгънәсенә күз ташлау да җитә. Билгеле булганча, кешелек тарихы күп кенә мәдәни чорларның эзлекле чиратлашуыннан гыйбарәт. Һәм модернизм баскычын атлап узган җәмгыятьләр постмодернизм заманына аяк баса. Дөрес, безнең җәмгыять бу баскычка җитүдән ерак әле. Шуңа күрә, иҗтимагый, фәлсәфи мәсьәләләрне читкә куеп, әдәбиятка гына мөрәҗәгать итсәк, XX йөз башы татар әдәбиятында модернизм чаткылары үзен шактый сиздергәнне күрербез. Кызганычка каршы, шушы “изм”ны танымау укучыны татар әдәбиятының М. Ханәфи, Г. Газиз, Г. Рәхим һ.б. исемнәр белән бәйле катламыннан мәхрүм итә һәм милли сәнгатьнең күп кенә сыйфатларын күләгәдә калдыра. Чөнки мәдәни чорларда һәр әдәбият үзенчә яши, милли төсмерләргә ия була, шул аермалы билгеләре белән, нәни чишмә кебек, дөнья әдәбияты дигән зур агымга килеп кушыла.

Постмодернизм әдәбиятының төп сыйфаты дип бер әсәр чикләрендә төрле темалар, әдәби алымнар, стильләр, төрле әдәби-тарихи традицияләрнең очрашуы күрсәтелә. “Албастылар”да да шушы синтез, кушылма уйланмада ук

күзәтелә башлый. Беренче, төп сюжет сызыгы армиядән кайткан Хәлим исемле авыл егетенең тормышы хакында сөйли: аны әнисе, авылдашлары белән мөнәсәбәтләрдә күрсәтә, өй салуын, өйләнүен, хатынын югалтуын бәян итә һәм, нәни кызын ияртеп, туган төбәгеннән чыгып китүе белән тәгалләнә. Реализм традицияләрен дәвам итүче бу сызыкта геройлар да, сурәтләнгән дөнья да, куелган проблемалар да чынбарлыкка охшаш, алар ышандыра. Әнә ул, Хәлим: "Житез-өлгер атлавына, нык адымнарына карап, аның бер сугуда бүрәнә өзәрдәй әзмәвер егет икәнен чамаларга мөмкин. Йөзе кояшта янган. Карашы туры, тирән.. Ә күзләре—күк төсендә, ачык зәңгәр!" Яки авыл: "Көтү күптән кайткан, урам тузаны басылган, авылның әле бер очыннан, әле икенче очыннан, адашып чит-ят утарга кергән бәрәннәрнең ара-тирә кычкырып куюы гына ишетелеп кала". Яшәвенең бөтен мәгънәсе бердәнбер улында булган "Ана яшьле күзләрен сөртә-сөртә, түшәктә ак юрганга чорналып яткан малаеның житү чәченнән, сакал-мыек баскан йөз-битләреннән сыйпый, бармак очлары белән генә куе кашларыннан йөгереп үтә, маңгаендагы миңенә тиеп карамакчы була да, инде кагылдым дигәндә генә кулын кабат тартып ала."

Шул рәвешле детальләштереп автор, әйтерсең, янәшәдә генә яшәп яткан героен укучы күз алдына бастыра, аның тормышын кабат тергезә. Бик кечкенә билгеләргә, төсләргә, исләргә укучының игътибарын юнәлтүдә, шул нәни "ваклыкларның" матурлыгын, шулар аша тормышның тулаем матурлыгын ачып бирүдә язучының осталыгы күренә дә инде. Авылга таралган сөт исе, кояшның кызыллыгы яки баласына сагыну-яратуын сөйләүче ананың сүз-хәрәкәтләре һәм башка бик күп табышлар реалистик хикәяләүне самими һәм тыныч-тигез корырга ярдәм итә.

Беренче сюжет сызыгыннан караганда, икенче чылбыр Хәлимнең саташуы, уйлану-хыяллануы кебек тоела. Ләкин каләм әлеге хыялны яңа чынбарлыкка әвереллдергән: Хәлим, буыннар кылган хатаның, явызлыкның жәзасын күреп, албастылар яши торган утарга эләгә, хәтерен югалта, күп еллар элек гаеп булган әтисен, мәхәббәтен очрата, хатыны һәм кызын алып бу тозактан котыла—жинеп чыга, ләкин албасты сихере Хәлимгә генә түгел, аның нәсел дәвамына да кагыла—кызы әтисез кала. Икенче, мифологик сюжет сызыгы беренчесенең ахырына килеп ялгана: сихерчеләрне жиңгән Хәлим авылдашларының битарафлыгын һәм усаллыгын күтәрә алмый, кызын бу тирәлектә калдырмаска теләп, урман юлы буйлап китеп бара.

Бу яна "чынбарлык" инде бөтенләй үзгә стильдә: анда капма-каршылыклар, үтә жете, хөкемдар сурәт өстенлек ала. Шом, ямьсезлек, куркыныч, чир, сихердән мәхәббәт, гүзәллек, бала сафлыгы, табигать илаһилыгына ташлану киеренкелек хасил итә, укучыны кызыксыну кысаларына эләктереп ала да ышандыра башлый. Хәлимнең утар һәм әпәләр белән танышуы, карчыкларның сихер белән шөгыльләнүе, Майяның бүреләргә каршы чыгуы, балыкка бару, качу-жәза, кышкы тормыш, хезмәт... вакыйгалары авылдагы ак, матур, тыныч тормышка каршы куеп, караңгы һәм куркыныч итеп сурәтләнә. Ләкин каршылыклар, актан—карага, матурдан ямьсезгә күчешләр моның белән тәгалләнми: ике төп сюжет сызыгының бәйләнгән һәр ноктасы парадокс чигенә житә. "Тормыш төбе"ндә Хәлим рух ныклыгын, көчен аңлый, мәхәббәтен таба, ата булу сөенечен кичерә. Ә инде кешедән өстен көчне—албастылар сихерен жиңеп, аклык-матурлык, тынычлык оясына—авылына кайткач, яраткан хатынын да, ныклыкның нигезе булган ышанычын да югалтып, чыгып китәргә мәжбүр! Ни өчен?

Сорауга жавап биргәнче, әсәрнең тагын бер сыйфатына тукталасыбыз бар әле: ул—әсәр чынбарлыгы һәм реаль чынбарлыкның махсус аерып куелуы—постмодернистик әдәбиятның тагын бер үзенчәлеге. Ягъни хикәяләүдә әдәби әсәрнең уйлап табылган, ижат ителгән икәнлеге ассызыклана, әсәр чынбарлыгының укучыга билгеле бер күләмдәге мәгълүматны житкерү өчен тудырылуы уку барышында ук аңланып тора. Галимнәр фикеренчә, хәзер инде әдәбияттагы үз дөньясы хакында сөйләүче язучы-автор урынын язучы-скриптор (кәгазъгә төшерүче) ала. Ул укучыга ләззәт бирерлек уен төсендәге язма ижат итә, шул текстка төреп әзерлеге төрле дәрәжәдәге укучыга "хакыйкатьләр" ача.

"Албастылар"да да әлеге скриптор хикәяләүне башлый һәм тәмамлый, бәян итәчәк хәлләрнең урынын, вакытын билгели, төп герое белән таныштыра,

моннан тыш, уйлап табылган чынбарлыкның кәгазьгә төшерүче ихтыярыннан башка яшәвен искәртеп китә: "Каһарманнарны ак кәгазьдә тудыру гына җиңел бит ул. Бер тәпи баскач, яши, сөйләшә, шатлана башлагач, алар сиңа әллә ни игътибар итмиләр, үз юллары белән, үз язмышларына каршы чыгалар да китәләр, бер киткәч, тиз генә әйләнеп кайтырга теләмиләр".

Әсәргә салынган беренче катлам, өске катлам мәгълүматлар да шушы хикәяләүче—скриптор гомумиләштергән хакыйкать, яшәү кануннары кебек тоела. Әйтерсең лә автор кызыклы сюжетка шул үзе әһәмиятле санаган законнарны үреп, эчтәлек белән янәшәдә үк укучы колагына әйтеп бара. "Кеше җиде буын бабасына кадәр бөтен хилафлыклар, гөнаһлар өчен җавап бирергә тиеш", "Кешедән курык! Чага торган елан әллә каян чагам дип килә, ә чага торган кеше, сөю сулышы белән исертеп тә чагарга мөмкин...", "Изге Китап белән кергән иман шартларын, Коръән образларын сихер-зәхмәт тә йолып, юып бетерә алмагандыр...", "Куркуны берни җиңә алмый", "Сүз алдый, хәтта күз дә алдый, ә миңа күңел алдамый", "Табигатьнең үз балаларына карата бер мәртәбә дә явызлык кылганы юк әле!", "Кешенең асылы менә шушы ак-кара рухлар көрәшеннән тора", "Җир пычрагына буяла барган саен, кеше пәйгамбәрлектән ерагая, еш кына Аллаһы тәгалә биргән изге сыйфат-хасиятләрен бөтенләй югалта", "Хис кешенең рухын йомшарта, аны көчсез итә", "Тәкъдирне узып язмыш бавын кисү—ай-һай зур гөнаһ бит...", "Күктәге баш Алла иң хәтәр сихердән дә көчлерәк бит", "Явызлыкка каршы явызлык дөрес түгел", "Дөреслек юк ул. Бары тик шәфкатьлелек кенә бар".

Юк, укучым, әлеге кануннарны аерып ялгышмадың, дигәндәй, автор аларны геройлары язмышында тагын бер кат күрсәтә, әсәр чынбарлыгы кысаларында шул кагыйдәләрнең үтәлү-үтәлмәү механизмын ача, аңлата, кисәтә...

Мәсәлән, беренче канунның дөреслеге Хәлим, аның әтисе, Нәфисәләр гаиләсе мисалында раслана: алар барысы да—ерак бабалары кылган хилафлык корбаны. Икенче канун яратудан нәфрәт чигенә атлаган Нәфисәнең үчләнү сәбәбен ача, явызлыгын сөю сулышы артына яшеренеп "чагу" буларак бәяли. Өченче канун Хәлимнең җиңү сәбәбен дини ышанулар белән бәйле аңлатканда калкып чыга. Дүртенчесе бүреләр мисалында да, кешеләрнең эш-гамәлләрен бәяләгәндә дә күренә һәм әсәрдәге күп вакыйгаларның сәбәбе итеп курку билгеләнә. Шул рәвешле, вакыйгалар катламында бу кодлар-кануннар кабатлана, шуның белән язучы әсәрнең максатчан язылуын ассызыклый. Аерым бер кодлар вакыйга катламын дөрес "укырга" юл күрсәтә. Мәсәлән, "табигатьнең үз балаларына карата бер мәртәбә дә явызлык кылганы юк әле" диюе белән автор урман эчендә яшәүче албастылар һәм табигать арасында чик уздыра. Карчыкларның мәрхәмәтле, ак табигать тәнендәге кара тап булуын искәртә.

Вакыйгалар катламы үзе дә яңа канун-хакыйкатьләргә бай. Чөнки нәкъ шушы катламда язучы үзе законнарын билгели башлаган Яшәеш моделен төзи, сюжет канвасына фәлсәфәсен яшерә. Шушы модельне җыеп торучы, Яшәешне бербөтен итүче образ таба: Юл. Хәлимнең районнан кайту юлы, албастылар утарына алып баручы, авылдан урманга илтүче, карчыкларны авылга алып килүче, Сания Хәлимне тапкан юл, онытылган догаларны искә төшерергә мәҗбүр иткән юл, хакыйкатьне аңлау яки албастыга әверелү юлы һ.б. Башланган урыны да, тукталган җире дә юк аның. "Юл бетү бит ул тормыш бетү, гомер өзелү дигән сүз", һәр кешенең яшәү юлы бар. "Юлы ерак аның. Күпме барасын ул үзе дә белми. Бер көн барырмы, бер атна, бер ай, бер ел барырмы? Әллә гомер буе барып та максатына ирешә алмасмы?" Максатка ирешү юлы юкмыни? Ләкин аннан да зуррак юл—Яшәеш үзе: "Явызлык та, изгелек тә юлга иярләшүчән була. Чөнки юл—язмышлар очраша торган урын. Һәм иң мөһиме, юлсыз урман, урмансыз юл булмый. Алар барыбер очрашалар. Алар очрашкан чакта башлана да инде яманлык белән изгелек көрәше".

Юл тоташтырган-берләштергән Яшәешне автор өч дөньяга аера: табигать, урман, албасты карчыклар дөньясы; кешеләр, авыл (җәмгыять) дөньясы; ышану, күк, иман дөньясы. Шушы дөньяларда, шуларны кисеп узган юлларда яманлык белән изгелек көрәше бара.

Яшәешне дөньяларга аерган кебек, автор фәлсәфәсен дә катламнарга бүлә. Башлап урман һәм табигать хакында сүз ача. "Юл белән урман бер-

берсенә шулкадәр береккән, бәйләнгән кебек, юлны урман "биленнән" чишеп ташласаң, мәһабәт имәннәр, озын, төз чыршы–наратлар, шау-шулы усаклар авып, имгәнеп, төрле якка таралып бетәрләр кебек тоела". Табигать–Яшәешнең дигән язучы Кешене дә шул Әнкәнең баласы саный. Хәлим–аю, Майя–бүре нәселеннән килеп чыккан. Шуна күрә Хабаровск тайгаларында аю Хәлимгә кагылмый киткән кебек, албасты сыерларын эзләп барган чакта бүреләр дә Майяга юл саба. Ә албастылар, күрәсең, карга нәселеннән булыр. Сөйләмнәре, язучының Хәлим күзе аша уздырып тәкъдим иткән чагыштырулары шуны дәлилли.

Хайваннар-кошлар үзләренең нәсел туганнарын таный. Ә кешеләр... аны ерак хәтеренә яшергән. Нәфисәнең Хәлимне төшендә аю итеп күрүе–шуңа ишарә.

Дөньяда һәр тереклек иясе–бертуган дип раслаучы язучы аны Кош белән бәйли. Кайчандыр Күк кенә булган, кошлар гына булган, шуңа кеше җаны күккә омтыла икән. Димәк, хәтер төпкелендә, аң тирәнлегендә табигать кочагына янадан кайтырга теләү яшеренгән булып чыга.

Табигать белән бәйләнешләрне сакламауда Кешене гаепләп, язучы мисалга "табигать белән кушылып, аның белән бер тында, бер сулышта яшәүче" мари халкын китерә: "Бу гади, самими тормышта яшәүче, ризыкка, тереклек итүгә талымсыз халык урманны илаһи бер көч итеп, аңа табынып яши. Мариларның күбесе әле дә мәҗүси. Һәр мари гаиләсендә, түрдә торган шкафтагы агач савытта кечкенә, тулы битле, йомры гәүдәле, корсагы алга бүлтәеп чыккан, тәнен, йөзен җыерчык баскан урман рухы яши". "Урман дөньясын бик беләләр алар. Аның холкын, йоласын, ымын–ырымын беләләр. Иң гаҗәбе шул: урман бавырына беркеп яшәсәләр дә, үзләренең йортлары кечкенә, кысан. Аны бик тиз яңартырга да җыенмыйлар. Аларча, ике буынга бер йорт салынса–шул җитә. Чөнки утыртылган агач кешеләрнең ике буын гомере кадәрле вакыт эчендә үсә икән".

Табигатьнең кеше "яклы" булуы әсәрдә гел кабатланып килә. Хәлимгә мәрхәмәтле эт тә, ат та, хәтта бөҗәкләр-үләннәр дә җанлы. Әбиләргә җәза биргән Күк һәм Яшен, Яшәү көче бүләк иткән Кояш... "Кешене олы афәттән шушы Кояш, чишмә, кошлар, чәчәкләр, күбәләкләр саклап калачак. Аллаһы тәгалә кешелек дөньясын урманнан гына мәхрүм итмәсен!" диюе белән язучы Яшәеш һәм Табигатьнең берлеген-бердәмлеген раслый.

Үзенең тамырларыннан аерылып, Табигатьтән ераклашкан Кешегә дә Яшәешне танып-белүнең юлы бар икән. Ул–табигать законнары белән яшәү, марилар кебек шул законнарга буйсыну. Табигатьнең үзеннән ярдәм табу. Бу яктан, Нәстә түтәйнең һәр иртә Хәлим өстенә артыш куагының киптереп тартылган тылсымлы онын сибеп җибәрүе–авторның матур табышы. Соңгы көнне шул онны сибеп җибәргән булса, Хәлим өстенә агач аумаган булыр иде дип, укучыны офтанырга мәҗбүр итеп, язучы уйлап табылган әсәр дөньясына чынлык бирә.

Урман эченә килеп кергән юлда да, язучы әйткәнчә, яманлык белән изгелек көрәше бара. "Яманлык"–албасты карчыклар, авылдагы аю һәм бүре нәселләренә кайчандыр ерак бабалары кылган хилафлык өчен явызлык эшләүчеләр: кешеләрнең аңын, хәтерен юкка чыгаручы, балаларын-ирләрен алып китүче, үлем чокыры янына китереп житкерүчеләр. Кешеләргә генә түгел, башка җан ияләренә карата да явызлык кыла албастылар. Язучы аларга каршы чыга алырлык көчне кешедә–Хәлимдә күрә. Дөрес, табигать үзе, аның яшене дә явызлыкка түзеп тора алмый, үз җегәрен күрсәтә: албастыларның сихер алачыгын яшен суга, үзләрен көчсезләндерә. Ләкин карчыклар теләгенә каршы килүче, алар "юлы" буйлап түгел, үз "юлын" табып киткән каһарман–Хәлим. Табигатьтәге караны, явызлыкны кеше юкка чыгара ала, юк итәргә тиеш, ди автор.

Албастылар гайрәте беренче карашка чиксез зур күренсә дә, Майяның саф күңеле, Хәлим һәм кыз арасындагы илаһи мәхәббәт, аның җимеше–гөнаһсыз бала аннан олырак. Кешеләрдәге сафлык, ярату хисе һәм җан ияләренең теләктәшлеге урман явызлыгын җиңәргә булышыр дигән ышану әсәрнең һәр вакыйгасында сизелә һәм хикәяләү пафосына һәрчак өмет хисе өсти. Уңышлы

сәфәр юраучы чукырлар яки һәрчак ярдәмгә килергә әзер булган Аксай яки Һау—Һау, хәтта күзенә туры карый алган кешегә буйсынучы аю йә бүреләр дә Ак—Кара көрәшендә кеше яклы, Ак тарафдары булып аңлашыла.

Урман юлы авылга китерә. Язучы аерып чыгарган икенче дөнья—кешеләр дөньясы—авыл, җәмгыять яшәеше булып гомумиләшә.

Беренче карашка, табигатьнең матур почмагына урнашкан Кампәрле җай гына яши кебек. Анда Саниягә кинәшче һәм терәк Ак бабай белән Васимә карчык, Кара сихергә йола сихерен каршы кую серен саклаучы Мәймүнә карчык бар. Ләкин авыл үзе Санияләр, Ак бабайлар кебек ярдәмчеллек кануннары белән яшәми. "Хәлимнең гаиләсе белән кайтып төшүе турындагы хәбәр тыныч кына яшәп яткан Кампәрле авылын чыгырыннан чыгарды. "Килен" дип тә әйтмәделәр, "гаилә" дип тә. "Хәлим сихер ияртеп кайткан", диделәр. Менә шуңа түзеп кара инде! Йөрәгең-жаның булса, ничек түзмәк кирәк?! Саниягә дә сүз күп ишеттерделәр. Гайбәт сөйләп йөргән Хатирә карчык янына ул үзе китте. Тегесен барыбер иманга китереп булмады. "Малаең сихерчеләр белән бәйләнгән, сихер йортыннан кайткан, хәзер бөтен авылны мур кырыр инде",— дип чәпчеде дә чәпчеде". Саниянең урманда бала табуы, иренең бик серле рәвештә югалуы да кешеләрне бу нәселдән читләштергән була. Читләшеп калсалар бер хәл, "беркөнне аларның капкасына дегет буяп киттеләр". Албастылар гына түгел, авылдашлары да Санияләр капкасына тәре сыза. Шушы урында автор романның буеннан-буена кабатланып килгән тәре символын "укырга" ачкыч бирә. Билгеле булганча, тәре—фашизмның да, христианлыкның да символы, шулай ук вакыт тәгәрмәченең тиз әйләнүен күрсәтү билгесе. Татарлар өчен тәре—дәүләтчелек югалу хатирәсе дә. Аның башка аңлатмалары да мәгълүм. Ләкин әсәрнең беренче кисәгендә язучының символны нинди максаттан куллануы ачыкланмый. Капкага дегет буяу күренеше тәренең явызлык символы, кара эш тамгасы булуын раслый.

Ялгыш юлдан киткән авыл, җәмгыятьнең кануннары нинди булырга тиеш соң? Бу сораугa Ак бабай болай җавап бирә: "Кешеләр бер-берсенә шәфкатьле булсалар, изгелек кылсалар, бер-берсен кичерсәләр—иман шул инде. Ходай тәгалә барысын да күреп, сынап тора, барысын да үз урынына куя... Менә синең капкаңа дегет буяп киткәннәр. Син шуңа үртәлеп, ачуланып, тузынып яисә үпкәләп йөрисең, шуның белән үзеңә авырлык аласың... Чын күңелең, ихлас җаның белән ул мәнсез бәндәләрне кичер. Үз явызлыкларына үзләре абынып, җәфа, борчу кичерсеннәр, иманга килсеннәр...".

Ләкин бу канун ярым-хакыйкать булып яңгырый. Чөнки Саниянең: "Каян, кемнән киләдер бу кадәр явызлык кешегә?"—дигән соравы җавапсыз кала, Майяның: "Күпме тырышсам да... кешеләрдән яраттыра алмадым",—дию җәмгыять законнарының табигать кануннарыннан үзгә икәнен раслый. Табигать балаларына Яхшылык кына кыла, аның усаллыгы Явызлыкка каршы юнәлергә мөмкин. Бу усаллык та куркыту белән чикләнә, чөнки урманда иң зур көч—курку. Майяның бүреләрне куркытуы, яшеннең әбиләрне исән калдыруы әлеге канунга мисал булып та килә.

Җәмгыятьтә исә Яхшылык түгел, Явызлык алдан йөри. Авыл үзе бөтенләй белмәгән Майяга каршы күтәрелә, аннан никадәр Яхшылык күреп тә, үз арасына кабул итәргә ашыкмый.

Авылдагы явызлык дигәндә, нәрсәләрне һәм кемнәрне күздә тотабыз соң? Ул—Нәфисәдәге кара көнчелек, аның яңауларын ишетеп тә, каршы төшүне, туктатуны кирәк тапмаган кешеләрдәге битарафлык, аннарын аракы томалаганнардагы усаллык. Бу Карага Хәлим—Санияләр, Ак бабай—Васимә карчыклар Аклыгы каршы куела. Ләкин кешеләр дөньясында яманлыкны юк итәрлек көрәш башланмаган әле. Кешеләрнең күбесе әлеге явызлыкка: көнчелек, битарафлык, усаллыкка күнеккән, аларны күрми яки күрмәскә тырыша. Ак герой—Ак бабай фәлсәфәсе дә көрәшкә өндәми. Шул ук вакытта кешеләрдәге усаллык—иң зур явызлык, ул кеше үтерүне дә бернигә санамый. Бу явызлыкка шәфкатьлелекне генә каршы куеп буламы? Юктыр, әгәр Ак бабай юлын дөрес дип тапса, хатынын югалткан Хәлим авылдан чыгып китмәс иде бит. Авылга алып кергән юлдагы изгелек-яманлык көрәше кешеләрнең яшәү кануннарын югалткан-онытканлыгын раслый.

Авыл һәм Урман өчен уртак, Табигать һәм Кеше дөньясында кисешүче тагын бер дөнья—Ышанулар дөньясы бар. Албасты карчыклар ышануы, кара сихер зәхмәте җан иясенең аңын—хәтерен алуга, аны колга әйләндерүгә юнәлгән. Мәҗүси сихер һәм дин—Аллаһы Тәгаләгә ышану исә әлеге явызлыкка каршы торырлык рухи көч бирә, өмет уята.

Табигать баласы булып, табигать кануннарын саклап яшәргә чакырса да, язучы Ислам динен мәҗүси ышанудан өстен куя. Хәлимгә Ак—Кара көрәшендә ярдәм иткән догалар, Хозыр Ильяс кебек карт һәм Күктәге баш алла, артыш таягы һ.б.—ислам дине атрибутлары. Дин кешене көчлерәк, чистарак, шәфкатьлерәк булырга өнди, өмет бирә, кара сихер исә өметсезлек, аңсызлык, хәтерсезлек, коллык баткагына төшерә дип, ышанулар дөньясын сурәтләү аша язучы берсен—кире кага, берсен—раслый.

Яшәешнең дини ышануларга барып тоташа торган катламына мөрәҗәгать итү—бүгенге татар әдәбияты өчен яңарак күренеш. Шуңадырмы, әсәрдә бирелгән мондый материал аеруча күзгә ташлана. Яңадан утарга әйләнеп кайткан Хәлимнең "Әлхәм" сүрәсен укуы, әнисе өйрәткән доганы исенә төшерүе, аларның мәгънәләре әсәр тукымасына бик шома кереп урнашкан. Саниянең догасы, сукыраюы, әбиләр алачыгын яшен сугу, Күк каргышы төшү кебек күренешләр дә тәэсирле. Ләкин пропаганда төсендә, әсәр логикасын боза торган урыннар да юк түгел. Мәсәлән, албастылар утарында үскән, ислам диненнән бихәбәр Майяның: "Сезнең Аллагыз әйбәт, Хәлим. Ул кешенең рухын сындырмый, аның күңелен богаулап, зиһенен томалап куймый..."—диюе ясалма тоела. Яки әсәрнең беренче кисәгендә Сания һәм Хәлимнең Кара сихергә каршы Ак—Мәймүнә карчыкның йола сихерен куллануы, бары тик икенче кисәктә генә дингә мөрәҗәгать итүе дә күңелдә ризасызлык уята.

Дөрес, язучы төп сорауга җавап бирергә онытмый: бу хакыйкатьне атлы бабай авызыннан әйттерә: "Җир йөзендә һәр адәм баласы—Алланың бер колы, димәк, изге зат. Ә һәр изге затта пәйгамбәрлек бар. Җир пычрагына буяла барган саен кеше пәйгамбәрлектән ерагая, еш кына Аллаһы тәгалә биргән изге сыйфат-хасиятләрен бөтенләй югалта". Бирәдә дин, иман кануннары белән яшәү изгелек-чисталык билгесе кебек шәрехләнә.

Язучы аерган өч дөньяны Юл гына түгел, бәлки үзәк каршылык та бәйли. Хәлим һәм албастылар каршылыгы. Ләкин һәр катлам "албасты" сүзенә үз мәгънәсен сала. Урман албастылары—гомерләрен явызлыкка явызлык белән җавап бирүгә багышлаган карчыклар, кайчандыр үзләрен авылдан куган нәселләрдән үч алучылар. Авылдагы имансызлар—дөнья пычрагына буялганнар шулай ук албастыга әверелә. Чөнки, язучы сүзләре белән әйтсәк, "кешенең асылы менә шушы ак—кара рухлар көрәшеннән тора. Албасты ягы җиңгән кеше тора-бара чынлап та бер явыз хәшәрәт кыяфәте алырга мөмкин. Фәрештә ягы җиңсә—ул Ходай тәгаләнең җирдәге рухи илчесенә әверелә". Димәк, язучының төп фәлсәфәсе ачык: һәр кеше Ак һәм Кара көрәшенә очрый, һәркемне албасты сагалый. Аңа каршы көрәшмәсәң, аны җиңмәсәң, үзең дә албастыга әверелəсең. Көнчелек албастысыннан җиңелгән Нәфисә, эчкечелек албастысыннан җиңелгән үтерүчеләр, битарафлык албастысыннан җинелгән авыл кешеләре кебек. "Кешеләр дөньясында албастылар юк, алар үзләре албасты, убыр, шүрәле, угры". Ләкин алар урман албастыларыннан да хәтәррәк. Алар начарлыкка гына түгел, яхшылыкка да начарлык белән җавап бирә, куркытып кына калмый, үтерүгә бара...

Әсәрдә үзәк идея белән бәйле тагын бер символ—тупыл агачы бар."Тупыл—шул ук Туба агачы, оҗмах үзәгендә үсеп утыручы Мәңгелек Агач, Дөнья Кәүсәсе, Яшәү умырткасы". Шундый ук тупыл албастылар аланында да, Нәфисәләр өе каршында да үсә. Табигать—Иман—Кеше дөньяларын тоташтыручы ясаган аннан автор. Албастыларның явызлыгына җәза итеп урмандагы агачны да, авылдагы агачны да яшен суга. Албастылар җиңсә, Яшәү умырткасы да тупыл кебек шартлап сынар дигән кисәтү сиземләнә.

Әсәрдә "албастыларны"—проблемаларны чикләп алу күңелдә ризасызлык та уята. Тагын бар бит әле ул кешенең кешелеген, аңын алырга, аны мингерәүләтергә теләгән кара көчләр. Мәсәлән, албастылар утарындагы тормыш идеология белән аңын томалап, халыкны колга әйләндерү сәясәтен хәтерләтә. Ләкин әсәрдә мондый катламны "укырга" ачкыч—кодлар, билге—символлар юк,

кешеләр тормышы җәмгыятьнең кечкенә берәмлеге—авыл кысаларында гына бәяләнә.

Бер яктан, үзәк образ булган Хәлим—нәкъ менә роман герое: көчле-матур, уңган-булдыклы, яхшы һәм чиста күңелле, мәрхәмәтле. Егерме яшьләр чамасында булган бу егетнең романда сурәтләнгән өч елдан артыграк тормышы эзләнүдә уза. Ул Яшәеш хакындагы хакыйкатьне эзли: Урман хакыйкатен, Иман хакыйкатен, Кеше хакыйкатен. Шул ук вакытта Хәлимнең көрәшергә дә, үз артыннан башкаларны ияртергә дә сәләтле икәне аерымачык: кыю, тәвәккәл, үзсүзле ул. Кешеләр эш-гамәленең албастылар кылганнарга тиң икәнен аңлый һәм шушы олы афәттән котылу, башкаларны коткару юлын эзләп китә. Дөрес, Хәлимнең эзләнү юлы озак булмас кебек, инде тәгәлләнеп килә: чөнки Табигать хакыйкатен дә, Иман хакыйкатен дә белә бит ул.

Шул рәвешле, язучы традицион роман герое—көрәшче геройдан үзгә образ тудыра алган. Хәлимнең роман гомерен эзләнү юлында уздыру үзенчәлекле тема билгеләргә һәм проблемалар куярга ярдәм иткән. Дөньяның өч катламындагы кануннар белән танышканнан соң, Хәлимнең яңадан Юлга аяк басуы исә укучы фикер-хыялын геройның шуннан соңгы тормышын "уйлап бетерергә" мәҗбүр итә, тәгәлләнмәгәнлек тәэсире тудыра.

Романда иң уңышлы, кызыклы образ, һичшиксез, Сания образы. Ул татар әдәбиятында төп урыннарның берсен алып торган архетип—корбанчылык сыйфаты беренчел булган Ак әби традицияләрен дәвам итеп язылган. Акъәбиләр (Ә. Еники), Бибинур (А. Гыйләҗев) карчыклар кебек үк, яшәүнең максатын бары тик балаларында күргән Ана өчен тормыш Хәлимнән башлана, Хәлим белән тәгәлләнә."Бала табуга Сания, терекөмеш кебек житез, дәртле хатын, кинәт кенә сүрелеп-сүлпәнләнеп кала", "Хәлименә бөтен гомерен багышлады". Ана—бала мөнәсәбәтләре шулкадәр җылы һәм илаһи, бу җылылыкны бирү өчен язучы Ана тавышы, Ана күз яше, Ана кайгысы, Ана колынын җылысы, Ана сөенече, Ана карашы кебек детальләрне бик оста файдалана: "Сабый өчен бигрәк тә үз анасының тавышы якын. Газиз, илаһи бер көй кебек". "Бер мәлдә Хәлим үзенең ирен читендә бер дым сизде. Нindидер тозлы бер тамчы шулкадәр көчле-куәтле иде, Хәлим шундук күзләрен шар ачып җибәрде". "Аның янында ап-ак чәчле, йөзләрен кат-кат җыерчык баскан, күп елаудан күзләре шешенеп беткән, күзе коесының төбенә үк төшеп киткән, йөзенең һәр күзәнәгеннән ниндидер олы авыртыну бәреп торган бер карчык утыра иде." "Аның күзләрендә сызылып яткан гаҗәеп матур, сихри бер яктылыкны, нур бөртеген күрмәү мөмкин түгел. Бу—баласының табылу сөенеченнән әле яңа гына кабынган күңел яктылыгы, бәхет нуры иде". Ана баласының бер генә эш—гамәлен дә шик астына алмый, аңа акыл өйрәтми, каршы килми. Саниянең һәр сүзе—җөмләсе, һәр хәрәкәте олы ярату хакында сөйләп тора.

Татар әдәбиятында билгеле алым—ананың сукыраюын да язучы үзенчә аңлата. Мәгълүм ки, Кол Галинең "Кыйссаи Йосыф"ында Ягъкубның, яки Муса Җәлилнең "Ана бәйрәме"ндә Ананың сукыраюы да бала кайгысы белән бәйләнгән. Ләкин Г. Гыйльманов тагын да тәэсирлерәк юл таба: Ананың күзләре—улы өчен корбан."Менә гомерем, менә кулларым—улым өчен гомерем дә, кулларым да җәл түгел, телисеңме, менә—күзләрем... Якты дөньяны күрүдән мәхрүм итсәң ит, тик улымны гына саклый күр берүк, и Раббым...", дип Аллага ялварган Сания, чынлап та, сукырая. Майя дәвалап күзле иткән ананың әсәр ахырында яңадан күрми башлавы исә тәэсирлелекне шулкадәр көчәйтә, шушы ноктада Ана һәм Бала мәхәббәте Егет—Кыз, Ир—Хатын мәхәббәтеннән көчлерәк һәм тирәнрәк булып тоела башлый: "Ул әнкәсенең "Улы-ы-ым!"—дип ачыргаланып, көяләнеп кычкыруын да, шушы иңрәүле тавыш белән бергә күзләреннән якты дөнья сурәтенең юыла баруын да белерлек түгел иде..." Сания белән Хәлим мөнәсәбәтләре сызыгы ана корбанчылыгының баланы яклаучы, саклаучы булуын раслауга хезмәт итә.

Постмодернизм әдәбиятында "җемелдәүче эстетика" дигән төшенчә бар. Ярдәмче геройларын иҗат итү барышында язучы нәкъ менә шушы алымны куллана һәм геройларның да тулы характер булуына ирешә.

"Җемелдәү"—укучының мәдәни хәтерендәге мәгълүматлар хисабына яңа мәгънәләр барлыкка килү ул. Бу вакытта романдагы тышчасы аркылы геройда

әдәби "генотип" яки архетип күренә башлый. Мәсәлән, шушы алым эпизодик образ—йөнтәс атлы картны ярдәмче образ дәрәҗәсенә күтәрергә ярдәм итә. Чөнки картның икенче "ягы"—Хозыр Ильяс булуы. Дини-мифологик образдагы төп сыйфатларны "биреп", Хәлимнән "танытканнан" соң, әлеге карт белән соңгы очрашуда язучы аның "хыялый" түгел, "чын" булуын искәртеп, болай ди:"Безнең заманның Хозыр-Ильясы ахры ул". Җемелдәү моның белән төгәлләнми. Хозыр-Ильясның романда тагын бер "игезәге" бар: Ак бабай. Шул рәвешле, көзгеле композиция алымы ярдәмендә образ дәвамчанлык таба, Хәлимне бала чагыннан романдагы соңгы күренешкә кадәр озата баручы, аңа ярдәмче-терәк өлкән ир-егет булып аңлашыла.

Мондый алым әсәрдәге башка образларны сурәтләгәндә дә кулланыла. Майя исеме Яшәү Алласы, гомер бирүче алиһә мәгънәсенә ия. Нәфисәнең игезәге булуы исә яңа фәлсәфи уйлануга этәрә. Кешедәге ике башлангыч: Ак һәм Кара, Яшәү һәм Үлем, Изгелек һәм Явызлык хакындагы искәртү төсендә төп идеягә килеп кушыла.

"Җемелдәү" мәгънәне тирәнәйтү белән чикләнми. Әйбер, интерьер, табигать сурәтләре дәрәҗәсендә ул каршылыкны көчәйтү өчен кирәк. Албастылар утарындагы каралык—Хәлимнәр өендәге аклык, әбиләр сихеренең чирканыч, Мәймүнә карчык сихеренең мавыктыргыч булуы, Сания әзерләгән ашлар—албастылардагы ризык, урман һәм басу рәсеме—бар да сюжеттагы Ак һәм Караны аеруга ярдәм итә. Әсәрдәге төп төсләр булган Ак—Кара да көзгеле композиция нәтиҗәсендә яңа мәгънә тудыра: башта ак фонда—кара, кара җирлектә ак яхшырак күренсә, аннары ак—карага, кара—акка әверелә. Бу процесс, хәтта, ырым такмагы дәрәҗәсендә дә кабатлана: Ак таш күк ташны яба, күк таш кара ташны яба. Шулай әсәрнең төрле элементлары арасында бөтенлек туа.

Әйтергә кирәк, имләү-өшкерү өлешләре бер тын белән укыла, аерым берләре ниндидер мәҗүси шигырьләр кебек дулкынландыра. Әсәрдә күңел сизү—интуициянең ролен югары күтәрүче күренешләр күп. Мәсәлән, Хәлим белән әтисенең бер-берсен тануы, Саниянең Хәлимгә авырлык килгән чакларны тоеп борчылуы, әнисе үлгән баланың бертуктамый елавы һ.б. Гомумән, әсәрнең геройлары шәхси гомер юллары буйлап күңеле кушканга ияреп, үз җанын тыңлап бара кебек. Нәтиҗәдә, мифологик материалның зурлыгы, аның сөйләшүләрдә, уйлануларда, курку-шатлыкларда һәрчак күрсәтелүе вакыт чикләрен киңәйтеп җибәрә. Шушы вакыйгаларны мең елга артка чигереп карыйсы килә, кешеләр мәҗүси заманнарда шулайрак: албастыларга әверелүчеләр аерым яшәгәннәр, Ак һәм Кара бергә кушылмаган төсле тоела башлый.

Һәм киресенчә, авыл тормышында колхоз-совхоз атрибутлары булмау вакытны алга "йөгертә", билгесез киләчәк кебек конкретлаштыра. Вакытның "җемелдәвенә" ирешкән язучы бу юл белән дә укучыны уйга сала. Үткән—Бүген—Киләчәкне бер җепкә тезә.

Әсәрнең җиңел укылуы, яратылуы, әлбәттә, тел белән бәйле. Эчтәлек, эчке мәгънә катламына үтеп кергәнче, аның хикәяләү рәвеше игътибарны җәлеп итә."Албастылар" бу яктан бик оста уйланылган. Әсәрнең беренче җөмләләре ак шигырь кебек укыла: "Июль ахыры. Чиллә күзе. Олы юл. Урман аланнарына керә—керә бормаланып сузылган бу таш юл, очы-кырые булмаган мари урманнарын урталай кисеп, алга йөгерә дә йөгерә. Барасы җир күп калмадымы әле, диган кебек, ул ара-тирә үр калкулыкларга килеп менә, биегрәк таулар очраса, хәл—егәрен юкка сарыф итмәс өчен, иренмичә әйләнеп уза. Мари урманнарының шомлы көе һич куркытмый аны.." Шушы стиль, вакыт-вакыт әсәргә әйләнеп кайтып, аңа үрелеп бара. Ләкин әсәр бөтенләе белән шигъри, чиста әдәби телдә язылып, персонажлар сөйләме, уй-фикерен җиткергәндә дә, хикәяләүче аңлатмаларында да шул шигърилекне сакларга омтыла. Кабатлауларның күплеге дә әсәрдә ритм тудыручы бер алымга әверелгән. Тәэсирлелеккә ирешүдә исә язучының төп коралы—эпитетлар. Шулар ярдәмендә язучы күпсөйләмле әсәрне бер өслүбкә җыя алган.

Әсәрдә уйланып бетмәгән, эшләнеп җитмәгән кебек тәэсир калдыра торган урыннар да бар. Кушйөрәкле Чәнти язмышы шундыйлардан. Югалганга кадәр һәм Хәлим албастыларга килгәннән соңгы тормышы шактый ачык күзалланса да, ике арадагы унсигез еллап гомер сызыгы караңгыда кала. Бу махсус рәвештә,

Хәлимнең рухи ныклыгын күрсәтү өчен төшереп калдырылганмы, мәхәббәтнең көчен раслыймы—әлеге гөманнарны дәлилләрлек сүз-җөмләләр яки билге-символлар юк әсәрдә. Икенче әпәнең кемлеге дә ачыкланмыйча кала.

Моннан тыш, Кушйөрәкле Чәнти һәм Хәлим язмышын чагыштыру язучы башлап тәкъдим иткән бер канунны—"Хис кешенең Рухын йомшарта, аны көчсез итә" дигән кагыйдәне кире кага. Мәхәббәт хисе һәм Майяның йогынтысы Хәлимнең акылын саклый. "Минем белән аралашкан чакта сина йоккан сихер, зәхмәт кими башлый",—ди ул егеткә. Нәкъ менә мәхәббәтләре албасты карчыкларны җиңәргә ярдәм итә. Бу очракта хис кешенең Рухын ныгыта, кешелеклелеген сакларга булыша. Кушйөрәкле Чәнтигә, сөйгәне Кампәрледә калган ир-егеткә, күрәсең, мәхәббәткә тиң күренеш белән очрашу насыйп булмый.

Язманың башында ук әсәрнең жанрын роман буларак билгеләгән идек. Язучы үз әсәрен "хыялый кыйсса" дип атаган, журналның русча аңлатмасында ул фантастик повесть кебек тәкъдим ителә. Ләкин әсәр романда табылырга тиеш барлык сыйфатларга ия һәм биредә хыялыйлык әдәби алым төсендә, постмодернистик әдәбиятның бер сыйфаты булып алга баса. Чөнки бу әдәбият чынбарлыкны кабат тергезү максаты белән түгел, бәлки яңа чынбарлык төзү—модельләштерү өчен языла. Шуңа да мондый әсәрләр төрле укучы тарафыннан үзенчәлекле "укылу"—аңланылу сәләтенә ия. Безнең романга биргән бәябез дә укылышның бер варианты—интерпретация генә булып кабул ителсен иде.

Укылыш барышында татар постмодернизм әдәбиятына хас сыйфат-үзенчәлекләрне билгеләү омтылышы ясалды. Чөнки шушы билгеләр яктылыгында "Албастылар"га кадәр язылган әсәрләрне дә күзәтеп узарга, татар әдәбиятындагы яңа катламга тулаем бәя бирергә була. Ә инде язылачак әсәрләрне интерпретацияләү хәзер аерып чыгарылган сыйфатларны табудан башлана ала.

"Албастылар"ның үзенчәлекле сыйфатлары дигәндә, нәрсәләрне күздә тотабыз соң?

**1.** Бер әсәр чикләрендә төрле әдәби-тарихи: реалистик, мифологик, символизм традицияләренең очрашуы, берләшүе. Ләкин мәдәни синтез моның белән чикләнми. Яшәеш фәлсәфәсе кысаларында табигать һәм кеше (натурфилософия), дин, галәм фәлсәфәсенең кисешүе күзәтелә. Мондый төрлелек Яшәеш моделен тудырырга ярдәм итә дә инде.

**2.** Конструктивизм—яңа чынбарлык уйлап табу, язучы һәм әсәр чынбарлыгының аерып куелган булуы. Ул әсәрне төрле әзерлектәге укучыга тәкъдим итәргә, һәр укучы өчен аерым эчтәлек тудырырга мөмкинлек ача.

**3.** Кодлаштыру, шулар ярдәмендә автор хакыйкатен, әсәр чынбарлыгы хакыйкатен, фәлсәфи-мәдәни хакыйкатьне укучыга тапшыру.

**4.** "Җемелдәүче" эстетика, ягъни образларның тышкы кабыгы аша башка, билгеле генотипларны күрсәтү. Бу өлкәдә автор шәхси иҗат алымы таба: "җемелдәүче" геройларының әсәр эчендә игезәген урнаштыра, көзгеле композициядән файдалана.

**5.** Бишенче сыйфатны татар постмодернистик әдәбиятының милли үзенчәлеге итеп билгеләргә кирәк. Татар модернистик әдәбияты кебек үк, постмодернистик әсәрләр дә, рус яки Европа әдәбиятындагы мондый алымнардан аермалы буларак, лириклыкка омтылалар. Шуңа ирешү өчен башка халыклардагы мондый тип әсәрләрдәгечә метафорик сурәт түгел, бәлки эпитетлар һәм детальләштерү алгы планга чыга.

Галимнәр фикеренчә, постмодернистик әсәрләрнең милли үзенчәлеге иң беренче чиратта сөйләмдә чагыла. Бу яктан, бүген үзе хакында хәбәр итүче постмодернизм әдәбияты белән XX йөз башында формалаша башлап оныттырылган, күздән югалтылган модернистик әдәбият арасындагы уртаклык прозадагы көчле лириклык, шигърилек белән дә билгеләнә.

Хәтер
Хәтер

## КЕМ УЙЛАГАН?

Аккош кебек ап-ак машина көзге шикелле ялтырап яткан асфальт юлдан йөзә дә йөзә генә. Тирә-як, август уртасы булуга карамастан, берни белән дә җәй азагын хәтерләтми. Көн эссе, магнитоладан талгын гына җыр агыла, ярымачык тәрәзәдән искән җил арткы урындыкта җырга кушылып көйләп тирә-якны күзәтеп баручы кызым Луизаның йомшак чәчләрен тирбәлдерә.

Күнелдә һичшиксез булачак тансык очрашу алдыннан була торган шатлыклы бер тантана. Очрашу һичшиксез булачак, Нажар абый әйтмешли: «Кем уйлаган—сюрприз очрашу».

Кичә Уфадагы өенә, Флорида апага шалтыратып, Нажар абыйның шәһәрдәме, дачадамы икәнен белешергә булдым. Телефонны Алсу алды. Хәл-әхвәл сорашканнан соң: «Әтием Минештедә, әнием абыемны Мәскәүдән каршы алырга аэропортка китте, килүегезгә әтием бик шатланыр, ул анда ялгыз бит»,—дип, ничек итеп Минештене табарга өйрәтеп, телефон аша үз кинәшләрен бирде.

Ел саен августта ял вакытында без гаиләбез белән житәкчесе ирем булган фермер хужалыгына урып-жыю эшләрендә ярдәмләшергә Илешкә кайтабыз. Ә бүген шушы уңайдан хөрмәтле Нажар абыйны да күрү теләге безне юлга чакырды.

Табигать шулкадәр тыныч, зәп-зәнгәр күктә бик биектә кошчыклар талпынып, тулып пешкән гәрәбә ашлыклар арасында зәңгәр күзле күк чәчкәләр сирпелеп кала, каршыда асфальтта безне ирештергән кебек бер якынаеп, бер ерагаеп машина тирбәлүенә ияреп рәшә артка чигенә, тирә-якта Дүртөйлегә генә хас төзек, тәртипле, матур авыллар күренеп-күренеп кала. Күнелгә тыныч, рәхәт: Илештә алдарак кайтып киткән ирем, улым көтә. Арткы урында кызым җырлап кайта, ә иң мөһиме безне остазым, бөек шагыйрь, гажәеп кеше белән очрашу көтә. Барысы да әйбәт, кайгы билгесе сизелми дә, дөнья чиксез, яшәү мәңгелек кебек.

Дүртөйлегә житкәч, туктап Минештегә юл сорадык. Аны Агыйделнен аръягында диделәр. Мин дә, шофер да бу якта булганыбыз юк икән. Юлчы алырга булдык, шөкер, күпергә житәрәк адым саен кулларына сумка яки төргәк тоткан кешеләр кул күтәрә. Туктап олы гына яшьтәге бер абыйдан Минештегә юл сорадык. Ул үз чиратында: «Винециягә кадәр утыртып алып барсагыз, юлны өйрәтәм, ләкин акча алмыйсыз»,—диде. Бераз салмыш иде ул. Луиза арткы тәрәзәне дә төшереп куйды. Безнең сорауны да көтеп тормыйча, абый сөйләнә дә башлады: «Беләм инде, беләм, безнең якташ Нажар абый янына барасыз»,—дип юл өйрәтә, Винеция авылының тарихына һәм исеменә тукталды, шагыйрь өчен районның дача салдыруын үзе салдырган кебек горурлык белән безгә аңлата-төшендерә, гәп куерта башлады.

Төшеп калганда әллә эсседән, әллә вакыт «шифасыннан» шактый гына «жылынуына» карамастан, тагын бер тапкыр юлны өйрәтте: «Барып житәрәк сулга борылырсыз»,—диде.

Без рәхмәт әйтеп хушлаштык.

Агыйделнең бу ягында мин беренче тапкыр идем. Искиткеч гүзәллек.

[1]«Кем уйлаган»—Н. Нәжминең 1983 елда Уфада дөнья күргән китап исеме.

Янәшәдә агачлар арасыннан ялтырап-ялтырап Агыйдел күренеп кала. Ике якта мәһабәт карагайлар, каен, усак, юкә агачлары, билгә кадәр үлән, юл буйлап чәчәкләр сибелгән. «Чыннан да монда туган кеше шагыйрь булмый кем булсын, монда туган кешенең һәрберсе шагыйрь булырга тиеш»,—дип уйладым. Ирексездән үземнең үскән, яшәгән Нуриман, гүзәл Сәрвә, Кызыл Чишмә, Павловка табигатенең кыргый матурлыгын янәшә куеп Нәҗар абыйның шигырьләрендәге кабатланмас гүзәллекнең кайдан алынганлыгын тойдым.

Барып житәрәк сулга юл күренде, без борылырга ниятләдек, шул вакыт ике кыз очрады. Туктап алардан тагы да юлны белешергә булдык. Абыйның сулга дигәне уңга булган икән. Сул як басу юлы гына. Нишлисең—бу кадәр эсседә уң белән сул гына буталырга да мөмкин.

Менешге күренде. Тау башында машинаны туктатуны үтендем.

> ... Үлгәч мине жирләсәгез иде,
> Минештенең сез Үрбашына...

дип шушы тау турында язды микәнни Нәҗар абый, дип уйлап куйдым. Әз генә түбәндәрәк яшь карагайлык. «Ак чишмә» дә якында гына булырга тиеш, күңел дертләп китте...

Юк, дөнья матур, яшәү мәңгелек. Бигрәк тә Нәҗар абый өчен. Олы шәхес, бөек шагыйрь өчен.

Авылга килеп кергәч, колхоз идарәсе янына туктап, Нәҗар абыйның йортын сораштык һәм ниһаять, «башка чыккан кешенең өе», ягъни «минештенский пленник» яшәгән урын. Соңгы хатында ул шаяртып шулайрак язган иде.

*«Халисә сеңлем!*

*Яңа йортка, яңа адрес буенча килгән беренче хат синнән! Күңелгә бик тә рәхәт булып китте. Телефон аша да беренче булып синнән хәбәр алган идем.*

*Хәйдәр Бигичев турындагы истәлекне бүген иртән язып бетердем, дөресрәге, акка күчердем. Ярыйсы булып чыкты—формасы белән кызык тоела, ә исеме «Әйтелми калган тост».*

*5 мартта Әмирхан Еники абыйның юбилей кичәсе. Фәридә Кудашева белән икебезне чакырды. Авыр булса да бармый калдыра алмыйм—ул мине бик якын күрә бит.*

*Дүртөйледән туры Казанга «Волга»да китмәкчебез. Истәлекне дә үзем белән алырмындыр—бер үк көнне барып керербездер.*

*Ул истәлек мәсьәләсе ничек итеп Нуриманга барып чыкты соң? Рифат Фәттәховка бәйлеме? Кызганычка каршы, мин егетне белмим.*

*Йорт һәм аның урыны, туган җир булгангамы, бик соклангыч кебек: килгәч күрерсең әле.*

*Ике шигырь яздым: беренчесе «Егет сүзе», икенчесе «Берәү» дип атала. Ике депутатлыкка кандидат турында портрет яздым. Басылармы, хәзер андый гадәт бармы—белмим, әмма берсе бик шәп кеше.*

*Хәзер үземне «минештинский пленник» дип атадым.*

*Телевизорга тышкы антенна куелмаган. Бүген телефон куйдылар. Номеры: 66-632, ул вакытлы шикелле. Авыл һәм район арасында бәйләнеш өчен ярап тора.*

*Район үзәгендә һәм авылда мөнәсәбәтләр бик яхшы. Йортта 5 февраль—81 яшь тулган көнне яшәтә башладылар. И гомер, әле генә 80 иде бит!*

*Вакытың булса, язгалап тор. Ни әйтсәң дә, мин башка чыккан кеше бит әле. Киләчәккә планнар зур.*

*Сәлам белән Нәҗар абыең. 24 февраль, 1999 ел.*

Мәһабәт, искиткеч зәвыклы итеп салынган йорт. Ихатада җан әсәре сизелми. Сәгать көндезге 3ләр тирәсе. «Ял итәдер»,—дип уйладым. Үзем эчтән генә шул кадәр юл үтеп, ярты ел буена килеп күрергә вәгъдә биреп тә, берәр җиргә китеп барса, күрми китү дә бик мөмкин дип, курка-курка гына ишек бавын тартам, ишек ачылды, рәхмәт төшкере.

Әй, Аллам: хөрмәтле Нәҗар абый, бөек шагыйрь, олы шәхес. Ап-ак чәчләрен артка салып кухня өстәле тирәсендә җинел җәйге киемдә генә ярып пешергән яңа бәрәңге белән йомырка «сыпыртып» утыра. Башын

күтәреп мине күргәч, өнсез калды. Үзе сөйләнә, әй, Аллам, әй, Аллам синме бу, Халисә сеңлем? Кайдан, ничек? дип сораша. Үзе шат, күренеп тора.

«Менә бит мин вәгъдәмдә тордым, сез чакырдыгыз, мин килдем, хәтта үзем генә түгел, юлдашлар да бар»,—дидем.

Очрашуда гына була торган ыгы-зыгы, кәстрүл, тәлинкә чыңы китте. Луизаны күреп сокланудан бигрәк гаҗәпләнү кичерде.

—Халисә, үзең-үзең инде, кызың бигрәк сылу, кемгә охшаган?—ди.

—Әтисенә,—дим.

Без Нажар абый белән кара-каршы утырып хәл-әхвәл сорашабыз, Луиза кухня тирәсендә булыша. Нажар абый зал өстәленә таза ашъяулык җәеп куйды. Луиза чынаяклар куя башлаган иде: «Юк, юк, сез минем кадерле кунакларым»,—дип серванттан затлы сервизын ала башлады.

Мин үз гомеремдә дә шулкадәр тәмле ризыкны ашаганым булмагандыр, әллә юлдан ачыгып килгәнгәме, әллә җылы, тату мөнәсәбәтме, уртага бүлеп пешерелгән яшь бәрәңге белән казылык, күчтәнәч бал, баллы бавырсак, тәмле чәй белән рәхәтләнеп сыйландык. Нажар абый ашамады. Ул өстәл аша безне җылы караш белән күзәтеп утырды. Үзе көнбатыш һәм рус классикларының Луиза исеме кергән әсәрләреннән шигырьләрне яттан укыды, өзекләр китерде. Мин аның хәтеренең яхшылыгына сокланып утырдым. «Исемен кем кушты, үзеңме?»—ди.

«Әтисе, дим.—«Ул туар алдыннан телевизордан «Башсыз җайдак» дигән фильм бара иде. Шундагы героиня ошады аңа, кызым туса, Луиза була»,—диде, димен. «Шәп,—ди Нажар абый,—үзеңә охшаган. Бәхетле генә була күрсен».

Луиза өстәл җыештыра, без сөйләшәбез.

«Язасыңмы, Халисә?»—ди.

«Соңгы вакытта әз»,—дим,—күңел төшенкелеге, ниндидер бушлык, хөкүмәт эше бар энергияне ала, гомер тамак ялына үтә, ах, кызганыч ул гомер»,—дим.

«Аңлыйм, минем дә андый чакларым булды, үз-үзеңне көчләмә. Үтеп китә ул. Сабыр ит»,—ди. Мин аның хәлләрен сорашам, нинди әсәрләр язганын сорыйм?

—Дүрт-биш шигырь яздым. Туган авылым турында, тыңла,—ди һәм укый.

... Бөтенләйгә кайттым куенына,
Мәңгелеккә синдә калырга...

Шатлыклы атмосфера моңсу тынлык белән алышына.

«Ашыкмагыз әле, Нажар абый, сез безгә, кешеләргә кирәк. Сез булганда дөнья матуррак та, баерак та, иртә әле мондый шигырьләргә»,—дим. Ул моңсу көлемсери:

—Алай түгел шул, Халисә сеңлем. Миңа ничә яшь икәнен беләсең бит. Әгәр тегеләй-болай була калса, мине шушында җирләячәкләр, Миңеште тау башына, урынны район, авыл хакимияте башлыкларына да күрсәтеп куйдым, беләләр, монда калырга телим»,—диде. Йөрәк чәнчеп куйды.

Заманыбызның бөек шагыйре, олы шәхес, талант иясе белән бер чорда яшәвебезнең мәгънәсен аңлап бетердекме икән без?

Нажар абый мине студент елларыннан ук белә, үз кызы кебек яратты, ярдәм итәргә тырышты, иҗатымны бәһаләде, авыр чакларымда эш, иҗат, гаилә мәсьәләләрендә дә киңәше белән ярдәм итәргә тырышты, яклады, мин дә, әтисез үскәнгәме икән, аңа тартылдым, үз иттем. Ул минем киңәшчем дә, дустым да, терәгем дә иде.

Иде... Кем уйлаган?

Ә бүген әле ул исән-сау, шат.

Өен күрсәтә башлады. Эш бүлмәсенә күтәрелдек. Өстәлдә өр-яңа сигнал данәсе булган «Күңел сәхифәләре» дигән китабы.

«Икенчесен алу белән сиңа җибәрермен»,—ди.

Ике якка тәрәзә аша матур күренеш ачыла. Агыйдел күренә, Роберт

Миннуллин язган «шагыйрь кинлекләре» колач җәя, нинди хозурлык, яшисе һәм иҗат итәсе генә иде. Без кәнәфиләргә утырабыз.

«Шигырь укы»,—ди ул коры гына. Укыйм.

«Чукынчык, шәп, яз!»—ди ул. (Шаярып һәм яратып ул «чукынчык» сүзен кулланырга ярата иде.)

Былтыр сентябрь аенда үзе сценарием язып, үзе төшерүне оештырган телевизион фильм героен, озак еллар Нуриман районында Байгилде мәктәбе директоры булып эшләгән Брест крепосте каһарманы, РФ һәм БРның атказанган укытучысы—үзенең дусты Ришат Сәлихович Исмәгыйлевны сораштырып утырды.

Көлешә-көлешә Байгилдедә бер очрашу вакытында булган кызык хәлне искә төшердек.

1994 елның июнь азагы иде. Искиткеч җылы, матур көн. Очрашуга чакырылган кунаклар арасында иң кадерлесе, билгеле, Нажар абый иде. Тантана авыл клубында кич үтәргә тиеш. Ә хәзергә кунакларны табигать кочагына, умарталыкка чакырып бераз ял иттерергә булдылар.

Җырларда җырланган Караидел буйлары. Язучылар Сәгыйть Мифтахов, Имай Насыйри, Гайнан Хәйри, Ярулла Вәлиев, Зиннур Насыйбуллиннар яшәгән һәм иҗат иткән яклар...

Нажар абый гүзәл табигатькә сокланып туя алмады. Учак тирәсендә гәп куертабыз. Нажар абый пинжәген салып якындагы шомырт агачына, хәзерге мәктәп директоры Салават Исмәгыйлев пинжәге янына элеп куйды. Пинжәкләр бер үк төстә иде. Зиннур Насыйбуллинның иҗаты, аның яшьли дөньядан китүе турында борчылып сөйләнелде. Балык шулпасы, шашлык белән сыйланып, дөнья, яшәеш, шигърият хакында озак кына сөйләшеп утырдык. Бераздан вакытның шактый соң икәнен, клубка кеше җыела башлаганын искә төшереп, тиз генә кайтырга әзерләндек. Нажар абый үрелеп пинжәген алып киде. Кунаклар алдагы машина белән кайтып китте. Салават Ришатович бераздан кайтып җитәсен әйтеп, торып калды. Без кайтуга зал тулы иде.

Кунаклар сәхнәгә күтәрелде. Шигырь кичәсе башланды.

Сүзне Нажар абыйга бирделәр. Ул микрофон янына килде, язмаларын һәм күзлеген алырга, дип кесәсенә тыгылды, тын калды, кесәләр буш иде. Пинжәге Салаватныкы булып чыкты. Халык көтә, ә ул аңа гына хас шат янгыравыклы тавыш белән көлеп җибәрде. Залга ни булганын сөйләп бирде. Ул көлә, халык көлә, без көләбез.

Соңыннан: «юк, мин сезгә буш кесә белән түгел, тулы күңел белән килдем»,—дип, бик матур итеп шигырьләрен укыды. Залдан җыр җырлавын үтенделәр, ул ялындырып тормады. «Уфа юкәләре»н җырлап җибәрде. Аңа без кушылдык, безгә зал кушылды.



*Нажар Нәҗми дусты, Брест крепосте каһарманы Ришат Исмәгыйлев белән. Байгилде мәктәбе, 1998 ел.*

Нуриман җиренә Нажар абыйның соңгы килүе үлүенә бер ел кала, 1998 елның сентябрендә булды. Җылы, ләкин болытлы көн иде.

Әйтүемчә, Нажар абый Ришат Сәлихович Исмәгыйлев турында фильм төшерергә тиешле төркем белән килде. Кәефе бик шәптән түгел: «Ашказаным авырта»,—диде. Шулай булуга карамастан, мавыгып-яратып шагыйрьләрчә эшләде ул фильмны. Авылның тоташ күренеше кирәк иде. Без авыл

каршындагы тауга күтәрелдек. Тау башыннан тирә-як уч төбендәге кебек күренә. Күлләр, күлләр, күлләр.

«Әкияттәге кебек»,—дип куйды Нажар абый.

Тау башы яшь карагайлык, түбәндә зур күл. Күл аша Ришат Сәлиховичның йорты.

Минем авыл тавында да шундый ук яшь карагайлар,—диде Нажар абый,—Ак Чишмә шунда гына...»

Кич табында ул инде юньләп утыра алмады, ашамады да. Икенче якка чыгып ятты. Мин аның янына чыктым. Озак кына сөйләшеп утырдык.

Ул зарланмады. Авырта да димәде. Шигырь укыды. Шигырь укыганда аның күзләре балкып-балкып китә, башын арткарак ташлап, чәчләрен селкеп ала, ирләрчә горур, рухи көч һәм акыллы мөлаемлек бар иде анда.

Фильмны декабрь аенда күрсәттеләр. Бик фәһемле, бик хис-тойгылы эшләнгән ул. Үз чоры кешесе. Аның кебек үк дәһшәтле сугыш тәмугын үтеп кайтып, иҗади укытучылык хезмәте белән шөгыльләнгән замандашы турында. Үзе хакында үзе әйтә алмаган сүзләрне дә герое образы аша әйтә кебек тоелды мина.

Ә без бөек шәхес, олуг шагыйрь турында үзе исән чакта юньле бер фильм да төшереп кала алмадык.

Иҗатын барлап утырам. Күпме кешеләрне белгән ул. Күпме кешеләр турында язган. Һәр кеше аңа бер дөнья, бер ачыш булган. Үзе исән чакта бөек лауреатлар, билгеле шәхесләр турында гына түгел, күңел бакчаларын, иҗат кырларын укып, өйрәнеп, яшьләргә дә, башлап язучыларга да аларның иҗатларына да үз бәһасен биргән. Каләмдәшләре иҗатына игътибарлы булган, укыган, аның күз алдында олысыннан алып кечесенә кадәр булган. Ул шигъриятебезнең киләчәге, үсеше турында уйланган, борчылган, җаваплылык тойган.

Минем аны соңгы күрүемдә ул тормыш белән тулы кеше иде.

Җыр хакында сүз чыкты һәм ул:

«Иртәгә минем яныма Дүртөйледән әнисе белән яшь композитор кыз Гөлнара Нигъмәтҗанова килә. Минем күңелгә аеруча якын булган «Их, ичмасам, еламасаң икән» дигән шигырьгә көй язган, шуны ишеттерә, түземсезлек белән көтәм»,—диде.

Бу йортка чыккач, Әмирхан абый Еники килеп киткәнлеген әйтте. «Рәхәтләнеп сөйләшеп утырдык, олыгайган, нинди талант, гомере озын булсын иде. Күңел теләгән кешеләр ешрак килсеннәр иде»,—диде. Иҗади планнары белән уртаклашты.

«Автобиографик эссе язып ятам, авыр бара, өлгерергә кирәк. Вакыт кыса»,—диде ул авыр сулап.

Минем алда инде 80 яшьтән узган кеше утыра. Ләкин карт кеше түгел, җылы, олы җанлы, бала күңелле, ап-ачык акыллы, яхшы хәтерле, үткер фикерле, дөнья, яшәү, яшьлек, шигърият турында әңгәмәләшә, ирексездән аның эрудициясенә, укымышлылыгына сокланасың, күңел аның картлыгына ышанмый, чөнки аның белән яшьлек арасында чикләр юк, һәр очрашу, сөйләшү саф чишмә суы шикелле күңелләрне сафландырып җибәрә, тирә-якны яхшырак, матуррак итеп күрсәтә, яңа шигырьләр язарга шаукым бирә, чын шагыйрь шундый булырга тиештер дә.

Ике атнадан ул пычак астына ятыр, дип кем уйлаган.

Безгә кузгалырга вакыт иде.

Нажар абый безне озата чыкты. Эргәдә генә әле ныклы матур йорт тора.

«Менә бу йорт минем төп нигез, үзем үз кулларым белән салдым, һәр ниргәсен беләм, анда хәзер нәсел тиешле кеше яши»,—диде.

Ихата, бакча тирәсен күрсәтте. Бакча тулы яшелчә утыртылган... Помидорлар бик күп, алар әле яшел, аны күмәргә килгәндә алар кызарачак...

«Менә кичә кое казып киттеләр. Тиздән су булачак, менә монысы мунча урыны, икенче килүдә кияү белән килегез, мунча кертермен»,—ди, үзе көлә.

Капка төбенә житкәч:

—Флорида апаның чәчкәләрен күрденме әле,—ди. Өй артына алып китте. Анда буйдан-буйга астралар: ак, кызыл, көрән, сары...

Флорида апа. Бу сабыр һәм мөлаем, акыллы шагыйрь хатыны белән бәйле күңелләрдә уелып калган бер күренешне искә алмый булмый.

Нажар абыйның 80 яше иде. Кичәдән соң юбилей банкетында мина каршы биш-алты олы гына яшьтәге ханымнар утыра. Кайсыберләрен таныйм: менә Земфира апа, минем университет укытучым, мәрхүм композитор Нариман Сабитов хатыны, аннан Якуп Колмый абыйның хатыны һәм башкалар.

Кайчандыр ирләре-гаиләләре белән дус булган, бергә шигырь укыган, инде мәрхүм булган язучыларның тол хатыннары.

Алар ялгыз гына, алар сүзсез генә, алар сабыр гына, алар моңсу гына. Нажар абый бөтен дусларын жыю белән бергә (ә Агыйдел рестораны кунаклар белән шыгрым тулы иде) үзенең инде мәрхүм булган дусларының тормыш иптәшләрен дә чакырырга күңел кинлеге, юмартлык тапкан.



*Шагыйрьләр—Дилә Булгакова, Нажар Нәжми, Халисә Мөдәррисова. Уфа 1998 ел*

Ул көнне Флорида апа кунак карап арыган, ләкин аның бәхете тулы иде.

Ә «Нефтьчеләр» сараенда Нажар абыйны соңгы юлга озатканда Флорида апа шагыйрьнең баш очында кайгыдан башын игән, ә бер читтәрәк шул ук юбилейда катнашкан тол хатыннар Флорида апага да үзләре тирәсеннән урын биргән шикелле, шомлы тынлык саклап, сабыр гына басып торалар иде. Кем уйлаган..?

Койма янында алмагач үсә. «Сез утырттыгызмы?»—дип сорыйм.

«Юк, ди Нажар абый,—мин әле утыртачакмын, үз нигезем бит!»

Урамга чыгабыз, машина инде кабызылган, берничә минуттан без аның белән хушлашачакбыз.

«Мине онытмагыз, килеп йөрегез»,—ди Нажар абый.

«Килербез, дим, үзегезне саклагыз, сез безгә бик кирәк,—дим». Ул моңсу гына елмая, кочаклашып хушлашабыз, машина кузгала.

Нәкъ бала чактагыча: картатаем мине озатып чыга да, күздән югалганчы карап кала иде.

Нажар абый да ерагая, япа-ялгызы урам уртасында безне борылышка кереп югалганчы кул болгап озата.

Ул бик үк гади булмаган ике гасыр арасын тоташтыручы да, аеручы да, алтын багана, ак жилкән, якты маяк булып басып кала.

Ап-ак чәчләре чорыбыз шигъриятенең намусы, өмете, ышанычы кебек жилдә тирбәлә.

**Халисә МӨДӘРРИСОВА**

Тағіх
Тарих

# ИЖ–БУБЫЙ МӘДРӘСӘСЕНӘ 220 ЕЛ

**2001 ел татар мәгарифе тарихына бәйле күп кенә истәлекле даталарга бай. Шуларның берничәсе данлыклы Иж-Бубый мәдрәсәсенә карый: бу елда авылда мәдрәсә барлыкка килүгә 220 ел, мәдрәсәгә яңа сулыш биргән мөдәррисләрдән Гобәйдулла Бубыйның тууына 135 ел, Габдулла Бубыйның тууына 130 ел тула. Ниһаять, мәдрәсәнең патша хөкүмәте тарафыннан юк ителүенә дә 90 ел.**

Билгеле булганча, XIX гасыр азагы—XX гасыр башы, «Татар ренессансы» исемен алган чор, татар халкы тарихында аеруча игътибарга лаек. Бу чор Р. Фәхретдин, Г. Баруди, Ф. Кәрими, Г. Исхакый, С. Максудилар шикелле бик күп олуг затларны мәйданга чыгарды. Бу мәшһүр затлар арасында Нигъмәтуллин—Бубыйлар гаиләсенең дә кабатланмас тарихи урыны бар. 1895—1911 елларда бу гаилә туган авыллары Иж-Бубыйны бөтен Русиядә дан-шөһрәт казанган, төрки-мөселман дөньясында зур абруйга ия булган белем учагына әйләндерде, һәм, Мөхәммәт Мәһдиев сүзләре белән әйткәндә, «Әгерже янындагы кечкенә генә татар авылы егерменче йөз башы Россия тарихында метеор кебек ялтырап алды».

XX гасыр башында татар белем учакларының иң күренеклесе булган Иж-Бубый мәдрәсәсе дисәк,—Габдулла Бубый искә төшә. Моның шулай булуы табигый хәл. Чөнки мәдрәсәнең даны аның мөдәррисенең абруе белән бик тыгыз бәйләнештә булган. «Безнең татарларда бит, мәдрәсә—имам, имам һәм мәдрәсә, болар арасында ул кадәр күп аерма түгел, аз гына бер аерма да юк»,—дип ассызыклый Г. Бубый үзе дә «Бубый мәдрәсәсенең кыска тарихы» дигән кульязмасында. Ә Иж-Бубый мәдрәсәсен яңартып төзүгә төп рольне нәкъ менә Габдулла Габделгаллэм углы Нәгъмәтуллин-Бубый (1871—1922) уйнаган. Ул гына да түгел. Гомумән, XIX гасыр азагы—XX гасыр башындагы татар халкының рухи, дини, мәдәни тормышында Габдулла Бубыйның эшчәнлеге һәм мирасы үзенчәлекле урын алып тора. Ул гомере буена үзенең педагогик һәм дини мәсләгенә тугрылыклы, көчле һәм какшамас рухлы булып кала алган, армый-талмый татар мәгарифен үстергән затлардан.

Шулай булса да, әгәр Габдулла Бубый бер үзе генә булса, гаиләсенең ярдәменә һәм хәерхаһлыгына таянмаса, аның бу олуг хезмәте уңышлы булыр иде микән? Иж-Бубыйны чын мәгариф учагына әверелдерү өчен Бубыйларның һәрберсе җанын-тәнен кызганмыйча эшләгән. Бубый мәдрәсәсе—алар гаиләсенең уртак җимеше, аларның хыял-омтылышларының нәтиҗәсе. Тирә-юньдә «гыйлемгә мәхәббәт, голәмага ихтирам, шәкертләргә яхшы тәрбия» бирү белән абруй казанган бу гаиләнең һәр әһеле мәдрәсәләрен чын уку-укыту үзәгенә әйләндерү өчен бар көчләрен куйган, милләткә хезмәт итүне шушы юлда гына күргән.

Йөз елдан артык тарихы булган мәдрәсәдә үзгәрешләр ничек башланган? Бубыйларның һәрберсенең бу эшкә керткән өлеше нинди булган? Бу һәм башка күп кенә сорауларга җавапны Габдулла Бубыйның Казан дәүләт университеты китапханәсендә саклана торган дүрт томлык кульязмаларыннан табып була. Аларның «Бубый мәдрәсәсенең кыска тарихы» исемле әсәренең бер өлеше 1999 елда «Бертуган Бубыйлар һәм Иж-Бубый мәдрәсәсе» дигән җыентыкта басылып чыкты. Ләкин башка әсәрләре әлегә кульязма хәлендә кала бирә.

Габделгаллэм хәзрәт гыйлемгә, белемгә омтылучан, шәкертләрне укытуны

өстен куючан мөдәррис була: «Безнең әткәй, башка күп мөдәррисләр кебек кунакка йөреп, шәкертләрне буш калдырмас, уку елы дәвамында башка авылларның һичберсенә кунакка чыкмас, [...] һәм башка бик күп мәдрәсә шәкертләре ике-өч көндә, хәтта атнасында бер дәрес белән ятканда, безнең әткәй шәкертләрне көнлек бер дәрестән бер дә куймас, вә шулай була торып үзе мәсҗидтән, биш вакыт намаздан һичбер сәбәп белән калмас, ләкин шәкертләрне, хәтта безне дә мәсҗидкә йөрегез диеп һичбер вакыт көчләмәс иде. [...] Диндар, бик тәкъва иде».

Гобәйдулла һәм Габдулла мәхдүмнәрнең формалашу чоры—XIX гасырның 70-80 еллары, ягъни татар әдәбиятына, иҗтимагый фикеренә мәгърифәтчелек идеяләре үтеп керә башлаган заман. Яңа әсәрләр исә белемгә, фәнгә омтылуның кирәклеген исбат итә, иҗтиһад итәргә чакыра. Буш вакытларында кулыннан китап, каләм төшермәгән хәзрәт, әлбәттә, бу әсәрләрне укый, уйлана. Бигрәк тә Ш. Мәрҗанинең һәрбер әсәрен, И. Гаспралының «Тәрҗеман»ын, хәдис китапларын, төрек гәзитәләрен яратып укый торган булган. Мондый халәттә үскән-тәрбияләнгән мәхдүмнәр дә шул ук китап-гәзитәләрне укыганнар, шулар йогынтысында аларның карашлары, фикерләре формалашкан. Габделгаллам хәзрәт йортында дин-диянәт, уку-укыту, мәгърифәтнең торышы турында барган кинәш-бәхәсләрне тыңлау да аларны киләчәк хезмәтләренә хәзерләгән.

Кечкенәдән гыйлемгә, белемгә омтылышлары тәрбияләнгән зирәк малайлар, башка бик күп иске мәдрәсә шәкертләреннән аермалы буларак, шактый мәгълүматлы, укымышлы булып үскәннәр, үзләре укый торган мәдрәсәдә «бик яшьли дәрес әйтергә» тотынганнар: бер яктан, әтиләренә укытуда булышсалар, икенчедән, үзләре укыту ысулларына өйрәнгәннәр, шәкертләр тәрбиясе, мәдрәсәләр хәле хакында уйлана башлаганнар. Шулай аларны иске мәдрәсәләрдәге тәртипләр, анда алып була торган белем дәрәҗәсе канәгатьләндерми башлаган. Дөньяви белемнең кирәклеге дә ачыла барган.



*Гобәйдулла Бубый, хатыны Нәсимә һәм уллары Фидан белән Зыяи. Сарапул, 1912 ел*

«Дөньяви белемгә омтылучы һәм рус уку йортларына керү мөмкинлекләре булмаган шәкертләрне,—дип яза Җ. Вәлиди,—төрек гимназияләрендә һәм укытучылар семинарияләрендә генә җылы кабул итәләр иде». Янарыш чоры кичерүче Төркиягә 1890 елда белем алырга юнәлгән «беренче карлыгачлар» арасында Гобәйдулла мәхдүм дә булган. Габделгаллам хәзрәттән шактый зур тәвәккәллек һәм чыгымнар да таләп иткән бу адым хәзрәтнең хөр фикерле яналык тарафдары булуын да күрсәтә. Габдулла мәхдүм исә әтисе мәдрәсәсендә белем алуын һәм хәлфәлеген дәвам иткән. Абыйсы җибәргән китаплар аша ул заманның күренекле гарәп һәм төрек реформаторларының әсәрләре белән танышкан. Габдулла мәхдүмгә бу елларда бигрәк тә зур йогынты ясаучылар—«Тәрҗеман» гәзитәсенең нашире һәм мөхәррире Исмәгыйль Гаспралы, Каһирә галиме Мөхәммәт Габдеһу, төрек язучысы һәм галиме Әхмәт Мидхәт (Мидхәт паша), шагыйрь һәм философ, 1876 елгы төрек конституциясе авторы Нәмык Кәмал һәм башкалар булган.

1895 елда җәдидчелекне маяк итеп куйган 24 яшьлек Габдулла мәхдүм имамлыкка указ ала һәм, җиң сызганып, эшкә керешә: «Мин, ибтидаи балаларга ысуле җәдид мәктәбе ачмакчы булып, Миңнешәех Фәттахетдин углы Галимовны Бакчасарайга, Исмәгыйль әфәнде Гаспринскийга ысуле җәдид өйрәнергә җибәрдем һәм, Мөхәммәтҗан хаҗидан (*Иж-Бубый бае.*—А. М.) үтенеп, дүрт сыйныфка зур-зур дүрт бүлмәдән гыйбарәт бер мәктәп салдырттым, аяклы парталар вә кара такталарның һәммәсен хәзерләттем»,— дип искә ала ул үзенең бу юллагы беренче адымнарын.

Аталары Габделгаллэм хәзрәтнең бу башлангычка булган мөнәсәбәтен Габдулла Бубый менә ничек тасвирлый: «Ысуле җәдидне бер дә каршылыксыз кабул кылды, вә үзе бу ысулны вә ничек ислах итү юлын белмәгәнлектән, мәдрәсәдән тәмам ваз кичеп, һәрбер эшне безгә тапшырды, вә сигез ел безнең мәктәп ислахыбызны шатлана-шатлана карап торып, тыныч җан вә тулы шатлык эчендә мәңгелек йортка китте. Ошбу сигез ел эчендә без, мәрхүм атабыз аркасында ислахны инкяр итүчеләрнең тәкфир вә ләгънәтләренә бер дә очрамадык. Чөнки ысуле җәдиднең вә мәдрәсәләр ислахының зарурлыгын вә кирәклеген безнең өчен ул сөйләр, бу хакта һәрбер бәхәсне ул кылыр, вә тирә-яктагы һәрбер имамның остазы вә һәрберсеннән гыйлемдә өстен булганга, берсенең дә авызын ачтырмас иде. Кырык елдан бирле фәкать искечә дәрес әйтеп килгән, искелектән башка һичбер нәрсә күрмәгән бер татар мөдәррисенең ысуле җәдидне һәммә парталары вә кара такталары белән кабул кылуы, вә бер углын Истанбулда сәнәви дүрт-биш йөз сум чыгым тота-тота биш ел «Мәктәбе мөлкияви шаһанә»дә укытуы вә аны тәкмил кылдыруы безнең татар мөдәррисләренең хәл вә халәтен белгән кешеләрне бер дә гаҗәпләндермәслек бер хадисә түгелдер».



*Габдулла Бубый, хатыны Хөсне-Фатыйма, кызлары Галия һәм Ситдыйка. Сарапул, 1912 ел*

Шул ук 1895 елның көзендә, укуын тәмамлап, Иж-Бубыйга абыйсы Гобәйдулла кайта. Ул «ибтидайябезне тәртипкә кертү юлында бик күп тырышлыгын сарыф кылды, вә акрынлап зур шәкертләрне дә укыта башлады»,— дип яза Габдулла Бубый. Агалы-энеле Бубыйлар бергәләп мәдрәсәне үзгәртү юлларын уйлыйлар, планнар төзиләр, программаларын эшлиләр. Бу эштә Гобәйдулланың Төркиядә алган белеме һәм тәҗрибәсе зур роль уйный: ул биш ел дәвамында укыган мәктәп француз укыту системасы нигезендә корылган алдынгы уку йорты була һәм Бубыйларга да үрнәк булып тора.

«Һәрбер эшнең иң элек нигезен яхшы кору зарур булганлыктан, без иң элек мәктәп ислахына да ибтидайядән вә аны тәртипкә салудан тотындык, вә акрын-акрын гарәбият шөгъбәләрен дә үзгәртергә керештек,— дип күрсәтә Г. Бубый.—Асылда, гарәбият шөгъбәләрен берьюлы үзгәртергә тотыну мөмкин түгел, куркыныч иде: чөнки искегә гадәтләнгән вә шунда тәрбияләнүдән башканы күрмәгән шәкертләрне берьюлы тәртипкә кую, хосусан аларны вә һәрбер искене мөкаддәс саный торган аталарын янага рази итү бик мөшкел, шуңа күрә берьюлы үзгәртергә керешкән вакытта гарәбият шөгъбәсенең бөтенләй таралып китүе, андагы бар мулла балаларының качып бетү ихтималы бик якын иде. [...] Без менә шулай иттек иске китапларны

акрын-акрын чыгарырга һәм яңа китаплар белән яңа фәннәрне иплэп-иплэп кертергә керештек». Бу юллар Бубыйларның мәдрәсәне үзгәртү эшенә ни калэр житди һәм уйлап тотынуларын ачык күрсәтә.

Агалы-энеле Бубыйларга тагын бер киртәне жимерергә кирәк була: яңа фәннәрне укыту өчен яңа дәреслекләр дә кирәк, ә алар юк дәрәжәдә. Һәм мөдәррисләр, башка жәдид мөгаллимнәре кебек үк, үзләре дәреслекләр язу эшенә дә алыналар. Гобәйдулла Бубый язган дүрт дәреслек 1898 елда басылып чыга. 1899 елда аның тагын бер, ә Габдулла Бубыйның ике дәреслеге дөнья күрә. Дәреслекләр язуны алар соңрак та дәвам итәләр. Алар язган дәреслекләрдә фән белән дин үзара берләшкән: фәнни төшенчәләрне алар дингә таянып аңлатсалар, дин нигезләрен, киресенчә, фәнни мисаллар белән ныгытканнар. Шуны да ассызыкларга кирәк: мәдрәсәләр өчен яңа булган дөньяви фәннәр кертү белән беррәттән алар дин дәресләрен дә тамырдан үзгәртәләр.

«Иске мәдрәсәләрнең һичберсендә, шулар жөмләсеннән бездә дә, тәжвид белән Коръән укыту бер дә булмаганлыктан, муллалыкка чыгачак шәкертләр намаз дөрес булырлык Коръән укый белүдән дә мәхрүм калырлар иде,—дип тасвирлый Г. Бубый.—Шуның өчен унбер-унике яшәр балаларның тәжвид белән Коръән беләчәкләренә башта һичбер мулла ышанмаган иде. Соңра, имтихан вакытында күргәч, шаклар каттылар, вә ихтыярсыз буларак, «ә», диделәр, «бу ысуле жәдид дигән нәрсәдә яхшы эшләр дә бар икән».

Шулай мөдәррисләр шәкертләрен яңача укуга гадәтләндерәләр: «Шәкертләрдә рух күтәрелүе, фикер ачылуы бик ачык күренә башлады,—дип сөенә остазлары.—[...] Шәкертләр күзгә күренеп алга бара башладылар. Безнең дә шатлыгыбыз артты, ижтиһад вә жәсарәтебезне дәхи дә куәтлерәк кылырга башладык». Бу юллар яңа мәдрәсәдә шәкертләрнең, гомумән, татарларның яңа буыны тууын күрсәтә. Бу яңача фикер йөртүче буын, булачак милләт хадимнәре, үзләренең остазлары белән кулга-кул тотынышып, тиздән яңа тормыш корырга керешәчәк. XX гасыр башында ургылып өскә калыккан татар мәгарифе, ижтимагый фикере, әдәбияты, гомумән, мәдәнияте нәкъ менә Бубыйлар һәм аларның фикердәшләренең беренче карашка күзгә бәрелеп тормаган, ләкин аң үсешен даими алга этәреп барган хезмәте белән булдырылган.

«Бубый мәдрәсәсендә үзгәреш бу дәрәжәгә килеп житә башлагачтын, бездә угыллары укый торган муллалар бик куркышып әткәйгә шикаятькә килделәр,—дип искә ала Г. Бубый.—Ләкин әткәй бик иске вакытларда да дин мәктәпләрендә һәрбер төрле фәннең укылмаклыгын, һәм искедән бирле дәрес китапларының заманга муафыйк янарып, үзгәреп килгәнлеген исбат итәрәк, аларны сүзсез калдырды. Алар әткәй авызыннан үзләреннән киреләренә сөйләнгән хакыйкатьләрдән башка бер сүз дә ишетмәгәч, ихтыярсыз жавапсыз калдылар, әткәйнең вафатына кадәр һичберсе сүз чыгармадылар вә балаларын алып китәргә дә жөсарәт итмәделәр. Әгәр шул вакытта әткәй сәламәт булмаса, алар ихтимал, ихтимал гына түгел, мәгълүм, һәммәсе балаларын мәктәптән алып китәрләр, мәктәп бөтенләй буш калыр, без дә шәкерт булмагач, кемне укытасың, мәктәптән, укытудан ваз кичәргә мәжбүр булыр идек. Алар әткәйнең вафаты соңында да балаларын алып китәргә теләп-теләп карадылар, ләкин ул вакытта инде балалары, күп нәрсәләр укып, фикерләре ачылганлыктан, аталарына бирешмәделәр».


Бу урында мөхтәрәм Хәсән ага Туфанның остазы Зыя Кәмалига багышлап язган шигыреннән бер өзек китерергә булдым. Бу юлларны, һичшиксез, Бубыйларга карата да әйтеп булыр иде. Менә алар:

Гарәп теле сәгатьләрендә дә
Фәнгә күчереп дәрес темасын,
Жаныбызга фикер хөрлегенең
Орлыкларын салып куйгансың.

Мәгърифәтләү иде төп теләгең
Инородец иллар баласын.
Сиздең микән үзең бу мәгърифәт
Безне кая алып барасын?..

Ирләр мәдрәсәсендәге үзгәрешләрнең уңышлы баруына ышангач, Бубыйлар кызлар мәктәбен торгызырга тотыналар. Бу вакытта алар инде өйләнгән, туганнары Мөхлисә абыстай да Иж-Бубыйга кайткан була. «Әткәй исән

вакытта ук,—дип яза Г. Бубый,—без кызлар мәктәбен дә ислах кылырга кирәштек. Һәм туганым белән икәүләп, шул кызлар мәктәбенә кайбер дәресләргә дә керә башладык. *(Гаҗәеп факт: XIX гасыр азагында, кызларны укуязуга өйрәтү дә хәрам саналган заманда, ике яшь мулла, кызлар мәктәбенә кереп, дәрес бирә! Бу хәлнең кечкенә бер татар авылында булуын да онытмыйк! Мондый манзараны күз алдына китерү дә кыен!—А. М.).* Әткәй боларның һичберсенә каршы тормады, киресенчә, безне хуплады, безгә рәхмәтләр укыды, догалар кылды. Вә шушы максатны искелеккә каткан вә һәрбер искене, хәтта иске киемгә кадәр, изге санаган муллалардан яклады».



*Иж-Бубый кызлар мәдрәсәсе (дарел мөгаллимат) 1908—1910 еллар*

Кызлар мәдрәсәсен булдыруны әниләре Бәдрелбәнат абыстай да яклый. «Үзенең дә әткәй аркасында фикере хөр булганлыктан, безнең кызлар мәктәбенә керүебезгә вә аны ислах кылуыбызга әнкәй бер сүз дә әйтмәде. Бәлки, киресенчә, безнең бу эшләребезне яклады, һәм үзе ул бик карчык вә бик тәкъва булып, кара халык тарафыннан гына түгел, бәлки тирә-яктагы бар муллалар тарафыннан да изге саналганнан, без аның бу яклавыннан вә бу игътибарлыгыннан бик зур файда иттек. Белер-белмәс вә шуның өчен каршылык кылучан күп кешене: «Әнкәй бар эшебезнең өстендә бит, әгәр шәригать буенча дөрес булмаса, ул ирек бирмәс иде» дип кенә туктата идек»,—дип искә ала Г. Бубый.

«Русиядә иң ислах кылынган вә иң элек мөгаллимәләр чыгара башлаган кызлар мәктәбе менә шушы Бубый кызлар мәктәбедер. Без үзебез дә бу мәктәптә тәртип күрсәттек, ысул вә системаларны карадык. Һәр көнгә икешәр сабак та бирдек. Ләкин бу мәктәптә тәмам җаннары, тәннәре белән эшләүчеләр, һәрбер рәхәтләрен шушы мәктәпнең алга китеше өчен фида кылучылар безнең тума кардәшебез Мөхлиса Бубый белән абзыйның җәмәгате Нәсимә вә минем җәмәгатем Хөснефатыйма булдылар,—дип ассызыклый Г. Бубый.—Болар өчесе дә кич буенча бездән дәрес укый, көн буенча мәктәптә укытырлар вә күрмәгән кеше бер дә ышанмаслык мәшәкатьләр чигәрләр иде. Болар Русия хатын-кызларын гыйлем вә мәгариф юлына кертү өчен иң начар вә иң кабәхәт сүзләр ишетә-ишетә һәрбер төрле бәла вә авырлыкларны йөкләделәр, вә бер тиен айлыксыз, фәкать милләт өчен дип, бик зур адәмнәр кыла торган хезмәт вә тырышлыкларны кылдылар».

Мәдрәсәнең уңышлары хакындагы хәбәрләр хакимият органнарына да барып житә. Һәм 1903 елның 23 ноябрендә Вятка губернасының халык мәктәпләре директоры Н. Меньшиков махсус Иж-Бубыйга килә. Үзенең отчетында ул мәктәптәге тәртипләр, укыту эшенең куелышы, шәкертләр һәм укытучылар хакында мәгълүматлар бирә. Отчетта мәдрәсәнең һәрберсендә өчәр ел укытыла торган дүрт бүлектән торуы, мәдрәсә курсын тәмамлаучыларның имам була алулары, ләкин башта өч ел дәвамында Иж-Бубыйда хезмәт хакы алмыйча укытырга тиешлекләре, мондый укытучыларның (хәзерге термин белән әйткәндә, стажерларның) унике кеше булулары да күрсәтелә. Бу мәгълүмат, бер яктан, Бубыйларның мәдрәсәләренә укытучы табу проблемасын ничек уңышлы чишүләрен аңлатса, икенчедән, остазлары кул астында өч ел тәҗрибә туплаган яшь муллаларның мөстәкыйль мөмкинлекләре киңәюен дә күрсәтә.

Инспектор ишек алдында булган күпчелек шәкерт һәм мөгаллимнәрнең русча шактый иркен сөйләшүләренә, ләкин мәдрәсә турында сорашуларга җавап бирергә теләмәүләренә игътибар итә. Бертуган Бубыйлар хакында ул:

«Ике мулла да русча бик яхшы сөйләшәләр. Белемне үз мәдрәсәләрендә алганнар, бик укымышлылар»,—дип яза. Мөдәррисләрнең мәдрәсә белән теләмичә генә таныштыруларын да күрсәтә. Шул ук вакытта Н. Меньшиков, күргәннәренә таянып: «Иж-Бубый мәдрәсәсендә укыту эшләренең куелышы башка мәдрәсәләргә караганда шактый күпкә югары, шуна күрә рус-татар мәктәпләре укытучылары аны мөселман академиясенә тиңлиләр»,—дигән нәтиҗә ясый.

Шулай, зур саклык һәм тырышлык белән, Русиянең караңгы бер почмагы саналган Вятка губернасында XX гасыр башына моңа кадәр татарларда күренмәгән система, программалары, дәреслекләре белән егетләр һәм кызлар өчен мәктәпләр комплексы барлыкка килә. Һәм Иж-Бубыйның даны еракларга тарала башлый. Русиядәге беренче революция елларында монда укучылар төрле төбәкләрдән җыела: Мәскәү, Казан, Уфа, Сембер, Әстерхан, Ташкент, Петропавел, Сәмәрканд һ. б. җирләрдән килеп укучылар күбәя.

Мәдрәсәнең даны таралуга Г. Бубыйның җәмәгать эшлеклесе һәм ялкынлы публицист булып мәйданга чыгуы да ярдәм итә. Ул XX гасыр башында «Хакыйкать яхуд тугрылык» исеме астында егермедән артык очерк яза. Аларның беренче җиде кисәге 1904—1906 елларда Казанда нәшер ителә. Башка очерклар, сигезенче өлеше, басылып, Казан губернаторы тарафыннан тыелгач, басылмыйча кала. Шулай булса да, революция елларында «Хакыйкать», кулдан-кулга күчерелеп, яңалыкка омтылган яшьләр арасында гаять зур популярлык казана. Г. Бубый үзенең дини мәсьәләләрдәге җәсарәте белән яңа фикере ачылып килә торган яшьләрне хәйран итә иде. Иске голяманың авторитетын югалту һәм иске мәдрәсәләрне туздыруда моның кадәр зур тәэсире булган, белмим, икенче бер әсәр бар микән?—дип ассызыклый Бубый шәкерте, күренекле галим Җамал Вәлиди.—Читтән укырга килүчеләрнең бик күбесе, мин үзем дә шул җөмләдән, әлеге «Хакыйкать»ләрне укып, андагы фикерләрне иясенең үз авызыннан алырга дип килүчеләр иде».

Үзенең азатлык җилләре, хөр фикерләре белән килгән революция татар яшәешендәге үзгәрешләргә дә зур этәргеч була. Революция елларында татар мохитына кергән яңалыклардан һәм хакимиятнең кайбер законнарны йомшартуыннан файдаланып, бертуган Бубыйлар мәдрәсәләрен камилләштерү эшен дәвам итәләр. Яңа программалар хәзерләнә, яңа фәннәр кертелә. 1903 елдан җәй айларында шәкертләрен русча укыта башлаган мөдәррисләр 1904 елның көзендә, «вәкыф хисабыннан русча бер мөгаллим алып, русчаны мәктәпнең програмы эченә» кертәләр, ә 1905 елда Сарапул земствосы тарафыннан Иж-Бубыйда бер класслы рус-татар мәктәбе ачтыруга ирешәләр. Ләкин бу аерым мәктәп булмый, ә «русча мөгаллимнең вазыйфасын земство өстенә» йөкләү була. 1907 елда кызлар өчен дә шундый ук эш башкарыла.

1908 елның җәеннән башлап, Иж-Бубыйда өч айлык мөгаллимнәр һәм аерым мөгаллимәләр курслары эшли башлый. Өч җәйдә (мәдрәсә ябылганчы) 168 мөгаллим һәм 106 мөгаллимә бу курсларда белемен арттыра. «Болар педагогикадан башка яңа фәннәр укып та бик файда кылдылар, килгән мөгаллим вә мөгаллимәләр һәммәсе бик риза вә бик шат булып киттеләр. Бәс, бара-бара Бубыйның бу җәйге сыйныфы тагын да куәтләнәчәк иде, ләкин 1911 елны бездә тотылдык, мәдрәсә дә ябылды,—дип уфтана Г. Бубый.—Шулай да башка җирләрдәге җәйлек мөгаллимнәр курсы, хөкүмәт тарафыннан ябылган вә рөхсәт сораган адәмнәргә рөхсәт бирелмәгән хәлдә, Бубыйныкы, без бер дә рөхсәт сорап азапланмаганлыгыбыздан вә хөкүмәт күзеннән мөмкин кадәр яшеренергә тырышканга, өй җәй тоташ дәвам итте».

Әйе, менә шулай милләтне агарту өчен тырышып ятканда, Бубыйлар гаиләсе өстендә кара болытлар куера башлый: бер яктан Ишми ишаннардан «Бубыйда хөкүмәт зарарына укыталар» дип донослар китсә, икенче яктан хөкүмәт даирәләре 1910 елның гыйнварендә эшләгән махсус киңәшмәдә, татар мәктәпләрендә барган үзгәрешләрне туктатырга тырышып, кадим мәктәпләрне генә хөкүмәт өчен файдалы дип табалар. Һәм яңа мәктәпләрне, аеруча Бубый мәктәбен «татарлар арасында гыйлем һәм мәгариф тараталар, фикер бирәләр, мәгълүматлы имам вә мөгаллимнәр житештерәләр» дип ачуланып, аларда фән укыттырмаска, фәкать дин генә укыттырырга дип карар чыгаралар.

1911 елның январендә данлыклы Иж-Бубый мәдрәсәсе тар-мар ителә, агалы-энеле Гобәйдулла һәм Габдулла хәзрәтләр кулга алына. Бубыйлар тормышының фаҗигале чоры башлана. Ләкин 15 ай буена хөкем көтеп, Сарапул төрмәсендә ятканда да, суд залында да, хөкем карарын үтәп, янадан 6 ай төрмәдә утырганда да Бубыйлар төшенкелеккә бирелми, мәдрәсәләрен яңадан торгызу хыяллары белән яши.

1913 елның 9 февралендә Габдулла Бубый төрмәдән азат ителә. Бубыйлар авылларында эшләрен дәвам итә алмаячагын беләләр. «Абзый белән без кинәшне беркеткән идек,—дип искә ала ул чорны Габдулла Бубый.—Икебез дә Бубыйда калырга, вә ничек кенә булса да шул кызлар мәктәбен алып барырга, хезмәт итәргә, алга җибәрергә. Ләкин кызлар мәктәбе ябылгачтын, без исәпне үзгәрттек, озак кинәшләр иттек, бер уйладык. Мәдинәгә мин барып, мәсҗидләр нәзарәте астында мәгариф җәмгыяте ачарга, хаҗиларны шуңа иганәгә ризалатып, акча җыярга, вә шул акча белән гарәпләр арасында гыйлем-мәгърифәт таратырга. Ләкин безне кайбер сәбәпләр бу уйдан кайтырга мәҗбүр итте. Ниһаять, без карарны бирдек [...] Кытай эченә, Голҗага китәргә, [...] Голҗаны Төркестанда гыйлем вә мәгариф таратыр өчен бер үзәк ясарга...»

Шулай итеп, Иж-Бубыйдагы белем учагы сүнә: «Бубыйның ирләр һәм кызлар мәктәбе заманында тантана белән дәвам кылды, мөкатдәс хезмәтләрен итте, ябылган вакытта да безнең тарафтан бер гаеп белән түгел, бәлки залим хөкүмәтнең золымы, әмере белән, безгә шәрәф бер ябылу белән ябылды. Халык соңыннан ни кадәр иҗтиһад итте, мәктәпләрне ачтырырга йөрде, ләкин өметсез җаваплардан башка һичбер нәрсә алырга муафикъ булмадылар». Бубыйлар гаиләсе дә төрле якка сибелә. Беренче булып, кызлар мәктәбе ябылганнан соң, 1912 елның көзендә Мөхлиса абыстай Троицкига китә, анда кызлар укытуны рәткә сала. Аннан соң 1913 елда гаиләсе белән Гобәйдулла Бубый Уфага китә.

Шул ук елның августында, олы кызы Галияне гимназиядә укырга Троицкида, апасы Мөхлиса абыстай карамагында калдырып, Габдулла Бубый, җәмәгате Хөснефатыйма һәм кече кызы Ситдыйка белән, Голҗага юл тота. Шулай, алар тормышында 4 елга сузылган Голҗа чоры башлана. Бу 4 ел эчендә Бубыйлар үз максатларына ирешәләр: Голҗада да ир һәм кыз балалар мәктәпләре, мөгаллимәләр хәзерли торган дарелмөгаллимәт гөрләп эшли башлый, халыкка гыйлем һәм мәгариф тарату эше җәелә... Голҗада Г. Бубый кертқән тагын бер яңалыкка гына махсус тукталам: башлангыч мәктәптә малай һәм кызларны бергә укыта башлыйлар. Бу башлангычның әһәмиятен аңлату, минемчә, кирәкми.

Иленнән, туганнарыннан аерылып яшәргә дучар ителгән Габдулла Бубый өчен бу дүрт ел чиксез озын, бик күңелсез еллар була. Ул туган якларын, мәдрәсәсен, туганнарын сагына, авылына кайтып мәдрәсәләрне яңадан торгызу өмете белән яши. Аның бу халәтен, уй-фикерләрен Голҗадан язган хатлары ачык тасвирлый.

Укучылар игътибарына Габдулла Бубыйның Голҗадан абыйсы Гобәйдуллага һәм 13 яшьлек кызы Галиягә язган хатларын тәкъдим итәбез. Бу хатларның күчермәсен Г. Бубый үзенең кулъязма җыентыгына керткән (җыентык Казан Дәүләт университетының китапханәсендә саклана.—А. М.). Аларның эчтәлеге укучыларда кызыксыну уятыр, дип ышанам. Минемчә, икенче хат аеруча игътибарга лаек: әтисенең кызын чиксез яратуы, аны ихтирам итүе, аның белән җитди сөйләшүеннән, хатның һәр сүзеннән күренеп тора. Әйтерсең, хат балага түгел, ә тиңдәшенә язылган...

Хатларның күчермәсе теле һәм җөмлә төзелешләре сакланган хәлдә бирелә.

**Альта МӘХМҮТОВА,**
*Казан дәүләт университетының*
*татар халкы тарихы кафедрасы доценты*

## Габдулла Бубыйның абыйсы Гобәйдуллага 1914 ел азагында Голҗадан язган хаты

Мөхтәрәм борадәрем әфәндем хәзрәтләре!

Көннәр уза. Сәгатьләр берәм-берәм кичә. Кошлар һаман йөри, очыша. Айлар йөз тула, йөз бетә. Әмма минем кальбемнән хәсрәтләре, минем эчләремне, бавырларымны өзә-өзә тышка атылган ул ачы аһлар, белмәм, дөньяның бер рәхимле сәгатенә туры килеп, кичәр, бетәр микән?

Мин сине сагынам. Мин синен белән бәрабәр төрмәдә кичердекемез вә синең белән мине ниһаять сез бер дәрәҗәдә якынлаштырган егерме ике ай гомерне өзелә-өзелә сагынам. Безне ихтиярсызлап бергә җыйган, бәйләгән, безне алты йөз житмеш көн төнен-көнен бергә булдырган, вә шул аркада бергә хисабы юк кинәшләр вә күп планнар корырга форсат табылган ул сөйкемсез вакытлар, ихтимал, янадан кайтмастыр, миңа кайтмас кебек тия. Кайтмасын әйдә. Кирәк дәгел. Мин ул ямьсез вакытларның кайтуын эстәмәймен. Ләкин синең белән бергә яткан ул вакытларны сагынам. Бик зиядә сагынам.

Ул таш капчыклар, ул күңелсез озын көннәр, ул ямьсез тавышлы зур тимер йозаклар, ул сөнгеле, мылтыклы ямьсез сакчы солдатлар миңа бер дә кирәк дәгел. Йа Рабби, кайтмасын ул сөйкемсез караңгы көннәр. Ләкин синең белән бик якынлашкан ул мәшьүм *(шомлы)* вакытларны, мәшьүм булса да, сагынам мин, бик зиядә сагынам мин ул вакытларны.

Хәтереңдәме? Төрмәдән беренче дәфга *(тапкыр)* чыгуымызда без икебез дә Бубыйның ул вәйран *(җимерелгән)* мәдрәсәләрен, хисапсыз золым тырнаклары астында изелгән ул мөкаддәс биналарны нә кадәр күрәсемез килмеш, аны күрергә атлыкмыш идек. Бардык. Капкасы йозакланмыш иде, койманың өстеннән кердек. Мәктәп ишекләре йозаклы булганлыктан, эчкә керә алмадык, бакчага юнәлдек. Сирин агачларының төбенә куелган эскәмиянен ике башына икебез барып утырдык. Алдыбызда зур тупыл агачлары белән ихата кылынган зур бер мәйданда, шәкертләрнең жимнастика уйный торган кораллары күренмәктә иде. Сине белмәймен. Әмма мин үзем, мәкъбәрәләр *(каберлек)* кебек бу ихата эчендә, озын бер исәпнең төбенә талмыш идем.

Бу мәдрәсәне бергә идарә кылган вакытларымыз, унбишләп мөгаллим бергә җыюларак, мәктәпләрне ислах вә алга җибәрү, вә шәкертләрне ничек укыту вә тәрбия итү хосусында кыйлган мөнакашә *(бәхәс)* вә мошаварәләремез *(киңәш)*... Һәммәсе фикеремнән, күңелемнән кичте. Белмәймен, күпме, азмы вакыт узды. Колагыма шәкертләрнең гөжләп тәнәфескә чыккан тавышлары ишетелде. Гүя мин, сыйныфта дәрестән чыгып, мөгаллимнәр бүлмәсенә кермеш, шунда утырмыш идем. Шул вакытта мине бу талгынлыктан синең:

—Габдулла! Әйдә. Болыт килә,—дигән калтыраган тавышың уятмыш иде. Син миңа, мин сиңа карадым. Минем дә күзләрем чыланмыш, синең дә күзләрең астыннан тамчы-тамчы яшьләрең агып чыкмыш иде. Җил улай. Тузаннар уйнай. Сирин вә тупыл яфраклары берсенә-берсе бәрелә, шапырдай. Мин үзем бәләкәй вакытымда үз кулым белән утырттыгым, кыйбла тарафындагы зур тирәкнең ботаклары бер бөгелә, бер тора. Тәрәзә түбәсенә күгәрчен тотмага менгән песәйнең койрыгы бер күтәрелә, бер төшә. Мәдрәсә тирәсен әйләнеп чыккан судагы үрдәкләр бакылдай, казлар кагылдай. Әнә! Алар йөгерешә башладылар. Боз ява, боз! Без дә мәдрәсә кырына, күләгәгә йөгердек. Шул арада син җирдән бер таш алдың да: «Менә сиңа, залим, ерткыч»,—диеп, тәрәзә түбәсенә ыргыттың. Таш вәйран мәдрәсәнең тәрәзәсендә тагы бер тишек ясап, эчкә очты; песәй күзләрен яшелле-зәңгәрле итеп, мәдрәсәнең түбәсенә качты...

Син ничек уйлайсың? Шул Бубый мәдрәсәләренең гөжләп торган иске вакытлары янадан безгә бервакыт кайтып күренер микән? Кайтмастыр. Мин ышанмаймын, кайтмастыр. Ләкин кем белә тагы? Заман да бик дәһшәтле, вә бер дә көтелмәгән, зур инкыйлабларның булмассызлыгына кемнәрнең кәфил *(гарантия бирүче)* булганы бар? Менә бөтендөнья сугышы кәмаль *(тулы)* куәт

белән дәвам кыйлып ята. Ике йөз елдан, хәтта өч йөз илле елдан бирле бөтен галәме Исламның канын эчеп симергән, вә ниһаять безне дә—Бубый мәктәпләрен дә—өзеләчәк тырнаклары астында изгән-бетергән инсафсыз залимнәр өстенә Аллаһының утлы, каһәрле куәтләре агып килде. «... Вә ләү лә дәфгулләһи әннәсә бәгъдәһүм би бәгъдил-ләфәсәдәтил әрдү...» *(«Бакара» сурәсе, 257 аятьтән.—А. М.)* дигән аяте кәримәнең мисдакынча *(дәлил)*, каннары фәсәд белән маяланган фәсадчы *(кан алучы)* милләтләр һәрбер тарафта җиңелде...

Мин уйлаймын: безем җиремезне фәсәд вә золым белән тутырган бу каһәрле кавемнең өстенә атылып яткан бу яшен кебек уклар, вә бу җәһәннәм кебек ашаучы утлар әллә безне бу сәфил *(хур кеше)* вә бәхетсез хәлемездән коткару өчен микән? Бик ихтимал бит, бу өмидсез вә рәхимсез куәтнең безнең әтрафымызны чолгап алган карангы болытларны куу вә безнең өстемездә очышкан бәла камчыларын сындыру, бетерү өчен Аллаһы Тәгалә тарафыннан махсус, юри җибәрелүе...

Бу вәхши, канлы сугышлар соңында галәме Исламга бәрабәр сәгадәт капкасының ачылмассызлыгына кемнәрнең сүз куешканы бар? Бу күкрәгән туп тавышлары, бу яшеннән дәһшәтле әсәрле утлар безне фәлях *(бәхет)* вә нәҗатка (котылу) чакырган бер сәда дәгел микән? Кем белә? Бу күкрәгән куәтләрнең бәрелешүләре, безгә дәүләт вә сәгадәт ягъмурын яудырырга хәзерләнгән болытларның яшеннәре, сагыйкалары *(яшен сугу)* булмасын?..

Мин сине бик зиядә сагынам. Менә бу хатымны да мин сиңа тулып түгелгән күз яшьләрем эчендә язып ятамын. Бу хатым өстендә күренгән таплар шул минем тирән тәэсирәтемнән кайнап аккан хәсрәт бөртекләредер. Үзем дә белмәймен, аптырыймын, нигә мин сине бу кадәр өзелә-өзелә сагынам микән? Ахрысы, картаям бугай.

Ихтимал, Голҗаның бу кадәр ямьсезлеге, мондагы хәятның мәдәнияттән ерак, үлем кебек бер сөкунәт *(тынлык, хәрәкәтсезлек)* эчендә кичмәклеге дә миңа яман тәэсир кыла, мине сагындыра торгандыр. Мондагы хәят, хәят дәгел бу, кабер бу, үлем бу. Голҗаның әтрафында ап-ак карлар табәкасы *(катлау)* астында калган ул болытлардан биек таулар миңа кәфенгә уралган гүҗлар, гыйфритләр кебек күренә...

Мин монда милләтемә кыйлып яттыгым хезмәтләр ләззәте белән генә бераз үземне-үзем юатам. Ләкин монда ул хезмәтләремә дә каршы торучылар юк дәгел, күп. Мәдрәсәләрне алга җибәрәбез диеп йөргән кешеләрнең минем ислах эшенә каршы килүләре, мөгаллимләргә махсус эшләргә катышулары мине ниһаятьсез дәрәҗәдә өзә, яндыра мине, көйдерә. Хәтта мин вакыт-вакыт бу мәктәпләрне бөтенләй ташлап чыгарга да житешәм. Ләкин мине бу мәктәпләргә бик нык бәйләп торгыза шуларда укып яткан милләтем балалары. Мин аларның истикъбалын *(киләчәк)* уйлаймын, кызганам, шуннан соң бөтен җәсарәтем *(кыюлык)* кырыла да китә, чыгып китәр хәлләрем югала.

Белмәм, шулай да мин монда озак түзеп тора алырым микән? Хәзерендә минем сенерләрем бик зәгыйфьләнгән, бик зиядә гасабилашып киткәнмен. Балалар укытып гомер уздырган һәрбер кешенең исәрләнүе билгеле бит. Хәзерендә мин дә шул бетәсе дәгел исәрләрнең берсе. Бер дә юкка ачуланам. Әллә нидәй хыялларга чумам. Бу сугышлар соңында Русиядә зур бер хөррият була калса,—мөгаен, булачак,—безгә укытырга, мәктәпләр ачарга ирекләр бирелсә,—әлбәттә, биреләчәк,—Бубый мәктәпләрен ачарга имкян табылса,—шөбһә юк, табылачак,—ул вакытта мин монда бер дә тормам, кайтырмын. Бубыйдагы ирләр мәктәбен дәгел, кызлар мәктәбен ачармын, шунда русчаны да мөкәммәл кертеп, кызларны һәм мөгаллимә, һәм учительница итеп чыгарырга иҗтиһад кыйлырмын. Ул вакытта мелла абыстай да Троицкидан кайтыр. Син, мин—барыбыз, яңадан бергә җыелып, яңадан хезмәт кыйлырбыз, ул вәйран мәктәпләрне яңадан гөрләтербез.

Мин менә шул исәптә. Мин менә бу игълане хәреб *(сугыш турында хәбәр итүче)* тупларына хөррият бәйрәмнәренә сугылган барабаннар диеп караймын. Күрәсең, алай булгач, безгә дә сәгадәт вә бәхтыярлык вакытлары, миңа да бу халкы юньсез, үзе ямьсез Голҗадан аерылу сәгатьләре озак дәгел, бәлки бик якын бит.

Монда сезгә язарлык кызыклы, юньле хәбәрләр юк. Фәкать гарбтә очышкан очкыннарның әсәре монда да күренә: консулның койрыгы бот арасында. Банкының кап-кара директоры белән кабакчы Чиков төн буенча, чәчләрен йолкый-йолкый елап үкереп чыгалар. Карагруһларның борыннары хәзер Габделхәмиднең тәхеттән төшкән көнендәге борыны кебек асылынган...

Монда да хәзер кыш булып бара инде. Голжаның әтрафын чолгап алган биек таулар ак кәфеннәр белән уратылды. Ул кар табәкалары акрын-акрын үсә, җәелә, ниһаять, озакламас, монда, Голжага да килеп житә. Затән монда көз галәмәтләре байтактан дәвам кыйлып ята. Урамнарда йөрер хәл юк, тездән балчык. Бакчалардагы җәй көнендә яшел хәтфәләр кебек куе яфраклар белән уралган агачлар, инде хәзер хаста кешеләрнең йөзләре кебек саргайдылар. Алар көзге җилнең ачы, каты исүеннән берсе дә разый дәгел, һәммәсе сызгыра, зарлана, корып беткән куллары белән әллә кемнәрдән ярдәм эстәй, селкенә. Болыннарда да ямь бетте инде. Ике ай мөкаддәм җәннәтләр кебек күренгән җирләр инде хәзер бер ямьсез, эчпоштыргыч бер чатырманлыктан гыйбарәт булып калды. Әтрафны тутырган аллы-гөлле чәчәкләр сулды. Күнелләргә рәхәтлек вә хушлык бирә торган тәмле исләр инде күптән бетте. Аларны иснәп вә аларга карап кәефләнеп, вә сайрау белән сызгыруларын арттыра торган сандугачлар әллә кая китте. Фәкать каргаларның ара-тирә суыктан зарланган мәэюс тавышлары гына ишетелә. Алар минем сенеремә тия, мине гасабилаштыра, мине өзәргә, мине җәфаларга гына ярай...

Әле монысы табигатьнең генә ямьсезлеге. Әгәр син моның өстенә Голжа белән халкының үз ямьсезлеген дә кушсаң, ул вакытта, йа Раббы, инде Голжадан ничек кенә качып котылырга?

Ләкин монда, кыш көне шул кадәр ямьсез вә күнелсез булса да, һаман да минем күнелемне юата торган нәрсәләр юк дәгел. Беләм, инде син сорарсың: «Нәрсә ул?»—диеп. Нәрсә ул? Мәгълүм. Мәктәп. Парталар арасыннан башларын гына күрсәтеп утырган балалар оясыннан башларын тыгып тезелгән карлыгач балаларына ошай. Аларның мөгаллимнәре тарафыннан бирелгән җимне, остазлары авызыннан чыккан тәмле сүзләрне, түземсезләнеп, көтеп торулары, берсеннән берсе көнләшеп, күнелләренә алырга тырышулары миңа бик кызык күренә. Мин шуның белән юанам, шатланам.

Ләкин мин сине һаман сагынам. Бубыйның ул дәһшәтле мәктәпләре, Иж кырындагы мисалы вә охшашы юк болын вә урманнар, һич бер дәкыйкә минем күнелемнән чыгасы юк. Шулар белән бәрабәр, шуларның җәүһәре буларак, син дә минем күнелдән чыгасың юк. Картайдым, ахрысы, мин, исәрләндем. Бер дә юкларны исәпләймен дә, үземне үзем хафалаймын. Хәерлегә булсын. Хуш, исән бул. Фидаи белән Зыяиның* минем өчен дә күзләреннән үп.

Синең белән бергә кыйлган хезмәтләрне һәрвакыт сагынып вә истикъбальның парлык вә мәсгуд көннәренә ышанып

*Габдулла Бубый.*
*Голжа.*

### Габдулла Бубыйның кызы Галиягә 1915 елның 10 маенда Голҗадан Троицкига язган хаты

Исәнме, сәвекле кызым Галиякәй!

Ананларның китүенә менә инде уналты көн дә тулып узды. Озакламассыз, сез кочаклаша-кочаклаша күрешеп, күзләрегездән тәмле сәгадәт яшьләрегезне агыза-агыза, сүләшерсез, сөенешерсез... Әмма мин!.. Мин бу көнгә кадәр фәкать синнән, бары сине күрүдән, вә сине кочаклый-кочаклый рәхәтләнеп сөюдән генә мәхрүм идем. Инде хәзерендә әтрафымда беренез дә юк... Кая

*Фидаи, Зыяи—Гобәйдулланың уллары.

Ситдиканың сиңа ошаган сәвемле йөзләре? Кая аның синеке кебек соры сөйкемле күзләреннән атылган тәмле карашлары? Кая аның: «Әткәй! Әткәй!»—диеп кычкырган, йөрәкләремдәге бар кайгы вә хәсрәтләрне куа торган татлы сәдалары! Һич булмаса, Фаикъның елау, усаллану тавышы да юк. Ул да киселде...

Хәят диген!.. Моны да хәят диген инде!.. Турысын әйткәндә, бу дөньяның кемләргә генә рәхәт вә сәгадәт күрсәткәне бар микән?.. Белмәм, бу ачы аерылышулар тагы нә вакытларга тикле сузылыр?.. Минем хәят йомгагым, әли әләбәд *(мәңге)*, шушылай тәкърләп, шушылай сүтелеп бармас бит?.. Бармас, мотлакан бармас! Бармас бит, сәвекле Галиякәем?.. Әтрафны бу үлем тынычлыгы белән каплаган бу кабер караңгылыгында бер үзем, бер ялгызым кайчанга тикле җәзаланырга мәҗбүр булырмын микән?.. Кем белә, бәлки безнең дә һәрбер төрле зур имтиязлар вә сәгадәтләр эчендә күрешер вакытыбыз бик тиздер, ихтимал, исәпләгәнемездән дә артык якынрактыр...

Бу көннәрдә мине рус мәэмүрләре Пржевальски белән Яркәндтә дәхи сораштырганнар. Ихтимал, мине, кайтачак диеп, берәр хәбәр баргандыр. Залим шималь карчыгаларының рәхимсез ерткыч тырнаклары кемнәрне каптырмай да кемнәрне, өзгәләп, харап итмәй!.. Ямьсез җәһәннәм җайирлары *(җәберләүче)*! Озакламас, ул агулы тешләреңез суырылыр, ул яман тырнакларыңыз куптарылыр, шайтан суыннан яратылган ул хәбис тәннәреңез аякларның асларында тапталаныр, бу күңелсез кара көннәр кичәр, бу сөйкемсез золым сәгатьләре узар, дөньяда хаклык вә гадәләт мәйдан сөрер, тугрылык вә хөррият хамиларының *(яклаучы)* мөсавәт*(тигезлек)* камчылары сезне җәзалар, тәэдип *(әдәп кылу)* кыйлар... Ух, йа Рабби! Бу шатлыклы минутлар кайчан гына килеп җитәр микән? Кем белә, ихтимал, бу вакытлар бик якындыр. Ихтимал, гарептә туралган бу кадәр адәм итләре бу золым вә истибдадларның *(золым)* бетү шатлыгын истикъбаль өчен суелган корбанлардыр...

Гареп тарафыннан агып килгән бу кара болытлардан нәләргә генә истидлял *(нәтиҗә чыгару)* кыйлырга мөмкин түгел!.. Бу атылган дәһшәтле туплар, бу руслар хиссасына *(өлеш)* куркыныч сагыйкалар *(үлем газабы)*, бу куәтле ягъмурдан куәтле сибелгән ук вә пулялар, беләсеңме, Галиякәем, болар нәләрне, нәләрне генә аңлатмайлар!..

Беләм, син вокзалда әбкәң белән әнкәң, вә Ситдыйка белән Фаикъ янында мине күрмәгәчтен, күз алларың караңгыланыр, сөйкемле яңакларың мәгъсүм яшьләрең белән чыланыр, кальбеңдә кайнаган сагыну утлары иреннәреңне яндырыр, уһлап харежгә *(тышка)* атылыр, ләкин нә эшләмәк кирәк? Мин дә сине сагынам. Мин дә сине күрәсе килү уты белән янам, кавырылам. Ләкин нә эшләмәк кирәк? Залим карчыгаларның тырнаклары астына төшүдән монда, кыен булса да, хөрриятта яшәү артыграк бит.

Вакыйгалар күрсәтә, калебем шаһидәт бирә, озакламас, бик тиз бер вакытның эчендә бик зур хөрриятләр булачак, гомум дөнья мөселманнарына, шулар арасында безгә—шималь төрекләренә дә бик зур сәгадәт вә шатлык көннәре туачак, бер дә исемезгә дә килмәгән дәүләт вә имтиязлар *(хокук тарафыннан)* безне чолгап алачак... Бу минутлар озак түгел инде, килеп житте. Мин әнә шул вакытта кайтырмын, сәвекле Галиякәй. Бубый кызлар мәктәбен ачармын. Бар куәтем белән тырышып, аны дарелмөгаллимат итәрмен. Русча лисанны мөкәммәл укыттырырмын. Аннан чыккан, шаһадәтнамә алган кызларның һәм мөгаллимә, һәм учительница булырларына хөкүмәттән имтияз алырмын. Син, гимназияне тәмам кылып, соңра тәрбия вә тәгълим курсын бетергәннән соң, әнә шул әзер мәктәпне кулыңа алып, идарә кылырсың...

Ух, йа Рабби! Мин әнә шул вакытта, бергә-бергә милләтемезгә хезмәт кыйларак, бик татлы вә бик сәвемле бер хәят кичерергә муафыйк булачагымызны уйласам, бар хәсрәтләремне уйласам, бар күргән вә күреп яткан авырлыкларымны онытам, кальбем шатлыклар белән тибә, күңелем тула, сизмәй дә калам, битләрем жылы яшьләр белән чыланган була. Ләкин монысы хәсрәт яше түгел, бәлки шатлык вә сөенеч яше.

Менә мин сине нидәен зур вә мөкатдәс максат өчен укытам, сөекле ике күзем Галиякәй!.. Шунар күрә син һәр кемдән артык тырыш, һәр

кемдән артык ижтиһад ит. Мин һәм бөтен милләт синнән шуны көтәбез. Истикъбальда кыйлачак бик зур хезмәтләрен голүм вә мәгариф белән зиннәтләнүеңне, бик тәрбияле бер кыз булып житешүеңне лязим вә фарыз кыйладыр.

Ихтимал, бу гыйлем-мәгърифәтләр синең үзеңә бер тиен файда китермәсләр, ихтимал, син шул белүең, аңлавың сәбәпле күп жәфалар вә бик күп кайгы вә хәсрәтләр күрерсең. Ләкин мадам ки *(әгәр шулай икән)* милләт синнән үз башына килгән бәла вә казаларны аңлавыңны эстәй, сине шуның өчен жәфаланырга вә һәр төрле хәсрәт вә бәлаларны юкларга куша. Вә мадам ки милләтнең чирен белү вә аны тиешлесенчә дарулау әсаслы голүм вә мәгарифтән башка мөмкин түгел, алай булгач, сина үз файдаңны түгел, бәлки милләт файдасын карап, шуның өчен тырышырга, вә шуның өчен үзеңне-үзең голүм вә мәгариф белән зиннәтләргә, вә бөтен ибнаи милләтебез *(милләт балалары)* арасында иң тәрбияле вә иң вөжданлы бер кыз булып житешергә ижтиһад итемле син, сәвекле ике күзем Галиякәй!

Курыкма, безнең кабыргаларымызны кимереп яткан бу явыз хәшәрәтләр синең алай камчыларың белән сыпырылыр; безне урап алган бу кара жыланнар безнең башымыздан күтәрелмәгән бу золым таяклары синең ләтыйф *(йомшак гүзәл)* вә ләкин куәтле кулларың белән куылыр, жибәрелер...

Хуш, исән бул, сәвекле Галиякәй! Минем өчен кайгырма. Сәламәтлегем бик жирендә булмаса да, ул каләр зарарлы да түгел. Әзерендә кымыз эчәргә башладым. Куәтем арткан төсле тия. Озакламаенча далага чыгарга торам. Син дә кымыз эч. Саф һавада күбрәк йөрергә ижтиһад ит. Фәкать ирләргә катышма. Әгәр син мин белгәннәрне белсәң иде, әгәр син аларның исәпләрендә береккән тәмсез фикерләрне уйласаң иде, әгәр син аларның кальб сәхифәләрен ачып караячак, шунда язылган әдәпсез, намуссыз жөмләләрне укысаң иде, ул вакытта син аларның йөзләренә лач итеп төкерер, аларның кырына да бармас, янларына да килмәс, мотлакан, качар идең...

Сиңа һәр вакыт хәерхаһ, сиңа һәрбер изгелекне эстәүче вә синең дәүләт вә сәгадәтең өчен һәрбер нәрсәсен фида кыйлырга хәзер сәвекле вә шәфкатьле атакаең

*Габдулла*

---

## 2002 елның беренче яртыеллыгы өчен вакытлы матбугатка язылу дәвам итә

Киләсе елда да журнал укучыларыбыз сурәтләнгән вакыйгалары һәм язылышы белән гаҗәеп кызыклы әсәрләр укый алачаклар.

**Суфиян Поварисовның** “Оҗмахка бер адым”, **Факил Сафинның** “Саташып аткан таң” *(романның икенче китабы)*, **Фоат Садриевның** «Бәхетсезләр бәхете» *(романның икенче китабы)*, **Камил Кәримовның** “Сакау күке”, **Марат Әмирхановның** “Тояк эзе” романнары; **Зәки Зәйнуллинның** “Гарасатлы юллар” повесте, **Айдар Хәлимнең** “Бөркетле баганалар”, **Нурулла Гарифның** “Байлар ничек яши” хикәяләре журнал битләрендә дөнья күрәчәк. Шигырь сөючеләр исә шагыйрьләр **Гамил Афзал, Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев, Равил Фәйзуллин, Әхсән Баян, Ренат Харис, Рәдиф Гаташ, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләм, Лена Шагыйрьҗан, Роберт Әхмәтҗан, Роберт Миңнуллин, Зиннур Мансуров, Газинур Морат, Рифә Рахманның** яңа шигъри әсәрләрен укып куаначаклар.

## ЩЕПКИНЧЫЛАР...

1961 ЕЛДА М.С.Щепкин исемендәге Мәскәү театр училищесының татар студиясендә укыганнарны шулай дип атау гадәткә кергән. Бу сүзне әйтүгә татар театр сәнгате турында ишетеп кенә белгән кеше дә сүзнең нәрсә һәм кемнәр турында барганын шундук аңлап ала. Бүгенге көндә Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрының, гомумән, татар сәнгатенең олы буын артистлары алар. Ринат Тажетдинов, Нәҗибә Ихсанова, Әзһәр Шакиров, Фирдәвес Әхтәмова, Равил Шәрәфиев, Гөлсем Исәнгулова, Наил Дунаев... Ә бит әле артист һөнәреннән китеп, башка өлкәдә эшләп танылган щепкинчылар да бар. Язучылар Туфан Миннуллин, Рабит Батулла, Сәнгать һәм мәдәният академиясе укытучысы Флера Хәмитова, журналист Миргалим Харисов, телевидение режиссеры Әхтәм Зарипов... Бүгенге көндә мәрхүм булганнар арасында кызыклы шәхесләр, чын мәгънәсендә иҗади кешеләр бар иде. Телевидение дикторы Иркә Сакаева, артистлар Дамир Хәйруллин, Мәсгудә Хәйруллина, телевидение режиссеры Клара Газизова...

Кеше хәтереңнең гаҗәеп бер үзенчәлеге бар. Роберт Рождественский әйткәнчә: "...то, что было не со мной помню". Шагыйрь сүзләрендәге дөреслекне мин үз мисалымда да сизәм. Кайсыбакыт китапта укылган хәлләр, кеше сөйләгән берәр вакыйга хәтергә сеңеп кала, күңелнең бер урынын биләп тора, аны үзеңә үлчәп карыйсың, әйләндереп төрле яклап тикшерәсең—һәм ул тәмам синең биографияңдәге факт шикелле кабул ителә башлый. Һәм минә әти-әниемнең яшьлек хатирәләре менеке дә төсле, аларның дуслары, сабакташлары да минем дусларым шикелле...

Мин щепкинчылар–Туфан Миннуллин һәм Нәҗибә Ихсанова гаиләсендә туып-үстем. Әлбәттә, әти-әни үзара да, дуслары белән җыелышканда да студент елларын һәрчак искә төшереп торалар. Кайбер хәлләр анекдот кебек кат-кат сөйләнеп, һәрвакыт яңа детальләр өстәлеп, сөйләүченең мөнәсәбәте аша үтеп шулкадәр минем хәтеремә дә сеңеп калган, урыны һәм вакыты туры килсә мин дә алар хакында сөйлим, үзем ул вакыйгаларда катнашкан кеше кебек искә алам.

Мин гаиләбез Казанның Ватутин урамындагы ике катлы иске агач йортта яшәгәндә туганмын. Хәзер ул өй юк инде, минем барып аның торган урынын гына карап кайтканым бар. Легендар йорт булып истә калган ул. Элек анда ниндидер профессор яшәгән булган. Шул фатир Мәскәүдән театрга кайтып төшкән яшь артистларның патшалыгына әйләнде. Барысы да егетләр, арасында бердәнбер хатын-кыз—әнием.

Зуррак бүлмәдә Ринат Тажетдинов белән Әзһәр Шакиров буйдак хуҗалыкларын җәйләп җибәрәләр. Ринат абый өйләнеп, Мәскәүдән Рәйсә апаны алып кайткач, өчәүләп шул бүлмәдә яшиләр. Икенче бер бүлмәдә патша булып Миргалим Харисов берүзе яши. Ә бер бик нәни бүлмәдә Равил Шәрәфиев урнашкан. Яшәгән дип әйтүе дә кыен, чөнки йоклаганда аның озын аяклары ишектән чыгып торган. Сөйләүләренә караганда, ул бүлмәдә профессорның эте яшәгән. Ә баскычтан менүгә, ишек төбендәге сигез квадрат метрлы бүлмәдә булачак ялкынлы трибун һәм язучы Туфан Миннуллин белән аның хәләл җефете Нәҗибә Ихсанова уртак тормышларын корып җибәргәннәр.

Әтиләр "апартаменты" белән Равил Шәрәфиев хөҗрәсенә бер мич була. Мичнең авызы әтиләр бүлмәсендә булса, арты Равил абыйда. Берсенә төтен, икенчесенә кызу. Бәлки аягын чыгарып ятуы да, Равил абыйның кызуга чыдый алмавыннан булгандыр. Бервакыт әни чак үлемнән кала. Казанга ул вакытта әле

медсестра гына булып эшләүче әнинен сенлесе Хәния апа курсларга укырга дип килеп төшә. Әти өйдә юк икән. Капкачы кубып төшкән мичкә шәп итеп ягалар, жылысы чыгып бетмәсен дип, эшермәсен ябып, әни белән Хәния апа йокларга яталар... Ярты төндә Хәния апа уянып китә, мине тудырырга бер айлап вакыты калган әнине уята. Икесенә дә ис тигән—аннарын югалтып егылалар. Ничек булгандыр, Ходай минем тууымны теләгәндер инде—Хәния апа шуышып коридорга чыга һәм ярдәмгә кешеләр чакыра. Мич жылысында рәхәтләнеп яткан Равил абый аларнын икесен култыклап урамга алып чыга. Ул төннен матурлыгы мина да тәэсир иткәндер инде. Әни сөйләгәндә, минем күз алдымда ачык картина килеп баса—кара төн, ап-пакь күбәләкләр булып кар ява, озын, ябык егетнен ике ягында истән әле айнып житмәгән йөкле хатын һәм яшь кыз. Гомумән, Равил абый минем беренче гыйнвар көнендә туганыма "сәбәпче" дә булган... Яна ел каршылаганда алар әни белән вальс биегәннәр, шуннан сон әнине тулгак тота башлаган. Кичке сәгать дүрттә мин туганмын. Югыйса, әти белән әни исәбе буенча мин 10 гыйнварда гына туарга тиеш булганмын. Равил абый куркып йөргән диләр. Гомумән, Равил абыйга мин бурычлымын. Әти өйдә юк чакларда әнигә ярдәм итеп ул мине учларына салып юындырган да әле. Болар турында сөйләвем шунын өчен—әлеге йортта көн күрүче "щепкинчылар" бер гаилә булып яшәгәннәр. Равил абыйнын әнисе, улы янына күченеп килгәч, ул барысынын да әнисе кебек булган.

Хәзер еллар йомгагын бераз сүтә төшәргә кирәктер. "Щепкинчылар" исеме бит юктан гына килеп чыкмаган, ул студент елларында ук туган. Татар егетләрен, кызларын махсус жыеп, студия дип атап Мәскәүгә жибәргәннәр. Башкала казанында бергә кайнап, уртак фикерле төркем булып оешканнар алар. Камал театры "кан янартуга" мохтаж бер вакытта театр сәнгате серләрен өйрәнәләр. Аларга зур өметләр баглап озатып калган өлкән татар артистларынын ышанычын акларга тырышалар. Кызыгы, уены-көлкесе дә, студент тормышына, бигрәк тә булачак артистлар тормышына хас шаярулар, төрттерүләр—"щепкинчылар"ны болар да берләштерә. Чөнки уртак хәтирәләр кешеләрне цемент кебек бер-берсенә беркетә. Берничә дистә ел бергә гомер иткән парлар да шул уртак хәтирәләре белән бай, бер-берсенә нык береккән.

Беренче курсларда егетләр, кызлар Мәскәүнен үзе белән, андагы мона кадәр күрмәгән, яисә ишетеп кенә белгән тормыш белән ашкынып танышалар. Мәскәүдә анын якын тирәсендә бу тынгысыз татарлар булмаган, карамаган бер почмак та, истәлекле таш та калмагандыр, мөгаен. Музейлар йөреп чыгылган. Әнинен архивында "1956 ел" дип язылып куелган Ясная Поляна күренешләре, анда төшкән открыткалар саклана—шунда да барып житкәннәр бит. Башкаланын данлыклы театрлары турында әйткән дә юк. Театр уку йортларында укучы студентларга керү бушлай, һәм аларбаскычка утырыпмы, берәр почмакка сыеныпмы барлык спектакльләрне карап, бөек артистларнын уены турында башкалардан ишетеп кенә яки кайдандыр укып кына түгел, үз күргәннәрен сөйлиләр. Ә бүген исемнәре классик булган артистлар белән студент еллары үткән. Без аларны бөек итеп кабул итәргә өйрәнгән. Ә менә, кеше ышанмаслык ябык Олег Дальнен баскычтан ике сикерүдә төшеп ашыга-ашыга йөгерүләрен (укыган вакытта ук ул кинога төшә башлаган булган), кечкенә гәүдәле, ләкин бик тә сөйкемле Александр Демьяненконын (барыбызга да мәгълүм Шурик) Иркә Сакаева белән дус булуларын, абыйлы-энеле Соломиннарнын тышкы кыяфәтләре белән генә түгел, холыклары белән дә аерылып торуларын (Виталий горур, башкаларга өстәнрәк карый, укытучысы Анненков булып кыланып күрсәтергә дә тартынмый, ә Юрий бик гади, энесенен кыланышларыннан бераз тартынган да сыман), Тамара Семинанын Катюша Маслова ролен әзерләп йөргәндә гомум кухняда төрмә күренешенә репетиция ясап, итәкләрен күтәреп күрсәтүләрен мин кайдан гына белер идем икән. Әни Василий Шукшинны да яхшы хәтерли. Анын турында сөйли, ә мин күз алдына китерәм, әнә бөек артист ВГИКнын тулай торагында агарып беткән солдат киеменнән төрле студент кулында йөреп төсе танымаслык булып үзгәргән алюмин кәчтрүл тотып, ул үзенә аш пешереп йөри. Инде артист булып эшли башлаган Олег Табаковнын ун баскыч сикереп, мөлаем, сөеп туймаслык "Крылишкиен"—Людмила Крылованы училище коридорлары буйлап эзләп йөрүләре үзем күргән кебек. Бу матур парнын аерылганы турында ишеткәч, мин дә, "щепкинчылар" белән бергә "их" диеп

куйдым. Тагын бер кызыклы деталь–ул заманда бу артистларнын берсе дә бүгенге кебек танылмаган, ә шулай да аларга шул ук вакытта үз сабакташлары ук игътибар иткән, истә калдырган бит.

Студент тормышы кызыклары житәрлек, аларны "шепкинчылар" бергә жыелганда күпләп искә төшерәләр. Гомумән, аларнын бергә жыелуы бик кызык. Бу кичәләр билгесез бер авторнын пьесасын уйнаган төсле. Берсеннән-берсе көләләр, берсенә-берсе төрттерәләр. Бер генә житди тема бар – ул да булса театр. Соңгы шундый "спектакль" әнинен быелгы туган көнендә булды. Мина ул туганнар табынын хәтерләтте. Абыйларым, апаларым, өлкән абыем Марсель абзый Сәлимжанов, этием, әнием...

Алар нәрсәләр искә төшерәләр сон?

Егетләрнен нәни генә стипендия акчасын тартып-сузып та бер айга житкерә алмагач, кызлар бүлмәсенә "кунакка" йөрүләре, ә каршы корпуста яшәгән Иосиф Кобзон, ул заманнарда ябык, кара гына бер егет татар кызлары бүлмәсенә ярты буханка кара ипиен кимерә-кимерә кергәләп йөргән. Ә куертылган сөт безнен өйдә але дә "Мәсгүдә сөте" дип атала. Ә бу исемнен килеп чыгышы болайрак. Әти кызлар бүлмәсенә кереп чәй эчәргә утыра, сыйлыйлар моны. Ә ул өстәлдәге куертылган сөтне күреп, бу нәрсә дип сорый. Аны-моны уйламыйча: "Чәенә салыйк, Мәсгүдә сөте",– дип әйтәләр. Егет кеше, күкрәк сөте дип уйлап, чәен дә эчмичә өстәл янынннан торып китә... Егетләр үзләре дә "туклану программасын" төзеп караганнар. Бу хактагы риваятьләр сөйләнгәндә, күздән яшьләр атылып чыкканчы көләсен. Егетләрнен бүлмәдәшләре белән чиратлап ашарга пешерүләре ни тора! Ринат Тажетдинов тозлы кәбестә ашына бер кашык тоз салган да, үзе дә татып карамыйча өстәлгә китереп утырткан. Наил Дунаев күз дә йоммыйча шул тозлы ашны тәмләп ашаган. Әтинен япон дөгесе бар икән әле. Аны күпләр әкият дип уйлый, ә бу, чыннан да, булган хәл. Бервакыт әти бүлмәдәшләрен искиткеч тәмле ботка белән сыйларга вәгъдә итә. Боткасы да нинди әле—япон дөгесеннән. Хәзер ул сатуда буламы, юкмы белмим, элек ул ясалма саго дип атала иде. Ә ул, бактын исә, дөге түгел, гап-гади крахмал икән. Аны берәмләп кенә кайбер ризыкларга кушалар. Әти аны ике кило сатып ала. Тотына бу



*Сулдан уңга, аскы рәттә: Н. Дунаев, Г. Исәнгулова, Д. Бәдретдин, М. Хәйруллина, Н. Ихсани, Д.Хәйруллин. Урта рәттә: Р. Галиәкбәр, Ф. Хәмит, Р. Тажи, Ә. Зарипов, профессор М. Н. Гладков, СССРның халык артисты Х. Әбжәлилов, Ф. Вәлиуллина, М. Харисов, И. Сакаева.*
*Өске рәттә: Х. Арсланов, Ә. Шакиров, Р. Батулла, Р. Шәрәфи, Х. Закиров, К. Газизова, Т. Миңнуллин, Ф. Хәсәнова, Ф. Әхтәмова. 1961 ел.*

моны пешерергә, бервакыт ботка кәчтрүлгә сыймыйча ташый башлый, аны икенче савытка бүлеп ала... Инде ике савыттан да ботка бүлтәеп чыгып, менә ташыйм дип тора. Китә шуннан тыз-быз йөгерү, тулай тораклагы кәчтрүлләрне җыялар. Ләкин ботка ашарлык булмый—аны чыгарып түгәләр.

Соңгы курсларда ачлы-туклы тормышларын бераз җинеләйтү нияте белән инде Мәскәүдәге тормышка күнеккән, хәтта шомара башлаган "щепкинчылар" төнге эшкә урнашу эмәлен кайгырта башлыйлар. Әти алдатмый, ризыклы урын таба. Ит комбинатына эшкә урнаша. Ичмасам, тамагы тук була. Әни белән Фирдәвес апа "Московская правда" газитәсендә ике ай эшләп алалар, тик бик авырга туры килә — ташлыйлар. Газитәләрне төргәкләргә бәйләп, төрле өлкәләргә җибәрүгә әзерлиләр. Конвейерга борыннарыбыз белән төртелеп йоклап китә идек, дип сөйли әни. Иртән эштән кайтканда, ике кыз ипи кибетенә кереп, "Саратовский калач" сатып алып ашый торган булганнар. Бик тәмле ак күмәч булган ул, гадәттә, сатуда иртән генә булып, көндезгә таба киштәләр бушап кала икән. Ул ипидән дә тәмле әйбер ашаганым юк, ди әни. Мәрхүм Дамир абый Хәйруллинга тузанлы эш эләгә. Ул ниндидер бер төзелештә вагоннан цемент бушата.

Укытучылары турында исә "щепкинчылар" сәгатьләр буе да сөйләргә риза. Һәрберсен яратып, сагынып искә алалар. Студияне җитәкләгән Михаил Николаевич Гладков аларны ин беренче сәхнә серләренә өйрәткән кеше, кайвакыт аны изгеләштерәләр бугай диген уй да туа. Укытучыларынын вафатына кадәр алар гел аралашып тордылар. Гладковлар гаиләсе ел саен Идел буйлап сәяхәткә чыга иде, һәм аларнын теплоходы Казанга туктаган көнне, ару-талуны белмәс Гөлсем Исәнгулова җитәкчелегендәге төркем чәкчәген, чәчәкләрен тотып елга вокзалына ашыга. Килә алмаган, яки белми калганнарны студент чагында староста булуын искә төшереп Гөлсем апа тәртипкә чакыра. "Ничек килә алмадын, ничек белмәден? Мин белдем бит",-дип шелтәли.

Бию укытучысы Евгения Дмитриевна Васильева авыл балаларына классик бию алымнарын сабыр гына өйрәтергә тырыша. Ләкин моны тормышка ашыру мөмкинлеге булмаганын анлагач, группаны ике төркемгә бүлә. Беренчесендә биюгә сәләтле егетләр, кызлар, икенчесендә минем әти кебегрәкләр –биергә сәләтләре чамалыраклар. Һәрберсенә игътибарлы була Евгения Дмитриевна. Ир-егетләрнен барысы да, хәтта минем әти белән Әхтәм Зарипов та вальска әйләнә башлыйлар. Бүген әни шпагатка утырып тамашачыларны шаккатыра икән, ул бит шул дәресләрнен нәтиҗәсе. Ә "Хушыгыз" спектаклендәге биюләрне искә төшерсәк? Ничек матур һәм җинел итеп вальс әйләнәләр бит "щепкинчылар"!

Ә җыр укытучысы Дунаевская "опера" дигән сәнгатьне бар дип тә белергә теләмәгән Туфан Миннуллинны да көчләп үзе белән ияртеп ин яхшы опера спектакльләрен курсәтеп йөртә. Ярәттыра алмаса да, укытучысы ана бу сәнгатькә хөрмәт белән карарга кирәклеген сендереп калдырган. Вокал дәресләрен алып барган Марина Петровна Никольская сабыр гына дөрес җырларга өйрәтә. Әни шул дәресләрдә бик күп романслар өйрәнгән. Камил җырлау ысуллары өйрәнгән "щепкинчылар" музыкаль партияле рольләрне курыкмыйча башкарып килделәр. Табигатьтән матур тавышлы Иркә Сакаева, Флера Хәмитова, Мәсгудә Хәйруллина өчәүләшеп катлаулы әсәрләрне оч тавышка җырлый торган булганнар. Бу дәресләр бер көлке ситуация белән дә истә калган. Марина Петровна Дамир Бадретдиновны романс җырларга өйрәтә. Егет тумышы белән Самара якларыннан, авыл кешесе булса да бик тәкәббер, кыяфәте дә "Отелло"дагы Яго кебегрәк, үзе хакында берниндн тортмәле сүз күтәрми. Димәк, аннан берәр хата китсә, көлергә ярамый, югыйса үзенә аяусыз дошман таптым дип исәплә. Ул рояль янына чыгып баса да, опера җырчылары формасын китереп, бераз чыгып торган иягән тагын күтәрә төшеп җырлый башлый... Тик дөрес нотага эләгә алмый! Кашлар тагын да җыерыла төшә, Марина Петровна: "Нет, Бедретдинчик, давай еще раз",-ди. Тагын сузып җибәрә: "Вижууу горы и долины..." Ләкин барыбер төгәл нотага эләгә алмый. Йөз кат кабатлагач та, укытучы үз теләгенә ирешә алмый. Ләкин студентнын күнелен рәнҗетерлек сүз әйтми.

Илья Михайлович Бычков—фәлсәфә укытучысы... Заманында Аргентинада илче булган. Төрле илләрне, төрле кешеләрне күргән, тормышка карашы китаплагыча түгел. Бәйсез фикер йөртүче шәхес, ул студентлардан да шуны таләп итә. Шуна күрә

дә щепкинчылар туры сүзле, актив позицияле шәхесләр булдылар. Әзһәр абый Шакиров бик күп фидакарьләр белән мәйданнарга чыгып, республикага мөстәкыйльлек даулап йөргән кеше. Бүген язучы, депутат Туфан Миннуллинның иҗатында, гражданлык позициясендә Бычковның роле искиткеч зур. Бик тә сирәк була торган хәл: Илья Михайлович кайбер рус студентлары төркемнәреннән имтихан алуны Миннуллинга йөкләгән вакытлары да булган. Гомумән, ул татарларны бүтәннәргә үрнәк итеп күрсәткән.

СССРның халык артисты Хәлил ага Әбҗәлиловның татар студиясен аталарча кайгыртуы турында да "щепкинчылар" озаклап сөйли алалар. Тамаклары тукмы, өс-башлары житешме, яшәү урыны унайлымы, укуларында нинди уңышларга ирешәләр-барысы да мәшһүр артист игътибары үзәгендә була. Зур артист, танылган сәхнә остасы театрның язмышы турында борчылган. Ә Мәскәүдәге татар студиясе кабул итәлү имтиханнарыннан башлап Г.Камал исемендәге театрда эшләячәген белеп укый, шуна әзерләнә. Шуна күрә дә сәхнә түрен тотучы Хәлил ага театрның киләчәк йөзе турында кайгыртуны үзенең шәхси бурычы дип саный.

Танылган режиссер Габдулла Йосыпов та булачак артистлар белән уку дәверендә үк таныша, гореф-гадәтләр, тел буенча киңәшләр бирә. Соңгы ике елда ул, гомумән, студентлар белән бергә була. Аның бер җөмләсе әле дә афоризм рәвешендә йөри. Ул: "Телегез өстендә эшләгез"; -дип әйтергә яраткан. Студиячеләр аны татарча әйбәт итеп сөйләшегез дип аңлаганнар. Соңыннан театрга кайткач кына укытучының ни әйтергә теләгәне ачыкланган. "Телегез өстендә эшләгез",-дигәне - сүзегезне үлчәп сөйләгез, теләсә ни кычкырмагыз, югыйсә театрда эшли алмассыз дигәнне аңлаткан икән.

Мин аларга кызыгып карап торам. Көнләшеп куям. Алар арасында кызыксыз кеше юк. Димәк, аларны сайлап алучылар алдан күрә белгәннәр, тоемлау көче аларда искиткеч зур булган. Әни кызыклы бер хәлне сөйли. Артистлык осталыгы буенча имтиханның өченче турына житкәч, кыл кебек тартылган күңеле тула, курку баса һәм ул еларга керешә, тәмам хәлдән таеп, тавышы беткәнче үкси. Күз яшьләренә буылып, шешенеп бетеп комиссия каршысына килеп баса. Инде сораганны төгәл үтәп бүлмәдән чыгып киткәч, аның янына Һидаят абый Солтанов килә. "Тавышына



*Сулдан уңга, аскы рәттә: Р. Шәрәфи, Т. Миңнуллин, Г. Исәнгулова, Р.Таҗетдин. Урта рәттә: Ә. Шакир, Н. Ихсани, Ф. Әхтәмова, М. Хәйруллина. Өске рәттә: М. Харисов, Н. Дунай, Р. Батулла.*

шикләнәләр, әйдә әле, кычкырып кара",–дип тавышын сынап карый. Һәм ана ышаналар...

"Щепкинчылар"нын иҗади юллары минем күз алдымда диярлек узды (бу юлы сүз Г.Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында эшләп калган артистлар турында гына). Шуна күрәдер, алар хакында язу мина кызык, чөнки үз фикерем, үз мөнәсәбәтем бар. Барысы турында булмаса да, кайберләре белән сөйләшеп, кайчак гел белмәгән, көтелмәгән яктан аларны ачып бернична язма әзерләгәнем бар. Ә барысы турында бергә язганда, аерым шәхесләргә күчкәнче, "щепкинчы" булып исәпләнмәсә дә, аларнын чордашы, иҗади фикердәшләре, үзләре белән бергә диярлек театрга иҗади житәкче булып килгән Марсель Сәлимжанов турында аерым әйтү кирәктер. Ул аларга дус та, көтүче дә, мактаучы да, чыбыркылаучы да, һәм ин мөһиме, алардан артист ясаучы кеше. Берәүне дә укытып кына артист итеп булмый, театрда кыйналып, кайнап кына ул артист була ала. Театрнын атмосферасын, труппанын йөзен исә баш режиссер билгели. Марсель абый да иҗат үрләрен "щепкинчылар" белән бергә яулады. Һәм "щепкинчылар" монын белән горурланалар. Артистлар чын күнелдән Марсель Хәкимовичны хөрмәт итәләр, әмма өзелеп яраталар дисәм, ул үзе үк миннән кычкырып көлер иде. Мин үзем, артист булмасам да, анын кул астында эшләмәсәм дә, аннан куркыбрак торам. Гөрелдәвек тавышын ишетсәм, үткен күзе белән мине эләктереп алса, "Әни килде" спектаклендәге нәни кыз Рәйхандай: "И, Аллам, нинди мизансцена куяр икән, кайсы якка борылырга кушар",–дип уйлыйм, яки бүгенге Әлфия булып: "Тазаргансын–ябык",–дип әйтүеннән шүрлим.

Инде щепкинчыларнын кайберләре турында аерым-аерым сөйләргә кирәктер. Ин якын кешеләрдән башлау дөрес булыр кебек. Мин аларны бик яхшы беләм бит...

**Туфан Миннуллин.** Ул училищега беркадәр тормыш тәҗрибәсе туплап, дөнья гизеп, чирәм жирләрне күтәрүгә катнашып килә. Үсүзле, кире иканлеген укый башлауга ук белдертә. Беренче курста бөтенесе бергә группалары белән жыелып бәйрәм итәргә планлаштыралар. Октябрь бәйрәме була ул. Өстәлләр әзерләнә, аллэни сый-нигъмәт булмаса да, ач студент өчен шактый мул табын була ул. Жыелып беткәч, Туфан Миннуллин хискә бирелеп, үзе язган шигырьне укый:

Әй, дусларым, бүген бәйрәм көне–
Бәйрәм итик бергә булганда.
Күлмәк тузса, майкалар бар әле,
Вино бетсә, су бар кранда.

Ләкин Казанда туып-үскән кызлар һәм аларга ияреп кергән ят егетләр аны тынларга теләмиләр. Шаулыйлар. Көләләр. Фирдәвес апа Әхтәмова шигырьне укырга теләи, аны да тынламыйлар. Ачуы чыккан эти ике дистә кешегә дип әзерләнгән өстәлдән эскәтерне бар әйбере белән бергә идәнгә тартып төшерә... Шунысы кызык–этине тукмарга дип сикереп торган ят егетләр каршына татар студиясе егетләре килеп басып: "Орынып кына карагыз",–дип этине яклыйлар. Эти һәрчакта үзе белән санлашуны таләп итә. Анын үз фикере бар, һәм ул үз сүзен, башкаларга житкереп әйтә. СССР тарихында "оттепель" дип аталган чорда Мәскәүдә яшәү, уку анын өчен үтә әһәмиятле вакыйга булгандыр. Татар студиясенә татар әдәбиятын укытырга килгән Әхмәт Фәйзи белән очрашуларын, бәхәсләшүләрен һәм Сталин елларынын дәһшәтле сулышын онытмаган шагыйрьнен яшьләрнен сүзләреннән кайчак куркып калуын эти хәзер дә искә төшерә. Беренче мәртәбә калэм тибрәтүләр, беренче "Чаян"да басылып чыккан шигыре дә Мәскәүдәге студент елларына туры килә. Шул еллар аны үз фикерен курыкмыйча әйтергә өйрәткән. Иҗаты, иҗтимагый эшчәнлеге халык язмышы белән сугарылган. Депутат, публицист буларак әйтә алмаганын ул пьесаларына кертә, шуна анын әсәрләре җәмгыятьнен ин актуаль проблемаларын яктырталар, күнелнен ин нечкә кылларын тибрәндерәләр. Әти театр сәнгатен, сәхнәне бик ярата. Камал театрында артист булып уйнаган чагында "Зәнгәр шәл"дәге урман сахнәсендә такта идәнгә сузылып, "учак" янында яту–анын өчен ин югары ләззәт булгандыр. Валлаһи, бу турыда сөйләгәндә, ул күзләрен йома-йома тәмләп сөйли. Шуна күрәдер дә анын иҗаты турыдан-туры театрга бәйле. Әллә ничә төрле театр сәхнәсендә анын дүрт

дистәгә якын пьесасы куелган, "Әлдермештән Әлмәндәр" исә бүгенге көндә халык тарафыннан классик әсәрләр исемлегенә кертелгән.

**Нәҗибә Ихсанова.** Кечкенә генә авылдан, шәһәрнен ни-нәрсә икәнен белмәгән килеш Мәскәү хәтле Мәскәүгә укырга китә. Әнинен бу егетлегенә әле дә сокланам. Анын туган авылында мин дә кунакка кайтып яшәдем. Ул вакытта анда электр уты да, радио да, ерак түгел асфальт юлы да бар иде. Әни чыгып киткәндә исә, ул егерме йортлы "географиядән төшеп калган" авыл булган. Мәскәү кебек зур шәһәрдә, ят мохиттә югалып калмыйча үз асылынны саклап калу өчен аз көч салмагандыр әни. Үз язмышынын дилбегәсен нык тотып, барасы юлын төгәл билгеләп, аннан тайпылмыйча бара белү анын чын-чынлап сокланырлык сыйфатлары. Шушы юлларны язганда, Нәҗибә Ихсанованы кайсы роле белән тәнгәлләштереп була икән дигән уй килде. Барлап чыктым. Һәм нигәдер Нәкый Исәнбәтнен "Зифа" исемле әсәре буенча куелган спектакльнен баш героинясы Зифа искә төште. Чибәр, горур, үз кадерен белүче гүзәл зат. Тик әни бик иртә карчыклар рольләренә күчте, ничә мәртәбә минем белән генә булганда әле, аны урамда туктатып, без сезне бик яратабыз, тик гел әбиләрролендә буласыз, театрда карчык уйнарлык артист юкмыни, диярләр иде. Яшь чагында әнинен әллә нинди алама киемле рольләрдә сәхнәгә чыгуын яратмый идем. Үскәч кенә әнинен характерлы актриса булуын, ролен истә калдырырлык итеп эшләвен анладым. Анын бит карчыклары да бер-берсенә охшамаган, һәрберсе үзенә бер төрле. Әниемнен мине куандырган "матур" рольләре дә бар иде. Шуларнын берсе француз драматургы Бомарше әсәре буенча куелган "Шаушулы көн" спектакле. Мин ана чын күнелдән гашыйк идем. Әниемнен шундый матур графиня булып сәхнәгә "йөзеп чыгуын" күреп кул чаба идем.

**Равил Шәрәфиев.** Мин тугач, ул мине коендырышкан, дидем. Бүген мин читтән генә аны күзәтәм, ничек итеп учында тотып торды икән ул мине? Кайсывакыт шундый якынаеп сөйләшәсе килә, тик ни өчендер килеп чыкмый... Равил Шәрәфиев исеме "щепкинчылар" арасында ин кин танылганы дисәм—кем каршы төшәр икән? Ул театрдагы күп санлы рольләре белән генә түгел, дистә еллар татар эстрадасында эшләве белән дә танылу алган артист. Театр сәхнәсендә уйнаган комик рольләре аша тупланган тәҗрибәсе, халык мәхәббәте татар эстрадасында уңышлы эшләвенә зур бер этәргеч булгандыр. Тик мин Равил абыйнын "Ябырылу" (*Л.Леонов*) әсәре буенча куелган спектаклендәге Федор ролен искә төшерәм. Һәм минем фикеремчә, ул, бәлки, комик артист кына түгелдер. Тамашачы ул сәхнәгә чыккач көлә, ә мин менә үкереп көлүче залны һәм жаны сызлаган Федорны уйнаучы Равил абыйнын өзгәләнгәнен сизеп аны кызганам. Янә бер вакыйга: "Әлдермештән Әлмәндәр"дә бер урында Әҗәл умартадан чыккан, Әлмәндәр шап итеп капкачын япкан күренеш бар. Спектакльләрнен берсендә Шәүкәт абый Биктимеров капкачны Равил абый башын алганчы ук ябып куя. Артист башы Әҗәлнеке түгел бит—авырта, ә сәхнәне барыбер тамашачы сизмәслек итеп уйнап бетерергә кирәк. Ә тамашачы һаман көлүен дәвам итә. Менә шундый эпизодлардан тора ул артист язмышы.

**Фирдәвес Әхтәмова.** "Щепкинчылар" арасында эти-әниемнән кала минем өчен ин якын кешедер. Үземне белгәннән бирле мин Фирдәвес апаны да беләм. Ана мин кушкан беренче исеме "Фи" иде. Күземне йомсам, анын билдән узып төшкән ике толымын күрәм кебек. Атаклы "Сәйдәш йорты"нда безнен күршедә алар Хәлимә апа Искәндәрова белән икәүләп яшәделәр. Шул вакытта да, хәзер дә ул минем белән үз тине белән аралашкан кебек сөйләшә. "Балалар бакчасына баргач ни ашадын" дип соравына мин, имештер "ывтаруй" дип жавап биргәнмен. Бу хәлне ул мина очрашкан саен сөйли, мине яратып, үз итеп сөйли. Сәхнәдә дә, тормышта да Фирдәвес Әхтәмова тышкы эффектлар белән мавыкмый, гади, ләкин үтемле ысуллар белән эш итә. Шунын белән якын, шунын белән кадерле, шуна күрә дә аны тамашачы үз итә. Күпләр аны Г.Камалнын "Беренче театр"ы буенча куелган телевизион спектаклендәге Бибиеннән исләрендә калдырганнар дисәм һич ялгышмам кебек. Артистнын язмышы шулдыр инде: бер роле тамашачы күнеленә кереп урнаша да аны шуннан танып калалар. Югыйсә, Фирдәвес апанын А.Островскийнын "Агайне, ак мыек" спектаклендәге *Липочкасы* да бик оста эшләнгән иде.

**Әзһәр Шакиров.** "Дәфтәр абый" дип йөртәләр аны минем балалар. Безнен бакчалар күрше иде. Ялгыз гына килгәндә, кәефе шәп булса, ул Диләрә белән Даниярга күтәрә алса, өен дә алып бирер иде. Шуна балалар ана тартылалар. Мина, балаларыма үскәнем дип дәшкәндә ул үз балачагын, авылын искә төшерәдер кебек. Чөнки Әзһәр абый әнинен авылдашы да бит. Алай гына да түгел, әни анын беренче мәхәббәте дә булгандыр сыман. Тик әни аны сайламаган. Анын турында язуы авыр да, жинел дә. Ин авыры гадиләштерү диләр. Әгәр дә гади генә әйберне күрәсен икән–көт тә тор, ул әллә ничә катлы, эче тулы сер булыр. Сәгать кебек. Барысы да анлашыла–кем белми! Ә син аны анлатып кара әле... Әзһәр абыйнын Пугачевы ("Канкай углы Бәхтияр") кебек. Менә ул–карагыз, патшаларча горур, халыкнын үзеннән чыккан, тик барысы да шулай жинел генә, гади итеп анлашылса икән. Һәм авыл абзые Галимулла ("Хушыгыз"), жир кешесе, барысы да анлашыла кебек, тик ул да гади, беркатлы түгел, анын эче тулы сер, һәм ул аларны ачып салырга ашыкмый... Әзһәр абый ижат иткән образлар–үзе кебек гадиләр һәм үзе кебек катлаулылар.

**Наил Дунаев.** Николай Иванович инде ул. Щепкинчылар арасыннан ин беренче язмамны мин анын турында яздым. Ул сабакташлары арасында аерым бер шәхес. Беркемгә дә охшамаган. Анын фикерләве рациональ, бу бераз артистларга хас булырга тиеш тә түгел кебек, ләкин ул Наил абый ижатына комачауламый, киресенчә, үзенә күрә бер үжәтлек, эзлеклелек өсти. Һәм нәкъ шул сыйфаты, һәр эшне мантыйк күзлегеннән башкаруы белән ул үзенә ихтирам уята. "Щепкинчылар" арасында нәкъ менә Наил абый мине тулысынча мөстәкыйль кеше итеп күрә кебек, мин анын мина хөрмәт белән каравын тоям. Наил абыйнын рольләре арасында энергиясе ташып түгелгән Фигаро—ин истә калганы. Наил абыйга спектакльнен искиткеч матур һәм күнелле булып истә калуы һәм хәтта Мәскәүнен атаклы Сатира театрындагы Андрей Миронов, Вера Васильевалар катнашкан спектакльдән күбрәк ошаганын әйткәч, ул да минем белән килеште, артистларнын анда рәхәтләнеп уйнавын искә төшерде. Ә шулай да ул уйнаган рольләре арасында тискәреләре Наил абыйга аеруча якын. Андый рольләрне уйнавы кызыклырак булуы турында ишетеп беләм. Наил абыйдан ни өчен дип сораганым да бар. Жавабы холкына хас булды–тискәре геройларымнын ни өчен шундый булулары мине кызыксындыра, диде ул.

**Ринат Тажетдинов.** Анын ижади юлы бәхетле. Ул театрда төрле пландагы рольләр уйнады һәм уйный–тискәресен дә, унаен да, явызын да, романтигын да. Трагедиядә дә, комедиядә дә: санап бетерерлек түгел. Рольләр исемлегендә теләсә кайсы артистны кызыктырырлыклары бар. Замандашларыбыз да, тарихи шәхесләр, мифик персонажлар... Хәтта кинога да төшкәне бар. Ринат абый зур ижтимагый эш тә алып бара. Менә берничә ел ул театр әһелләре һөнәри берләшмәсенен Татарстан бүлеген житәкли. Ринат абый йөкләнгән эшне төгәл үтәүче кеше, ләкин ул беренче нәүбәттә, артист, зур артист. Бәлки театр тәнкыйтьчеләре күзлегеннән караганда, анын "Диләфрүзгә дүрт кияү" спектаклендәге Жәмиле аерым телгә алынырга тиеш тә түгелдер, ә мина Ринат Тажетдинов дигәч, шул аз сүзле егет искә төшә. Артист өчен унайсыз роль бу. Нәрсә кыландырасын инде ул һәрьяклап унган егет белән? Ринат абый Жәмилне бик тә сөйкемле итеп күрсәтә алды, Диләфрүзнен нәкъ шушы егетне сайлап алуы тамашачыны чын күнелдән куандыра иде. Ринат абый бик тә ягымлы, сөйкемле кеше һәм анын сокландыргыч бер сыйфаты бар. Ул теләсә кайсы кампаниядә үз була белә, үзенә генә аерым бер игътибарны жәлеп итмәсә дә, аны күрми калу мөмкин түгел.

**Гөлсем Исәнгулова.** Анын исемен әйтүгә: "Әй-йе-е!"–дип куясы килә. Горур һәм тәкәббер дә ул. Юбилее якынлашкан көннәрдә мин ана: "Гөлсем апа, сезнен турында языйм әле",–дип мөрәжәгать иткән идем. Башта ризалык бирсә дә, соныннан катгый рәвештә баш тартты. Мина ышанмады. Мина ул һаман да нәкъ әнием тосле кечкенә балага караган кебек карый. Бу юлы язганым өчен мине гафу итәр, дип өмет итәм. Гөлсем Исәнгулова үзенчәлекле актриса, һәм мина калса, Г.Камал театрында ул үзенен зур ижади потенциалын ачып бетәрә алмады. Күнеле белән романтик башкорт кызы реализмга тартым татар театрында үзен ачып бетерү өчен ана жай булмагандыр. Ләкин куелган кысаларда да ул кызыклы образлар ижат итте. Сонгы елларда ижат иткән "Хушыгыз" спектаклендәге Сажидәсе искиткеч иде. Гөлсем

апа үтә дә тынгысыз кеше. Үзенә, бүтәннәргә дә тынгылык бирми–нидер уйлап таба, нәрсәдер оештыра. Курсташлары аның бу сыйфатын белеп, аннан яратып көләләр һәм аны "кайнана" дип атыйлар.

**Флера Хәмитова.** Ул сәхнәдән матур күренергә ярата иде. Һәм күренә иде. "Зәңгәр шәл"дәге Мәйсәрә, "Сүнгән йолдызлар"дагы Сәрвәр тамашачы өчен гүзәллек эталоны булып истә калган булса, анда Флера апаның өлеше гаҗәеп зур. Матур көчле тавышы, ягымлы итеп сөйләшүе тормышта да ана игътибарны юнәлтә. Аның сәхнәдә матур булып каласы, "карчыкларга" күчәсе килмәде, ахры. Бүгенге көндә ул студентларга сәхнә серләрен өйрәтә икән, аның мона тулы хокукы бар. Чөнки ул сәхнәдән гүзәллеккә мәдхия җырлау остасы.

**Мәсгүдә Хәйруллина.** Аның язмышы фаҗигале. Сөекле ире, талантлы артист Дамир Хәйруллин вафатыннан соң ул ике кечкенә улы белән кала. Шәхси тормышында аның өлешенә төшкән авырлыкны ул күтәрә алмады. Сәхнәгә көче җитмәдеме, шарты булмадымы. Югыйсә... Югыйсә, анда сәләт тә, сәхнә сөйкемлелеге дә, мөлаем йөз, челтерәп торган матур тавыш та бар иде. "Әниләр һәм бәбиләр" спектаклендә җырлавы әле дә колагымда яңгырап күңелне җылытып тора. Мәсгүдә апа әни янына елышты, әмма әни ана кирәгенчә ярдәм итә алмадым, дип үкенә.

**Рабит Батулла.** Аның яна исеменә һаман да өйрәнеп бетә алмыйм, өйрәнеп тә булмас, ахры. Роберт абый, дип дәшергә күнегелгән шул. Аның энергиясе, эшкә бирелүе әкияти дәрәҗәдә зур. Һәм ул бөтенләй көтелмәгән эшләргә тотынырга курыкмый, тәвәккәлләп артист булган, режиссер да булып караган, язучы, сәясәтче, инде Коръәнне дә тәрҗемә итүче. Аның белән бергә телевидениедә бүгенге "Әлли-бәлли-бәү" тапшыруы кебек бер тапшыруда икәүләшеп артист булып катнашканыбыз да бар. Бүген дә исемдә, ул минем "этием" була, мина йоклар алдыннан әкият сөйли иде. Берсе күнелгә уелып калган. Канатларыннан рәсеме коелган күбәләк турында иде ул... "Щепкинчылар" мәҗлесендә Роберт абый бөтенләйгә тугарылып китеп күңел ача. Гаиләнен мәзәкче малае бугай ул.

**Әхтәм Зарипов.** Ул—"щепкинчылар"нын теләсә кайсы өлкәдә дә югалып калмыйча эшли алуларына ачык бер мисал. Беркемгә дә охшамаган артист, ару-талуны белмәс сценарист, телевидение режиссеры.

Мин монда башка "щепкинчылар" турында язмадым. Чөнки мона хакым юк дип исәплим. Щепкинчылар үзләре бу эшне башкарып чыксалар, кызыклырак булыр. Алар бит бер гаилә, иҗат белән берләшкән гаилә.

Татар мәдәниятендә кырык елдан артык щепкинчылар буларак билгеле төркем, үзе бер тарих, ул махсус өйрәнүне таләп итә. Мина калса, алар турында фәнни хезмәтләрне бүген үк яза башларга кирәк. Алар кабатланмас йолдызлар.

**Әлфия МИҢНУЛЛИНА**

# ИКЕНЧЕ ЮЛ

## ЯЗУЧЫ ҺӘМ ГАЛИМ АЛЬБЕРТ ЯХИНГА 70 ЯШЬ

Элеккегеләр Мәккәгә җәяү барганнар. Шуңа күрәдер инде Хаҗилар илгә бер генә саналганнар. Бүгенгеләр исә анда самолет белән генә оча. Сәяхәт оештыручы фирмалардан юллама аласың да ике-өч көн эчендә хаҗ кылып, изге кешегә әверелеп кайтасың. Шик юк, Мәккәгә барып җиткәч җәяүлеләре дә, туристлары да Хаҗи инде—Ходай каршында йөзең пакь.

Ләкин диндарлар җәяүле Хаҗиларга ныграк ышана. Алар Тәңрегә тугрылыкны исбат итәр өчен гомерләрен кызганмыйча, мал-мөлкәттән ваз кичеп, чын күңелдән Коръәнгә, изгелеккә табынганнар, битарафларны үзләренә иярткәннәр, киләчәк буынны тәрбияләгәннәр.

Һәркем юлны үзе сайлый.

Язучы һәм галим Альберт Яхинның тормыш юлы Арча—Азнакай—Казан—Шәле тирәсендә. Язмышын, иҗатын өйрәнәм дисәң, хәтта аның үзен эзләп табар өчен дә әнә шул тукталышлардан белешергә кирәк. Сез аны университеттан, мәктәптән, иҗат бүлмәсеннән, архивтан, бакчадан, һичьюгы су буеннан эзләп карагыз дисәләр барыбер теге тукталышларны үтәргә туры килер.

Без аның белән җиде сәгать буе сөйләшеп утырдык. 70 яшьнең 7 сәгате...

*—Альберт Гатуфович, һәр юбилей сезгә бер үсеш алып килгән. 30 яшьтә Сез аспирант, 35 тулганчы фәннәр кандидаты булгансыз. 40 яшьтә «Чаян» журналының баш редакторы. 50 дә—университетның кафедра мөдире һәм СССР Язучылар союзы әгъзасы. 60 яшьлек бәйрәмегезне күренекле галим буларак каршы алгансыз. Ә 70 яшегезне кем булып каршылыйсыз?*

—Бишенчедән башлап унберенче сыйныфка чаклы укучылар өчен әдәбият дәреслекләре язучы булып каршылыйм.

*—Дәреслекләрнең төзүчесеме?*

—Юк. Тел төбегезне аңлыйм. Бездә чынлап та дәреслекләрне төзүчеләр чыгара. Икешәр-өчәр төзүче автор булып берләшә дә моңарчы басылган дәреслекләрне берләштереп, үз авызларыннан бер кәлимә сүз өстәмичә, методик күрсәтмәләр, әсбаплар чыгара... Ә мин дәреслекне үзем язам.

*—Димәк, бөтен татар баласы Сезнең дәреслекләр аша әдәбиятны өйрәнә?!*

—Юк! Минекеләр—альтернатив дәреслекләр.

*—Сезгә кадәр, ягъни сездән башка язылганнарын гамәлгә яраксыз дип аңларгамы?*

—Юк. Моңарчы дәреслекләрне «ташка басылган» дәреслек итеп чыгарганнар. Аларның төп принцибы—поэзияне ятлап кына сөйләү, ә роман кебек күләмле әсәрләрне күзаллау өчен әсәрдән өзек китерелгән. Хакыйкатьне ятлауга караганда аны иҗади исбат итү кызыклырак. Уку иҗади эшкә әверелергә тиеш.

Дөресен генә әйтим, җиде сәгать эчендә Альберт Яхинның «Юк!» дигәнен бик күп тапкырлар ишетергә туры килде. Кире кеше дип әйтергә ашыкмыйм, әмма аның белән иңгә-иң яшәүчеләрнең һәм бергә хезмәт итүчеләрнең хәлен аңлыйм. Ул педагог, галим, язучы һәм гражданин буларак һәрвакыт үз фикеренә ия кеше. Өңгәмәдәшнең күңелен күрер өчен генә: «Әйе, әйе!» дип, ялган мөһер сугып утыручылардан түгел. «Юк!» дип кискен бәяләү—аның иялөнгән гадәте түгел, ә холкы.

Ул әдәбият укыту эчтәлеген реформаторларга хас үҗәтлек белән яңартырга тели.

«Альберт Яхинча анализлау» дигән төшенчәгә әдипләр һәм шәкертләр колагы ияләнде инде. Теге яки бу әсәрне анализлаганда Альберт Яхин авторның үзен дә

чакыра. Бер аудитория шәкерт, язучының күз алдында, яратып язган әсәрен шөребен шөрепкә аерып, ваклап сүтә һәм иҗади бәхәс белән бәяләп, яңадан җыеп куя. Йә, син әйбәт әсәр авторы, йә—пүчтәк! «Пүчтәк» дигәннән соң аудитория ишеген каты итеп ябып чыгып киткән язучыларның хәлен аңлыйм мин. Әлеге ысул белән бүгенге әдәбиятны тулаем анализлап бәяли калсаң, сөенә-сөенә иҗат итеп яткан 300 язучының 20сен генә мактарга мөмкин булыр иде мөгаен.

Алайга калса, ул 300 кеше арасында Альберт Яхин үзе дә бар бит. «Крокодил» (Мәскәү), «Һәнәк» (Өфе), «Чаян» (Казан) журналы укучыларын сөендереп, соңрак юмористик хикәяләрен туплап, ике китап чыгарган һәм әдәбият сәхнәсендә шактый бәхәсләр тудырган язучы ул. Миңа калса, аның хикәяләр язудан туктавы, үзенең яңача анализлый башлаган елларына туры килә бугай...

Альберт Яхин теориясе белән бәяләп, дәреслекләрдәге Һ. Такташ шигырьләрен яңадан өйрәнсәң «аһ!» итәсең. Шагыйрьнең лирикасында юлбашчыларның сәясәте белән килешмәү, «идеологик чистартуны» фаш итү, тираннарга нәфрәт һәм хәтта әүлиялык кычкырып тора икән. Шулай итеп, Һ. Такташ даһилар исемлегенә («обоймасына») кучә. Моның өчен ул шигырьләрнең ярты гасыр буе төрелгән кызыл тукымасын гына сүтеп алырга кирәк.

*—Альберт әфәнде, шәхес культы чоры әдипләрен өйрәнүегез мода артыннан куу гына түгел микән?*

—Юк. Утызынчы еллар хакында искә төшереп тору гел кирәк. Шәхес культы куркынычының әле дә беткәне юк. Без бу турыда ачыктан-ачык сөйләшергә күнекмәгән генә.

Кандидатлык диссертациясен язар өчен Шамил Усмановны өйрәнгәндә дисеңме, Һ. Такташ биографиясен архивлардан эзләгәнгәме, әллә Хәсән ага Туфан белән дустанә аралашып яшәгәнгәме—мин үземне гел дуслар тарафыннан нахакка хөкем ителгән корбаннар арасында гомер кичергән кеше итеп тоям.

*—Без ул һәлакәтне Сталин белән бергә күммәдекмени?*

—Юк! Безнең көннәрдән дә моңа күп мисал китерергә була. «Азат хатын» журналында басылып чыккан хикәясе өчен Гомәр Бәшировны «милләтче» дип мыскыл итәргә маташканда житмешенче еллар иде инде. Бөтен матбугат чаралары аны «фаш итеп» язып чыкты. Мин ул чакны «Чаян»ның баш редакторы.

*—Сез дә яздыгызмы?*

—Юк! Ул вакытта обкомның беренче секретаре Табиев иде. Фикрәт Әхмәтҗановичны мин әле дә булса хөрмәт итәм. Кырыс, әмма гадел житәкче иде ул... Һәр атнаның җомга көнендә мин Табиев янына кереп күрешергә тиеш. Йомышым бармы, юкмы—анысы секретарьны кызыксындырмый, иң



*Альберт Яхин Хәсән ага Туфанның юбилеенда. 1980 ел.*

мөһиме—кабул итү бүлмәсендә кемнәр көтеп утыруга карамастан, горур атлап, билгеләнгән вакытта чиратсыз-нисез узарга тиеш.

*—Ай саенмы инде ул?*

—Юк! Һәр атнада, бер җомганы да калдырмыйча!

*—Бүгенге редакторларның төшләренә дә керә алмый торган хыял бит бу!*

—Анысын ук әйтә алмыйм... Шулай бер җомгада Табиев әйтә миңа: син «Азат хатын» журналында Гомәр Бәшировның теге хикәясен укыдыңмы, ди. Мин яшермим, дөресен әйтеп салдым: укымадым, дидем. Укырга кушты. Алай гына да түгел, фикеремне әйтергә һәм журналда язып чыгарга кирәк иде.

Икенче җомгада киддем дә әйттем: бу хикәянең кимчелекләре бар, ләкин анда берниндә дә милләтчелек рухы юк, Сезгә ялгыш җиткергәннәр, дим... Шул көннән башлап матбугат чаралары Гомәр Бәшировка яла ягудан туктады.

*—Альберт абый, холкыгызга күрә тормышта Сезгә гел кыендыр. «Юк!» дигән кешеләрне бездә бик өнәп бетермиләр бит: эш урынында артык үстермиләр; мактаулы исемнәр бирмиләр; һәр башлаган яңалыгыңа аяк чалып торалар; дусларың да качып бетә, бер ялгызың каласың.*

—Фикереңбелән бөтенләй үк килешеп бетмим. Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев, Туфан Миңнуллин кебек берәгәйле дусларым барында мин үземне ялгыз тоялмыйм. Сибгать ага Хәким белән дә гомер буе дус идек. Сугышка чаклы минем әти Арча районының Күлле Киме авылында һөнәри училищеда укыткан. Шунда ул бер укучының шигырьләрен күргән дә: «Синең урының агрономнар арасында түгел, шигырьләреңдә зур шагыйрь бар!»—дигән. Ул бала Сибгать Хәким булып чыкты. Сибгать агай мине күргән саен, әтиемне искә ала иде.

Дәрәҗәгә мактаулы исемнәргә килгәндә—үзең язган дәреслекләр буенча киләчәк буынга матур әдәбият укытудан да мактаулырак дәрәҗәне белмим мин.

*—Альберт абый, теләсә кайсы хатын үзенең ирен зур начальник итеп күрергә тели. «Синең кебекләр күптән «генерал» булып бетте инде, ә син әле һаман педагог булып йөрисең», дип, Эльмира ханым битәрләмиме Сезне?*

—Шөкер, андый гадәте юк. Эльмира апагыз атаклы Акчуриннар нәселеннән ул. 50 елга якын Яхиннар фамилиясен йөртә. Зыялы хатын ул, иҗат кешесен аңлап, ярдәм итеп яши. Туры килүен кур—Чыңгыз Айтматовны минем Эльмираның әнисе тәрбияләп үстергән. Шулай итеп, минем хатын зур язучы тирәсендә үскән бала. Сирәк кенә булса да Чыңгыз Айтматов белән хәбәрләшеп торабыз.

*—Альберт абый, хатыныгыз Сезнең Шәлегә кайтып, авыл укытучысы булып йөрүегезгә дә ризамы?*

—Әйе, рәхәтләнеп риза! Шәле бит ул Арча—Азнакай—Казан өчпочмагының уртасында. Шәледә үзебез күтәргән зур бакчабыз бар. Үзйөрешле мотоблок белән җир сөрәбез, бәрәңге утыртабыз, алабыз...

Альберт Яхинның «Әйе!» дигән сүзен ишеткәнче сөйләшеп утырырга иде исәбем. Ниһаять, җиде сәгать үткәч, тәки морадыма ирештем... Барыбер инде бер күрешүдә генә язучы һәм галим кешенең бөтен язмышын сөйләттереп булмас.

Сүз ахырына калдырып шунысын да әйтим әле. Альберт Яхин, университетның татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлап, Азнакай районының Тымытык авылына физкультура укытучысы (!) булып кайта. Ул көн саен өеннән мәктәпкә чаклы араны баштүбән кулларында атлый. Кызык өчен генә башланган бу кәмит мәктәп балаларын да җәлеп итә. Тора-бара алар да, җае чыккан саен, баштүбән йөрергә керешәләр. Әйе, балалар үзләре яраткан педагогның һәр фигылен өйрәнеп, шөгылен ятлап, белгәнен кабатлап, аңа охшарга тырышып үсә, йөргән юлларын үтәргә омтыла. Татар әдәбияты фәнен өйрәнүдә Альберт Яхин язган дәреслекләр үзе бер яңа юл булып тора. Әдәбият—милли аңыбызның Мәккәсе бит инде ул. Ә Мәккәгә һәркемнең үз юлы.

Әйеме, якташ абый?!

*Әңгәмәне* **Камил КӘРИМОВ**
*алып барды*





# 17—ИСРА (ТӨНГЕ ЙӨРҮ, ЯГЪКУБ УГЫЛЛАРЫ) СҮРӘСЕ

**(Исра сүрәсе 111 аятьтән тора. «Исра» сүзе «төнлә йөрү» мәгънәсен үз эченә ала.)**

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Аятьләребезнең бер өлешен күрсәтим дип, бер төн эчендә илчесен *(Мөхәммәдне)* Харам мәчетеннән тирә-ягы нигъмәт *(бәрәкәт)* белән тулы Акса мәчетенә китергән Аллаһ кимчелекләрдән азат. Ул, хакыйкатән, ишетеп, күреп торучы.

**2.** Без Мусага Китап бирдек вә Исраил оныкларына:

—Миннән башка һичбер затка ианнып, аны тәнре *(юлбашчы)* итмәгез,— дип бу Китапны тугры юлга юнәлтүче рәһбәр иттек.—**(3)** Әй, Нух белән бергә *(көймәдә)* йөргән *(котылып калган)* кешеләрнең токымы, шуны белеп торыгыз, Нух шөкер иткән бер бәндәм иде.

**4.** Без китапта Исраил токымына:

—Сез Җир йөзендә ике тапкыр фетнә *(гаделсезлек)* чыгарачаксыз вә азгынлык дәрәҗәсендә тәкәбберләнәчәксез,—дидек. **(5)** Ике янауның *(куркынычның)* берсе килгәч, өстегезгә куәтле колларыбыздан торган гаскәр җибәрдек. Алар өй борынча йөреп, сезне эзәрлекләделәр. Шулай итеп, вәгъдәбез җиренә житкезелде.

*(«Тәфсирләрдә куәтле коллардан торган бу гаскәр ниңвалы Сәнҗариб, бабиллы Навуходоносор яки Җалут гаскәрләре икәнлеге сөйләнә. Болар Тәүратны, Акса мәчетен яндыралар, Исраил токымнарыннан чыккан галимнәрне үтерәләр һәм 70.000 ләп кешене әсир итәләр. Исраил угылларының беренче фетнәсе Зәкәрияне үтерү, Әрмияне зинданга ташлау—шушы кырылышларның сәбәбе, диелә».*

Хәсән Чантай, Садретдин Гүмүш тәфсирләреннән.)

**6.** Ахырда аларга каршы көрәштә сезгә янә *(җиңү һәм өстенлек)* бирдек; малларыгызны вә угылларыгызны арттырдык, халкыгызны күбәйттек. **(7)** Игелек кылсагыз үзегез өчен, яманлык кылсагыз да үзегез өчен. Тагын башка төрле җәза вакыты килсә, йөзегезне кара итсеннәр, моннан элек тә кергәннәре кебек, янә мәсҗедкә керсеннәр вә кулларына ни эләксә, шуны җимерсеннәр *(дип, башыгызга тагын дошманнарыгызны өстердек).*

*(«Исраил токымының икенче тапкыр афәткә дучар булуының сәбәбе хәзрәти Яхъяны үтерүләреннән һәм хәзрәти Гайсәне үтерергә тәдбир корганнарыннан килеп чыга».*

Мостафа Чагрыжы тәфсиреннән.)

**8.** Бәлки, Раббыгыз сезгә миһербанлы булыр; әгәр сез яңадан фетнә корсагыз, Без дә сезне тагын җәзага салачакбыз. Без җәһәннәмне кяферләр өчен зиндан иттек.

**9.** Шик юктыр ки, бу Коръән иң тугры юлга юнәлтүче; игелек кылган

---

Журнал өчен **Рабит БАТУЛЛА** әзерләде.

мөэминнәргә үзләре өчен бөек бер әҗер алачаклары турында сөенечле хәбәр китерүче. **(10)** Ахирәткә ышанмаганнарга килсәк, алар өчен әрнетүле газап хәзерләнгән. **(11)** Кеше яхшылык теләп *(Аллаһка)* дога кылган кебек үк, үзенә яманлык та тели. Адәми зат ашкына. **(12)** Без төнне һәм көнне *(кодрәтебезнең дәлиле итеп)* яралттык. Төннең дәлилен *(караңгылыгын)* сөртеп, Раббыбыздан килгән ризыкны эзләр өчен һәм *(вакыт)* хисабын белер өчен көннең дәлилен—яктылыкны кылдык. Һәрнәрсәне тәфсилләп аңлаттык.

**13.** Һәр инсанның муенына *(үзенең язмыш кошын асып, ягъни гамәл дәфтәрен)* үз Кошын чорнадык. Кыямәт көнендә шул *(кош, дәфтәр)* кешенең алдына *(ачылып)* килеп куначак. **(14)**

—Үз дәфтәреңне укы. Үз-үзеңне хөкем итәргә шушы гамәл дәфтәрең житәр. **(15)** Тугры юл сайлаган кеше, үзенә яхшылык сайлаган булыр. Кем тугры юлдан тайса, үз башына булыр. Һичбер гөнаһкяр башка кешенең гөнаһысын үз җилкәсенә алмас. Без пәйгамбәр күндермичә *(кисәтмичә)* генә бер кешегә дә газап бирмибез. **(16)** Бер шәһәрне *(халыкны)* һәлак итәргә теләгәч, байлыклары белән масайган хуҗаларына *(игелек кылыгыз, дип)* әмер бирдек; шуңа да карамастан, алар бозыклык кылды, шунда алар өстенә әйтелгән сүз хакка чыкты. Без дә аларны тар-мар иттек.

**17.** Нухтан соң Без ничәмә-ничә халыкларны һәлак иттек. Бәндәләренең гөнаһларын белеп-күреп торыр өчен Раббың житә. **(18)** Күз ачып йомганчы узып китә торган бу дөньяда *(байлык)* теләгән кешегә Үзебез теләгәнчә бар нәрсәне дә кичектермичә бирербез. Ахырда Без аны җәһәннәмгә тыгарбыз. Ул кеше анда кыйналып, *(мәрхәмәтебездән)* мәхрүм буларак *(янар өчен)* урнашыр. **(19)** Мөэмин булып, Ахирәтне теләсә, Ахирәткә ярарлык тырышлык белән гамәл кылса, менә аның тырышлыгы кабул булыр *(югары бәяләнер)*.

**20.** Барысына да—аларга да, боларга да—фани дөньяны гына алга сөргәннәргә *(кяферләргә)* дә, Ахирәтне алга сөргәннәргә *(мөселманнарга)* дә Раббының хәзинәсеннән *(теләгәннәрен)* бирербез. Раббыңның хәзинәсе беркемгә дә тыелмаган *(чиксез)*. **(21)** Бакчы, Без инсаннарны *(байлыкта)* бер-берсеннән өстен куйдык. Әлбәттә, дәрәҗә вә өстенлек мәсьәләләрендә Ахирәт тагын да бөегрәк.

**22.** Аллаһтан башка тәңрегә табынма *(бер генә нәрсәне дә, бер генә җан иясен дә «илаһ» дип таныма)*. Ахырда кыйналырсың вә ялгыз башың калырсың. **(23)** Раббың бары тик үзенә генә гыйбадәт кылуыгызны, ата-анагызга да игелекле булуыгызны катгый рәвештә боерды. Аларның берсе яки икесе дә сезнең янда картайса, аларга: уф *(туйдым сездән)*, димәгез; аларны битәрләмәгез; икесенә дә яхшы мөгамәләдә булыгыз. **(24)** Миһербан һәм түбәнчелек белән алар алдында *(күңел)* канатларыңны җәй дә әйт:

—Раббым, сабый чагымнан алып, алар мине ничек сөеп үстергән булса, Син дә аларга шулай мәрхәмәтле бул,—дип дога кыл. **(25)** Раббыгыз сезнең күңелегездә ниләр барын *(ата-анагызга булган мөнәсәбәтегезне)* бик яхшы белеп тора. Сез *(ата-анагызга)* игелекле булсагыз, шуны белеп торыгыз, Аллаһ яманлыктан ваз кичеп, тәүбәгә юнәлгәннәрне аеруча ярлыкаячак.

**26.** Туганнарыңа, мохтаҗларга, юлчыга үз хакларын бир. Мәгънәсезгә исраф кылма. **(27)** Малын әрәм-шәрәм итүчеләр—шайтанның кардәшләре. Шайтан исә Раббыга шөкер итмәүче зат. **(28)** Үзең дә Аллаһтан нигъмәт сорап ялварган чакта *(хәер бирә алмау сәбәпле, кыенсынып)* мохтаҗлардан йөз чөермә, һич югында аларга күңелләре рәнҗемәслек йомшак сүзләр әйт.

**29.** Кулыңны үз муеныңа бәйләмә *(саран булма)*; кулларыңны җәеп тә җибәрмә *(артыгын юмартланма да)*. Ахырда *(саран дип)* сине ачуланырлар, *(малыңны туздырып)* син бичара хәлдә калырсың. **(30)** Раббың теләгән колына ризыкны мул бирер, теләмәгәненә киметер. Хактыр ки, Ул бәндәләренең ни кылганыннан хәбәрдар, барысын да күреп тора.

**31.** Фәкыйрь калудан куркып, балаларыгызны үтермәгез. Без аларга да, сезнең үзегезгә дә ризык бирәчәкбез. Аларны үтерү, хактыр ки, зур гөнаһ.

**32.** Зинага якын бармагыз. Чөнки зина—бер нәҗес гамәлләр, пычрак юлдыр.

**33.** Хаклы бер сәбәп булмаса, Аллаһ кушмаган җанны кыймагыз. Кем хаксызга үтерелсә, без анын якыннарына *(үч кайтару өчен)* хак бирдек. Ләкин ул да үч алганда хәттин ашмасын. Чөнки *(аңа инде гадел микъдарда үч кайтарырга форсат бирелде)* Аллаһтан ул ярдәм алды инде.

**34.** Балигъ булганчыга чаклы *(сезнең карамактагы)* ятимнәр малына, *(шул малны арттыру ниятеннән тыш)* якын килмәгез. Антыгызны *(ятим каршындагы вазифагызны)* җиренә җиткезеп үтәгез. Антыгыз өчен җавап тотасыгыз бар.

**35.** Үлчәгәндә дөрес үлчәп бирегез, алдамый торган бизмәннәрдә үлчәгез. Бу гаять яхшы гамәлдер, нәтиҗәсенә күрә дә бик игелекле эш булыр.

**36.** Белмәгән нәрсәгә иярмә. Колагың, күзең вә күңелең *(син кылганнарга шаһит булып)* сине җавапка тартыр.

**37.** Җир йөзендә масаеп йөрмә. Чөнки син *(булыр-булмас көчең белән)* Җирне яра алмыйсың, *(булыр-булмас буең белән)* таулар биеклегенә җитә алмыйсың. **(38)** Алда саналганнарның яманнары Раббы хозурында хупланмый. **(39)** Менә боларның барысы да сиңа Раббың тарафыннан вәхий ителмеш хикмәтләрдер. Аллаһтан башка уйдырма тәңрегә табынмагыз. Ахырда рисвай булып, *(Аллаһның рәхмәтеннән)* мәхрүм калып, җәһәннәмгә атылырсыз.

**40.** Раббыгыз сезгә бары тик угыллар гына биреп, үзенә фәрештәләрне кызлары итеп алган икән! Хакыйкатән, сез коточкыч көфер сүз сөйлисез бит.

**41.** Исләренә төшереп, гыйбрәт алсыннар дип, Без бу Коръәнне төрле аятьләр рәвешендә аңлаттык. Ләкин, шуңа да карамастан, аларның *(Коръәнгә булган)* нәфрәте артты гына. **(42)** Әйт:

—Әгәр сез сөйләгән кебек, Аллаһ янында тагын башка илаһлар да булса иде, алар Гарешнең хуҗасы Аллаһ янына *(тәхетенә)* утыру чаралары күрә башлаган булыр иде,—диген. **(43)** Ләкин Аллаһ алар сөйләгәннәрдән бөек, олуг һәм кимчелекләрдән азат *(Аллаһ әкбәр)*. **(44)** Җиде кат күкләрдәге, Җир һәм Җир өстендәгеләрнең барчасы Аллаһка тәсбих *(мактау)* әйтә. Аны мактамаган беркем дә, бернәрсә дә *(хәтта җансыз җисемнәр дә)* юк. Аяныч ки, сез *(мөшрикләр)* аларның тәсбихен аңламыйсыз. Аллаһ Ул—сабыр вә ярлыкаучы. **(45)** Коръән укыган вакытыгызда Без Ахирәткә ышанмаганнар белән сезнең арага күренми торган пәрдә корабыз. **(46)** Аны *(Коръәнне)* аңламасыннар өчен күңелләрен каплыйбыз, колакларын саңгыраулатабыз. Син Коръәндә Раббының берлеге турында зикер иткән чакта алар нәфрәтләнеп кирегә борыла. **(47)** Сине нинди максат белән тыңлаганнарын, үзара ни турында чыш-пыш килгәннәрен һәм аларның:

—Сез саташкан бер адәми затка иярәсез,—дигәннәрен бик яхшы беләбез. **(48)** Бакчы, синең хакта әллә нинди мәсьәләләр уйлап чыгаралар. Шуның аркасында алар юл тапмаслык итеп адашты. **(49)** Алар әйтә:

—Сөякләребез череп, туфрак булганнан соң без тагын яңадан тереләчәкбезме? *(Без моңа ышанмыйбыз)*,—диләр.

**50.** Әйт:

—Әйе *(тереләчәксез)*, хәтта сез ташка яки тимергә әйләнгән булсагыз да,—диген.—**(51)** Сез—сай акыллыларга терелтүе мөмкин булмастай булып күренгән *(артык зур яки артык кечкенә бөҗәк кебек)* нәрсә булсагыз да *(терелтәчәк)*,—диген. Алар:

—*(Үлгәннән соң)* безне кем терелтәчәк?—дип сорар.

Син әйт:

—Сезне иң башта яралтучы *(терелтәчәк)*,—диген.

Шуннан соң алар мыскыллы рәвештә башларын артка ташлап:

—Кайчан?—дип сорарлар. Әйт:

—Озакламас,—диген. **(52)** Аллаһ сезне чакырып алган Көнне сез Аңа тәкбир әйтеп килерсез, үлем белән терелү арасында бик аз вакыт узган сыман тоелыр. **(53)** Бәндәләремә әйт, иң татлы сүзләр генә сөйләсеннәр. Чөнки шайтан аларның арасында гауга чыгаручы. Шайтан—кешенең иң хәтәр дошманы. **(54)** Сезне иң яхшы белүче Раббыгыздыр. Ул ихтыяр итсә, мәрхәмәтле булыр, ихтыяр итсә, сезне җәзалар. Без сине алар өстеннән вәкил итеп *(ирексезләп*

*дингә кертергә дип)* җибәрмәдек. **(55)** Күкләрдәге, Җирдәге бар нәрсәне Аллаһ яхшы белеп-күреп тора. Хакыйкатән, Без пәйгамбәрләрне дә бер-берсеннән өстен куйдык. Даутка Зәбурны бирдек. **(56)** (*Ий, Мөхәммәд*) әйт:

—Аллаһны инкарь итеп, табынганнарыгызга ялварыгыз. Алар өстегезгә килгән афәттән дә коткара алмас, язмышыгызны да үзгәртә алмас,—диген. **(57)** Алар табына торган бу мәхлуклар үзләре Аллаһка якынаю юлларын эзлиләр. Үзләрен Аллаһка якын дип уйлап, Аның рәхмәтен өмет итәләр, Аннан куркып торалар. Чөнки Аллаһның газабы коточкыч бер газап һәм ул газаптан куркырга кирәк.

**58.** Кыямәт көненнән әүвәл Без юк итмәгән яки дәһшәтле газапка тотмаган бер генә шәһәр дә, авыл да юк. Китапка *(Ләүхел Мәхфүзгә)* шулай язылган. (59) Могҗизалы аятьләребезне иңдерүдән бераз тоткарлаган нәрсә баштагы халыкларның ул аятьләребезне ялганга чыгаруы булды. Сәмуд кавеменә ачык бер могҗиза буларак, Без ана дөя җибәрдек, алар исә *(дөяне бугазлап)* гаделсезлек кылдылар. Шуңа күрә, Без аятьләрне бары тик кисәтер өчен, аң булсыннар өчен генә күндерәбез. **(60)** Исеңдәме, Без сиңа:

—Раббың кешеләрнең барчасын чорнап алды,—дигән идек. Сиңа күрсәткән күренешне вә Коръәндә ләгънәт ителгән *(агулы зәкъкум)* агачын кешеләрне сынау өчен генә күрсәттек. Без аларны куркытырга тырышабыз, ләкин бу *(тырышулар)* аларның электә булган нәфрәтләрен *(буйсынмауларын)* арттыра гына.

**61.** Фәрештәләргә:

—Адәмгә сәҗдә итегез,—дигән идек. Иблистән башкалары барысы да сәҗдә итте. Иблис исә:

—Мин балчыктан ясалган бер бәндәгә сәҗдә итәмме соң,—диде. **(62)** Шуннан *(Иблис әйтте)*:

—Бу адәми затны миннән дә өстен ясадың. Ант итәмен ки, әгәр дә мине Кыямәт көненә чаклы яшәтсәң, аның нәселен, бик азыннан башкасын, үземә каратачакмын, тугры юлдан яздырачакмын,—диде.

**63.** Аллаһ боерды:

—Кит *(күземнән югал)*. Сиңа ияргәннәрнең барысы өчен дә, тулы җәза, һичшиксез, җәһәннәмдә булыр. **(64)** Көчең җиткәннәрне *(азгын ләззәткә чакыра торган)* тавышың белән аздыр, аларга каршы атлы гаскәр белән җәяүле гаскәрләреңне яуга күтәр, малларына, балаларына уртак *(ата)* бул. Матур вәгъдәләр биреп үзләрен алда. Шайтан инсаннарга ялганнан башка нәрсә бирә алмый. **(65)** Шунысы хактыр ки, минем ихлас бәндәләремә син баш була алмассың. Аларны саклап калыр өчен бер Аллаһ җитәр.

**66.** Үзе тарафыннан булдырылган нигъмәтләргә ирешер өчен, Раббыгыз сезгә диңгезләрдә йөзәргә дип, көймәләр ясады. Хактыр ки, Ул сезгә бик тә мәрһәмәтле. **(67)** Диңгездә йөзгән чагыгызда башыгызга афәт төшсә, Аннан башкага табынганнарыгыз юк була. Ул *(Аллаһ)* сезне коры җиргә чыгарып, коткарып калгач, йөз чөерәсез. Бәндәләр һич шөкер итмәс.

**68.** Җирне урталай ярып, сезне җир астына уптырмас яки башыгызга таш яудырмас, дип уйлыйсызмы? Ахырда сез үзегезне яклардай беркемне дә табалмассыз. **(69)** Ул безне тагын диңгезгә чыгармас, *(чыгарса да)* өстебезгә давыл җибәрмәс, инкарь иткәнебез өчен безне суга батырмас, дип өметләнәсезме? Ахырда бу эшләребез *(суга батырганыбыз)* өчен безне гаепләр өчен ярдәмче зат та табалмассыз.

**70.** Хактыр ки, Без адәм балаларын дан вә шәрәфләргә күмдек. Аларны коры җирдә дә, диңгез-суда да йөрттек. Үзләренә тәмле-татлы ризыклар бирдек. Янә дә аларны яраткканнарыбызның күбесеннән өстен кылдык.

**71.** Кыямәт көнендә һәр кавемне үзенең өндәүчесе белән бергә *(хисап тотарга)* чакырырбыз. Кемгә *(гөнаһ-саваб)* дәфтәре уң кулы ягыннан бирелсә, ул кешеләр энә очы хәтле дә рәнҗетүгә дучар ителмәс һәм алар гамәл дәфтәрен шатлык белән укыр. **(72)** Бу дөньяда *(күңел күзе)* сукыр булган Ахирәттә дә сукыр булыр. Шуның өстенә алар тагын да ныграк адашыр. **(73)** Алар сине дус иткән булыр иде. Әгәр дә син вәхий иткәнебезгә каршы

уйдырма ялганнар таккан булсаң, әкренләп сине фетнә юлына төшергән булырлар иде. **(74)** Әгәр дә Без сине *(ң иманыңны)* ныгытмаган булсак, син чак кына булса да алар ягына авышкан булыр идең. **(75)** Ул чагында, һичшиксез, Без сиңа тормышның һәм үлемнең әчесен кат-кат татыткан булыр идек. Ул чагында син үзеңне Миннән яклар өчен дус табалмас идең. **(76)** Сине йорт-җиреңнән куып чыгарыр өчен, алар ниләр генә кыланмый. *(Сине куган тәкъдирдә)* алар синнән соң озак тора алмас. **(77)** Синнән алда күндергән пәйгамбәрләрнең кануннары да шушындый иде. Бу кануннарда һичбер үзгәреш табалмассың.

**78.** Кояш төш турыннан авышып, төн караңгылыгына чаклы *(өйлә, икенде, ахшам, ястү)* намаз укыгыз. Таң атканда да иртәнге намазны укыгыз. Иртәнге намазның шаһитләре бар *(фәрештәләр)*. **(79)** Төннең бер вакытында уянып, үз иркегез белән, нафилә намазы укыгыз. Ихтимал, Раббыгыз сезгә шәрәфле урын бирер.

**80.** Әйт:

—Раббым, керәчәк урынга тугры юлдан керт, чыгачак юлымны да тугры ит. Дөреслек белән эш кылырга миңа ярдәм итүче куәт бир,—диген. **(81)** Тагын әйт:

—Хакыйкать *(дөреслек)* килде, ялган китте. Чөнки ялган бетәргә мәхкум,—диген.

**82.** Без Коръәннән шундый хикмәт индерәбез ки, ул мөэминнәр өчен шифа һәм рәхмәттер, гаделсезләр өчен исә бары тик зыян гына китерә. **(83)** Берәрсенә нигъмәт бирсәк, ул йөз чөерә дә китеп бара. Әгәр дә аңа яманлык килсә, ул өметсезлеккә төшә.

**84.** Әйт:

—Һәркем үз нәфесенә күрә гамәл кыла, бу мәсьәләдә кемнең тугры юлда икәнен Раббыбыз бик яхшы белеп тора,—диген.

**85.** Алар синнән рух турында сораштырыр. Әйт син:

—Рух Раббымның боерыгында. Сез бик аз беләсез бит,—диген.

**86.** Ихтыяр итсәк, сиңа вәхий иткәнебезне кире алыр идек, аннан соң син дә Безнең җәзаларыбыздан яклаучы табалмас идең. **(87)** Аллаһның рәхмәтеннән башка. Чөнки Аның сиңа булган мәрхәмәте чиксездер. **(88)** Әйт:

—Шунысы хактыр ки, бәндәләр белән барлык женнәр бергә җыелышып, берсенә берсе ярдәм итешсәләр дә, Коръәнгә охшаш башка китап мәйданга китерә алачак түгел,—диген.

*(Җен-ул гадәти булмаган көч белән кешеләрне котырта-аздыра ала торган адәми зат, ягъни, җенле адәм, җене белән эшли торган кеше, армый-талмый бозык юлда, җинаять юлында йөрүче бәндә. Бу аңлатма Мәүлана Али китабыннан алынды.)*

**89.** Хактыр ки, бу Коръәндә Без инсаннарга һәртөрле *(мәгънәле)* кыйссалар сөйләп аңлаттык. Шулай да инсаннарның күбесе инкарьчылар булып калудан башканы белмәде.

**90.** Алар әйтте:

—Син җир астыннан чишмә чыгармыйча, без сиңа ышаначак түгелбез,—диделәр. **(91)**—Яки син безгә хөрмә бакчасы, йөзем багы барлыкка китер, анда челтер-челтер чишмәләр агып торсын. **(92)** Яки, үзең әйткәнчә, өстебезгә Күкне яргалап төшер. Яки фәрештәләре белән бергә алдыбызга Аллаһ килеп төшсен. **(93)** Яки син үзеңә зиннәтләр белән бизәлгән алтын йорт салып күрсәт яки Күккә ашып кара. Күккә ашсаң да, без сиңа инанмыйбыз, Күктән без укырлык китап алып төшмәсәң,—диделәр. Әйт син аларга:

—Аллаһ әкбәр! Әлхәмдүлилләһ, мин гап-гади бер адәми зат түгелмени? Мин Аллаһ тарафыннан сезгә җибәрелгән илче генә,—диген. **(94)** Үзләрен тугры юлга күндерүче җибәрелгәч:

—Аллаһ безгә гап-гади бер бәндәне пәйгамбәр итеп җибәргәнме?—дип әйтүләре кешеләрне иман китерүдән тоткарлый.

**95.** Әйт:

—Әгәр Җир йөзендә кешеләр урынына фәрештәләр яшәсә иде, әлбәттә, пәйгамбәр итеп без фәрештә иңдергән булыр идек.

**96.** Әйт:

—Минем белән сезнен арада*(гы мәсьәләләр буенча)* хакыйкый Аллаһның шаһитлеге житә. Аллаһ бәндәләренен ни кылмышын күреп, белеп тора,—диген.

**97.** Аллаһ тугры юлга күндергән кеше тугры юлдан барыр, кемне тугры юлдан яздырса, ул кешегә Аллаһтан башка химаяче табалмассын. Кыямәт көненндә аларны сукыр, телсез вә чукрак хәлдә йөзтүбән китерербез. Алар барасы һәм шунда каласы жир—жәһәннәмдер, аның уты сүрелә башласа, янә көчлерәк дөрләтәчәкбез.

**98.** Аятьләребезне инкарь итеп:

—Сөякләребез череп, туфракка әйләнгәч тагын бар булып терелүебез мөмкин эш түгел,—дигәннәре өчен аларга әнә шундый җәза биреләчәк.

**99.** Күкләрне һәм Жирне яралткан Аллаһның аларга охшаш булганнарны да яралтырга кодрәтле икәнен алар күрмиме? Алар өчен Аллаһ бер әҗәл вакыты тәгаенләде, монда шикнең булуы мөмкин түгел. Ләкин залимнәр инкарьчылыктан башкасын кабул итмәделәр.

**100.** Әйт:

—Раббымның хәзинәсенә сез хужа булып алсагыз, *(ул хәзинә)* бетәр, дип куркып, *(башкаларга бирмичә)* кысып кына тотар идегез. Адәм баласы бик тә саран токым,—диген.

**101.** Без Мусага тугыз могҗиза *(аять)* бирдек. *(Ниләр булганын)* әнә, Исраил токымыннан сора. Муса алар янына килгәч, Фиргавен аңа:

—Әй, Муса, сина сихер зәхмәте кагылган дип уйлыймын,—диде. **(102)** *(Муса)* әйтте:

—Үзең белеп торасың, боларны *(Муса күрсәткән могҗизаларны һәм аятьләрне)* гыйбрәт булсын дип, күкләрнен һәм Жирнен Раббысы иңдерде. Әй, Фиргавен, мин дә сине харап булачак кеше дип уйлыймын,—диде. **(103)** Шуннан соң Фиргавен аларны *(Муса белән Һарунны)* куып җибәрергә теләде. Ләкин Без аны *(Фиргавенне)* яраннары белән бергә суга батырып һәлак иттек. **(104)** Шуннан соң Исраил угылларына:

—Шул жирдә яшәп калыгыз. Ахирәттә барчагызны кубарып бер урынга жыячакбыз,—дидек.

**105.** Без аны *(Коръәнне)* хак буларак иңдердек, ул Хакыйкать алып килде. Сине дә бары тик *(савапчыларны алда җәннәт көтә дип)* сөенче алучы вә *(гөнаһлыларны җәһәннәм көтә дип)* кисәтүче буларак кына күндердек. **(106)** Кешеләр Коръәнне әкрен-әкрен, тора-тора укысыннар дип, *(сүрәләргә, аятьләргә)* бүлгәләдек һәм аны берәм-берәм иңдердек.

**107.** Әйт:

—Инансагыз да, инанмасагыз да, ул *(Коръән)* бер Хакыйкать. Аннан алда гыйлем алганнар да аны *(Коръәнне)* укыгач, шундук *(сакаллары өстенә)* йөзтүбән *(сәҗдәгә)* капландылар,—диген. **(108)** Һәм әйттеләр:

—Аллаһ Тәгаләдә кимчелек юк! Әлхәмдүлилләһ, сөбханаллаһ, Раббыбызның вәгъдәсе жиренә житкезелде,—дип **(109)** елый-елый йөзтүбән капландылар. Ул *(Коръән)* аларның иманын ныгыта.

**110.** Әйт:

—Аллаһ дисезме, Рахмән дисезме. Кайсысын әйтсәгез дә була. Аллаһның үзенә генә хас матур исемнәре күп. Намазыгызны каты тавыш белән укымагыз. Артык пышылдауга да күчмәгез. Урталыкны тотыгыз,—диген.

**111.**—Аллаһ әкбәр, сөбханаллаһ—Аллаһка хакыйкый мактаулар булсын. Ул бала тудырмаган, кодрәттә тиңе булмаган, яклаучыга ихтыяжы булмаган Аллаһка дан,—дип тәкъбир әйт. Аны олыла.

صدق الله العظيم

# МӘСЛӘГЕБЕЗГӘ ТУГРЫБЫЗ

Игажәп соң бу дөнья дигәнең! Күзгә күргәннән бирле Мәскәүнең официоз газеталары тынгы белми. Аларга үзәк телевидение каналлары кушылды. Соңрак бу шау-шуны Татарстандагы урыс телле кайбер газеталар күтәреп алды. Дәүләт Думасында ыгы-зыгы башланды. Белми дә торганбыз, баксаң, Русия Федерациясенең бөтенлегенә куркыныч яный икән бит! Һәм кайдан диген әле. Бу куркыныч, бу афәт Татарстаннан килә икән. Татар халкының үз язмасын латинга күчерергә ниятләве, дөресрәге, яңадан латин имласына әйләнеп кайтуы, аз да түгел, күп тә түгел, Рәсәйнең җимерелүенә сәбәп булырга мөмкин икән, ягъни аның дәүләт иминлегенә куркыныч тудыра икән. Күпмедер вакыт үткәннән соң рәсми "Российская газета"да "Нам, татарам, не все равно" дигән баш астында татар халкына мөрәҗәгать тә басылып чыкты. Үзләрен татар халкының киләчәге өчен көне-төне баш ватучылар итеп күрсәтергә теләгән бер төркем кешеләр татар халкын акылга килергә, латин имласыннан баш тартырга чакыралар. Юкса, алар фикеренчә, без дөнья цивилизациясе арбасыннан төшеп калачакбыз, имеш! Кайчандыр борынгы акыл ияләре "Иң яхшы дару–вакыт" дигән. Шулайдыр! Вакыт барысын да үз урынына утырта. Тора-бара бу мөрәҗәгатьнең Мәскәүдәге мәгълүм бер даирәләр тарафыннан махсус оештырылганлыгы ачыкланды. Имзалары күрсәтелгән байтак кына шәхесләр андый мөрәҗәгатькә кул кую түгел, хәтта аны күргәннәре дә булмавы хакында белдерделәр. Куелган хәтле имзаларның да кемнәрнедер юмалап, кемнәрнедер өркетеп җыелганлыгы сизелә. Кемнәрдер, бәлки, Татарстан җитәкчеләренә хөсетлегеннән кул куйгандыр. Анысын аларның үз намусында калдырыйк. Мөрәҗәгатькә кул куйган мәскәүле милләттәшләребезгә бирәсе килгән сорау да тел очымда кымырҗый: кайсыгыз үзегез бик сөйгән кириллица хәрефләре белән татарча чыккан матбугатны укып бара соң? Әгәр укысагыз, 800 меңнән артык татар яшәгән Мәскәүдә "Казан утлары" журналын алдыручылар саны ике дистәләп кенә булмас иде кана.

Ләкин иң гаҗәпләндергәне шунда, татар халкына "изгелек" теләүче бу кешеләр моннан тугыз ел элек кайда булганнар икән?! Чөнки татар имласына латин хәрефләрен кайтару турындагы беренче карар әле 1992 елда ук, беренче Бөтендөнья татар конгрессында бертавыштан кабул ителгән иде. Шул ук карарны Икенче конгресс делегатлары да хуплады. Татарстан Язучылар берлеге җыелышы да шундый эчтәлектәге карар кабул итте. Ярар, болар күптәнрәк булган вакыйга, хәтере кыскарак кемсәләрнең аларны онытып җибәрүе дә мөмкин дип фараз итик. Ләкин латинга күчәргә әзерлек, аның буенча фикер алышу бик озак дәвам итте югыйсә! Татар газеталары, журналлары хәреф үрнәкләрен дә тәкъдим иттеләр, орфография кагыйдәләре дә басылып чыкты. Әйтәсе килгәнен әйтергә теләгән кешегә вакыты да, матбугатта мәйдан да җитәрлек иде. Инде килеп,

1999 елда Татарстан Президенты М. Ш. Шәймиев "Латин графикасы нигезендә татар алфавитын торгызу турында" Законга кул куйганнан соң үткән ике елдан артык вакыт эчендә дә авызга су капкандай утырмаска мөмкин иде. Ярый, хәерлегә булсын! Аңлаган кешегә аңламаслык түгел. Татарстанның мөстәкыйльлегенә карата үткәрелүче басымның инде тел һәм әдәбият, мәгариф һәм мәдәният өлкәсенә дә күчә баруы турында сөйли бу ыгы-зыгы.

"Казан утлары" байтак еллар үз укучыларын гарәп имласында уку һәм язу үрнәкләре белән таныштырып килде, соңрак журнал битләрендә, әбүнәчеләр теләген искә алып, әдәбиятыбыз классикасыннан кайбер үрнәкләр, мәкаләләр һәм хәзерге әдипләр иҗаты латин имласында да бирелә башлады. Ничек кенә булмасын, без үз мирасыбыздан баш тарта алмыйбыз. Гарәпчә язылганы да, латинчасы да үзебезнеке, үзебезнең әдәби һәм рухи мирасыбыз, ул безнең имлабыз тарихы сәхифәләре, һәм, ниһаять, безнең бүгенгебез һәм киләчәгебез.

Моны журнал укучылар да бик яхшы аңлый. "Бар микән хәзер Рәсәйдә латин хәрефләрен танымаган хет бер мәктәп баласы?–дип яза Мәскәү шәһәреннән **Ким Насретдинов.**–Бөтен мәктәпләрдә чит ил телләрен (инглиз, алман, француз) өйрәнәләр. Татар теленә латин имласы тәңгәлрәк килә икән, ник аңа каршы килергә инде?! Читтә торган кардәшләр аерылып кала, имеш. "Какая трогательная забота"! Тел бит үзгәрми, хет татарча яз, хет русча. Һичшиксез латин имласын кертергә кирәк.

Ник бездән–Татарстаннан читтә, еракта торучылардан сорамыйлар соң? Аларга без кирәкми, безне бетерергә, урыслаштырырга кирәк. Аларның рөхсәтен беркайчан да ала алмабыз. Татарстан хакимияте дә үз файдасына зарар килмәсен дип курка. Бернигә дә карамыйча үзебез көчеп, аларны факт алдында калдырырга кирәк. Шуңа күрә журналларда, газитләрдә латин имласында материалларны күбрәк бастырырга кирәк, халык иялешә торсын".

"Яңа алфавитка күчү, дөресрәге, латинга кире кайту бик кирәкле эш. Мин аны 1929 елдан 1940 елга кадәр файдаландым, укыдым һәм хәзер дә дөрес итеп яза һәм укый алам. Бик уңайлы иде, язма телебез саф татарча яңгырашлы иде. Кириллица алфавитына күчерү бары тик политик сәбәпләр аркасында гына булды. СССРдагы барлык халыкларны бер милләткә–совет милләтенә әйләндерергә, ягъни урыслаштырырга омтылу ята иде ул гамәлнең нигезендә. Моны бик ачык аңлыйбыз, беләбез бит!"

Бу юллар Башкортстанның Мәләвез шәһәрендә яшәүче **Т. Хәкимова** хатыннан алынды.

Шушы хат белән ул "Кызыл таң" газитендә басылган "Күчәбезме?" исемле мәкаләне дә җибәргән. "Башкортстандагы татар мәктәпләре латин алфавитына күчәчәкме?" дигән сорауга Башкортстан Республикасы Халык мәгарифе министры урынбасары Миндебәй Юлмөхәммәтов болай дип җавап биргән:

"Башкортстан мәктәпләрендә татар телендә укучы балалар латин алфавитына күчмәячәк. Ул безнең республика җитәкчелеге кабул иткән закон түгел". *("Кызыл таң", 23 июнь 2001 ел).*

"Менә шундый хәлләр! Беләм, бу хәлне сез турыдан-туры үзгәртә дә, безнең күпчелек татар халкы теләгәнчә, аны Башкортстанда үткәрә дә алмыйсыз,–дип дәвам итә Т. Хәкимова.–Иң аянычлысы шунда, хәзерге заманда бердәмлек җитми. Ә ул иң мөһим бер категориядер. Шул бердәмлек булмау аркасында, тарих күрсәткәнчә, без җиңелдек һәм киләчәктә дә җиңеләчәкбез. Мондый эшләрне бергә булып, бергә тормышка ашырырга иде дә бит... Югары власть башында утыручылар моны аңларга, эшләргә тиешләр".

Татарның нинди имлада укырга тиешлеген татардан башка

беркем дә хәл итәргә тиеш түгел. Ә татар халкы, аның бөтен дөньядан, шул исәптән, Башкортстаннан да килгән делегатлары үз сүзен әле 1992 елда, Бөтендөнья татар конгрессында ук әйткән иде. Инде Башкортстанга килгәндә шунысын гына әйтергә кала, анда яшәүче татарлар да республиканың тулы хокуклы гражданнары. Алар да Башкортстан казнасына налог түли. Мәгарифкә һәм мәдәнияткә тотылган акчаның үзләре түләгәнчә күләмдә аларга кайтырга тиешлеген дә алар белми түгел. Теләсәләр латинча да укырлар, гарәпчә укырлар, телиләр икән, иероглифлар белән дә язарлар, укырлар. Бу аларның эчке эшләре. Башкортстан җитәкчеләренең бу гамәленә бары тик шулай дип җавап бирергә генә кала. Нинди имлада һәм нинди телдә укырга икәнен бары тик халык, татар халкы үзе генә хәл итә ала. Соңгы сүз аларда! Без башкортның эчке эшләренә тыкшынмаган кебек, аларның да татарның эчке эшләренә, гаилә хәлләренә борын тыкмауларын таләп итәргә хакыбыз юкмы?!

Инде килеп шундый бер риторик сорау бирәсе килә: Мәскәүнең кайчан да булса татарга яхшы булсын дип, татар мәдәнияте гөрләп чәчәк атсын дип тырышканы бармы? Тырышсалар, үзләре үк үрнәк күрсәтерләр, Мәскәүдә кайчандыр эшләгән татар театрын торгызырлар, нәшриятларны, мәктәпләрне яңадан ачарлар иде. Ул гына да түгел, әле күптән түгел генә Россия Федерациясенең Милли мәсьәләләр белән шөгыльләнүче министрлыгы гомумән дә бетерелде. Әйтерсең, Русиядә милли мәсьәлә юк! Без Мәскәүгә беркайчан да кирәк булмадык, аңа безнең байлык кына кирәк иде. Инде хәзер барлык тапканыбызның 70 процентын умырып барып та тынычланырга исәпләре юк кебек. Шушы ук язмыш башкортларны да, Башкортстанны да көтмимени?! Мондый очракта Русиядәге икътисади яктан иң көчле ике республиканың берләшеп, бер сүздә булып эш итүе генә хәлебезне азмы-күпме җиңеләйтә алыр иде. Һәм икътисадта, һәм мәдәнияттә, һәм тел-мәгариф өлкәсендә.

Ә инде яңа имлага килгәндә, Сезнең үтенечегезне дә искә алып, хөрмәтле укучылар, "Казан утлары" киләчәктә дә латин хәрефләре белән язмалар бирүен дәвам иттерәчәк.

**Флүс ЛАТЫЙФИ,**
*баш редактор урынбасары*

# «ALTAYLI» TATAR ŞAĞİRE

Yağqub Aymanov icatı belən min siksənençe yıllar axırında, Ğ. İbrahimov isemendəge Tel, ədəbiat həm sənğət institutının qulyazmalar həm tekstologiə bülegendə «Yegermençe ğasır başı tatar lirik poeziəse» antologiəsen təzegəndə oçraştım. Anıŋ şiğerləre ğasır başı uquçılarına məşhür «Şura» jurnalı (Orenburg), «Qoyaş» gazetası (Qazan) səxifələre, Qazanda həm Semipalatta basılğan ike kitabı aşa ireşkən bula.

Annan birle küp sular aqtı. Ber ğasır çaması ğəmer ütte diərgə də yanydır. Bəlkem, xəzer inde bu şiğerlərgə iğtibar itərgə də kirəkməs? Ul çorda da uyxislərne rifmalaştırıp birergə omtılış zur bulğan, küplər yaŋa tuğan tatar waqıtlı matbuğatı bitlərendə üz isem-psevdonimın kürergə tırışqan. Əmma Yağqub Aymanov əsərlərə belən tanışa başlağaç, antologiə təzegəndə meŋnərçə şiğertezməne uqıp, çın poeziə cimeşləren ezləp, saylap alıp şaqtıy «qırıslanıp» kitkən bulsam da, min şatlıqlı minutlar kiçerdem. Çөnki sovet çorındağı şiğer basmalarında, fənni tikşerenülərdə iskə-sanğa alınmağan bu avtor, çınnan da, şağirlek sələtenə iə bulıp çıqtı. Başta uq küzgə taşlanğanı şul: əsərlərə məğrifətkə, əxlaqlılıqqa өndəw belən ütədən-ütə suğarılmağan, alarda didaktika, üget-nəsixət, wəğəzçelek bөtenləy yuq. Şiğerlərdə tağın ber nərsəne oçratmadım: bu zarlanu, üz yazmışınnan, tirə-yündəge xəllərdən, tormış-yəşəyeştən zar-intizarlıq. Qayberəwlər kebek minminen bar nərsədən өsten quyıp, zaman belən, ictimaği moxit, çordaşlar, zamandaşlar, milləttəşlər belən konfliktqa kermi, alarğa ləğnət tə uqımıy Aymanovnıŋ şaqtıy üzençəlekle lirik geroyı.

Məğlüm ki, şağirneŋ (xəyer, ğadi uquçılarnıŋ da) xis-kiçereşlər dөnyası başlıça dürt tөrle sfera belən bəylənештə yəşi: məxəbbət, çor-zaman, tabiğət, tarix. Ğədəttə şiğri icatta bolarnıŋ bөtenese də bertigez dərəcədə gəwdələnə almıy, qaysı da bulsa berse genə өstenlek itərgə mөmkin. Yağqub Aymanovqa kilsək, şunı kürəbez: anıŋ kiçereşlər dөnyası başlıça tabiğəttən alğan xistoyğılar belən xərəkətkə kilə, şunlıqtan anıŋ lirik icatı başlıça tabiğət lirikası sıyfatında bəyələnergə tieş.

Cir yөzendə geografik şartlar, tabiğət küreneşlərə tөrle urında tөrleçə bulğanlıqtan, şağirlərdə də tabiğət taswirı ber rəweştə genə çağılış tapmıy. Diŋgez yarında yəşəp icat itüçe şağirlərneke tawlı cirlərdə ğəmer kiçermeş qələmdəşenə oxşamas. Şunlıqtan uquçıbız küŋelendə «qaysı yaq tabiğətenə xas küreneşlər belən xozurlanıp icat itə soŋ Aymanov?» digən soraw tuuı da mөmkin. Ğəmer-ğəmerdən tatarlar yəşəgən tirəlek çağılamı aŋarda? Yuq, Qazan artı, Taw yağı, Tambov urmannarı, ğөmumən, İdel-Yortnıŋ, İdel-Ural tөbəgeneŋ küŋellərebezne biləp torğan maturlığın surətləmi ul. Anıŋ icatına, qayçan ğına qarama, Altay tөbəgenə bəyle obraz-surətlər, detal'lər, mifologik tөsmerlər kilep kerə. Bilgele inde, Qazan tarafında yəşəp yatıp yazmağan andıy əsərləren şağirebez. Bu—Yağqub Aymanovnıŋ şəxsi tormış-yazmışı belən bəylelek nəticəse.

Qayda tuğan, qaylarda ğəmer kiçergən soŋ bu şağir? Mondıy sorawlarğa cawap ezləp ğasır başı matbuğatına da, başqa tөr çığanaqlarğa da mөrəcəğət itep qaraw əlləni küp məğlümat birmədе, tabılğan qədərese bik az: Səyfi Qudaş ber yazmasında anı qazaq (!!!—**Z.R.**) şağire dip atıy, Ufanıŋ «Ğaliə» mədrəsəsendə uqığanlığın əytə. Bezgə oçrağan iŋ berençe «Gəl» isemle şiğerendə avtor üzen «Ufa şəhərendəge «Mədrəsəi Ğaliə» taləbennən qapallı Yağqub Aymanov» itep kürsətə. Өçençeseneŋ axırında «Ufa. Qazaq» dip quyılğan. Tağın ike şiğerendə ul üzen Qapallı dip atıy. Əytergə kirək, bu çor matbuğatında şaqtıy yış telgə alınğan Qapal—qazaq cireneŋ kөnçığışındağı ber şəhər ul, tatarlar monda şaqtıy küp bulğan, tatarça spektakl'lər də

quyılǧan. Ber ara biredə tatar zıyalıları da (məsələn, Zarif Bəşiri) yəşəgənlege bilgele. Aŋlaşıla ki, Ufaǧa Y. Aymanov şul yaqlardan kilep çıqqan. Bıltırǧa qədər anıŋ turında bar belgənnərem şular ǧına ide.

Yaǧqub Aymanovnıŋ antologiəbezgə (qızǧanıçqa qarşı, kitap rəweşendə basılǧanı yuq) kergən qayber şiǧerləren «Miras» jurnalında çıǧarǧaç, akademik Mirqasim Ǧosmanov miŋa Qazaqstanda yəşəgən çaqta Aymanovnıŋ enesen kürep belgənlegen, şaǧir üze isə şəxes kul'tı qorbanı buluın xəbər itte həm, Qazaqstannıŋ iminlek organnarınnan soratıp alıp, anıŋ cinayət eşenə qaraǧan dokumentlar belən tanışu məmkinlegennən faydalanırǧa kiŋəş birde. Tatarstannıŋ iminlek organnarı, bezneŋ institut citəkçelegeneŋ sorawına cawap itep, Qazaqstannıŋ şundıy uq organnarına mərəcəǧət ittelər. Həm küptən tügel miŋa bu dokumentlar belən tanışu məmkinlege tudırıldı. Alar Qazaqstan respublikası Milli iminlek komitetınıŋ Pavlodar əlkəse buyınça departamentında saqlanǧannar.

Yaqub Aymanov (ətise iseme kürsətelmi) 1891 yılda Alma-Ata əlkəseneŋ Taldı-Qurǧan awılında (xəzer əlkə üzəge, şəhər) tuǧan, milləte buyınça tatar. Ufanıŋ «Ǧaliə» mədrəsəsen təmamlaǧaç, tuǧan yaǧında məǧəllimlek itə. Revolütsiədən soŋ uqıtuçı bulıp eşli. Utızınçı yıllardaǧı repressiə anı da çitlətep uzmaǧan. 1937 yılnıŋ 15 oktəbrendə Aymanovnı, Pavlodar şəhərendə tatar məktəbe mədire bulıp eşləgən cirennən, 1917 yılǧa qədərge çorda islamçıl xərəkəttə qatnaşqan dip qulǧa alalar. Berençe soraw alu biş kənnən soŋ ütkərelə həm anı, 1915-1916 yıllarda Qapaldaǧı opolçenie drujinasında muzıkant bulǧanlıǧın da istə totıp, milli faşistik oyışma əǧzası sanap, ǧəyepləren tanırǧa quşalar, ləkin Aymanov əç mərtəbə sorawnıŋ bersenə də uŋay cawap birmi. İke kənnən soŋ anıŋ yəşəgən cirendə tentü uza həm nindider qoyı yanında cirgə kümep yəşerelgən revol'ver tabıla. 24 oktəbrdə təzelgən aktta Aymanov soraw alu waqıtında üzeneŋ xalıq doşmanı ikənlegen tanuı həm kontrrevolütsion oyışmanı, anıŋ çlennarın satmayaçaǧı terkəlgən. Ləkin Aymanov aŋa imza quyudan baş tartqan. İrtəgesen soraw alu E. Əmirov digən şahit qatnaşında ütkərelə. Bu keşe, Barmakov digən berəwneŋ Aymanov turında səyləgənnərennən çıǧıp, Aymanovnı milli-faşistik, kontrrevolütsion Alaş-Orda oyışmasınıŋ əǧzası bulıp toruın əytsə də, Aymanov üzeneŋ mondıy oyışmada tormawın, ǧəyıple sanamawın belderə. Şuŋa da qaramastan, operupolnomoçennıy yərdəmçese, keçe leytenant Smagul Qosubayıv, ǧəyıpləw süzen yazıp, anda Aymanovnı uqu plannarın əzüçe, yəşlərne kontrrevolütsion ruxta tərbiyələwçe sıyfatında kürsətə. 29 oktəbrdəge əçlek utırışında qulǧa alınǧan un keşeneŋ (ber tatar həm tuǧız qazaq) eşe qaralıp, bişesen cəza birüneŋ iŋ yuǧarı çarasına — atıp üterügə, qalǧannarın isə un yılǧa xezmət belən təzətü lagerena cibərügə xəkem itələr. Şulay itep, repressiv orǧannar taǧın ber tatar şaǧiren yuqqa çıǧara.

Ləkin Yaqub Aymanov əsərlərenen basılǧan qədərese yuqqa çıqmadı həm ul bügen də «yəşərgə», yəǧni uqılırǧa, əyrənelergə tieşle icat.

Yuǧarıda bu şaǧir əsərlərenen lirik-tematik eçtəlegendə, şiǧri yanǧıraşında tabiǧət küreneşlərе belən bəylelek əstenlek ala dip əytkən idek. Altay təbəgendəge tawlar, urmannar, yılǧalar belən xozurlanıp yazǧanda, bilgele ki, avtornıŋ eçke dənyası da çaǧılış taba. Ul şaqtıy dərəcədə küzətüçe sıyfatındaraq kürenə, serle küŋelen biləgən xis-toyǧılar tınıç buyawlarda gəwdələnə, kiçereşlər urǧıp-qaynap çıqmıy. İkençe ber nərsə də bar anıŋ şiǧerlərendə, balladalarında: bu — Altay təbəgeneŋ ütkənenə bəyle tarixi şəxeslər, mifologik obraz-surətlər. «Tabiǧət» kitabı, məsələn, «Altayǧa Çınǧıznıŋ kilüe» şiǧere belən açıla. Anıŋ:

Taw başların cimergəndəy, qatı, kəçle,
Güeldəp dawıl çıǧıp taǧı iste.
Aǧaç, taş, taw eçləren yanǧıratıp
Şunda küktən kiŋ cilkəle berəw təşte.
Qarandı tərle yaqqa, tawǧa basıp,
İglan itte, min — Çınǧız, dip, ismen açıp,
Şul cirne ǧəyrətenə məskən itep,
Şatlanıp Altay ilə sələmləşep.

Şatlıǧın xəl telennən səyləp tawda,
Yaltırap qarşı alǧan yoldız, ay da,
Uyanıp barça qoşlar, sanduǧaçlar
Çüeldəp sayrap quydı menep talǧa.
Taŋ ata, aşıǧıp tən təsen cıya,
Qoyaş ta tawdan qarıy, yəze kələ.
Tabiǧət xanı belən maqtanışa,
Quaqlar sələm səyləp başın iə, —

digən yulların uqığanda avtornın ul yıllar poeziəsendə (məsələn, Nəcip Dumawida) romantik buyawlarda çağılış tapqan Çıngız xan obrazın ideallaştıruın kürəbez. Şunısı qızıq, əlege şiğer əwwəl tapqır «Şura» jurnalında (1912 yıl, 8 san, 248 b.) basılğanda: «İğlan itte, min — Çıngız, dip, ismen açıp» digən yulı təşerep qaldırılıp, anın urınına küpnoqtalar ğına tezelgən, axırdan ikençe yul da «xanı» süzesez genə kiterelgən (qısqası, uquçığa tekstnı jurnaldağılar ğayət tə bozıp təqdim itkənnər). Y. Aymanov «Ülün əkənen ülüe» isemle ikençe ber şiğerendə Çıngız xannın anası Ülün əkənen Çıngıznın atası Yəzükəy «qəbren qoçıp yığlap» şul qəbergə kerep kitüe surətlənə. Bu çaqta tabiğət tə bitaraf qalmıy: çişmələr yığlıy, taşlar awa, taw başları tetri, yəşen yəşni. «Dənyağa atlarnın elek çıgu» şiğerendə məğlüm mifologik motiv — «Matur atlar yəzep tulqın eçennən» kilep çıgu «Yıraq Altay — tərek yortı» belən bəylənеştə gəwdələnə:

Səyekle atlar elek şunda tanıldı,
Matur Altay tawında anlar tabıldı,
Anın monlı buyında üste, yaraldı,
Adəm dustı bulıp şunnan taraldı.

1914 yılda Semipalat şəhərendə Y. Aymanovnın «Saman» isemle küləmle poeması ayırım kitap bulıp çıqqanlığın yuğarıda əytkən idek. «Yoldız» ğazetası bitlərendə (1915 yıl) ana Ğarif Musin yuğarı bəyə birə, əsərne tarixi poema dip atap: «Yağqub Aymanovnın «Saman»ında məğlüm ber dəwerdəge bəten tərek xalqının tormışı taswir itelgəngə, ul — poema, məwzuğı tarixtan alınğanğa — tarixidır», — dip, əsərnen janrı xaqında üz fikeren əytə.

Poemanın eçtəlege waqıyğalarğa şaqtıy bay həm ul başlıça məxəbbət sujetına qorılğan. Curat isemle tərek qəbiləse xanının Salixay atlı qızı Yəsükəy (Çıngız atası) qabiləsenen bahadir yegete Samanğa ğaşiq bula. Bu ike qabilə arasında doşmanlıq yəşəgənlektən, yəşlər quşılmasqa tieşlər. Alar küreşkən waqıtta Salixaynı küzətergə cibərelgən saqçılar kilep çığıp, Samannı cərəxətlilər həm, ülde dip uylap, anı taşlap, Salixaynı alıp kitələr. Ləkin Saman ülmi, Kükçə isemle tərek (tərki) əwliyəsenə: «Min tağın Salixay belən qawışa alırmınmı?» — dip mərəcəğət itə. Əwliyənen cawabı:


— Beləm, əy yeget, başın yəş kəndə
Ul qız utırğan sinen künеldə.
Ləkin bulmas ul sinen can səygən,
Sezgə yazmışnın qəhre birelgən...
Sina süzem şul: ildən, cirdən biz!
Bu eş artınnan yərmə, cənüb giz!

Berniçə yıl ütkəç, Salixay Saman qəbere bulırğa tieşle cirgə kilep çığa həm şunda üz-üzen həlak itə. Tağın berniçə yıl ğəmer uzğaç, Saman da bu yaqlarğa qayta həm, Kükçə əwliyədən xəlne belgəç, Salixaynın qəberenə kilep, pıçaq belən üz-üzen suyıp ğəmeren betərə.

Ğarif Musin üzenen risenziyəsen tübəndəge süzlər belən təmamlağan: «Bu kengə qədər bezdə «Saman» zurlığında hiçber original'nıy əsər (şiğer qisemennən) çıqqanı yuq. Yağqub əfənde Aymanov cənablərenə ütkən tormışıbıznı şulqədər matur wə şulqədər canlı qıylıp kürsətkəne eçen çın künеldən rəxmət əytep, anın talantı aldında baş iəmez. Kiləçəktə anın şundıy çın ədəbi əsərlərе ədəbiatımızğa hədiə *(bülək — Z. R.)* itüenə əmidebez tamdır *(tulıdır, zurdır — Z. R.)*».

Əmma bu əmet çınğa aşqanmı-aşmağanmı — bez belmibez, çənki Y. Aymanovnın 1915 yıldan son ədəbi icat eşe belən şəğıllənü-şəğellənməwe turında beznen qulda bernindi də məğlümat yuq. Qazaqstan cirendə barğan qatlawlı ictimaği tormış, sovet xakimiəte qullanğan repressiv çaralar ana tatar şiğriətenə xezmət itərgə qomaçawlağanmı, başqa tərle səbəplər çığıp torğanmı, anın 1915 yıldan sonğı matbuğatta ber genə əsəre də kürenmi. Bəlkem, anın ğailəse arxivında nərsədə də bulsa saqlanadır? Ətilərе qulğa alınğan çaqta Məskəw konservatoriəsendə uqığan ulı Cəwdət Aymanovqa 17, ikençe ulına (Ture, Tolya — ?) 13 kenə yəş bulğan bit əle...

**Zəfər RƏMİEV**



## Әдхәт Синугыл

### ФӘРДЛӘР

*Фәрд—гарәпчә икеюллык шигъри шәкел төшенчәсен аңлата. Шигъриятtә фәрд жанрында язылган икеюллыклар Якын вә Урта Шәрык мәмләкәтләре әдәбиятында киң таралыш тапкан. Алар дөнья әдәбияты классикларыннан Сәгъди, Хафиз Ширази, Низами Ганжәви, Баба Фәрид, Бабур һәм татар шигъриятендә Дәрдмәнд кебек шагыйрьләр иҗатында бар.*

*Иң кечкенә поэзия жанры буларак, фәрдтә әйтеләсе фикер аерым бер икеюллыкта гәүдәләнеш таба. Эчтәлекләре ягыннан мәкаль вә әйтемнәргә яки канатлы сүзләргә тартым булган фәрдләрдә афористик яңгыраш типик күренеш санала. Назым шәкелендәге фәрдләрнең кафияләшү тәртибе а—а рәвешендә кабатланып килә. Кайбер очракта а—б формасында кафияләшүче фәрдләр дә күзгә чалына.*

*Фәрд жанрына караган әсәрләр арасында шулай ук үгет-нәсихәткә нигезләнгән—чәчмәдә язылганнары да очраштыргалый. Бу очракта алар, Нәваи иҗатында күренгәнчә, «хикмәтле сүзләр»не хәтерләтәләр...*

*Фәрд шәкелендәге шигырьләремнән бер бәйләмне мин дә олуг басмабыз—«Казан утлары» аша укучыларыбызга тәкъдим итәм. Кабул кылсагызчы...*

*Автор.*

**Бар да изге, бар да әйбәт ниятләләр,**
**Гаепләләрне эзли... бар гаепләләр.**

**Халкың алдында бозау бул тынычларда,**
**Арыслан бул иркең яклап сугышларда.**

**Йодрыклар бер йомарланса, инде чыда,**
**Бармаклардан—чүкеч кебек—очкын чыга.**

---

Әдхәт СИНУГЫЛ *(1935)—Кырымда яшәүче татар шагыйре. Татар, кырымтатар телләрендә басылган унга якын лирика, балалар өчен һәм тәрҗемә китаплары авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.*

Ни дисәң дә ишәк ишәк булып кала,
Асканда да патшаны—эше юк анда.

Агачтан тик агач кына үсә ала,
Миләштән һәм беркайчан да көтмә алма.

Юлны күз күрсәтә дип бирмә күрсәтмә,
Күздән дә яхшы тормыш юлны күрсәтә.

Аерган хатынның түгел гәүдәсе дә,
Җен кебек күренер хәтта шәүләсе дә.

Кылыч телгә килгәнче минут та ашмый,
Тел башны телгәләп-тураклап та ташлый.

Кабып йотар алдыннан яман сүз катмый,
Төлке тавык ахирен үтереп мактый.

Типсә дә бия колынга тибә белә:
Беркайчан тибеп аны имгәтми бия.

Яшь яңгырын койган адәм сирәк түгел,
Яшь кою өчен бит күп су кирәк түгел.

Кеше инде—кеше, ул әүлия түгел...
Ике кеше бирәүгә армия түгел!

Ур-ра кычкырсалар да бар җиңүчеләр,
Җиңүчеләрне дә килеп җиңүче бар.

Тәрәзнең дә үзенә күрә киеме...
Биемнең дә үзенә карап килене.

Чукрак белән җыр турында киңәшмиләр,
Сукыр белән яктылыкка көнләшмиләр.

Кырда әрем корса ни дә, корымаса ни,
Начар адәм торса ни дә, тормаса ни.

Һәр көнне без көтеп алалмый шашабыз,
Һәркөнне без гомер белән хушлашабыз.

Караңгы караңгы инде, ни эшләмә,
Караңгыда караңгы эшләр эшләнә.

Уфа җилләре искәндә буйга исә,
Казан җиле аркылы да, буй да кисә.

Пешекли алса пешекче пешекчене,
Сихерли алмый сихерче сихерчене.

Ат булмассың син, арба булып, дуласаң,
Хак сөйләргә хакың да юк—пакь булмасаң!

Бөеклек дәгъва кылмыйча бөеклек кыл,
Шаяртканда да тоз кебек микъдарын бел.

Аракыдан исереп, кеше үлә дә,
Мәхәббәттән исерсә ул—тилерә дә...

Гадәтләнсәң, куркуның да кими көче,
Мактанчыкның тышына ошамый эче.

Көч белән Гаделлек берләшкәндә бергә,
Аннан да көчле Берлек булмастыр җирдә.

Чыдамаучы бәхетсезлеккә—бәхетсез,
Акыл сүзе юл табар акыллыга тиз.

Җан ул кыйммәт синең кебек башкага да,
Җандай кыйммәт хакыйкать туу анда да.

Шәүләң бөеклеге әле ул син түгел,
Бәхәстә чигенә белгән акыллы гел.

Алтынны була төсенә карап белеп,
Кешенең төсенә карап—кара белеп!

Саклауга караганда телдән тирән сер,
Җиңел саклау телдә күпкә кайнар күмер.

Туганнар белән дошманлашу зур хата—
Ят белән дошманлыктан да авыр хәтта.

Берәүне дә тыңларга теләми сөйләү—
Эреләнеп, үз-үзең Аллага тиңләү.

Йөз-килбәт ул көзгедә яхшы чагыла,
Эчке дөнья—әңгәмә барган чагында.

Хәтер калуны саклау—акыл кимлеге,
Калган хәтерне җую—акыл җиңүе.

Коры сүз ул эшнең фәкать күләгәсе,
Хаталану яхшы белмәүлек бәласе.

Йокы һәм дә йокысызлык китсә артып,
Икесеннән дә яхшылык көтмә артык.

Күпме йолдыз исәпләнсә Күк илендә,
Шунча хәйлә хатын-кызларның кальбендә.

Берәүдә дә даими бәхет булалмый,
Дошманлашкан дус дошманнан айрымланмый.

Өреп тә, йотып та булмый бер үк вакыт,
Тормыш мәшәкатьле чакта кирәк шатлык.

Галимлек—ачы тамыр, татлы җимеше,
Акыллылык—киләчәкне дә күрүче.

Бер үк эшне эшләсә дә ике кеше,
Бер үк нәтиҗәне бирми алар эше.

Икеләнгән кеше бүленә икегә,
Өйләнсә дә, өйләнмәсә дә үкенә.

Фани дөнья йорты—безнең кунакханә,
Бакый дөнья—ул безнең Мәңгелек ханә.

Үз тинтәклеген аңлаган тинтәк түгел.
Мәхәббәттә ант бозу җинаять түгел.

Котылгысыздан курку түгел акыллы,
Дошман белән куркактан куркыр акыллы.

Үз дәрәҗәсен кайгырткан күп күбен дә,
Үз намусларын кайгырткан аз күренә.

Алтынны ут, хатын-кызны сыный алтын,
Хатын-кызлар сыный гомер ир-ат халкын.

Озынлыгы белән булмый озын гомер,
Эчтәлеге белән озын була гомер.

Акчаң аз икән, мәшәкатьләрең дә аз,
Көндәшләрең аз икән, уңышың да аз...

Камил кеше язмышын бер дә каргамый,
Урап кайтмас җиргә беркем дә соңламый.

Хата белән кеше кумелгәндә үзе,
Үз хатасын да танымый аның күзе.

Сөйләгәндә аз сөйләр өчен күп тыңлап,
Кешегә бирелгән бер тел, ике колак.

Башканы гел буйсындырырга теләүче—
Үз теләгенең колыдай колбиләүче!

Атаның катылыгы шәп дару-дәва,
Татлы ул ачы булуга караганда.

Намуслылык тудыра гел гадел җанны,
Ә гаделлек гаделсезләргә зыянлы.

Дөньялыкта мөгаен юктыр авырдан—
Авыр кайгыда кирәкле сүз табудан.

Дәлилгә каршы торырлык дәлилләр юк,
Ирекне бәяләп бетерер сүзләр юк.

Өйрәтмәгән яугирне яуга озату—
Хыянәт итеп аңарга, аны сату.

Мәшәкатьтән курыккан кеше баемый,
Тормыштан ләззәт тапканнар ярлы булмый.

Бер адәм бер энә урлап җәза ала,
Берәү Илне талап хаким булып кала!

Курку күпчак алдау-йолдауга этәрә,
Ачу килү гаделсезлеккә китерә.

Сәламәтлек өчен һәрчак эш зарури,
Кануни булса максат, чара—кануни.

Егылганны торгызганда гына иел,
Син дә бүген кичәге инде син түгел.

Дошман хатасына уйламый абынма,
Сабыр акыл гына җиңә тик барын да.

Ата була белгәннән өйрәнсен ата,
Кирәкмәгәнне онытсаң, акыл ота.

Ялган тудыргач, ялганны тышаулыйлар,
Ялганчы дөрес әйтсә дә ышанмыйлар.

Язылмаган кай канун—иң көчле канун,
Кораллар телгә килгәндә—телсез канун!

Еланнарны чакмый беркайчан еланнар,
Күпме кол булса, шунча җирдә дошманнар.

Гөнаһ кылучылар бар да гөнаһ колы,
Җир асты патшалыгының бер тик юлы.

Гаделсезлек таянычы көч вә ялган,
Исереклек—язу ул теләп акылдан.

Табигать чыдавын чыдый явызлыкка,
Тик бер дә ул чыдый алмый ялгызлыкка.

Төлке тиресе ябынганнардан сак бул,
Башактан икмәккәчә юл—бик озак юл.

Вазгыятькә буйсыну ул гарьлек түгел,
Бер җинаять икенчесенә ача юл.

Ачулы кешедә була тулы агу,
Җан тынычлыгы ул бит иң яхшы дару.

Теләгәнне бирмәсәләр, ал биргәнне,
Акыл бит ул Табигать-Ана бүләге.

Кеше булган кеше ул үти үз сүзен,
Иң яхшы кеше сиңа һәрчак син үзең.

Сатылмыйдыр судагы йөзгән балыклар,
Ата-бабалар өчен түли оныклар.

Колачың җитмәгәнне син кочалмассың,
Мәхәббәт, Үлемнән дә һич качалмассың.

Масайма бик түбәм тиде дип түбәгә,
Югарылыкның нигезләре түбәндә.

Кайберәүләр алалмый үз-үзен кулга,
Үзенә хуҗа булалмаган тиң колга.

Хаклы булуыңа шикләнсәң судлашма,
Үзеңә тиң булмаган белән дуслашма.

Фани дөнья татлы бер кыска төш кенә,
Кешегә бирелгән гомер үтеч кенә.

Дәшәр җирдә дәшми калу кыюсызлык,
Дәшмәс җирдә дәшүең зур акылсызлык.

Ютәл һәм Мәхәббәтне яшереп булмый,
Оят, Шәраб, Мәхәббәт тартыну белми.

Бәхет кирәкмәгән кеше иң бәхетле,
Кан коеп ирешкән бәхет—ул бәхетме?

Җаваплылык тою өчен үз сүзеңә,
Әйтер сүзләреңне әүвәл әйт үзеңә.

Дуслыкның гомере кайчак ике күнлек,
Дуслашкан дошман ямаулы ыштан кебек.

Үз-үзеңне юкка-барга типкәләмә,
Гаебең булса, язмышка үпкәләмә.

Егетләрнең егетлек—сыйфат көзгесе,
Икеләнү—беренче акыл билгесе.

*Әдәбиятыбыз тарихына*

# «МИН СИННӘН ЕРАКЛАРМЫН, ЕРАКЛАРМЫН, ЕРАКЛАРМЫН...»

МИРХӘЙДӘР ФӘЙЗИНЕҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ

Күренекле драматург Мирхәйдәр Фәйзинең хәзерге Татарстанга мөнәсәбәте, бу яклардагы туганлык бәйләнешләре бөтенләй өйрәнелмәгән дип әйтерлек хәлдә булмаса да, бер-беребезне ишетергә бик теләмәгән-легебездән микән, бу мәсьәләгә карата бәхәсле, хәтта хата фикерләр матбугатта әледән-әле күренеп тора. Берәүләр, бернинди нигезсез генә, Мирхәйдәр Фәйзине Татарстанның Балтач районындагы Шода авылыныкы дип, әсәрләрен, бигрәк тә мәшһүр «Галиябану»ны шунда язган, дип расларга омтылалар. Мондый фикерләр бигрәк тә каләм ияләренең Балтач җитәкчеләре белән әңгәмәләрендә, бу төбәктән язган мәкаләләрендә, салпы якка салам кыстыру ниятеннәндер, күп еллар буе кабатланып килә. Икенчеләр, киресенчә, аның Татарстанга мөнәсәбәтенә әлләни игътибар итмиләр яисә аны язганда төгәлсезлек җибәрәләр. Әйтик, моннан ун ел элек, драматургның йөз еллыгына язылган бер мәкаләдә аның Шодага килеп йөрү сәбәбе апасының бу авылда кияүдә булуы белән аңлатылды. Баймак шәһәрендә җирләнгән кабер ташында драматургның милләте дә яшерелгән: «Выдающийся советский драматург Мирхайдар Файзи» дип язу белән чикләнгәннәр. Югыйсә, ул «Галиябану»ны язып «выдающийся» булганда илдә советлар да юк иде әле!

Мирхәйдәр 1891 елның яңа стиль белән 1 ноябрендә Ырынбур ягының Орск шәһәреннән ерак түгел Күкшел утарында Фәйзулиннар гаиләсенең унберенче, төпчек баласы булып дөньяга килә. Әмма аның нәсел тамырлары хәзерге Татарстан белән нык бәйләнгән. Әнисе Зәйнәпнең туганлык җепләре, Мирхәйдәр Фәйзи өстәп төзегән 14 буынлы шәҗәрә нигезендә, «Казанның Камай мирзага барып тоташа». Әтисе Мостафа Чистай өязенең Шахмай авылыннан булып, 19 яшенә кадәр шунда яшәгән, «бодай күмәче ашау нияте белән 1854 елда кечкенә арба тартып Орск ягына килеп чыккан», сагынып, җай килгәндә кайтып йөргән. Ун яшьлек Мирхәйдәрнең әти-әнисенә ияреп Татарстанга беренче сәфәре вакытында да юллары Шахмайга сугылмыйча калмый. Килүләренең төп сәбәбе Мирхәйдәрнең уналты яшькә олы абыйсы Сәетгәрәйнең туен үткәрү була. Ул Түнтәр мулласы Ишмөхәммәт Динмөхәммәтовның Фатыйма исемле кызы белән никахлашып, «Ишми ишан» кияве булачак. Моның ничек килеп чыгуын Сәетгәрәйнең олы улы, үз чорының күренекле журналисты Сәгыйть Фәйзуллин да аңлатып яза алмады. Бәлки Мостафа Фәйзуллин бу яклар белән туганлык элемтәләрен ныгытып калдырырга омтылгандыр һәм Ишмөхәммәт Динмөхәммәтов белән Чистайдамы, Ырынбур ягындамы очрашкач, кодалашырга килешкәннәрдер?

1902 елда указ алган Сәетгәрәйне, Ишмөхәммәт хәзрәт тәкъдиме беләндер, Шода авылының яңа оешкан мәхәлләсенә мулла итеп билгеләгәннәр. Драматург менә шушы гаиләгә кунакка килеп йөргән. Элек Сәетгәрәй яшәгән йортта моннан нәкъ ун ел элек Мирхәйдәр Фәйзи музее ачылды, димәк, теләгән кешегә драматург тормышын һәм иҗатын яхшырак өйрәнү мөмкинлеге туды. Ләкин, Вакыйф Нуруллин урынлы язганча, республикабыз читендәге бу музей әдипләр еш килә торган изге урынга әверелмәде әле.

Мирхәйдәр безнең якларга икенче тапкыр 1906 елда сәяхәт ясый. Алар, әти-әнисе һәм өч кыз туганы белән бергә, бер тройкада һәм бер пар атта Орскидан кузгалып Ырынбур, Казан, Чистай, Шахмай, Шода, Түнтәр, Малмыж

кала һәм салаларында булалар. Малмыжда Мирхәйдәрнең бертуган апасы Фатыйма белән җизнәсе Камал Мозаффаровлар яши, шуңа күрә яшь драматург алдагы килүендә дә бу шәһәргә тукталмыйча калмый.

1916 елның июль-август айларында безнең якларга «илле бер көнлек сәяхәт» Мирхәйдәр һәм аның иҗаты өчен дә, бөтен татар әдәбияты өчен дә иң мөһиме була. Мөһимлеге шушы сәфәрдән соң язылган «Галиябану» драмасы белән бәйле. Әсәрнең нәкъ менә Шода сәфәреннән соң ук дөньяга килүе драматург иҗатын аз-маз өйрәнүчеләргә (ә бәлки өйрәнмәгән килеш язып чыгучыларгадыр) «Галиябану»да сурәтләнгән фаҗигале вакыйгаларны шушы авыл белән бәйләү өчен зәгыйфь кенә булса да җирлек бирде. Хәтта һәр мәгълүматны үлчәп кенә дөньяга чыгарырга күнеккән тарихчы Радик Салихов белән Рамил Хәйретдинов та Шода авылы хакында «милли драматургия тарихында беренче булган «Галиябану» музыкаль драмасы нәкъ менә биредә язылган» дип раслыйлар *(«Памятники истории и культуры татарского народа» китабы, Казан, 1994)*. Чынлыкта мондый карашның бернинди нигезе юк, автор су буенда яшьләр уенын тасвирлаганда гына Шодада алган «ямьле күренешләрдән» файдаланган. Бәлки бу «изге ялган» Шода кешеләренә һәм авыл советы рәисе Гыйльмулла Дәүләтшинга авылда Мирхәйдәр Фәйзи музеенын һичшиксез ачылырга тиешлеген югары оешмалар каршында нигезләү өчен кирәк булгандыр һәм шуннан рәсми төс алып калгандыр. Кирәкле эшкә дә комачаулык ясаучылар азмы бездә? Әмма Шодада язылмавы драманың да, монда эшли торган музей-йортның да әһәмиятен һич киметми. «Галиябану» барлык татар халкыныкы булган кебек, аның авторына багышланган музей да—бөтен милләткә хезмәт итә торган рухи мирас үзәге.

Мирхәйдәр Фәйзи Шодага бу килүендә чагыштырмача озаграк тора, биредәге тормышны инде әдип буларак күзәтә, күргәннәренең бөтенесен көндәлекләренә язып бара. Бу як халкының үзенчәлекле көнкүреше, табигате, игенчелек эшләре, халыкның киенү рәвеше, яшьләрнең кичке уеннары—әдип каләменнән берни дә читтә калмый.

Сәетгәрәй абыйсы белән алар Түнтәрдә Ишмөхәммәт хәзрәттә дә кунак булалар. Драматург мондагы чиктән ашкан байлыкка игътибар итә. «Ишминең өйләре дворец кебек тора»—дип яза ул. Асты таш, өсте агач өйнең урам якта унбиш тәрәзәсе, эчендә егермедән артык бүлмәсе бар икән.

Мирхәйдәр Малмыжда Ишмөхәммәтнең улы, яңа карашлы Габделхәй Динмөхәммәтов белән очраша. Үзе дә әдәби әсәрләр язгалый торган бу кодасы белән драматург гомергә дус булып кала. 1922 елның декабрендә Габделхәйнең үлү хәбәрен алгач, көндәлекләренә шундый сүзләр язып куя: «аңлы, галим, гакыллы кодам әрәм булган. Халык эшчесе, зур хезмәтләре белән танылган талант җиргә күмелгән... Миңа аң бирүдә дә... синең тәэсирең зур булган иде. Син мине тәрбиялидер идең».

Драматург укымышлы, мәгълүматлы Сосна мулласы Сөләйман Даутов белән дә очраша, итек бастырып, аның белән күп шәһәрләрдә сәүдә итүче, Финляндия күргәзмәсендә алтын медаль алган Балтач мулласы Сабирҗан Сәгъдетдиновта кунак була. Мәҗлестә бүтән авыл муллалары да катнаша. Монда Мирхәйдәрне шагыйрь, мөхәррир дип олылап хөрмәт итәләр. Билгеле, «мөхәррир»нең Сәетгәрәй мулла энесе булуы да мондый хөрмәткә сәбәп биргәндер. Мәшһүр тарихчыбыз Равил Фәхретдинов «Кичке азан» китабында язып чыкканча *(ТКН, 1997)*, сәүдә белән шөгыльләнгән Сабирҗан хәзрәтне «раскулачивание башлангач бай мулла дип сөргенгә сөргәннәр».

Әгәр Мирхәйдәр Фәйзи бу якның муллалар тарихы белән кызыксынса яки тарихчы-галим Шиһабетдин Мәрҗани хезмәтләре белән таныш булса, биш мәхәлләле Сосна авылының мәчетләрендә һәм мәдрәсәләрендә элек тә «укымышлы, мәгълүматлы» муллалар эшләгәнен яисә укып чыкканын белер иде. Әйтик, бөтен татар дөньясында билгеле шәҗәрәгә исем биргән Әмирхан бине Габделмәннән (1771—1828)—язучы Фатих Әмирхан бабасының этисе—сабый чагында беренче сабакны Сосна мәдрәсәсендә алган. Чөнки моңа җитди сәбәп булган: аның этисе белән бертуган абзасы Сәфәр хәзрәт элегрәк үзе дә шушында белем алган, аннары ун еллап имам һәм мөдәррис булып эшләгән. Сәфәр хәзрәтнең биредә укуына да төпле сәбәп булгандыр, хәзер белә алмыйбыз гына. Әмирхан хәзрәт үзе Чистай өязе Талкыш авылыннан булып, укып белем алгач, шунда имам һәм мөдәррис вазифаларын үтәгән. Шулай итеп, Мирхәйдәр Фәйзи 1912

елда Казанга килгәч күрергә бик теләп тә, узып киткәндә «башын гына күреп» калган Фатих Әмирхан белән аның нәсел башы бер үк Чистай төбәгенә барып тоташа икән. (Казан хакимияте башлыгы Камил Исхаковның әбисенең әтисе Борһанетдин хәзрәт Төхфәтуллин да хәзерге Балтач районы Югары Кенә авылына Чистай өязенең Курманай авылыннан килгән, ул да умарталык тотып һәм башка кәсепләр белән үз тормышын властьлар күпсенерлек көйле алып барган, шуның өчен 1932 елда, авылдан бердәнбер гаилә буларак, район башкарма комитетының кулак хуҗалыклар исемлегенә кертелгән.)

Мирхәйдәр Фәйзи кайларда гына яшәсә дә, Казанны күңеленнән чыгармаган. 1920 елның июль башында, Юлыктагы өендә иске газеталар карап утырганда бер хәбәр күрә. «Апрельнең 7 сендә, чәһәршәмбе көн, Казан шәһәрендә бер көндә ике җирдә әсәрләрем уйналган (Красноармейский дворецта—«Галиябану», Мулланур Вахитов клубында—«Тәкъдирнең шаяруы»)»—дип яза драматург һәм мона сөенүен белдерә. Ә тагын биш көннән аның көндәлегенә мондый сүзләр языла: «Казанда 25 июньдә (искечә 12 сендә) татар җөмһүрияте тантаналы суретттә гамәлгә куелган. Нинди күңелле, нинди куанычлы хәл. Җанга никадәр ягымлы тоелганын тәгъриф итеп бетәр хәл юк. Яшәсен иҗтимагый татар шуралар җөмһүрияте!»

1922 елның көзеннән 1923 елның язына кадәр Уфада яшәгәндә дә Казан, Татарстан белән гел кызыксына, тынгысыз бер ашкыну белән шул тарафларга талпына ул. Бәлки Уфаның котелмәгәнчәрәк кабул итүе дә, авыруларының гел көчәя баруы да аның җанын борчып торгандыр. Шәһәргә беренче чыгуында ук ул китап кибетенең тәрәзәсе аша үзенең «Галиябану»ын күрә. «Кереп берсен бер миллион 200 мең акча биреп алып чыктым. Авторскийларын, гонорарларын алып мәнфәгатен күрү урынына, үз китабымны үзем сатып алып чыктым. Мәнфәгатен читләр күрә»—дип яза. «Урамда «Тәкъдирнең шаяруы» куелачагы хакында афиша»га юлыгып, тагын бер хәйран кала. Чөнки «кем әсәре икәнлек язылмаган. Димәк, белмиләр яки яшерәләр».

Режиссер Мортазин белән очрашып сөйләшү дә драматургның кәефен күтәрерлек булмый, чөнки аның биш пьесасын кыш буе уйнар өчен нибары йөз миллион сум тәкъдим итәләр». Әсәрләре белән ни гомер файдаланган бер мөхәррирне атналык тормышын да тәэмин итмәслек бер хак белән эксплуатацияләргә теләү, аның аптыраулыгыннан файдаланып, хиссиятен мыскыл итү төлкелек түгел дисезме? Эх, сез, кешеләр!..»

Әсәрләре бушка диярлек алынса да, тәнкыйть авторга карата шактый ук аяусыз була. «Бабич» журналының икенче санында Исмәгыйль Рәмиев «Тагын бер шарлатан» исеме астында аның «Урал суы буенда» әсәрен тәмам бетереп мәкалә урнаштыра. Янәсе, Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану»ы да кат-кат уйналып, үзе танылмаслык үзгәртелеп, «туксан тугыз иләк аша үткәрелеп» кенә шәп булып чыкты. «Ә бусы үзе язган килеш сәхнәгә куелды да изелде. Әй, егет, башың яшь шул».

Мирхәйдәр Фәйзинең мондыйлар белән көрәшергә теләге дә, физик көче дә юк. Ә җаны сыкрый. «Аз-маз бирелгән дәрәҗәгә дә көнләшеп, тәрбиясез сүгенүчеләр була икән, талаша торган бер сүзем дә юк... Шөһрәткә чыгып бара, тизрәк тәртеп төшерик, дип кенә шундый ялганнар белән дөньяга чыгуда мин төшенми торган берәр сер бар микәнни соң?» Драматургның бу «җавабы» үз вакытында дөньяга чыкмыйча, көндәлекләрендә генә калган. Ә тәнкыйтьче үз бәяләмәсендә бер нәрсәне абайлап җиткермәгән: «Галиябану» бөтен татар һәм башкорт сәхнәләреннән төшмичә «кат-кат» уйналган икән, әсәрнең мона кадәр күрелмәгән уңышы шушы бит инде!

Татарстанда, татарлар арасында үзен яхшырак аңларлар дип уйлагандыр, бәлки, драматург 1922 елда көндәлекләренә болай язып куя: «Их... татар илен сагынам мин! Рухымны иркәләгән, табигатемне борчымый торган татар тормышын сагынам. Казан, Татарстан, син кайда? Ал баланны үз куенына! Куй мине үз туганнарым арасына! Алар белән бергә яшисем килә. Эзләп тапкан гөлләрем белән аларның гына бакчасын бизисем килә...»

1923 елның 25 гыйнварында көндәлекләренә теркәлгән менә бу сүзләр Мирхәйдәр Фәйзинең Уфадагы халәтен бигрәк тә ачык сурәтлиләр. «Урамда чанага төялеп «Галиябану»ны җырлап барган татарларны тавышлары югалганчы туктап тыңладым. Йөгереп барып чаналарына менәрдәй, мин дә сезнең иптәшегез, мина бәйрәм сезнең арагызда гына, дип кочаклардай булдым. Эх, нинди

бәхетле булыр идем шулар арасында! Нинди матур җырлыйлар. Үзәкләремне өзеп, кызыктырып, үкертеп узып киттеләр халык балалары».

Менә, ниһаять, ул Татарстанда. «Күңелебезнең үз иленә чыктык»—дип куана Мирхәйдәр. 1923 елның яз азагы бу. Иҗатташлары белән сөенечле беренче очрашулар. Галимҗан Ибраһимов белән очрашуга баргач, «Яшь йөрәкләр» мөхәррироннән: «Авыл тормышын нечкә аңлап, аны садә, җиңел, матур итеп күрсәтә алуда син ялгызсың» дигән мактау сүзләре ишетә.

Казанда тәмам урнашып беткәнче дип, Мирхәйдәр Фәйзи күңеленә бик якын булган Шода авылына барып килергә була, Малмыжга, Сәрдеккә, Түнтәргә сугыла. Бу юлы Шода Мирхәйдәрне яңа сөенеч һәм яңа көенеч белән көткән: ул күршеләрендәге Гыйлембану исемле сылу кыз белән таныша. Көенече шунда, көчле авыруы сәбәпле, аңа гаилә корып бәхетле тормыш өмет итәргә соң инде, докторлар да өйләнмәү мәслихәт, дип торалар. Бу юлы Шодада шактый озак, ай ярымга якын торуы да, бер яктан, авылда бераз сихәтләнергә теләүдән, икенче яктан, күңелен алгысыткан «матур кыз» янында күбрәк буласы килүдәндер. «Чишмә янында» исемле озын шигыре дә шушы сәфәрдә, Шода авылында языла, көндәлекләренә авыл табигатен, яшьләр тормышын, чишмә яны һәм җыен күренешләрен тасвирлаган бик күп битләр өстәлә. Ни көенеч, Шоданың драматург әсәрләренә кат-кат кергән бу чишмәсе юк инде. Тегермәннәр бетеп, инештә су саеккач корды, диләр. Мирхәйдәр Фәйзиләребезнең онытыла, җаннарыбызны хәтерсезлек били башлаган елларга туры килә бу. Менә хәзер, асылыбызга кайту, кыйблабызны яңартып, югалта язган чын бөекләребезне кабаттан табу чорында, мәнсезлегебез корыткан чишмәләр дә өр-яңадан тибеп чыгар бәлки, дигән хыялый бер өмет тә җанны җылытып тора. Ә аңа кадәр Шода халкы бөтән бер чишмәне Мирхәйдәр Фәйзи исеме белән карап тота.

Драматург Шодадан киткәч туган якларын урап килү өчен юлга чыга, эти-әнисенең каберендә була. Ә күңелендә һаман Казан, Шода. Җүнәйдә ул яшьләргә Шода көенә шул як җырларын җырлап күрсәтә, су буенда утырып, Шода җыены, андагы мәхәббәте мөнәсәбәте белән яза башлаган «Сәрвиназ» хикәясен дәвам иттерә *(«Свод памятников истории и культуры. Республика Татарстан» китабында бу әсәр әкият дип билгеләнгән һәм Шодада язылган дип күрсәтелгән).* Әмма «күргәннәрдән җыеп» язылган бу хикәя дә каршылыксыз гына кабул ителми. Драматург сентябрьдә Казанга килгәч, уку өчен аны Садри Җәләлгә («Безнең юл» журналы) биреп карый, әмма иҗатташы хикәяне ошатмыйча кире кайтара. Октябрьдә «Кызыл шәрык яшьләре» журналына илткәч, редактор Ш. Рәмзи дә, күләме зур дип, бастырудан баш тарта. Әмма сәбәп һич тә күләмдә булырга охшамаган. «Шундый матур язылган... Нигә ярлы крестьяннар тормышыннан итеп язмадың?»—ди аңа редактор. Рәсми тәнкыйтьнең, идеологиянең әдәбиятны сыйныфларга, «дуслар»га һәм «дошманнар»га бүлә башлаган чор инде бу. Сырхау җанына бер дәва, сынып барган рухына таяныч эзләп, ашкынып килгән драматургны Казан әнә шулайрак кабул итә. 1924 елда аның авырлыгы киемнәр белән 50 килога гына кала. Докторлар көнгә дүрт тапкыр ашарга, тәрбияләнергә киңәш итәләр. «Кесәдә акча бетеп, күмәчне дә такы-токы гына ашап йөрим»,—дип яза «халык баласы». Чөнки китапханәдә эшләгән хезмәт хакы кечкенә, аны да вакытында бирмиләр, гонорар аз, кыйммәтчелек. «Франция» номерларында көнгә 300 мең түләп торасы. Бер кадак бал 175 миллион, бер пар пима 12 миллиард тора *(Ходаем, иң авыр чорга туры килдек дип, без дә гел зарланабыз бит әле!).* Өстәвенә, каләмдәшләрнең матбугатта бер-берсен рәхимсез тәпәләп торуы. Гыйнвар уртасында татар театрында «Адашкан күңел»не куялар. Мавияне мәшһүр Ф. Ильская уйный, халык бик яратып карый. Ике көннән «Татарстан» газетасында Һади Такташ болай язып чыга: «Мондагы урынсыз җырлар, Фәйзинең һәрбер әсәрендә кабатланып килгән биюләр чүп өстенә чүмәлә булып төшәләр. Әсәрдәге шахтерлар типларын алсак, алары белән Фәйзи үзеннән көлдерү белән генә калмый, ачуны да китерә».

Февральдә «Ак калфак» куела. Март башында ук «Кызыл Татарстан»да Раун псевдонимлы берәү «... әсәрдә техника ягыннан да бик күп гайре табигыйлыклар булу өстенә идеологический яктан да бер нәрсәгә яраксыз шаблонный бер нәрсә. Андый нәрсәләрне үзләренең хуҗалары белән үк архивка ташларга вакыт түгелме икән?»—дип язды.

Тагын шул «идеологический як»! Тәнкыйтьчеләр авторны хурлау өчен яңа

сүз сайлап та тормыйлар. Ярты ел элек кенә «Татарстан»да Гомәр Гали дә «Урал суы буенда»ны «идеология һәм халәте рухия ягыннан табигый булмаган кебек, технический ягыннан да муаффәкыятсез»—дип гаепләгән иде.

Яисә менә 1913 елда язылып, 1924 елда басылган «Авыл бәйрәме» пьесасына карата Гомәр Толымбайский тәнкыйте: «Җырлар, биюләр, егетләр белән кызлар сөйләшүе, эчүләр. Картлар белән яшьләр арасында сүз көрәштерүләр. Тагын җырлар, тагын бию, тагын җырлар...

М. Фәйзинең бу нәрсәләре бөтен әйберләренә үзәк булып киткән икән. Хәерле булсын, чөнки аның бу китабы эшчеләр һәм крестьян өчен бер төрле дә файда китерми».

Мирхәйдәрнең бер генә юанычы бар: әсәрләре сәхнәләрне тутырып уйнала, уйналган саен халык ябырылып карый. Әмма, рәхимсез ташланган тәнкыйть тә үз эшен эшләгәндер, аның сәламәтлеге һаман начарая, шул сәбәпле ул Казаннан китәргә тиеш була, докторлар шулай куша. Бу якларны соңгы тапкыр күрү ихтималын уйлаптыр, киткәнче Шода якларында йөреп килә. Көндәлекләрендә үзәк өзгеч язмалар. «Мин авылда, авылның да Татарстанныкында бит! Матур җирләрдә рәхәтләнеп йөрим, көннәрем күңелле, ямьле, рухымны күтәреп үтә... Үземне яхшы сизәм. Саф һава, яхшы ашау, матур күренешләр, тәртипле тормыш, татарлар—һәммәсе саулыгыма тәэсир итәләр!»—дип яза ул Шодада.

Гыйбрәт өчен дә кат-кат өйрәнерлек бу сүзләрне. Вакытында аз гына да кадер күрмичә сыкрап «китеп барган» бик күпләрнең уртак моңнары кебек бит алар. Нилектән Мирхәйдәр Фәйзигә «саулыгына тәэсир итә» торган шушы уңай шартларда озаграк яшәп калырга мөмкин булмагандыр—әйтүе кыен. Әгәр Шодада калырга кыстасалар, авыл яшьләре арасында җанына якын бер эш тә бирсәләр... Андый эшләрне үлеп ярата иде бит. Үзе булса, Гыйлембану белән очрашуларына шаһит булган чишмәсе дә кормас, шифалы суы мәңге тибеп торыр иде, бәлки. Арча кантоны драматургны Әтнәгә эшкә җибәрергә чакырып караган әнә. «Их, мин Татарстаннан китү белән зур бәхетсез. Үзем китәм, күңелем кала»—дип инрәп язарга да туры килмәс иде аңа.

«Ибрай яры янында», «Их, нинди күңелле!» исемле шигырьләре дә Шодага шушы килүендә язылa. Иҗатының азагы инде бу. Шигырьләр үкенечле соңгы мәхәббәте Гыйлембануга багышланган. «Их, нинди күңелле!» китапта «Чылтыр-чылтыр чишмә ага, Авыл кызы су ала» дигән юллар белән башланса, куен дәфтәрендәге беренче варианты болай булган:

Чылтыр-чылтыр чишмә ага,  
Гыйлембану су ала.

Шодадан Казанга килгәч, май азагында куен дәфтәренә: «Төрле-төрле бәхетләремнән аерылып, Казаннан китәм. Бөтен бәхетем, күңелем бу якта кала»—дип яза. Бер айдан шул ук дәфтәргә хушлашу-бәхилләшү сүзләре языла: «Хуш, Казан. Мин синнән ераклармын, ераклармын, ераклармын... Бер вакыт, кайда Казан дип, тилмереп, син калган якка карармын да, өзелеп-өзелеп сагынырмын».

Мирхәйдәр Фәйзи Самарага кадәр пароходта Муса Җәлил белән бергә бара. Вокзалда Мирхәйдәр әйберләр янында торып кала, Муса икесе өчен дә Ырынбур поездына билет алып килә. Ә драматург күңелендә—һаман Казан! Инде Самарадан Ырынбур далаларына таба юл алу да җиңел түгел аңа: Идел буйлары кала, дип сагышлана ул. Шушында куен дәфтәренә Татарстан турында ике строфалы шигыре дә языла:

Татарстан илләрендә,  
Татарлар арасында,  
Баллары бар гөлләрендә  
Күңелемнең ярасына.

Шунысына рәхмәт: Татарстанга, үз иткән халкына рәнҗеп китмәгән Мирхәйдәр Фәйзи. Рәнҗүен түгел, саф күңелен, күңел җәүһәрләре булган мәңгелек әсәрләрен калдырып китте ул.

**Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ**

# БЕРГӘЛЕК БӘХЕТЕ

ДРАМАТУРГ ЮНЫС ӘМИНОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ ТУЛУ УҢАЕННАН

Авылда үткән безнең гүзәл балачакның җәйге җылы кичләреннән берсе иде. Без— өч-дүрт малай— Урта урам белән Иш буе урамын тоташтыручы ямь-яшел чирәмле киң генә тыкрыкта уйнап йөрибез... Инде көтүләр дә кайткан, анда-санда адашып калган мал-туар да эзләп табылган, абзарга алып кайтып ябылган... Шәһәрләрдән бик тә ерактагы авылга иплә кенә илаһи бер кичке тынлык, моңсулык иңеп килә...

Менә шундый кабатланмас татлы тойгылар уята торган минутларның берсендә безнең колакка акрын гына агылучы моңлы җыр авазы ишетелеп китте. Әйе, әйе, ялгышмадык кебек—ул җыру авазы укытучыбыз Юныс абый ихатасыннан ишетелә иде.

Бала-чага кызыксынуы, бала-чага түземсезлеге безне шунда ук аларның өр-яңа тәбәнәк рәшәткәсе янына китереп бастырды һәм шундый күренешкә тап булдык.

Юныс абый үз өйләренең бакча як тәрәзәсен киерептереп ачып куйган да, җайлап кына тәрәзә төбенә менеп утырган һәм... тыенкы гына, урамга ишетелер-ишетелмәслек итеп кенә җыру суза. Ялгызы гына моңланып утыра.

Юк, балачак хәтеренә бик озакка сеңгән бу кичне Юныс абый җырлаган җырның сүзләре дә истә калмаган, аның нинди көй сузганын да белмим. Ул чагында без, бала-чаганы, иң гаҗәпләндергәне: өйрәтеп, белем һәм тәрбия биреп, авылда зур абруйга ия булып яшәгән укытучыбызның үзенең әнә шулай ихлас хискә чумып, тирән кичерешләр кочагында онытылуы иде... Авылның ул чагындагы гадирәк, кырысрак тормышын гына белеп үскән бала-чага өчен бу яңа да, сәер дә һәм серле дә күренеш иде.

Әйе, без инде моңа кадәр дә Юныс абыйның язучы икәнен белә идек, аның төннәрен мунчада ялгызы утырып пьесалар язуы турында да өлкәннәр авызыннан ишеткәнебез бар иде һәм моңа бик сәерсенә дә идек. «Шунда үзе язганнарны үзе артист булып уйнап та карый икән» дигән сүзләр инде безнең колакларны бигрәк тә торгыза, бигрәк тә хәтергә сеңеп кала иде... Аннары Юныс абый турында: «аның язган пьесаларын куярга куркалар икән, син нимес әсирлегендә булган кеше бит, дип әйтәләр икән!»—кебек сүзләр дә йөреп алды... Шуннан соң тагын бераздан авылда: «Юныс абый Мәскәүнең үзенә барган икән, бер бик зур кеше янына кергән дә ул аның пьесаларын куярга, ниһаять, рөхсәт биргән икән»,—дигән хәбәр дә таралды.

...Юныс абыйның Минзәлә театры белән иҗади дуслыгы илленче елларда башланды бугай. Безнең Барҗы авылына ул театрның атаклы режиссеры Сабир ага Өметбаев еш кына килеп йөрде— алар, ике иҗатчы, сәхнә әсәрен бергәләп тагын да камилләштерә, шомарта, яхшырта иделәр, ахрысы... Авыл китапханәсеннән мин алып укыган пьеса китаплары эченнән кайчагында Сабир Өметбаевның Юныс абыйга җибәргән телеграммалары да килеп чыга иде әле—күрәсең аларны Юныс абый китап эчендә онытып калдырган булгандыр инде.

Ә инде авылга театр килеп, аның Юныс абый иҗат иткән «Язылмаган законнар» спектаклен куюы—бусы безнең Барҗы авылы тарихында иң зур вакыйга булгандыр, мөгаен. Халык инде зур клубка шыгрым тулган, башланырга әле байтак кына вакыт калса да анда шундый гадәти булмаган тынлык—гүяки бөтен кеше менә-менә башланачак чын могҗизаны көтә. Үзебезнең авыл кешесе тудырган, ул китереп чыгарган могҗизаны.

Шулай шул: Юныс абый Әминов язган драмалар һәм комедияләр алар, чыннан да, онытылмаслык тиң әсәрләр. Менә хәзер инде алар иҗат ителгәнгә дә илле еллап вакыт узды, ләкин шуңа да карамастан ул пьесаларга салынган тормыш көче һаман да тылсымлы бер чишмә сыман бәреп тора. Аның әсәрләре укыла да, карала да!

Юныс Әминовка зур дан китергән һәм 1957 елда Мәскәүдә уздырылган Татарстан әдәбияты-сәнгате декадасы вакытында гаять күтәренкелек белән күрсәтелгән «Язылмаган законнар»ны гына алыйк. Биредә бит авылның уңган егете Шәйхенур белән шулай ук чибәр, булган кыз Фәридәнең мәхәббәтләре һәм алар гаиләсенең язмышы гына түгел. Гәрчә, ныклап торып уйлаганда, 1948 елда языла башлап 1954 елда тәмамланган пьеса өчен менә шушы да зур казаныш түгелме соң әле?! Чөнки ул елларның югарыдан төшерелгән боерык-карарлары кешедән бары тик колларча хезмәт итүне генә көтә иде бит! Кешенең эш машинасы булуын, көн-төн эшли торган әнә шул машинада бер тыңлаучан шөрепкә әверелүен!

Ә биредә, бу әсәрдә, үзәккә —гаилә, мәхәббәт мәсьәләсе куелган. Әлбәттә, эш

кешеләренең мәхәббәте, аларның гаиләсе. Ләкин, икенче яктан алып карасак, эшләми торган кеше, зур шәхес, гомумән, була аламы соң?! Барыбыз да эшлибез, хезмәт итәбез ләбаса: игенче дә, эшче дә, журналист та, төн белән көнне алыштыра-алыштыра иҗат итүче әдәбият-сәнгать әһелләре дә...

Бу пьесада механизатор Шәйхенурның—инде өйләнгән Шәйхенурның—авылга яңа килгән фельдшер кыз Назлыбикәгә күзе төшә. Әсәрдә бу эш бик тә мотивлаштырып бирелә: яңа фельдшерны болар үзләренә фатирга да керткәннәр—димәк, ул Шәйхенурның күз алдында йөри дигән сүз, икенчедән Фәридә көндезләрен генә түгел, ә кичләрен дә эш диеп өйдән югала—йә идарә утырышына, йә җыелышка китә, йә бүтән бер мәшәкате чыгып тора аның...

Шулай итеп, драматург тамашачыны да, укучыны да тормышның реаль вакыйгалары, персонажларның конкрет адымнары аша уйландыра. Әнә шул уйлар алга таба куерачак вакыйгаларның оеткысы булып тора.

Алдынгы да, чибәр дә Фәридә шул рәвешле ялгызы кала. Әсәрдә аның хисләре, психологиясе гаять тирәннән ачыла: «Мин гарьләнүдән ут кебек кызышкан йөземне бәхетсезлектән калтыранган кулларым белән каплап, тын, караңгы урамнар буенча ялгызым киттем. Әткәйнең таныш капкасын ачып кердем. Баскычка мендем, ләкин ишек шакырга көчем җитмәде. Кире төштем. Шул вакыт кинәт күз алдыма кара дулкыннарын ярга бәреп аккан Иш елгасы килде. Аның төпсез упкыннары миңа яшьтән таныш бит. Капка тавышына гаҗәпләнгән әткәй үзе килеп чыкмаса, белмим...»

Тамашачы белән укучы менә шулай алдынгы һәм чибәр Фәридәне генә кызганып, аны гына яклап утырганда яшен кебек ялтырап Фәридәнең әтисе Фазыл сүзләре балкып китә:

«—Гаепнең Шәйхенурда гына булуы мөмкин түгел. Фәридәнең үзендә дә, бездә дә гаеп юкмы икән?.. Кызыбызны җиленә дә, давылына да сыгылмаслык нык итеп үстерә алмадыкмы әллә? Габдри кызы Сараны ал, юлдан язган адәм актыгын да кеше итте бит. Ә безнең кызыбыз авылның мактаулы егетен дә кулында тота алмады.»

Күрәсезме, алдынгы колхозчы, идарә әгъзасы булган Фәридә турында аның әтисе нинди зур җитешсезлеген әйтә. Аның кеше, шәхес буларак йомшак ягын ачып сала. Фазыл абзыйның мондый акыллы сүзләре гүяки бер Фәридәгә генә түгел, ә бөтен бер җәмгыятькә һәм аерым кешеләргә сизелерлек тәэсир итүче әдәбият-сәнгать әсәрләренә дә карый иде. Аңлыйсыз булыр, сугыштан соңгы еллар идеологиясе өчен бу—яңа омтылыш.

Әйе, әсәр ахырында без Шәйхенур белән Фәридәнең яңадан кушылачагына ышанабыз. Ләкин бусы да пьесада бик нечкә алым белән күрсәтелә. Персонажларның икесе дә балага таба ымсына, шуңа якыная. Димәк, зур сынау үткән яшьләр инде киләчәктә бәхетнең, бергәлекнең кадерен белерләр, дип уйлый күңел.

Шулай, Юныс Әминов пьесаларының персонажлары—гади авыл кешеләре. Ләкин аларның тормышы кызыклы, мәгънәле. Драматургның жанр ягыннан «комедия» диеп куелган әсәрләрендә дә без сугыштан соңгы авылның йөзен, аның кешеләрен күрәбез. «Өти балак» комедиясенең вакыйгалары колхоз фермасында бара, ләкин шулай булса, монда эш күренешләре түгел, ә кешеләрнең холык-фигыльләре, аларның үзара мөнәсәбәтләре, кызыклы сөйләшүләре хәтердә кала. Комедиянең төп героинясы Гөлүзә баштa үзен-үзе дә карамый торган, шапшаграк һәм пырдымсызрак кыз итеп бирелә. Эшендә дә эленке-салынкы гына йөри ул, башкаларның алда баруына да исе китми аның. Әмма... Әмма—көннәрнең берендә фермага яңа зоотехник, яшь чибәр егет килә. Менә шунда инде безнең «өти балак»ның бөтен холык-фигыле үзгәрә: аның йөрәгенә мәхәббәт иңә.

Игътибар итегез—бу әсәрдә кешене югарыдан төшкән нинди дер үтә җитди карарлар, боерыклар түгел—ә аның үз йөрәгендә шытып чыккан мәхәббәт үзгәртә.

Билгеле, бу комедиядә сыер савучыларның җәйләүдәге тормышы байтак күрсәтелә, социалистик ярыш баруы да үзәктә тора. Ләкин эш кешеләрен күрсәтүне, аларның үзара ярышып хезмәт итүен тасвирлауны кем начар дип әйтә соң әле. Эш эшләмәгән кеше бик сирәк ич инде ул. Ә инде эшләгәндә ярыш килеп чыгу—бусы да бик табигый нәрсә... Димәк, бүгенге көн өчен дә биредә барысы да дөрес һәм табигый дигән сүз.

«Тамырлар» комедиясе исә бераз башкачарак. Анда кешеләрдәге «минеке» дигән тойгы белән «безнеке» дигән хис каршы куела. Белүебезчә, хәзер бездә бу мәсьәләгә карашлар бик үзгәрде. Ләкин... Ләкин, әйдәгез әле, әлеге проблеманың үзәгенәрәк төшеп карыйк. «Минеке» дигән хис нәрсә ул? «Безнеке» дигән тойгы ни ул?

Юныс Әминов комедиясендә яшьләр авылның горурлыгы булырдай алма бакчасы утырту нияте белән янып-көеп йөриләр, ә Гапсаттар абзый белән аның карчыгы исә үзләренә мунча салу уе белән җенләнгән. Комедиянең асылын менә шушы каршылык тәшкил итә.

Бик тә озын гомерле, хәтта безнең көннәргә үк килеп ялганган проблема бу. Бөтен ил, дәүләт байлыгын үзләштереп бетерергә теләүче бүгенге түрәләр дә бик әйбәт гәүдәләнә ич монда! Алар да бит үз ояларына ташу, үз-үзләрен генә кайгырту дигәндә бөтен оятларын, чик-чаманы оныталар. Барча халык, бөтен җәмгыять тик алар өчен генә эшләргә тиеш дип уйлыйлар алар. Тәмам комсызланып бетәләр—ил, халык алдында көлкегә калуларын да уйлый алмас хәлгә төшәләр. Әсәрдәге мүк җыям дия-дия сазга баткан Хәерниса—әнә шундый мескен адәмнәрнең җыелма тибы булып гәүдәләнә. Ул көлке тип булса да бик масштаблы образ булып чыккан.

Әлеге идея драматургның «Умырзая чәчәкләре» дигән эпик драмасында тагын да калкурак күтәрелә. Билгеле, авторның бу әсәргә булган кереш сүзендә драманы Совет хакимиятен урнаштыру өчен көрәшүче каһарманнарга багышлавын белдерүе әсәрне бераз берьяклырак аңлауга да урын калдыра. Драма урыны-урыны белән ул чорның кайсыбер әсәрләре шикелле артык «кызылланып» та куя кебек. Ләкин ул әсәрләргә мөнәсәбәттә объективлыктан читләшмәскәрәк тырышсак иде. Ачыграк әйтсәк: егерменче гасыр башында илне һәм халыкны изә-изә, талый-талый шушы фаҗигале хәлләр килеп чыгуга сәбәпче булганнар икән—димәк Рәсәй патшасы һәм , гомумән, байлар, хакимнәр катламы фәрештә кебек изге булмаган инде алар! Әнә ич, бүгенгеләр дә халыкны, илне талауда, ерткычлыкта чик-чаманы искә алмыйча, вакыйгалар агышын шул якка таба борып җибәрергә маташа. Аз гына алгарак карый алмыйча! Үз янәшәсендәге адәмнәрнең ничек авырдан яшәүләрен аңлый алмаганга күрә—әхлакый һәм сәяси яктан «күрә карау» булганга күрә!

Менә драматургның тагын бер әсәре—алтмышынчы еллар ахырында язылган «Гөлҗәннәтнең җәннәте». Автор аның жанрын психологик драма дип билгеләгән. Ә нинди драма турында сүз бара соң?

Колхоз рәисе Лотфулла үзеннән күпкә яшь булган кызга өйләнә. Үзе чынлап та яраткач, яшь хатынны бүләкләр белән сөендереп торгач, бәхетле булырбыз дип уйлый, шуңа өметләнә. Баштарак кыз үзе дә моңа ышана, өйләренә зур бәхетнең килүен көтә. Әмма бу тормыштагы кайбер нәрсәләргә тырышлык һәм көч кую белән генә, зур акча белән генә ирешеп булмый бугай шул... Психологик драма бездә әнә шундый характердагы тирән уйлар уйлата, җитди фикерләргә алып кереп китә.

Ул елларда хезмәт темасына язылган бик күп әсәрләрдән аермалы буларак биредә Юныс Әминов бүген дә актуаль яңгырый торган социаль-әхлакый проблеманы иң үзәккә китереп куя. Ягъни ир белән хатынның гаилә бәхете нәрсәдән гыйбарәт? Гаиләдә бәхетле булу өчен бер якның яратуы гына җитәме? Матди байлык мул булу тормышның бүтән җитешсезлекләрен оныттыра, каплый, яшерә аламы?

Менә шушындый сорауларга җавап табу өчен драматург әсәрдә күрше яшәгән тагын бер гаиләне—Гайсә белән Мөслимәне—тамашачы күз алдына китереп бастыра. Аларның да тормышы майлаган кебек кенә бармый, җитмәсә әле балалары да булмыйчарак тора...

Күрәсез, драматург ситуациянең, чынлап та, җитдиен кора. Анда уңай чишелешкә ирешү өчен кешеләрнең үзләренең тырышлыклары гына да җитми кебек, язмыш дигән «кырыс бабай»ның катнашуы да шәйләнеп ала... Менә болар барысы да әсәрнең мәгънә тирәнлеген, тәэсир көчен арттыра, Юныс Әминов драматургиясенең колачын киңәйтә. Ә тулаем алып караганда бу—чынбарлыктагы җанлы, тере кешегә якынаю, аның күңел төпкелләренә әчкәрәк үтеп керергә тырышу, катлаулы рухи-эмоциональ тормыш белән яшәүче замандаш йөрәгенең чын һәм ихлас юлдашы булырга омтылу иде. Бөтен татар драматургиясе өчен дә мактаулы адым, дөрес юнәлештә хәрәкәт итү билгесе иде.

Әйе, драматург Юныс Әминовның илленче, алтмышынчы һәм җитмешенче елларда язылган драма һәм комедияләрендә социаль мотивлар бик көчле чагыла. Бу, бер яктан шул чорда хөкем сөргән коммунистик идеаллар тәэсире белән аңлатылса, икенче яктан карасаң—авторның үзенең дә кешелек карашлары бик тә гуманистик, бик тә кешелекле иде. Гади генә итеп әйткәндә, кешеләрнең матур яши алуын, аларның бәхетен дә ул бары тик бергәлектә, бердәмлектә генә күрә иде. Югарыда күреп узган бүтән юлларны, социаль тигезсезлекне аның иманы кабул итә алмады.

Шул уңайдан 1963 елда безнең Баржы авылында булып узган бер тетрәндергеч вакыйга искә төшә.

Бик тә эссе килгән май ае иде ул. Әле мәктәптә укулар да тәмамланмаган иде, без—сигезенче сыйныф балаларының нәкъ менә дәрестә утырган вакыты иде. Кинәт елганың аргы як урамыннан «ут бар!» дигән дәһшәтле тавыш ишетелде. Без әлеге куркыныч сүзнең мәгънәсен аңышу белән сыйныф бүлмәсенең ачык тәрәзәләреннән тиз генә урамга коелыштык та, шомлы аваз килгән якка чаптык. Килеп җитсәк—бер өйне ялкын инде тоташ

ялмап алган, күршедәге икенче өйнең түбәсе дә инде янып ята. Бездән алдарак җитешкәннәр әнә шул өйдән әйберләр чыгарыша. Озак уйлап тормыйча без малайлар да шуларга булыша башладык. Ут эссесе битләрне, колакларны пешерә—куе төтен тынны буа, күзгә каплана. Аның бит әле ул чагында юньле су сиптергечләре дә юк! Ә коры кул белән генә андый дулап котырынган ут стихиясенә каршы нәрсә эшли аласың соң? Кыскасы, ул көнне безнең авылның сигез хуҗалыгы янып бетте. Бик зур афәт килде.

Әнә шул кайгылы көннең кичен үк Юныс ага үзе янган кешеләр янына килеп, аларга акчалата ярдәм күрсәтәчәген әйткән. Һәм ул сүзендә торган да.

Хәер, Юныс аганың бик тә ярдәмчел, кешелекле икәнлеген мин үз гаиләбез мисалында да раслый алам. Торып яткан өебез искергәч, безнең алга йортны яңарту мәсьәләсе килеп басты. Әмма бит моңа бик күп акча кирәк. Ә ул чагында гади колхозчыда андый акча каян булсын?! Бары тик «хезмәт көненә» генә эшләп... Әнә шундый авыр чагында безнең әти-әни ярдәм сорап шулай ук Юныс абыйга мөрәҗәгать итте. Ул, ике дә уйламыйча, безнең гаиләгә бурычка зур гына суммада акча биреп торды.

Әйе, озак еллар буена Әгерҗе төбәгендәге Баржы урта мәктәбендә балалар укыткан драматург Юныс ага Әминовның әнә шундый яхшылыклары санап кына бетерерлек түгел. Ул әдип буларак кына түгел, ә кеше буларак та үрнәк биреп—якты күңел, киң күңел белән яшәде.

Менә хәзер Юныс ага Әминовның 80 еллыгы уңаеннан аның иҗатын, аның яшәү рәвешен күз алдыннан үткәрәм дә, аны бүгенге татар язучыларының яшәеше белән чагыштырып карыйм. Кешелеклелек, ярдәмчеллек ягыннан нишләп соң бүгенгеләр бик тә калыша икән? Ярый, хөрмәтле Гариф ага Ахунов улы Рәшит белән бергәләп иҗади яктан да, башка мәсьәләләрдә дә бик күпләргә ярдәм итте. Мәрхүм әдип Шәйхи Маннур яшь язучылар өчен үз исемендәге махсус бүләк булдырып китте. Мәрхүм Фәрваз абый Миңнуллин да бары тик әдәбият мәнфәгате белән генә яшәде—шуңа күрә гадел һәм кешелекле булды... Бүген исәннәрдән Туфан ага Миңнуллинның укучы балалар өчен махсус стипендия булдыруын да ишетеп бик сөендек. Рәхмәт аңа!

Әмма бүгенге иҗатчылар арасында ни өчен бүтән иманны кыйбла итүчеләр күбәя бара соң? Алар үзләре тормыш авырлыгын күрмичә үскәнгәме? Гаиләсендә дә кечкенәдән үк әрләнә кебек үз ояңа ташу галәмәте генә күреп, шуңа өйрәнеп үскәнгәме? Бәләкәйдән үк бүтәнчә тәрбия алмагангамы? Яки иҗатны бары тик сүзләр белән генә эш итү дип, тел бистәсе булу дип—тар мәгънәдә генә аңлагангамы? Һәрбер Зур Иҗатның бары тик Зур Яшәү җимеше генә була алганын белеп бетермәгәнгәме?

Бүген, татар милләтен бергә туплау, бер максатлар тирәсенә җыйнау үтә актуаль бурычка әверелгән чагында, халыкның рухи юлбашчыларыннан аеруча зур җаваплылык сорала лабаса!

...Менә авыл урамыннан ашыкмыйча гына бер ир-ат атлый. Ул уртача буйлы, уйчан-сабыр йөзле, күзлек кигән... Бигүк күрсәтмәскә тырышып тәмәке дә пыскыта, ахрысы...

Бу—Юныс ага Әминовның көне буена мәктәптә балалар укытканнан соң арып-талып өенә кайтып баруы. Аның юлы көн саен безнең тыкрык каршыннан үтә. Шуңа күрә мин аның күзенә күренергә кыймыйчарак кына, әмма бик тә зур кызыксыну белән аны карап, озатып калам...

Менә хәзер, бу еллардан соң инде бик күп сулар аккач, Юныс ага үзе дә мәңгелек дөньяга күчкәч—ул чакларны искә төшереп, уйлап утырам.

Көне буена мәктәптә бала-чага белән мәш килгәннән соң тагын төннәр буена утырып менә дигән драма әсәрләре язарга каян көч тапты икән Юныс ага? Күрше авыл Баржы-Умгада туып-үскән классик әдип Таҗи Гыйззәт үрнәге аны иҗатка дәртләндереп, авырлыкларны җиңәргә рухландырып торганмы? Әллә үзебезнең авылда туып-үсеп ерак Казакъстан якларына юл алган һәм соңрак шулай ук аларның классигына әверелгән (хәзер аңа Алма-Атада һәйкәл тора), легендар тормыш кичергән Сабир Шәрипов мисалы маяк булганмы аңа? Кызганыч, ул үзе исән чагында мин аңардан боларның берсе турында да сорап кала алмадым.

... Авырып, Казан хастаханәләренең берсендә ятканда, без аның янына шагыйрь Әхмәт Рәшит белән бергә барган идек. Әллә ничек, әллә яшьлегебез белән шунда, әллә шулай тиеш диеп уйлап, аңа чәчәк тә алып килгән идек. Ә ул исә без алып килгән чәчәкләрне шундук хастаханәдә эшләүче кызларга бирде...

Мин шаһит булган менә шушы күренеш тагын бер мәртәбә Юныс аганың холкын, табигатен ачып сала. Әйе, ул кешеләр өчен дип яшәде—тормышны, дөньяны бизәп, анда якты нур булып яшәде!

**Мансур ВӘЛИ-БАРҖЫЛЫ**

*Котлыйбыз!*

## Китаплы гомер

Шәһидә Максудова (Гөлшәһидә) әдәбиятка тәрҗемәче буларак килеп керә. Аның тарафыннан тәрҗемә ителгән әсәрләр арасында рус язучыларыннан Л. Толстой, В. Телпугов, В. Чивилихин әсәрләре, шулай ук, казакъ язучыларыннан А. Кекильбаевның «Хатынгол балладасы», С. Санбаевның «Ак дөя» повестьлары да бар.



Тәрҗемә жанрында каләме шомарып, үз язу стилен, формасын таба алу Шәһидә Максудовада оригиналь әсәрләр язу теләге уята. Аның беренче повесте «Минем кала алуым» 1970 елда, «Асылбикәне җирләгәндә» исемлесе 1997 елда «Казан утлары» журналында басылып чыга. Бу әсәрләр авторның вакыйгаларны оста сурәтли алуы, каләменең төгәллеге, һәр сүзне яратып, аңлап урынлы куллана белүе белән дә яраттыра.

Шәһидә апага белемне һәм тәрбияне бер үк вакытта авылда да, шәһәрдә дә алу насыйп була. Ул 1926 елның 29 ноябрендә Татарстанның Әгерҗе районы Уразай авылында Габдрахман мулла белән Йозлекәй абыстай гаиләсендә дөньяга килә. Әтисе үлгәннән соң 1932 елда кызны 1 класска укырга Казанга алып китәләр. Башлангыч сыйныфны шәһәрдә укыгач, язмыш аны янәдән авылга кайтара. Сигез еллык белемнең яртысын шәһәрдә, яртысын авылда алганнан соң, ул Минзәләдә кыска сроклы укытучылар хәзерләү курсларында укый һәм 1942 елны Әгерҗе районының Салагыш мәктәбендә укытучы булып эшли башлый. Ирешелгәннәр белән генә чикләнеп каласы килми аның, кире Казанга килеп урта мәктәп тәмамлый, 1947 елны Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Университет—белем, әдәбият дөньясына керү белән бергә кызның шәхси тормышында да зур роль уйный.

«...Университетка керү өчен имтиханнар тапшырып йөргән чагында, минем күземә дулкынланып торган чәчле, шәрыкъ кешеләренәрәк охшаган түгәрәк, каратут йөзле, күперенке алсу иренле бер кыз чалынды. Ул безнең белән бергә имтихан биреп йөргән бер генә кызга да охшамаган иде. Мин аның чәчрәп дулкынланганын да, кайгырып аһ органын да күрмәдем. Имтиханнарны ул тигез генә биреп бара, үзен сабыр-тыныч тота, әмма коңгыртмы-яшькелтмә күзләрендә, салмак-сабырлык белән бергә, йөрәккә ут сала торган бер көч тә бар иде...»

Язучы Гариф Ахунов «Йолдызлар калка» исемле әсәрендә хатыны Шәһидә апаның портретын әнә шулай сурәтли. Шәһидә Максудова турында сүз әйтергә телибез икән Гариф абыйны, Гариф абый турында сүз әйткәндә Шәһидә апаны искә алмый калып булмый. Чөнки алар тормыш юлыннан гына түгел, әдәбият дөньясыннан да кулга-кул тотынып ярты гасыр янәшә атлаган шәхесләр. Гариф абый шаяртып: «Ул бит язучы Гариф Ахуновка түгел, студент Ахунов Гарифҗанга чыкты кияүгә»,—дип әйтергә ярата иде. Шулаен шулай да бит... Әмма да ләкин күңелләрендә матур әдәбиятка мәхәббәт хисе булмаса, Татарстанның икесе ике ягында туып-үскән бу җан ияләре бер үк елны, бер үк бүлеккә укырга килерләр идеме дә, якынаеп китә алырлар идеме икән! Гариф абый язганча, кызга булган хисләрен аңлатырга сәбәпче дә нәкъ менә Галиҗанәп Китап үзе булган бит.

Китап, гомумән, Ахуновлар гаиләсенең төп байлыгы, яшәү рәвеше. Шәһидә апа да түрә хатыны булып иркәләнеп кенә яшәп ятмый, үзе дә әдәби әсәрләр иҗат итү белән бергә гомерен татар әдәбиятын пропагандалауга багышлый. Ул—1952 елда «Пионер каләме» журналында хатлар бүлеге мөдире, 1954-1957 елларда Татарстан китап палатасында библиограф, «Хезмәт байрагы» газетасында әдәби хезмәткәр, 1960-1968 елда Әлмәт шәһәр китапханәсендә, 1969-1983 кә кадәр Татарстан Язучылар берлегендә китапханәче. 1993 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

Бүгенге көндә Шәһидә Максудова ире, Татарстанның халык язучысы Гариф Ахунов турында истәлек китабы чыгару эшләре белән мәшгуль.

*«Казан утлары» журналы коллективы юбилярны олуг бәйрәме белән чын күңелдән котлый, исәнлек-саулык, иҗат уңышлары тели.*

**Гөлзадә БӘЙРӘМОВА**

# *Нәниләр дөньясы*



*Алсу бишек баласы чагында ук кешеләргә текәлеп карый белә иде. Бу кадәресе, әйе, сабыйларга гомумән хас. Тик Алсу карашын кешеләрдән һәм әйберләрдән тиз генә алмый иде, керфекләрен дә селкетмичә тирә-юнен озаклап өйрәнергә көче җитә иде аның. Бу кадәресенә исә бик сирәк нәни җаннар сәләтледер.*

*Аның бу сыйфатына беренче тапкыр Актаныш төбәгенә әнисе Илусә һәм әтисе Рөстәм хөрмәтләләрем белән бергәләп кылынган сәфәрдә игътибар иткән идем мин. Әнисенең туган авылы Яңа Кормашта. Ул, кайтып кергәч тә, иң башлап әбисен «өйрәнде», аннары гына карашы әйберләргә күчте—әллә элекке кайтуларында барысын да күңелендә калдырган да хәзер шуларны хәтеренә җуелмаслык итеп сеңдерергә тели иде тагын...*

*Үсәрәк төшкәч, әле мәктәпкә кергәнче, Алсу әтисенең эш урынына—Язучылар берлегенә еш килеп йөрде. Әтисен сагынгандыр да әнисен әйдәләп җитәкләгәндер. Әллә иҗат серләренә төшенергә теләдеме икән, шулайдыр әле—килеп керүгә үк әтисенең күзләренә төбәлеп карый иде, сагынуын бизәүче сәерлек-серлелек бизи иде карашын.*

*Әнә, Алсу ишегалдында асфальт ярыгыннан үсеп чыккан ялгыз үләнгә текәлде. Үлән кыягының очы нигә тараеп бетүен өйрәнә бугай ул. Әллә үләннең бөтен буе кызыксындырамы аны—белмәссең. Бәлки, ул үләнне тамырын тартып чыгармыйча күрергә телидер. Шулайдыр.*

*Мондый күзәтүләрем мине гел бер сорауга этәрде—кем булыр икән Алсу? Әйе, иҗат кешесе булыр, тик кем: рәссаммы, шагыйрьме? Әллә аның бу фани дөньяны һәм аның кешеләрен яратуы үзе үк инде иҗатмы?!*

*Һәм алты яшендә Алсу рәсемнәр ясый башлый. Әмма шунысы бар—күп кенә рәсемнәре бер сюжетка корылган була, ягъни серияле рәсемнәр. Дүрт кенә рәсемнән торган сюжетлары да бар, унга ук җиткәннәре дә ишле. Әлбәттә, алдан ук уйланылган буладыр, рәсемнәрен тиз ясый. Аның рәсемнәре инде меңнән арткан. Моның өчен исә җәһәт уйлану сәләте, хыялың бай булуы кирәк.*

*Рәсемнәренә кызыклы текстлар да таба Алсу. Шушы юлдан «йөгереп», ул шигырьләр һәм кыска хикәяләр язуга барып җитә. Һәм аның беренче иҗат җимешләре—рәсемнәре, шигырьләре һәм хикәяләре—республика матбугатында басылгалады.*

*—Хәзергә мин кызыма,—ди Алсуның әтисе шагыйрь һәм драматург Рөстәм Мингалим,—акрынрак иҗат итәргә кушам. Беразга тукталып торса да ярар иде. Әй-й, иҗатта аны тыеп буламыни?! Рәсемнәр ясавын, шигырь-хикәяләр язуын белә! Аның фикерләре өлкәннәрчәрәк, уйлау рәвеше дә шулайдыр, күрәсең. Ә аңа уникe яшь кенә, алтынчы сыйныфта гына укый әле.*

*Әйе, үзен өлкәннәрчәрәк тота Алсу. Бәлки, аның тормышны һәм кешеләрне томырылып күзәтүе-өйрәнүе, шулай ук томырылып иҗат итүе дә шуннан киләдер.*

*Журнал укучыларга Алсуның ике кыска хикәясен тәкъдим итәбез.*

*—Уңышлар телим сиңа, Алсу! Бәхетле яшә! Иҗатың да бәхетле булсын!*

**Мәгъсум** абыең **ХУҖИН**

# Алсу Мингалимова

ХИКӘЯЛӘР

## Һәркемгә бәхет эзләүче...

Илгиз әнкәсе белән генә яши, әткәсе юк. Ул, әнкәсенең биш сум акчасын тотып, кибеткә ипигә чыккан иде. Ипидән арткан акчасын бер хәерчегә биреп кайтты. Кибет янында торган сәләмә карт:

—На хлеб, подайте на хлеб!—дип һәркемгә кулын сузып кала ич.

—Казаныбызга таралган, дөньяга сибелгән барлык бәхетсезне син генә туйдыра, киендерә алмассың. Аларны син генә бәхетле итә алмассың!—дип ачуланды әнкәсе Илгизне.—Әйдә, утыр, ашыйбыз. Үзебезнең хәлне күрмисеңме?!

Илгиз үзенең хатасын аңлады да, аңламады да. Ашарга ипие дә булмаган кешене ничек инде кызганмыйсың?

Алар, тыныч кына утырып, итсез аш ашадылар. Әзрәк үпкәләшкәннәр шул инде. Сөйләшмичә генә сөтсез чәй эчтеләр. Илгиз, әнкәсенә рәхмәт әйтеп, өстәл яныннан китте. Бераздан иртәгә буласы дәресләренә хәзерләнә башлады. Математикадан эше авыр булды, чөнки ул аны яратмый. Инглиз теле белән күптән дуслаштылар. Әдәбияттан Илгиз әзерләнеп тә тормады. Классташларының кечкенә башларына сыя да алмаслык күп китап укыган малай ул. Китап арты китап геройларын башына тутыра. Шулар Илгизнең миендә һаман йөгерешә, шаулашалар. Кайчакта алар пышылдап кына Илгизне киләчәктә язучы булырга котырталар. Илгизнең язып караганы, язганнарын әнкәсенә укыганы да бар. Их, Тукай һәм Пушкин кебек язасы иде, дип уйлый ул еш кына. «Син үзең кебек яз!—дип кинәш итәләр аңа Тукай һәм Пушкин геройлары.

Илгиз хәзер дә нидер язарга уйлап утырды. Язылмый, әллә каләме, әллә башы авырая. Ул авызын зур ачып иснәде дә йокы бүлмәсенә керде. Мендәрен дә җайлап тормыйча гына урынга ауды. Шулай, күзләрен йомып уйланса, ул дөньяны ачыграк күрә. Әйе, әнә бит теге хәерче. Кулында—Илгиз калдырып киткән акча. Телендә һаман шул:

—Подайте на хлеб!..

Кинәт хәерче югалды. Аның урынында бөдрә чәчле Пушкин басып калды. Тиз арада Пушкин бөдрә чәчле имәнгә әйләнде. Имән тирәли мәче йөри. Тик мәче имәнгә алтын чылбыр белән түгел, капрон җеп белән бәйләнгән икән. Алтын чылбырны кемдер урлаган инде. Пушкин геройлары да ачыкканнар, ябыкканнар. Илгиз янында, имеш, әнкәсе сөйләнеп тора:

—Бәхетсезләр заманы килде, улым. Син артыңа борылып кара әле, артыңа,—ди.

Артына караса, Илгиз шаккаткан, аның каршында—китап тавы. Алар Пушкин китаплары икән. Тешсез карт тычканнар китап тавы өстендә елап йөриләр. Тешле яшь тычканнар китап кимерә. Бу тауга туры таш юл тоташа. Юл буена тезелешеп хәерчеләр утырганнар, баш киемнәрен җиргә куйганнар.

Яшь кенә бер исерек хәерче хатын килде дә Илгизнең колагына ук чыелдап Пушкин шигырен укый башлады:—«Я памятник себе воздвиг нерукотворный. К нему не зарастет народная тропа...»

Шунда Илгиз йокысыннан уяна язды, ярый әле уянмады. Тиздән, имеш, ул Идел ярына килеп чыкты. Балык тотарга исәбе. Менә нәкъ аның аяк очында Тукай язган «Су анасы»ның алтын тарагы ялтырады. Ялтырады да суга сикерде. «Ялгыш күргәнмен, тарак түгел, сары бака булган ул»,—дип уйлады Илгиз. Иделгә кармак салды. Әһә, әһә! Чиртә... Эләкте!

—Мине пешереп ашый алмыйсың. Мин—алтын балык. Җибәр мине Иделгә!—диде балык.

—Алтын булсаң, мин сине теш табибенә сатармын. Әнкәмнең кайчакта сөт алырга да акчасы җитми. Әй, иптәш балык! Әллә соң син Пушкин язган алтын балыкмы?

—Әйе!—диде балык.—Җибәр син мине?

Әзрәк кенә уйланып торгач, Илгиз:

—Бер үтенечем бар. Шуны эшләсәң, җибәрәм,—диде.

—Мин инде картайдым. Зур эшләр эшләрлек көчем калмады. Берәр кинәш сорасаң, дөрес кинәш бирә алам,—диде балык.

Илгиз тагын бераз уйланып торды да:

—Казанда хәерчеләр күп. Казанда гына түгел... Әй, синең телевизор караганың юк шул. Карасаң—бөтен җирдә бәхетсезләр. Мин аларның барысын да бәхетле итәргә телим. Ничек шуны эшләргә?—диде.

—Барлык кешеләргә бәхет эзләүче ахмак син!—диде алтын балык.

Илгиз, бу сүзләргә үртәлеп, кулындагы балыкны чак кына агачлар арасына ыргытмыйча калды.

—Барлык кешене бәхетле итәргә йөрүче бер кешене дә, хәтта үзеңне дә бәхетле итә алмый!—диде балык.—Син әнкәнне бәхетле итәргә тырыш! Әгәр һәркем әнкә-әткәсен бәхетле итәргә тырышып яшәсә, киләчәктә җирдә бәхетсезләр булмас!

—Карале, иптәш балык! Шундый акыллы башың белән ничек, ни өчен минем кармакка эләктең?—дип сорады Илгиз.

—Син ахмакка акыллы кинәш бирер өчен эләктем,—диде балык.

Илгиз үпкәләмәде.

—Мин чеп-чи ахмак түгел үзем. Бер әнкәмне генә бәхетле итә белермен, тырышырмын,—диде ул. Алтын балыкны суга җибәрде. Балык йөзеп китте. Бераздан алтын башын Иделдән чыгарды да Илгизгә кычкырды:

—Сау бул! Кинәшем кирәксә, тагын кил!—диде.

Илгиз аңа, сау бул, дияргә дә, рәхмәт әйтергә дә өлгермәде. Күзен ачты. Аның күңеле алтын балык кинәше белән килешкән, йокысы тәмам качкан иде. Өстәл янына барып кулына каләм алды. Күргәннәрен язарга булды. Илгиз янына әнкәсе килде:

—Бик матур гына йоклап алдың. Сөйләнә-сөйләнә. Нинди төш күрдең?—диде әнкәсе.

—Хәзер шуны язам, әнием, соңыннан сиңа укырмын. Хикәя язам, исеме «Һәркемгә бәхет эзләүче ахмак»,—диде Илгиз.

## Чыпчыкбай

Ю-у-ук, борын-борын заманда түгел, бу заманда, нәкъ безнең заманда яшәгән, ди, чыпчыклар төркеме. Алар арасында булган шундый бер чыпчык—зур чыпчык, әрсез чыпчык, житез чыпчык. Бу чыпчык акча янчыгы тапкан—баеган! Чөнки янчык эчендә акча күп булган. Янчыгына тагын акча җыйган, тагын...

Көннәрдән беркөнне ул, янчыгын асып, базарга очкан. Базарда бер абзый фил сата икән.

—Филеңне күпмегә бирәсең, абзый?—дигән Чыпчыкбай.

—Ал, ике генә сум—дигән абзый.

—Бик алыр идем дә бит, минем шул бер генә сум акчам бар,—дип алдаган бай чыпчык.

Абзый бераз башын кашып торган да:

—Йә, ярар алайса,—дигән дә, филен бер сумга биргән.

—Әйдә, Чыпчыкбай, филләр янына китик!—дигән бер сумлык фил.

—Юк, юк! Син нәрсә, филчик! Чирик! Чик-чик! Хәзер без чыпчыклар янына барабыз!—дип чыркылдаган чыпчык.

Бәхәс болай беткән: фил житез булган, тешләре үткен, авызы зур булган, хап итеп чыпчыкны капкан һәм аны акчасы-янчыгы белән бергә йотып җибәргән...

—Килегез! Алыгыз, ал! Бер сумга фил бирәм!—дип, теге абзый филен янадан сатып тора икән...

*1999*

*Юмор-сатира*

# Тәлгат Нәҗми

ХИКМӘТЛӘР

## Кәгазь җене

*Үзем турында*

Минем гомер юлым ап-ак кәгазь арасында узачагы сабый вакыттан ук билгеле иде инде. Үз-үземне ныклап белмәгән чакта, тәпи йөри башлагач, сайлау участогында юкка чыкканмын. Әни эзли торгач, кызыл чүпрәк ябылган комиссия өстәле астыннан тапкан.

Ташланып барылган сайлаучылар номерын язган кәгазь кисәкләрен җыеп, берегезгә дә бирмим, дигәндәй, кочаклап, утырганмын күзләрне елтыратып.

Тел ачылгач, санарга өйрәттеләр. «Р» хәрефен әйтә алмый идем. Шуна күрә очраган бер кеше егермедән соң санарга куша иде. Мин: «Җемеле, җемеле бел, җемеле ике, җемеле өс, җемеле дүт»,—дип сибәм генә...

Укытучы Әхмәт абый Фәләхов (бер урамда—Таубашында яшибез—бездән ерак түгел генә торалар) үзе чыгарган шигырь дә ятлатты әле.

Беренчесе әбигә багышланган иде:

Сездә бүген ничәсе?
Бездә—Кадер кичәсе.
Таубашында якты йолдыз
Нәҗметдин Хәдичәсе...

... Гади кешеләр баласы мин. Нәселебездә «җонлы куллар» юк. Әти—колхозчы. Саба Лесхозы, Тәмле Чишмә, Чокырча, Әлеш якларында колхоз диләнкәсен кистереп йөрде яшь вакытта. Соңыннан мәктәптә ат карады, бергәләп каравыл тордык.

Әни дә колхозда эшләп йөргән булды. Сугыш вакытында әби үлеп, сеңлесе Гөлчирә белән энесе Әсхәдулланы тәрбияләгән (әтисе—хезмәт армиясендә). Шуңа күрә бер класс та укымаган. Кул да куя белми. Дөрес, без беренчедә укыганда Наилә апа Әминова-Җиһаншина өйгә килеп сабак биреп йөрде. «Габидә» дип язарга да өйрәнгән иде. Яшьтән төпле белеме булмагач, тора-бара шул алты хәрефне дә онытты.

Акчаны бик әйбәт саный аның каравы. Шунысы—бик житкән.

Шул ук Әхмәт абый әтигә багышлаган шигырь дә өйрәтте әле бәләкәй вакытта, бүген дә хәтерлим:

Агач башлары селкенә,
Җилгә түгел—давылга.
Урмандагы хатыны кугач,
Самат кайта авылга...

—дип, эчтәлеген аңламыйча гына сөйләп күрсәткән идем, әти берне «сылады». Бүтән сөйләмәдем...

... Башлаган теманы дәвам итик әле. Кәгазь белән дуслык укырга кергәнче дә дәвам итте. Әтинең бертуганы—Бәдәр апа мәктәптә җыештыручы булып эшли иде. Аларга бик еш кунакка—кунарга менгәләдек. Әз булса да акчага эшләгәч, аларда шикәр, иртәнге чәйгә сары май була иде. Шуна күнел тартылды.

Ул үзе белән мәктәпкә дә алып бара иде. Менә шунда жыеп күрсәтә идем инде кәгазьне.

... Кыш уртасында әни печәнлектән төшеп, агарынып-күгәренеп, өйгә йөгереп керде дә:

—Әни, печән арасында әллә нәрсә бар!—диде әбигә.

Менеп киттек. Өчәүләп. Дөрестән дә, жәй көне үлән күтәреп ташый торган жәймәдә бозау кадәр әйбер ята.

Әби башта белгәннәрен укыды, төкерә-төкерә өшкерде. Аннары кылтыр-кылтыр килгән куллары белән төргәкне әйләндереп, чиште...

Әйбәтләп карасак, минем кәгазьләр икән анда, менгереп яшергәнемне үзем дә онытканмын...

—Дуңгыз!—дип, әби дә берне «сылады»...

## Ишек ачылсын

2001 елның май аенда—алмагачлар чәчәк аткач—Россия Федерациясенең М. Глинка исемендәге, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре иясе, мәшһүр якташ композиторыбыз Фасил Әхмәтовның туган авылында ачылган музей тантанасына чакыру алдык. Фасил ага миңа ике яклап якташ булып чыга. Ул Кукмара районының Шөнбаш (рәсми исеме Салтык-Ерыклы) авылында туган. 1946 елда әтисе Әхмәтгали Саба урман хужалыгына баш бухгалтер булып күчерелә һәм аларның гаиләләре егерме ике ел табигатьнең гүзәл почмагында—Лесхоз бистәсендә яши. Фасил Әхмәтов шуннан Казанга—музыка училищесына юл тота. Ул гомеренең соңгы көннәренә чаклы үзен ике районныкы итеп санады.

Фасил ага жор кеше иде. Берсендә, танылган шагыйрь, композиторның дусты Разил Вәлиев шалтырата икән моңа.

—Фасил абый, хәлләр ничек? Кичә әйбәт кайтып життеңме?

—Хәлләр ярый, тик менә илле сум акчаны таба алмыйм...

—Ни, Фасил абый, без аны кичә ресторанда, өстәп түләдек бит...

—Алай булса ярый, мин бит Йолдыз алган дип торам...

Шуннан кунаклар шау-гөр килеп көлделәр дә, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин, композиторлар Ренат Еникеев, Мирсәет Яруллин берсен-берсе уздыра-уздыра Фасил ага белән бәйле мәзәкләр сөйләп алдылар, музей ишегенең һәрчак ачык булуын телəделәр. Классик композиторыбыз рухына багышланган аш мәжлесе ахырында Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеев та тостын Фасил Әхмәтчә итеп әйтте:

—Без, бер төркем әдәбият һәм сәнгать әһелләре, Пермь өлкәсенә атналыкка бардык. Очрашулар байтак булды. Соңыннан бүгенге кебек чәйгә дә чакыргаладылар. Әмма, ничектер, тостлар бик рәсми, коры чыга, каушау, дулкынлану бар. Казанның үзеннән зур язучылар, композиторлар килгән бит... Бу рәсмилеккә Фасил озак түзмәде: «Мин тостны үземчә, шигырь белән әйтәм»,—диде һәм әйтте дә:

Сезнең дә бар мачыгыз,
Безнең дә бар мачыбыз,
Безнең мачы сезгә килсә,
Зинһар, ишек ачыгыз...

## Пролетар язучысы

Мин үземә карата әйтелгән «язучы» дигән олы сүзне тәүге тапкыр 2000 елның 29 апрелендә—Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында ишеттем.

Районыбызның—ике йөз еллегә якын үзешчәне катнашкан «Мишә буйларыннан юл алып, Саба моңнарына уралып» дип исемләнгән ижат отчеты шаулап-гөрләп бара. Тәнәфес игълан иттеләр. Фойега чыгып барабыз.

—Әнә, Сабаның үз язучысы,—дип төртеп күрсәтте халкыбызның яраткан җырчысы Флера апа Сөләйманова тормыш юлдашы Габделхак агайга.

Без өйләнеп кергәндә аларның кулында «Саба мәзәкләре» иде инде. Миннән автограф сорадылар...

Алга узып шуны да әйтергә кирәк, кайбер вакытта үземне:

—Пролетар язучысы,—дип таныштырам. Шаяртып, әлбәттә.

—Ничек?—дип сорыйлар, бөек пролетар язучысы Максим Горькийны тиз генә күз алдына китерәләр.

Мин шул арада тыйнак кына итеп:

—Чөнки унбиш елдан артык Сабаның Пролетар урамындагы алтмыш өченче йортында торабыз,—дип әйтергә өлгереп калам.

## Йомшак итеп...

«Идел» журналы баш редакторы Рашат Низамиев белән бер елны, бер көнне *(1950, 1 март)* туганбыз. Ярты гасырлык юбилейларыбыз да бер чорга туры килде. Шул уңай белән Рашат Сабага кайтты. Китапханәдә матур гына очрашу уздырдык, Саба урман хуҗалыгында эшләгән бер комплект сувенирлар бүләк иттек үзенә.

Район хакимияте башлыгы Рәис Нургали улы Миннеханов янына да кереп чыкты ул. Татарстан Язучылар берлеге идарәсе исеменнән спонсорлык ярдәме сорарга исәбе бар иде юбилеен үткәрергә.

Үзе генә кереп китте. Мин коридорда көтеп тордым. Мәшһүр «Шүрәле» балетын язган композиторыбыз Фәрит Яруллин турында «Атаклы кешеләр» сериясендә чыккан китабын да алды. Аңа «Сез—Сабаны, Саба Сезне үстерсен!» дигән теләкләрен дә сырлады.

Көткән кешегә озак бит. Шактый торды ул башлыкта. Һәм май кояшыдай балкып, бик канәгать булып чыкты Рашат Миәссәр улы. Шунда ук дулкынлана-дулкынлана сөйли дә башлады:

—Искитмәле җылы кабул итте, малай. Әллә телевизоры бар инде. Ишек төбенә үк килеп каршы алды, кулы белән «шап» итеп сугып күреште. Кечкенә өстәле кырыена кара-каршы утырдык. Китапны шундый тирән канәгатьләнү белән алды, эченә язганнарны укыгач, матур итеп елмайды. Җайлап кына хәлләрне сораштырды, районның бүгенге икътисадый-социаль-мәдәни проблемалары белән таныштырды, финанс авырлыкларына киң итеп тукталды. Аннары үземә уңышлар тели-тели алгы бүлмәгә кадәр озата чыкты...

—Болары аңлашыла,—дип сүзен бүлдердем яшьтинең,—акча мәсьәләсе, спонсорлык мәсьәләсе ничек соң? Тизрәк шунысын әйт,—дип ашыга-кабалана сорадым.

Рашат бер генә сүз белән җавап кайтарды:

—Өметсез...

## Кадаклау

Авыллар шәһәргә якынлаша, дип күпме сөйләсәк тә аның үзенә генә хас яклары бар әле. Мәсәлән, тавык утыртып чеби чыгару, каз бәпкәләре саклау, көтү куу...

Көтү куу, дигәннән Балтач район хакимияте башлыгы урынбасары, танылган шагыйрь, бик күп китаплар, популяр җырлар авторы (« Керик әле урманнарга»—үзе ни тора!) Гарифҗан Мөхәммәтшин Сабага—халык хуҗалыгы алдынгылары слетына килгәч, бер мәзәкнең кыскача эчтәлеген сөйләп киткән иде.

... Авыл иртәсе. Ак көмеч белән «ашарлык» саф һава. Кояш күтәрелеп килә. Әкрен-әкрен генә һәр капка диярлек ачылып, аннан мал-туар чыга. Алар артыннан тавыш бирә-бирә чираттагы көтүче атлый. Ашыгыч эше булмаганнары сыерын, сарыгын, кәҗәсен күздән югалганчы озатып кала.

... Менә көтү узып киткәннән соң шыгырдап тагын бер капка ачыла.

Аннан бик кызуланып башта сыер, аннан кимано гына эләктергән, ялангач, нәфис, ак балтырлы, кыскасы, алиһәдәй чибәр (әйтерсең, урта гасыр картинасыннан төшкән) хатын ыжгырып чыгып көтү артыннан чаба башлый.

Шунда әлеге яшь хатынның сикерә-сикерә биегән күкрәкләрен, арт шәрифләрен ике күзен дүрт итеп карап торучы ут күршесе, түземлеген җуеп:

—Төшеп бара бит!—дип кычкырып кала.

Чибәр ханымның җавабы да матур һәм кыска була:

—Төшмәс, төшмәс! Шул төшмәсенгә дип кадаклап ятканда соңарып калган көтү инде бу!..

## 95 яшьне... беренче тапкыр

2001 елның апрелендә Татарстанның халык язучысы Гомәр Бәшировның 100 еллыгына багышланган кичәнең язмасын телевизордан күрсәттеләр. Атна буе көтеп алып, бик тәэсирләнеп карадым бу тапшыруны. Болай итүемнең сәбәпләре бар.

Беренчедән, ул кичәнең үзендә, Г. Камал исемендәге академия театрында, Татарстанның халык артисты Хәлим Җәләлов бөек әдипнең мәзәкләр барлау эшен хәзер дәвам итүче республикада ике кеше—танылган язучы Рабит Батулла белән Сабадан Тәлгат Нәҗмиев бар, дип олы сәхнәдән әйтте,—дигәннәр иде.

Шуны да ишетәсем килде. Әмма, кызганычка каршы, ул төшен кискәннәр иде. Безне шулай иткәлиләр: йә кисәләр... йә «һәм башкалар»га кертәләр...

Икенчедән, 1997 елда миңа Гомәр ага Бәширов белән элек «обком больницасы» дип аталган шифаханәдә (хәзер—диагностик үзәк) бервакытта дәваланырга туры килгән иде. Аның палатасында сөйләшеп тә утырдык әле. Күчтәнәчкә кечкенә савыт белән «Саба» совхозында тутырылган «Саба балы» алып кердем. Капкачын ачып карады да: «Юкә балы икән бу»,—диде. Аннары: «Без якташлар бит. Әнием Олы Кибәхуҗадан иде»,—дип искә алды. Бик озак сөйләшеп утырдык. Әдәбият мәсьәләләре, дөнья хәлләре турында. Кияве Мөхәммәт абый, кызы Лилия апаны да искә алдык. Мин Мөхәммәт абый Мәһдиевнең шәкерте, үзе исән вакытта аларда еш булуым турында да әйттем. Аннары:

—Гомәр ага: йөзне тутыра алырсыз микән?—дип иплəп кенә сорап куйдым.—Кайсы да булса олы язучыбызның үзе исән вакыттагы бер гасырлык юбилей кичәсен күрергә насыйп булганы юк бит әле, әйеме?

—Шәт, иншалла, диде аксакал,—шул аяклар сызлавын исәпкә алмаганда, җитди авыруым юк минем...—дип өстәде.

Насыйп булмаган икән шул... Шагыйрь әйтмешли, әй язмыш, язмыш (!) дип сызланырга гына калды: меңьеллык татар әдәбияты агачыннан 98 яшьлек Олы Ботак сынып төште.

... Миңа, Гомәр ага Бәшировның 95 еллыгына багышланган кичәдә катнашу бәхете дә тәтегән иде.

Кичә барышында Гомәр ага Бәширов көчле алкышлар астында бик олпат кыяфәттә, әкрен генә сәхнәгә күтәрелде дә, микрофон алдына килде, аннары бераз уйланган да, дулкынланган да, каушаган да кебек итеп, тамагын кырып куйды һәм салмак тавыш белән:

—Туксан биш яшьне беренче тапкыр үткәргәч, нәрсә әйтергә дә аптыраган инде,—дип сүзен башлады...

## Матурлык

Танылган шагыйрь Роберт Миңнуллинның 50 яшьлек юбилей кичәсендә иҗатташ дусты Гәрәй Рәхим юбилярның туры сүзле булуы турында кызык итеп сөйләгән иде.

—Бауман урамындагы китап кибетенә язучыларның портретларын сатуга чыгарганнар. Анда син дә бар, Гәрәй,—ди икән Роберт Мөгаллим улы.

—Ну, ничек ясалган соң алар? Мин матур чыкканмынмы?—дип, самими итеп сорап куйган Гәрәй Рәхим.

Шуннан Роберт:

—Каян килеп матур булсын инде, Гәрәй дус. Нәкъ үзең шикелле инде!—дип җавап биргән.

## Искә төшерүе дә авыр

Татарстан Республикасы Президентын өченче срокка сайлаулар алдыннан унбер районның газета мөхәррирләрен Балтачка киңәшмәгә җыйдылар.

Матур тормышлы, киң күңелле, кунакчыл кешеләр ут күршеләребез. Кыскасы, соңгы елларда Балтач ягы, йөзек кашы кебек, һәрдаим балкып, игътибарны гел үзенә тартып тора.

Тарихи Себер тракты (Карадуганда музее бар) даулы-шанлы чорларны кичә-кичә, Балтач аша уза. Моннан ике гасыр элек бөек рус әдибе А. А. Радищев, атаклы сәяхәте вакытында шушы якта тукталып, кунак була. Аннары Янгул, Кариле, Арбаш авылларын әсәрләрендә телгә ала. Тарихи һәйкәлләр күп Балтач авылларында. Сосна Пучинкәсендә бөек шагыйребез Габдулла Тукайның әнисе җирләнгән. Шодадагы атаклы драматург Мирхәйдәр Фәйзи («Галиябану»ны шунда язган) музее үзе ни тора!

—Белгәнегезчә, Мамадыш, Малмыж, Париж—престижные города мира, дигән шаярту бар. Малмыж бездән ерак түгел,—дип сүзен дәвам итте шигъри җанлы Гарифҗан Мөхәммәтшин,—Тбилиси, Балтаси, Кутаиси,—самые зеленые города,—дип тә өстәде ул.

Ә инде сүз сайлаулар мәсьәләсенә күчкәч, мин:

—Лаеклы кандидат ведомостька гына керсен, сайлыйбыз аны. Борис Николаевичны да сайладык әле,—дидем.

Әңгәмәгә колак салып барган тарихи шәхес—Арча сабан туенда Ельцин әфәнденең күзенә кара «яулык» бәйләп, чүлмәкне бер сугуда «ваттырган» хакимият башлыгының беренче урынбасары Шәфигулла Зиннәтуллович:

—Ул сайлауларны, зинһар өчен, искә төшермәгез әле,—дип куйды.

## Хуты калмагач

XX гасыр тәмамланып килгәндә, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артистлары драматург Туфан Миңнуллинның егерме биш ел сәхнәдән төшми торган «Әлдермештән Әлмәндәр» спектаклен ике көн сабалылар өчен куеп киттеләр. Атаклы режиссер, СССРның халык артисты, яңа гына «Намуслылык һәм абруй өчен» номинациясендә Россиянең иң зур театраль бүләгенә—«Алтын битлек» премиясенә лаек булган Марсель ага Сәлимҗанов, театр директоры Шамил Закиров та килгәннәр иде.

Әлмәндәр ролен алыштыргысыз башкаручы якташыбыз, СССРның халык артисты Шәүкәт Биктимеров уйнавы, спектакльдә Һидият Солтанов, Вера Минкина, Нәҗибә Ихсанова, Равил Шәрәфи, Илдус Әхмәтҗан, Айдар Хафиз, Илдус Габдерахманов кебек өлкән һәм урта буын актерларның катнашуы тамашачылар күңеленә хуш килде.

Соңыннан район хакимияте кабул итү мәҗлесе дә уздырды. Бик матур тостлар әйтелде, хатирәләр яңартылды. Равил Шәрәфи сөйли:

—Свердлау шәһәрендә Гариф Ахуновның «Хәзинә» романы буенча фильмга төшеп ятабыз. Бер кичне әйбәт кенә мәҗлес оештырдык. Иртәгесен баш гөҗли инде. Безне кунакханәдән киногa төшерә торган җиргә көн саен бер таксист илтә. Ярар, Шәүкәт абый алда утыра. Без, Делюс Ильясов белән, арттa. Шуннан шоферыбыз Делюс абыйның таушалган йөзенә карап:

—Кичә бер-бер хәл булдымы әллә?—дип сорады.

—Әйе, күбрәк киткән,—диде Делюс абый.

Шуннан соң Шәүкәт абый:

—Я какой, какой?—дип өсте-өстенә сорау бирмәсенме.

—Тебя не поймешь! Ты всегда красный,—дип җавап бирде шоферыбыз.

... Икенче көнне артистлар хезмәт коллективлары, укучылар белән очраштылар. Шәмәрдән ит комбинатында шулкадәр яхшы итеп каршы алганнар боларны, өстәл өстендәге затлы ризыкны күз белән карап бетерү дә мөмкин булмаган.

Кыскасы, алар Шәмәрдәннән соң Саба урман хужалыгына барырга тиеш иделәр.

Равил Шәрәфи, үләр хәлем юк, бүтән ашарлык хутым калмады дип, Лесхозга борыла торган чатта төшеп калып, Саба кунакханәсенә, жәяүләп юл тоткан...

## Халык бәясе

Үзе Казан төзүче-инженерлар институтын (хәзер академия) тәмамласа да, әдәбиятне һәм музыка сәнгатен яратучы, алай гына да түгел, күпсанлы жырлар, шигырьләр, шаян хикәяләр, юморескалар, памфлетлар (шаярулар) авторы Рөстәм Зарипов Мөслим районы эчке эшләр бүлеге начальнигының сәяси эшләр буенча урынбасары булып та эшләп алды.

... Болар өч ижатташ дус—драматург Фоат Садриев, район газетасы редакторы Алмаз Хәйруллин һәм Рөстәм, Яна елны каршылап шампан шартлатканнан соң, саф һава сулау нияте белән, матур табигатьле Мөслимнең сихри кышкы урамнары буйлап йөрергә чыкканнар.

Бераз баргач, ни күзләре белән күрсеннәр: берәү газиз башын йомшак карга тыккан бит!!!

—Әйдә, ярдәм итик, кешене мондый хәлдә калдырырга ярамый, әрәм булуы бар,—ди йомшак күнелле, кешелекле драматург.

—Исереккә пычак та булмый ул,—дип өсти юк-юк та милиция каны сенә башлаган Р. Зарипов.—Башы кызган анын, суыну өчен махсус тыккан ул.

Фоат ага Садриев барыбер үзенекен итә. Тартып чыгара теге адәмне.

Шуннан исерек дигәнебез битендәге карны сыпырып төшерә дә, билгеле драматургны танып ала бит... һәм

—Писатель-халтурщик!—дип әйтеп тә сала.

Ә инде Рөстәмебез кет-кет көлә-көлә:

—Фоат абый! Халык синен гениальный әсәрләрне укый икән бит!—дип төрттереп ала.

## Аркылы килүе

Сабаның 2000 елы юбилейларга бай булды. Тыйнаксызлык булса да әйтим, 1 мартта ук үземә илле тулды. Шул айның ахырында Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының атказанган урманчысы Нургали Миңнехановның житмеш яшен, апрельдә халык депутатларының район Советы рәисе урынбасары Нурислам Насыйбуллинның алтмыш еллыгын билгеләп үттек. Өчебез дә Татарстан Республикасының Мактау грамотасы белән бүләкләндек. Май аенда мөхтәрәм академигыбыз Әбрар ага Кәримуллин житмеш бишен, күп кенә китаплар авторы Мәгъсум Хужин белән музыка профессоры Мәхмүт Нигъмәтжанов житмешләрен тутырдылар. Әбрар ага юбилее көннәрендә шифаханәдә иде. Ә менә Мәгъсум абый өйдә туры килде. Остазымны һәм ижат дустымны (бергәләп өч китап чыгардык бит!) жылы итеп котладым. Аннан чәйгә утырдык. Чәй мәйсез түгел иде.

—Мин бу «утлы су»ны йотмыйм. Үземнең юбилейда да бер грамм капмадым, туктаган килеш туктап торам,—дидем.

Мәгъсум абыйның сабыр холыклы, итәгатьле жәмәгате Мәгъферүз апа минем әлеге жөмләләремә игътибар итеп калып, соңыннан: «Әнә, Тәлгат...»—дип әйткәләгән дә булса кирәк...

Ярар. Сабантуйлары житте. Район житәкчелеге югарыда телгә алынган Сабаның мировой өч бөркетен милли бәйрәмгә алып кайттырды. Аларны хөрмәтләүнең югары ноктасы мәйдан уртасында булды. Хакимият башлыгы Рәис Нургали улы Миңнеханов юбилярларны истәлекле көннәре белән котлап, саулык-байлык, ижат уңышлары, озын гомер теләде, башларына жәйгелеккә түбәтәй киертте, кышлыкка чәшке бүрек бүләк итте, күчтәнәчле пакетлар тапшырды. Жавап сүзе белән Әбрар Гыйбадулла улы чыкты, тирән рәхмәтен белдерде, гүзәл туган ягына мәңге бурычлы икәнлекләрен әйтте. Үзен фотосурәткә

дә төшереп алдык. Алга таба узып, монда шуны әйтергә кирәк, бу Әбрар аганың туган җиренә исән вакытта ахыргы кайтуы, ә рәсемгә, гомумән, соңгы төшүе булды. Ул шул көнне Казанга кайтып, хәл алырга караватына яткач, җәмәгате Кинтә ападан бүләк бүрекне бүлмәсенә керттергән һәм карчыгы әйберләрне урнаштырып йөргәндә шуны кигән килеш изелеп йокыга киткән...

... Сабантуй салкынчарак көнгә туры килде. Шуңа күрә кунакларны кайнар чәйгә—чатырга чакырдык. Юбилярны тагын бер кат тәбрикләп, тост тәкъдим иттек. Мине дә ныгытып кыстый башладылар. Мин алдын-артын уйламыйча:

—Үземнең илле яшемдә дә эчмәдем,—дип әйтеп ташлаганмын бит...

Шуннан соң, малай, каршымда утыручы Мәгъсум Хәмитовичның чал чәчле чигәсе алсуланып китте, сирәкләнгән чәчләре үрә торып басты, Брежнев бабайныкыннан да калынрак кашлары биш сантиметр өскә күтәрелде дә миңа коточкыч матур итеп карап:

—Синең ул юбилееңда эчмәвең минем бугазыма бернечә мәртәбә аркылы килде инде!—диде.

## Менәргә иде Урал тауларына

Давыт пәйгамбәр шулкадәр матур җырлаган—бөтен кош-корт, киек-җәнлек, таш-кыялар аның җырын тыңлаган. Хәтта агымсу да агышыннан туктап, Давыт җырына соклана торган булган, диләр.

Давыт пәйгамбәрдән бу сәләт Илһамга күчкән. Ә Илһамнан кемгә күчәр икән?—дигән сорау куя танылган язучы, җәмәгать эшлеклесе, режиссер, безнең районның Шекше авылы кияве Рабит Батулла.

Легендар җырчыбызны миңа тәүге тапкыр алтмышынчы еллар башында—бала вакытта Чиләбе өлкәсенең Копейск шәһәре сәхнәсендә (кунакка баргач) күрергә туры килде. Баянчысы мәрхүм Рифкать Гомәров, конферансьесы, ягъни мәгънәле сүз әйтүчесе XX гасыр ахырында туксан яшен тутырган Фәйзи ага Йосыпов икәне хәтердә калган.

Шул ук алтмышынчы елларның ахырында Сабада ике көн рәттән җырлаганы бүгенгедәй истә әле.

Беренче концертны август кинәшмәсендә катнашкан укытучыларга багышлады ул, икенчесен—Саба халкы өчен бирде. Җырлап та куйды инде. Тик «Менәргә иде Урал тауларына» дип сузып җибәргәч, арткы рәтләрдә утыручы Миннегаян (халык аны, Мишка дип кенә йөртә иде. Билгеле шәхес—Советлар Союзы Герое Гали Закиров малае ул):—Нәрсә калган анда сиңа?!—дип кычкыргач, тамашачылар да, Илһам абый үзе дә рәхәтләнеп көлгәннәр иде.

## Яртың һәм...

Илдус Зәйнетдинов «Авангард» колхозын җитәкләгәндә ике Шыңар уртасына (Олы Шыңар һәм Кече Шыңар авыллары) мәһабәт мәдәният сарае салдырып куйды. Иркен тамаша залы, фойе, китапханә, башка ярдәмче бүлмәләре һәркемне сокландырырлык итеп эшләнде. Зал стенасына зәвык белән иҗат ителгән зур форматлы картиналар урнаштырылды, түшәмгә затлы люстра эленде.

... Менә мәдәният йортын ачу тантанасы бара. Бик күп кунаклар катнаша анда, Казаннан артистлар килә. КПСС райкомының икенче секретаре Зөфәр Шәйхетдинов, олы тантана белән котлап, мәдәният учагының халыкны тәрбияләүдәге роленә тукталa, эчкечелекне, сүз унаеннан аракының үзен дә тәнкыйтьләп ала. Гомер буе кибеттә эшләгән «Әчтәпи» кушаматлы Мөнәвәрә апа килешмәүчәнлек күрсәтеп:

—Иптәш Шәйхетдинов, син алай аракыны бөтенләй бетереп ташлама әле, яме. Синең бит аны катнаштырып, 8 нче Мартка шаярып язган шигырең дә бар,—дип сөйләп тә күрсәтә:

Сигезенче Мартын,
Күңлем сиңа тартым,
Онытма ир хакын—
Аңладыңмы, хатын?

Янда торсын яртын,
Таза булсын артын,
Шушы бөтен шартым.
Үбеп, кочып, картын.

## Эреде

«Кешеләр мәңгелеккә китсәләр дә, үзләренең кылган гамәлләре белән жир йөзендәгеләр өчен сүнмәс маяк булып калучы шәхесләребез бихисап. Шундый олы затларның берсе—композитор Фәтхерахман Әхмәдиев»,—дип язды «Шәһри Казан» газетасы чын талант иясенең житмеш еллыгы уңаеннан.

Мина Фәтхерахман ага белән гастрольләрдә йөрергә туры килде 1972 елның жәендә. Болар—композитор үзе, виртуоз гармунчы Гани ага Жәмниханов, яшь жырчы Зәбир Жәббаров һәм кечкенә кызын ияртқән ханым—тагын бер жырчы (исем-фамилиясе истә калмаган инде) өстән кемнеңдер тәкъдим итүе буенча Сабага «шабашка» килеп төштеләр. Аларның йә концерт алып баручылары, йә биючеләре булмый. Шуннан мине—автоклуб мөдирен—боларга өстәп чыгардылар.

Ярар. Гастрольне Урта Сабадан башладык. Ул вакыттагы мәдәният бүлеге мөдире Госман ага Гарипов зур булмаган туган авылы халкына игелек кылгандыр инде...

Әйбәт кенә чыгыш ясыйбыз. Гани абый кечкенә гармуннарда сузып жибәргәндә, күрек сырлары арасыннан аллы-гөлле болын чәчәкләре күренеп китә, былбыл тавышлары ишетелгәндәй була. Зәбирне (тора-бара ул тавышсыз кала) озакка сузылган кул чабуларга күмәләр. Мин рәхәтләнеп сөйлим. Чөнки мая зур. Армиядән кайткан гына жәй бит. Анда да тик ятмаган. Репертуарда яттан белә торган житмеш сигез шигырь бар иде!!! Әмма алкышларның иң олысы—тере композиторга—«Кама буе—туган як», «Солдатлар» *(Р. Әхмәтҗанов сүзләре)*, «Чистай вальсы» *(Ф. Әхмәдиев музыкасы һәм сүзләре)*, «Ромашкалар» *(Х. Туфан сүзләре)*, «Җырлыйм әнием турында» *(Г. Зәйнәшева сүзләре)* кебек жырларның авторына, әлбәттә. Ул башта теге яки бу әсәрнең язылу тарихына кыскача гына аңлатма бирә. Аннары үзе уйнап жырлап жибәрә...

... Гөлләр иркәләнә жәйге таңнарда
Йөрәкләр яшәрә
Язгы моңнарга.
Мәңге, мәңге, мәңге яшисе килә!
Гөрләшеп яшик
Сез дуслар белән!

Сизгәнсездер, «Мәңге яшисе килә» дигән жырның соңгы куплеты бу. Аның ничек язылуы турында Фәтхерахман абыйның сөйләве бүгенгедәй күз алдында тора. Кыскасы, болар авылында берәүнең яшь гомерен вакытсыз өзәләр. Шуны жирләгән көнне клубта концерт була. Фәтхерахман ага көндез әлеге жырның сүзләрен дә, көен дә язып, кичен сәхнәдә үзе уйный-уйный жырлый: ә залдагылар... үкереп жылыйлар...

... Гастролебез уңышлы гына барганда, күз тиде бит. Бер совхоз үзәгендә концерт куйганнан соң, Фәтхерахман Әхмәдиевне аерым чәйгә чакырдылар. Таң алдыннан гына кайтты. Икенче көнне без Олы Кибәчегә киттек. Аны соңрак үзебез илтеп куябыз, диделәр.

Ярар. Кичкә таба кайтты бу. Чүнниктә хөрмәт күрсәткәннәр. Жыр-музыка иҗатучы директор белән баянда уйнап утырганнар. Күчтәнәчкә бер рам кәрәзле бал да биргәннәр. Кош тоткан кебек сөенеп кайтты композиторыбыз.

—Тәлгат, бер ярты бар, әйдә, жибәрик,—ди бу.

Әле минем яшь, бозылып житмәгән вакыт.

—Концерттан соң иркенләп салырбыз, Гани абзыйны да дәшәрбез,—дим. Мин, мәсьәлә шуның белән хәл ителде, дип уйладым. Алай булмаган икән шул.

... Олы Кибәченең кечкенә клубында аяк басарлык урын юк. Күрше-тирә авыллардан да килгәннәр.

Мин, армиядән махсус тектереп алып кайткан ап-ак костюмны (туфли дә ак) киеп, концерт башларга йөрим. Эссе, сәхнәдә чыдый торган түгел, житмәсә арткы ишек тә юк.

—Фәтхерахман абый, Аллага тапшырып башлыйбыз,—дим.

Каршы килмәде бу. Мангаендагы тирен сөртте дә идәндәге баянны алырга бөгелгән иде... Эреде дә китте!..

Пәрдә алдына матур итеп чыгып бастым. Кул чабып каршы алдылар... Һәм композиторыбызның үзен начар хис итүен, концертның икенче көнгә күчерелүен игълан иттем.

—Рәхмәт инде, рәхмәт! Без сезнең ничек хис иткәнегезне белеп торабыз,—дип кычкырдылар да таралдылар тамашачылар.

Яшьләр «вечер» уйнарга тотынды. Без төн уртасында гына фатирга кайттык, чыгып китәргә арткы ишек юк бит!

—Мин бөтен Татарстанны җыр белән туендырам, ашарга бирегез,—ди Фәтхерахман абый.

Фатир хуҗабикәсе өч литрлы банка белән сөт һәм күпереп пешкән бер бөтен күмәч китереп куйды...

Иртәгесен мине уята Фәтхерахман ага.

—Концерт булдымы?—ди бу.

—Булды...

... (тагын нәрсәләр әйткәнне язып булмый).

Көн буе борчылды, мәрхүмкәй. Тегенди-мондый нәрсә түгел, сөт тә эчмәде.

Кичен концертны дүрт сәгать ярым итеп куйдык. Зурлап рәхмәт әйттеләр.

Әмма Гани абый Җәмнихановның күңеле тыныч түгел иде. Ул гастрольләр башланганнан бирле республика газеталарына мактап язудан курыкты. Нигә дисәгез, «шабаш» фаш итәлә, филармония администрациясе белеп, «выговор» эләгәчәк бит. Бу юлы концерт өзелгәнне язып җибәрергә, дип бик шикләнде ул.

Мин, үземчә тынычландырырга тырышып, шаяртам:

—Борчылма, Гани абый, сезне моннан да түбән эшкә куймыйлар инде...

## Аллага тапшырдык

2001 елның ямьле июнь аенда әдәбият-сәнгать сөючеләр өчен истәлекле ике көн булды—районга язучылар һәм артистлар килде.

Көндезен Татарстанның халык шагыйре, республикабызның Г. Тукай исемендәге бүләге иясе, «Казан утлары» журналы баш редакторы, кырыклап китап авторы Равил Фәйзуллин (ул безнең районда моннан 40 ел элек—1961 елда булган икән) сатира-юмор остасы, «Ком сәгате» романы авторы Камил Кәримов, драматург Рәдиф Сәгъди һәм мин фәкыйрегез Саба урта мәктәбенең чыгарылыш класс укучылары белән очраштык.

Кич белән Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театры артистлары уйнаячак Рәдиф Сәгъдинең «Сынган беләзек» спектакле алдыннан, тамашачылар белән җылы әңгәмә кордык.

Икенче көнне иртән әдипләрне район хакимияте башлыгы Рәис Миннеханов кабул итте.

Балалар иҗат үзәгендәге узган очрашуда район мәктәпләренең татар теле һәм әдәбияты укытучылары, китапханә мөдирләре дә катнашты. Биредә үк бөтен гомерен мөгаллимәлеккә багышлаган, озак еллар Казанның 18 нче эшче-яшьләр мәктәбенә директорлык иткән Гөлчәчәк Галиеваның башта «Казан утлары» журналында басылган, соңыннан аерым китап булып чыккан «Тулгак» повестен тәкъдир итү дә булды. Кичәгә Гөлчәчәк ханым үзе, шулай ук гомер иткән ире—бөтен дөньяга танылып, халыкара аренага чыккан Казан компрессор фәнни-производство берләшмәсен 24 ел җитәкләгән техник фәннәр докторы, әдәбиятне һәм сәнгатьне яшьтән үк яратучы һәм гомер буе ихтирам һәм ярдәм итүче (ул—үз җаваплылыгына алып, рөхсәтсез, атаклы сынчы Бакый Урманче үтенече буенча заводында язучы Шәйхи Маннурның Мамадышта куелачак һәйкәлен койдырган милләтпәрвәр дә әле) Әхмәт Мөхетдин улы Галиев белән бергәләп кайткан иде. Кайтканнар дип шуңа әйтүем, Әхмәт ага бала

вакытта—сугыш елларында районыбызның хәзерге Югары Утар балалары йортыинтернаты биләмәсендә урнашкан жидееллык рус мәктәбенең башлангыч классларын тәмамлаган. Анда бертуган апасы директор булганлыктан, әнисе белән авыр сугыш елларында Арча районының Сеже авылыннан килеп, шунда яшәп алганнар. Аннары яшьтән үк бик сәләтле Әхмәт Чүриле жидееллык мәктәбен гел «5»кә бетереп, Казан авиация техникумына укырга кергән. Соңыннан институт, аспирантура тәмамлаган.

... Театральләшкән кичә бик матур үтте. Анда жиде дистә гомер кичергән зыялы Галиевлар яшьлек чорындагы «Асиләсе-Василәсе» көенә дуэт та башкаргач, алкышлар мул булды. Китап укучыларга жырның бигрәк тә финал өлеше охшады:

> ... Без бик тату торабыз,
> Матур тормыш корабыз.
> Татулыклар бетмәсен дип,
> Аулак өйдә, тын урында,
> Балалар өйдә югында
> Иркәләшкән булабыз...

Тагын шунысын да әйтергә кирәк, Галиевлар безгә Гөлчәчәк апа ягыннан бик якын карендәшләр дә әле. Шулай булгач, өйгә чәйгә дә кайттык. Бераздан Утар якларына әйләнергә ниятләдек. Әхмәт Мөхетдинович өстен алыштырганда, әлеге-баягы бәләкәй Гаделебез, кунакның миңен күреп алды бит.

—Аягыңда нәрсә ул?—ди кызыксынучан сабый...

—Миң. Кечкенә вакытта мин—Миңнәхмәт булганмын.

Гадел сорауның икенчесен яшен тизлеге белән бирде.

—Хәзер кем соң син?!

Ярар, машина янына чыктык. Салонга зыялы шәхес—Әхмәт абый кергәч, кузгалып китәр алдыннан, кычкырыбрак:

—Аллага тапшырдык!—дидем.

Онык сәерсенеп колак салды бу сүзгә, «мыегына» чорнап та куйды, ахыры...

... Утар якларына барып житкәнче байтак яшьлек хатирәләрен исенә төшерде Әхмәт ага.

... Менә бу урман эченнән сугыш вакытында каршыга мылтыклы дезиртирлар чыкты. Директор апам белән укытучыларга акча алып кайта идек Сабадан. «Беттек!»—диде дә чанага ятты апа. Мин, 12-13 яшьлек малай, дилбегә белән атыма—«Барса»га сигнал бирдем. Ул «тегеләр» янына житүгә, ыргылып икесенең өстенә сикерде дә жан-фәрманга алып китте. Ике якка егылып калдылар. Бераздан, арттан пулялар гына чыжлап калды.

«Барса»ны бик кечкенәдән үзем үстергән идем. Колхоз рәисе мәктәпкә килеп:

—Өч колын ачка үләргә ята. Алыгыз. Аякка басса, үзегезгә булыр, барыбер әрәм булалар,—диде.

Берсен алып кайттык. Бер стакан сөт эчергәч, күзен ачты, тагын берне эчкәч, торып басты...

Һәр әйткән сүзне аңлый иде. Дәрес бетәр алдыннан мин укый торган классның тәрәзә янына килеп басар иде. «Барса» турында аерым язам әле, Алла боерса...

Менә шулай итеп, Югары Утарга килеп тә житкәнебезне сизми калганмын. Яңгыр да ишеп ява башлады, яшен яшьнәргә тотынды.

- Бабай, бисмилланы әйтеп, башыңны сыпыр,—диде биш яше тулмаган Гадел (без Алланы шундый вакытта еш искә алабыз бит!). Авыл таралып бетә язган... Ә менә жидееллык мәктәп вакытындагы йортлар—төп бина, җыештыручылар торган өй, Әхмәт Мөхетдинович яшәгән йорт исән-сау икән әле. Аллеялар, агачлар, бакча, нигездә, үз урыннарында. Гомумән, бик зур тәэсир белән кайттылар кунаклар. Гадел дә...

Кичен әти-әнисе мунчага кергәч, ваннасына салынган суга аяк басар алдыннан, «мыегына» чорнаган сүзне исенә төшереп тә инде:

—Аллага тапшырдык!—дигән.

# 2002 ЕЛДА ДИНИ БӘЙРӘМНӘР ҺӘМ ИСТӘЛЕКЛЕ КӨННӘР

Мөселман календаре буенча 1422-1423 еллар

**21 февраль (пәнҗешәмбе)—Гарәфә көне.** Хаҗ кылучылар тарафыннан Мәккә янындагы Гарәфә тавына бару һәм тау итәгендә намаз уку көне.

**22 февраль(җомга)—Гайдел-Әдъхә, Корбан бәйрәме.** Иң зур мөселман бәйрәме. Ураза тәмамлангач, нәкъ 70 көннән соң башлана торган Корбан чалу бәйрәме һәм ул 3 көн дәвам итә. Бу көн Татарстан җөмһүриятендәге барлык календарьларда кызыл төс белән билгеләнгән.

**23-25 февраль (шимбә, якшәмбе, дүшәмбе), Тәшрикъ көннәре.** Бу көннәрдә мөселманнар фарыз намазларын укыганнан соң, Аллаһ Тәгаләне мактап махсус сүзләр әйтәләр.

**15 март (җомга)—Мөхәррәм ае башланган көн.** 1423 ел, яңа мөселман елы башланган көн. Бу айда күп итеп хәер *(зәкят)* бирелә, изге гамәлләр кылына.

**21 март (пәнҗешәмбе)—Нәүрүз, ягъни яз бәйрәме.**

**24 март (якшәмбе)—Гашура көне.** Сөнниләр тарафыннан Аллаһ Тәгалә үзенең ун пәйгамбәренә күндергән изгелекләре хөрмәтенә, ә шиитлар тарафыннан Мөхәммәд пәйгамбәрнең оныгы Гали хәлифәнең улы имам Хөсәенне (626-680) җәзалап үтерү көне истәлегенә билгеләп үтелә.

**30 март (шимбә)—Идел Болгарстанында Ислам динен рәсми рәвештә кабул иткән көн.**

**14 апрель (якшәмбе)—Сәфәр ае башланган көн.**

**10 май (җомга)—Һиҗрәт кичәсе көне.** Мөхәммәд пәйгамбәрнең һәм аның сәхабәләренең туган шәһәрләре Мәккәдән (Ясриб) Мәдинә шәһәренә мәҗбүри күчеп киткән, һиҗрәт иткән көн. Шушы көннән, ягъни 622 елның 16 июль көненнән башлап, мөселман ел исәбе, ягъни һиҗри ел исәбе башлана.

**25 май (шимбә)—Мәүлид бәйрәме.** Иң зур бәйрәмнәрнең берсе—Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көне. Бу изге бәйрәм нәкъ бер ай дәвам итә. Бу вакытта мәчетләрдә вәгазьләр укыла,хәер сәдака (зәкят) өләшенә. Күп кенә мөселман илләрендә факеллар һәм фонарьлар кабызып, тантаналы мәрасимнәр уздырыла.

**8 сентябрь (якшәмбе)—мөселман календарендә изге саналган Рәҗәб аеның беренче көне.** Бу айда Ибраһим пәйгамбәрнең, Гайса пәйгамбәрнең туган көннәре һәм башка истәлекле көннәр билгеләп үтелә. Шулай ук кече хаҗ, гомрә хаҗы кылына.

**12 сентябрь (пәнҗешәмбе)—Рәгаиб кичәсе.** Мөхәммәд пәйгамбәрнең әтиәнисе Габдуллаһ һәм Әминәнең бергә кушылуын искә алу кичәсе.

**4 октябрь (җомга)—Мигъраҗ бәйрәме.** Мөхәммәд пәйгамбәрнең Мәккә шәһәреннән Иерусалимга һәм аннан җиде кат күккә—Аллаһ Тәгаләнең тәхете янына кылган могҗизалы сәяхәте. Мигъраҗ уразасы 60 ай яки 100 төн ураза тотуга тиңләнә.

**7 октябрь (дүшәмбе)—Дүрт изге айның берсе,** мөселман ай календаре буенча, сигезенче ай—**Шәгъбан ае башлану көне.**

**15 октябрь (сишәмбе)—Хәтер көне.** Казанны саклап каһарманнарча һәлак булган бабаларыбызны искә алу көне.

**21 октябрь (дүшәмбе)—Бәраәт кичәсе, ягъни "ләйләтул-Бәраәт".** Бәхет һәм һәртөрле уңышлар, изгелекләр иңә торган изге көн. Нәкъ шушы төнне Аллаһ Тәгалә, һәркемнең изге гамәле һәм догаларында ялварып сораган үтенечләрен исәпкә алып, кешеләрнең язмышы турында карар кабул итә.

**6 ноябрь (чәршәмбе)—чират изге Рамазан ае һәм ураза башланган көн.** Рамазан аенда иң кадерле кичә—Кадер кичәсе.

**5 декабрь (пәнҗешәмбе)—Гайделфитыр.** Ураза бәйрәме тәмамлангач, авыз ачу бәйрәме башлана.

*Журнал өчен* **Хаҗи Абдулла ДУБИН** *әзерләде*

## ЗАКОН ГАМӘЛДӘ БУЛСЫН

27 сентябрьдә Г. Тукай музеенда «Татарстан телләре турындагы» законны тормышка ашыруга нәрсә комачаулый?» дигән шигарь астында татар зыялыларының җыелышы булып үтте. Анда кабул ителгән резолюциядә: «2002-2003 яңа уку елында республиканың барлык татар мәктәпләрендә татар телен латин графикасы нигезендә укытуга күчәргә» диелгән.

Җыелышта Бөтендөнья Татар Конгрессы башкарма Комитеты, Татар иҗтимагый үзәге, «Мәгариф» Ассоциациясе, Татарстан Язучылар берлеге һәм башка оешмалар вәкилләре катнашты. Чыгыш ясаучылар Татарстан хакимияте органнары һәм Республика Президентының «2001 елның 1 сентябреннән латин графикасы нигезендә татар алфавитын яңадан торгызу турында»гы законны гамәлгә кертүне күздә тоткан документларның үтәлүенә контрольлек итмәүләрен билгеләп үттеләр. Җыелышта Татарстан Дәүләт Советына законның һичшиксез үтәлергә тиешлеге турында мөрәҗәгать кабул ителде.

## УРТАК РУХ БӘЙРӘМЕ

Сентябрь ахырында Казанда һәм Татарстанның Әгерҗе, Буа районнарында татар, мари, чуаш әдәбияты һәм сәнгать көннәре булып узды. Тугандаш республикалар халыклары тарихына, сәнгатенә, һөнәренә мәхәббәт тәрбияләүгә багышланган «Без һәм безнең Ватаныбыз» исемле Идел буе республикаларының китап бәйрәмен Татарстан яшүсмерләр китапханәсе оештырды.

Бәйрәмне тантаналы рәвештә «Казан» милли мәдәният үзәгендә Татарстан, Чуашстан һәм Мари Иле сәнгать эшлекләләре, язучылар, китапханәчеләр ачып җибәрде. Алар Казан тамашачыларын зур концерт белән куандырдылар. Ә килгән кунаклар игътибарына Идел буе республикасы халыклары тарихына багышланган бай эчтәлекле китап күргәзмәсе тәкъдим ителде. Шулай ук, Казанның «Дуслык йорты»нда «Мәдәни әңгәмә» исемле «түгәрәк өстәл» оештырылды. Ул милли мәдәниятләрнең үзара бәйләнеше, аларның алга таба үсеше һәм яшьләрдә төрле милләт халыкларына хөрмәт тәрбияләү проблемаларына багышланды.

## УРТА ДИҢГЕЗ ЯКЛАРЫНДА

Октябрь башында Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин Төркиядә һәм Кипрда булып кайтты. ТЮРКСОЙ (төрки илләрнең уртак мәдәни оешмасы) чакыруы буенча, төрки телдә сөйләшүче илләрдән килгән шагыйрьләр белән бергә, ул Истанбулда һәм Кыбрызның (Кипр) Лефкоша (Никосия), Гирнә (Кирения), Газимагуса (Фамагуста), Гүзәлйорт (Оморфо) шәһәрләрендә булды, рәсми очрашуларда катнашты, югары уку йортларында, мәдәният үзәкләрендә узган кичәләрдә чыгышлар ясады.

## УКРАИНАДА БОЛГАР ҖЫЕНЫ

Украинаның Полтава өлкәсе Перещепино авылы янында (биредә борынгы Болгар хакиме Кубрат хан кабере саклана) Болгар җыены узды. Аны Дунай Болгарстаны һәм үзләрен Кубрат хан вакытларыннан калган болгар токымы дип санаган вәкилләр оештырды. Бу җыенда Казаннан Болгар милли конгресс вәкилләре дә катнашты. Госман Хәлилов сүзләренә караганда, төрле темаларга багышланган «түгәрәк өстәл»ләрдән тыш, җыенда мәдәни чаралар да узган, болгар фильмнары фестивале үткәрелгән. Җыелышта катнашучылар киләчәктә һәйкәл куяр өчен Кубрат хан каберенә истәлекле билге урнаштырды. Биредә Гомумболгар мәдәни үзәген дә төзергә уйлыйлар.

## ШАГЫЙРЬ ЮБИЛЕЕ

4 октябрьдә М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында күренекле шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе **Ренат Харисның** 60 яшьлек юбилеена багышланган кичә булып узды. Шагыйрьне Татарстан җитәкчелеге исеменнән Премьер-министр Р. Миңнеханов котлады. Шагыйрь бәйрәменә Мәскәүдән һәм тугандаш республикалардан атаклы шагыйрьләр килгән иде. Мостай Кәрим, Равил Бикбаев, Вадим Кузнецов, Юрий Семендер... Шагыйрьне котлап Татарстан язучылары исеменнән Идарә рәисе Фоат Галимуллин чыгыш ясады. Кичәдә танылган сәнгать осталары тарафыннан шагыйрьнең әсәрләре башкарылды.

## ЯЗУЧЫНЫ ОЛЫЛАУ

Әлмәтнең «Нефтьче» мәдәният сараенда фронтовик язучы **Әдип Маликовка 80 яшь** тулуга багышланган юбилей тантанасы үткәрелде. Юбилярны хөкүмәт исеменнән Дәүләт Советы Рәисе урынбасары шагыйрь Роберт Миннуллин тәбрикләде. Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин, Әлмәт шәһәре һәм районы хакимияте башлыгы Ришат Әбүбәкеров язучыга тәбрикләүләрен житкерделәр.

Юбилей көннәрендә «Рухият» нәшрияты Әдип Маликовның Сажидә Сөләйманова истәлегенә багышланган «Гомер мизгелләре» дигән китабын бастырып чыгарды. Кичәдә нәшриятның башкарма директоры Илсөяр Хәйруллина авторга әлеге китапны бүләк итте. Кичә Әлмәт артистлары әзерләгән театральләштерелгән әдәби-музыкаль композиция белән тәмамланды.

## ӘДИП ИСЕМЕН МӘҢГЕЛӘШТЕРЕП

Башкортстанның Тәтешле районында халык шагыйре Әнгам Атнабаев исемен мәңгеләштерү йөзеннән, туган авылы Күрдемдә аның музее ачылды. Әлеге тантанада шагыйрьнең дуслары, язучылар, туганнары, балалары катнашты. Тәтешледә бер урамга аның исеме бирелде. Киләчәктә ул укыган мәктәп тә шагыйрь исемен йөртәчәк.

## ЭРОТНЫҢ ЯҢА КҮРГӘЗМӘСЕ

Г. Тукай музеенда Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, рәссам-график Эрот Зариповның «Татар зыялылары» исемле шәхси күргәзмәсе ачылды. Ул—татар халкының күренекле шәхесләре портретларын ясаучы рәссам. Аның бу картиналары «Багышлау» сериясен тәшкил итә. Соңгы елларда аның бу сериясендә халык шагыйрьләре һәм язучылары Илдар Юзеев, Шәукәт Галиев, Равил Фәйзуллин, Гариф Ахуновларга багышланган күргәзмәләре булып узган иде инде. Жәмәгатьчелек хөкеменә чыгарылган бу күргәзмәдә үткән гасырларда татар халкы мәдәнияте һәм әдәбияты тарихында зур эз калдырган мәшһүр шәхесләр—Габдулла Тукай, Заһир Бигиев, Каюм Насыйри, Шакир Мөхәммәдев, Галимжан Баруди, Гали Рәхимнәрнең портретлары урын алган.

## 2002 ЕЛ КАЛЕНДАРЕ

Татарстан китап нәшрияты 2002 ел өчен дивар календаре бастырып чыгарды.

Ул үткән еллардагыдан үзенең тарихи, әдәби, сәнгати һәм сәяси мәгълүматларга бай булуы, әдәп һәм әхлак темаларының киң яктыртылуы белән аерылып тора. Казанның 1000 еллыгын бәйрәм итәргә әзерлек уңаеннан аның битләрендә «Чал Казан» дигән рубрика дәвам итә. Календарьда ислам дине бәйрәмнәре, мөселманча календарь тәртибе күрсәтелгән. «Жирле сөйләшүләребез», «Гореф-гадәтләребез», «Ерактагы якын кардәшләр», «Ни өчен болай әйтелә?», «Татарстанның тереклек дөньясы», «Яшь талантлар», «Жыр—йөрәккә ял» һәм башка рубрикалардагы язмалар белән танышырга мөмкин.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Язучылар берлеге идарәсе һәр ел саен балалар әдәбияты өлкәсендә нәтижәле ижат итүче язучылардан берәрсен Абдулла Алиш исемендәге премия лауреаты дип игълан итә. Быел бу мактаулы бүләккә шагыйрь, прозаик, Татарстан радиосының баш мөхәррире **Жәүдәт Дәрзаман** лаек булды.

* * *

Дәүләт идарәсе органнарында озак еллар нәтижәле эшләгәне һәм татар әдәбияты өлкәсендәге зур казанышлары өчен Балтач район хакимияте башлыгы урынбасары, шагыйрь **Мөхәммәтшин Гарифжан Садыйк** улы Татарстан Республикасының Мактау Грамотасы белән бүләкләнде.

## *Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** Кышкы пейзаж—*фотоэтюд.*

**Тышлыкның дүртенче битендә:** шагыйрә Флера Гыйззәтуллина.

# ЯҢА КИТАПЛАР

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. **Сайланма әсәрләр. V том.** - Казан: Тат. кит. нәшр. - 2001. - 400 б. Тиражы - 2000 данә.




Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин сайланма әсәрләренең чираттагы басмасы—5 томы дөнья күрде. Житмешкә якын хезмәтне эченә алган бу китапка шагыйрьнең төрле елларда (1969—2001) язылган әдәби-публицистик мәкаләләре, иҗат портретлары, әңгәмәләре, эссе-уйланулары тупланган. Томлыкта—шагыйрь белән фикердәш һәм иҗатташ булып, аралашып яшәгән мәшһүр шәхесләрнең (Бакый Урманче, Нәҗип Җиһанов, Әмирхан Еники, Җәүдәт Фәйзи, Мостай Кәрим, Гариф Ахунов, Әбрар Кәримуллин, Миркасыйм Госманов, Әхсән Фәтхетдинов...) үзләре һәм иҗатлары, гомумән, егерменче гасырның икенче яртысында яшәгән йөзләгән әдипләр, сәнгатькярләр, фән эшлекләре турында байтак белешмә-мәгълүматлар табарга мөмкин.

Томлык ахырында, сайланма басмаларга хас булганча, һәр аерым язма-мәкалә турында искәрмә-анлатмалар бирелгән.

Зәки ЗӘЙНУЛЛИН. **Агыйделнең аръягында...** —Казан: «Идел-Пресс» нәшр. —2001.—440 б. Тиражы—3000 данә.




Зәки Зәйнуллин—гомеренең байтак елларын хәрби хезмәткә багышлап, полковник булып, техник фәннәр докторы дәрәҗәсенә ирешкән кеше. Соңгы дистә елларда укучылар аны язучы буларак та яхшы беләләр. Бу китапка авторның соңгы елларда язылган ике романы һәм бер повесте кертелгән. Китапка исем итеп бирелгән «Агыйделнең аръягында» дигән роман-кыйссада болгар-татарларның борынгы тарихы, бабаларыбызның чукынудан качып, Урал-Агыйдел ярларына китеп, шунда авыллар, мәдрәсәләр салып дөнья көтүләре, легендар шәхес Мирсәет Солтангалиевнең балачагы турында байтак гыйбрәтле хәлләр сурәтләнә. «Ат караклары» дип исемләнгән роман Оренбур далаларыннан Самара каласына кадәр сузылган атаклы «Ат караклары сукмагы» һәм ат урлауны үзләренең яшәү кәсепләре иткән башкисәр ир-егетләр турында. Ә «Ата нигезе» повестенда—хәмер, эчкечелек аркасында имгәтелгән нәсел, югалтылган туганлык хакында бәян ителә. Китапта үзе һәм әсәрләре турында авторның кыска кереш сүзе дә бирелгән.

Индекс 73210



Флера Гыйззәтуллина

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)